# Казан утлары



5

МАЙ

1967

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

5

МАЙ

1967

## Бу санда:

ПОВЕСТЬЛАР, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек. Повесть . . . 3

С. Кудаш. Әйдә, тамсын; Кайгыртам; Бик чәнчешеп; Карт бөркет; Ак сакалын селкә-селкә; Юлда барганда; Кала икән. Шигырьләр . . . 47

М. Садри. Пушкин Одессада; Данко; Крейсерда сандугач. Шигырьләр . . . 50

М. Мәһдиев. Этюдлар . . . 53

Г. Афзал. Җанга якын урыннар; Китабым; Кичке моң; Туган телем; Гөлҗимеш. Шигырьләр . 62

Б. Рафиков. Хәтер саклый; Кай арада; Таш кыяны; Төнге утлар; Төн күзәтә; Бәхет юлы; Картлыгыма нәсихәт; Урманчы истәлегенә. Шигырьләр . . . 66

Н. Фәттах. Улым турында хикәяләр . . . 68

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

Г. Әпсәләмов. Унсигез яшь. Очерк . . . 70

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ ИЛЛЕ ЕЛЛЫГЫНА

М. Мөхәррәмов, А. Әхмәдуллин. «Эш» газетасы битләрендә әдәбият-сәнгать мәсьәләләре . . . 80

Р. Гарәфетдинов. Татар яшьләренең демократик хәрәкәте тарихыннан . . . 86

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ф. Насыйров. Хезмәтенә карап хөрмәте. Гөлләр чәчәк ата. Очерклар . . . 91

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР

В. Монасыйпов. Суйдыпар; Нәкъ үзе. Скетчлар . . . . . . . . . . . . . . . . 98

БЕЗНЕҢ САФКА

А. Гыйләҗев. Төкле аягың белән . . . . . 103

ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Г. Ахунов. Язучы һәм заман . . . . . . . . 105
З. Мәҗитов. Фәнни тирән һәм туры сүзле тәнкыйть өчен . . . . . . . . . . . . . . . 114

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

А. Фәтхи. Азатлык өчен көрәшләрнең яңа бер әдәби документы . . . . . . . . . . . 121
Ә. Кәримуллин. Беренче татар китаплары . 126

БАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ж. Тәрҗеманов. Мәңге яшь талант . . . . 135

ТӨРЛЕСЕННӘН

С. Сүнчәләй. Каргалыда татар туе . . . . 137

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ


Н. Арсланов. Тиен; Тукран; Икмәк валчыгы; Өч дус. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 150
Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 156
А. Ключарев. Вьетнам солдатына. Җыр. Н. Дәүли сүзләре.

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

*Гомәр Бәширов*

# Туган ягым — яшел бишек



*Автобиографик повесть*[1]

## Сабыйлык дөньясында

### I

Аякны-кулны, ботны-чатны, дигәндәй, малайларча, як-якка ташлап өйалдында йоклап яткан чагым. Бервакыт йокы аралый әнинең кытыршы кулы белән башымнан сыйпавын тойдым, ягымлы тавышын ишеттем:

— Тор инде, улым, тор, бик озак йокладың. Әнә Хәкимҗаннар әллә кайчан урамда инде...

Колагым ишетә, әмма күзем ник кенә ачылсын. Йокының татлы ширбәте бөтен тәнемә таралган да шундый рәхәт эчендә оетып яткыра, минем, бу рәхәтне качырмас өчен, хәтта кыймылдап кына да карыйсым килми.

Бераздан әни йомшак кына тагын бер дәшеп куйды. Минем дә инде йокым бераз ачыла башлады. Урамда ат пошкырганы ишетелде, арба кигиләрен чыгырдатып, ниндидер бер юлаучы узды. Ишек алдында, тыелып кына, «авыз эченнән» генә, бия «шыркылдап» куйды. Бу аның ашарга биргәндә үзенчә рәхмәт әйтүе. Нигә бу вакытта, көпә-көндез, ат өйдә икән?..

Торырга вакыт икәнен дә чамалыйм. Әмма ул чагында наянлыкны да белә башлаганмын инде, ахрысы. Шуның өстенә, бераз иркәләнәсем килебрәк тә ятам. Ник дисәң, олылар иртәдән кичкә кадәр гел аяк өстендә, гел эштә. Иркәләүләр алай еш эләкми торган иде.

Менә узып барышлый ачык ишектән әти тавышы колакка чалынды;

---

[1] Әсәр бергиткадәр кыскартылып басыла

— Һи! Бу малай һаман тормыймыни әле? Нигә уятмыйсың? Белми ята ошай[1]. Бия аңа колын алып кайтты бит!

Колын! Шуны гына ишетүем булды, ялт итеп сикереп торуым булды. Шулай булмыйча соң! Авыл малаеның иң мавыктыргыч, иң матур хыялларыннан берсе шул колын лабаса инде!

Ишек алдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын! Үзе җирән, аркасыннан бармак иңлеге коңгырт тасма сузылып киткән, алгы аякларының балтырына тикле ак оек кигән. Таяк шикелле нечкә һәм озын, әмма хәлсез аякларын бик сәер итеп дүрт якка тырпайткан да имгән булып маташа.

Минем янда гына кулын артка куеп, колыннан күзен алмыйча, эти елмаеп тора. Ул да бик куанган.

— Безнең бия, — ди, — бер бик матур колын алып кайтасы килеп, күптән үк эзләнеп йөри башлаган иде инде.

— Ник элегрәк алып кайтмаган соң?

— Һе, ансат кына сиңа! Мондый матуры еш очрыймыни аның? Менә кичә болынга кунарга төшкәч, шушы ак оеклысын туры китергән дә иртәп үк кайтасы иткән...

Биягә минем шундук күңелем йомшап, карашым яхшырып китте. Болай югыйсә ул мине бик үк санламый да, янына җибәрмәгән чаклары да булгалый. Җитмәсә, бер күзенә ак төшкәнлектән, күрше малайлары үртәп җен ачуымны чыгаралар:

— Сезнең атыгызның бер күзе өшегән! — диләр.

Менә хәзер мин аларның авызларын ачарга да ирек бирмим. Өшегәнме? Өшегән булса да, колынның әнә ниндиен алып кайткан!

Әмма кара бия минем шикелле йомшак күңелле булып чыкмады. Мин колынны аркасыннан сыйпамакчы булып «бәһ-бәһ» дип янына бара гына башлаган идем, бия, яман да ачуланып, колакларын шомартты, дәү сары тешләрен ырҗайтып, ашардай булып башын миңа таба айкады.

Эти мине тиз генә үз янына тартып алды:

— Чу! Якын барасы булма! Ачуын китерәсең, — диде.

Берәр атнадан без бияне җиңелрәк эшләргә җиккәли дә башладык. Я урман аланыннан, аз гына салып, печән алып кайтабыз, я җиңелчә генә тегерменгә барып киләбез. Безнең колын ул вакытта бик куркак иде әле. Берәрсе катырак кычкырып җибәрсә, я шакылдап капка ябылса, колын «дерт» итеп сискәнеп китә; юлга чыктыңмы, тәртәгә орынып кына йөри. Әгәр атлы кеше очраса, я берәр капкадан эт-мазар өреп чыкса, куркынып шундук анасының күкрәгенә сыена торган иде.

Өммикамал апай зәңгәр сатиннан муенча тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә кыңгырау да тагып җибәрдек. Колын башын селкеткән саен кыңгырау шундый сөйкемле тавышлар чыгара, әйтерсең, чың-чың итеп берьюлы әллә ни тикле көмеш тәңкә коела.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көннен көн озын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Әүвәле башта күз тимәсен өченгә колынның маңгай чәченә артыш ботагыннан нәни генә тияк ясап тактым, ялына аллы-кызыллы чуклар бәйләдем.

Иртә тордыммы, иң беренче куанычым шул: икмәк йомшагы электерәм дә колын янына чыгам. Баштарак ул, якын-тирәдә кеше күргә, тизрәк анасына барып сыена торган иде. Тора-бара акрынлап ияләнә башлады. «Бәһ-бәһ!» дип дәшүгә, колакларын торгызып, борылып карый торган булды. Бераздан кыйгачланып, матур гына уелып кергән борын тишекләрен селкеткәләп, иди исни башлады. Аннары тагын да кыюлана төште. Көл төсле зәңгәрсу соры, хәтфә кисәге шикелле йом-

---

[1] Белми ятканга охшый.

шак иреннәре белән уч төбеннән ипи сыныкларын әләктереп алырга өйрәнде.

Хәзер инде ул миннән курыкмый. Ялларын, маңгай чәчләрен сыйпаганда зәңгәрсу күзләрен әллә кайларга төбәп тын гына рәхәтләнеп тора иде.

Мин аңа, тизрәк үссен дип, өйдәгеләрдән яшереп кенә, апара эчертәм, җай килгән саен ипи сыныклары каптырам. Ике-өч айдан колыныбыз зерә дә чаяланып китте. Ул хәзер инде, элекке шикелле, тартәгә ышкылып йөрми, эт өргәннән дә курыкмый. Кая ул! Хәзер инде ул башын аска иеп, «алгы аякларым белән салып егам!» дигәндәй, яныйяный, пыр туздырып, этләрнең үзләрен куып йөри. Капка ачылдымы, иң әлек ул чыгып чаба. Колынның, сабыйлык җиңеллеге белән, койрыгын-ялын тузгытып, сикергәләп, уйнап йөрүен карап тору үзе бер рәхәт була. Әй бер заман муенын кәкрәйтеп, койрык чәнчеп, төп-төз тояклары белән тып-тып басып, юыртып китә, агай! Колаклар шәмәргән, күзләрендә ут! Бераз барган саен: «Күрдегезме мине!» дигән сыман бөтен гәүдәсен катырып куйган килеш, әле бер якка борылып карый, әле икенче якка. Ул да түгел, дәү айгырлар шикелле, гайрәт белән борынын киереп, пошкырып куйган була, я, борынын күккә чөеп, алтын ялларын җилфердәтеп кешнәп җибәрә. Көмеш кыңгыраулар чыңлый диярсең!

Әти, яшькелт-зәңгәр күзләрен кыса төшеп, тавышсыз гына көлә:

— Әй, юеш танау, әй, кыланчык! — Аннары, дилбегәсен тартып, биягә чөңгереп куя. — На, әйдәсәнә, атлар-атламас ниямәрсә тыңлап барасың? Колыныңны мактаганнымы?.. Уңган мал булыр, боерган булса! Алдан да чаба, күкрәге дә киң, торыгы да озын...

Мин инде киләсе елга, колын тайдан кырыкмышка чыккач, аңа атланып Убырышный[1] һәм Мончалка дигән урман аланнарына ат ашатырга йөрүләр, анда барганда малайлар белән узышулар, җәйнең эссе көннәрендә зират астындагы тегермән буасында аны коендырып кайтулар турында да хыяллана башлаган идем. Әле ул гынамы? Язгы сабан туйларында, ялына кулъяулыклар тагып, мәйданга атланып чыгасың. Ул чагында инде аның каеш йөгәне дә булыр, йөгәнгә җиз тәңкәләр тезелгән булыр. Әти, кырыкмышны җигәргә өйрәтер өчен, кечкенә камыт белән кечкенә генә чана да әмәлләп бирер. Кем белә, ул вакытка кадәр, бәлки, төсен дә үзгәртер әле. Я кызгылт-җирән булыр, я туры төскә керер...

Әмма көз көне, кырпак төшеп кар яуганны көткән бервакытта, колыным базарга барган җиреннән әйләнеп кайтмады. Мин аңа нидер булуын биянең авыл буенча кешни-кешни кайтуыннан ук сизенгән идем. Ул ишек алдына кайтып кергәч тә тынычлана алмады. Бөтен көченә кешни дә, капкага таба борылып, колакларын торгызган хәлдә байтак вакыт тыңлап тора. Колыны җавап бирмәгәч, тагын кешни...

Минем «Колын кая?» дигән соравыма берәү дә җавап бирмәде. Әти, миңа аркасы белән торган хәлдә, атны тугаруын дәвам итте. Әтигә атның кешнәве дә ошамый иде булса кирәк, аңа да кычкыргалап алды. Мин нидер булуын сизенеп еламсырый башлагач, түзмәде, дилбегә башын селкеп күрсәтте.

— Туктыйсыңмы син, юкмы? Менә күп шыңшысаң!..

Әллә миңа кизәнде дилбегәсе белән, әллә язмышына. Ул вакытта мин бу икенесен аерып аңларлык түгел идем әле.

Сабый баланың күз яшен коңгырлы яңгырга охшатырга була. Явуын чынлап та ява, әмма тиз кибә. Күрәсең, вакыт узу белән дөньяның бүтән борчулары басканлыр, колынсыз калу хәсрәте алай еллар буена

[1] Убырышный — алпавытларга түләнә торган оброк сүзеннән килеп чыккан булса кирәк.

сузылмады. Тик шул вакытта кабынып калган якты өмет бик озак күңелне балкытып торды: кара байталыбыз җәйнең бер кояшлы иртәсендә болыннан, теге чактагы шикелле, тагын бер матур колын ияртеп кайтмасмы икән?

Мин шул бәхетне яшүсмер чакка кадәр көттем.

II

Кышкы кичләрнең балалар өчен иң күңелле, иң куанычлы сәгате, ихтимал, шәфәкъ батканнан соң башланадыр. Су буйларына, тау битләренә — бөтен тирә-якка тын гына, йомшак кына кызгылт караңгылык инә. Шуа торган Кабак тавында казылмаларны да, калкулыкларны да аера алмый башлыйсың. Өйләрдә әллә кайчан ут алдылар.

Соң инде, соң. Кайтырга вакыт. Ат чишмәсендә сызгыра-сызгыра атын эчерткән иң соңгы егет тә бая ук менеп китте. Көмеш бизәкле зәңгәр чиләкләрен сайрата-сайрата чишмәдән су китерүче кызлар да туктады. Бик соң инде. Инде без генә, чана шуучы малайлар гына калдык. Аларның да, уенга әлмәшләнеп, күзенә ак-кара күренми башлаганнары гына.

Иптәш малайларга:

— Әйдә, тагын бер генә! — дим мин.

— Әйдә!

Инде чәнәшкәнең[1] арты да әллә кайчан каерылып төшкән. Итек белән бияләйләр дә гел боз гына. Бүтәнне әйткән дә юк, шуып төшкән саен егыла-мәтәлә торгач, чалбарларга тикле сыгып ташлардай булган. Кайткач орыш эләгәсен дә белеп торасың. Шулай да кайтып кына булмый бит. Булмый!

Талчыккан аякларны көч-хәл белән атлап, мышкылдап, чәнәшкәләребезне тау башына сөйрибез. Әмма берсенең дә кайтыр исәбе юк.

— Тагын бер генә шуыйк инде!.. — диләр.

Ләкин ул тагын бер генә булып калмый, ике дә, өч тә, биш тә булып китә...

Кабак тавының өстенә ук менәсең дә, чәнәшкәнне аякларың белән этәреп кузгалып китәсең. Түбәнгәрәк төшкән саен чәнәшкән һаман кызулый бара. Колакларында җил уйный, битенә зәһәрле салкын бәрә. Яр кырыенда утырган тәбәнәк баганалар, җелт тә җелт килеп, егылышып кына калалар. Рәхәт! Чәнәшкән оча гына.

Менә син бер малайны узлың, менә икенчесен дә артта калдырдың. Син шул рәхәтнең муллыгына түзә алмыйча, алдагы малайны да узып китәчәгеңә нык ышанган хәлдә, ташып торган бер җилкенү белән кычкырып җибәрәсең:

— Һәәә-й-йт! Кагы-ы-ыл!..

Шулай да иң кызыгы, үзенең рәхәте белән тыннарыңны буа торганы алда әле. Тауның буеннан-буена шулай буран уйнатып, сызгыртып шуып төшәсең-төшәсең дә, кинәт бер заман җирдән аерылып, очып китәсең! Инеш буендагы вак таллар, күпер төбендәге кар өемнәре аста кала, җил очларыңнан, изүләреңнән, бишмәт итәгеңнән җил бәреп керә. Очу рәхәтеннән хәтта йөрәгең кысылып килә, күзләрең йомыла. Күзеңне ачканда син инде боз өстендәге тирән карга чумган буласың. Авызың-борының кар, муеныңа, җиң эчләренә кар тулган.

Синең артыңнан, куанычыңнан кычкыра-кычкыра, чыелдый-чыелдый иптәшләрең коела башлый. Кайсы, чәнәшкәсеннән атылып китеп, карга башы белән чума, кайсы-берсе өстеннән очып уза, иптәше өстенә барып төшә. Тик ничек кенә туры килгәндә дә үпкәләштән дә, ачуланыштан да түгел. Кая ул ачулану, кая ул үпкә-сапка! Бөтенесе уһылдый, көлә, кычкырып җибәрә. Берсе кар астына киткән сынар итеген, чәнәшкәсен

[1] Кечкенә чана.

тартып чыгара, бөтәне бүреген каккалый. Тынычсыз-көнебез бетеп, беребезне беребез бүлдерә-бүлдерә куанырга, мактанышырга тотынабыз:

— Күрдеңме: минем чәнәшкә кайларга очты!

— Һи, менә мин ул! Минеке әнә кая барып төште!

— Ә мин «выжт» Ахунжан янынннан!

— Әйе! Синең тимерле булгач та!..

Бил тиңентен кар ерып, мышный-мышный текә ярдан күпер өстенә менәбез. Анда тагын да шул ук сүз:

— Тагын бер генә! Әйеме?

— Әйдә, әйдә!..

Тик өйалды баскычына аяк баскач кына искәрәсең: киез итекләрең бөгелми, баскан саен таеп китә, бишмәт итәкләре шакраеп каткан да як-якка тырпайган, берәр нәрсәгә бәрелүгә, калай шикелле шыңгырдап тора. Бияләйләр ишек тоткасын тота алмый. Бөтен өс-баш каткан, тик борын асты гына җепшек...

Баскычларны яман да шак-шак китереп, үзем белән бер көтү суык ияртеп, ишектән килеп керүгә иң элек яшь этәч булып апай ташланды:

— Ә, кайттыңмы, эшем кешесе? Әле ярты төн дә җитмәгән ич, тагын азрак йөрисең калган!

Миндәге кайнарлык әле һаман да сүрелмәгән. Дәртле уенның әле генә татыган рәхәте, бөтен тәнемне биләп, үз алдына кыландереп, күңелләрне җилкендереп тора. Мин үземне, абый укыган китаптагы шикелле, әле генә сугышта булып чыккан, дошманны җиңеп, шәһәрләр алып кайткан батырдан бер дә ким хис итмим. Әйдә, бәйләнә бирсен...

Апай кеше бик чая тотынса да, әти белән әни алдында аның кул белән шаяра алмасын әллә каян белеп торам. Минем күз әни белән әтидә. Әни өс-башыма карап алды да башын чайкады, «атаң алдында күп боргаланма», дигәндәй ым кагып тизрәк чишенергә кушты. Әти миңа юньләп карамый да, аның үз эше эш. Ул верстагы янында, бармак юанлыгы калын зәңгәр карандашы белән, рамга ярасы такталарын сызгалый. Ара-тирә янында басып торган шәкерт абыйга берәр сүз әйтеп куя. Әһә, менә кечкенә абый да кайткан. Ул, миңа борылып:

— Нихәл? — диде, бүрегемне чөйгә алып элде. Бу Хәмзә абыйның минем белән исәнләшүе дә, үзенә күрә минем хәлемне белешүе дә инде. Бу атнада минем әле аны беренче генә күрүем. Ул бүген кичкә таба гына Курса мәдрәсәсеннән ялга кайткан. Болай булгач, бүген кече атна икән, китап укый торган кич.

Ләкин куанырга иртәрәк булган икән. Шунда апай, зур ачылган күзләре белән, шаккатып, минем бүген беренче генә тапкыр киеп чыккан өр-яңа киез итекләремә текәлеп, кычкырып куйды:

— Әнекәем! Карагыз әле, күрегез әле бу тамашаны! Нишләттең ул итегеңне, ә?!

Каян гына күреп алды соң әле бу апай! Карасам, үзем дә шаккаттым. Итегемнең кунычлары ак килеш калса да, түбән ягы тоташ пычраккка баткан, буялып, бозланып каткан. Нигә болай булуы шунда гына исемә төште.

Гыйбаш абыйдан алып кайтканнан соң мин, яңа итегемне киеп, сөенче алырга дип күрше Хәкимҗаннарга кереп киттем. Башта ак өйләренә сугылдым. Хәкимҗанның бабасы пеләш Миңлебай түр яклрында шөшлесе белән шак та шок суккалап чабата ясап утыра. Кашлары җимерелгән, такыр башын чабатасына игән. Ник ичмасам күңел өчен бер генә күтәрелеп карасын! Хәкимҗан, минем янга кермәкче булып, ишектән борынын гына суза башлаган иде, Миңлебай бер генә тамак кырды. Хәкимҗан шундук кирегә атылды.

Миңлебай карт, көтеп-көтеп тә башын күтәрмәгәч, аш өйләренә

кереп киттем. Тик анда да юлым уңмады. Бозау имезергә дип, аш өйләренә сыер керткәннәр икән. Ул аркылы баскан да уздырмый гына бит. Мин сыер койрыгы янында никадәр генә лышык-лышык борынымны тартып торсам да, итегемне анда да күрүче булмады...

Аннан чыккач, малайлар тавышын ишетеп, инеш буена йөгердем. Итегем шундый ак, шундый матур, андый итек бер генә малайда да юк!

Яннарына барып баскач, малайлар минем итекне күреп шаккаттылар:

— Ай-ай! — диделәр.

...Ул арада апайның шау-шуына әти дә борылып карады. Карандашын верстагына куйды. Аның урынына аршын аламы дип күзне мөлдерәтеп торганда, ул, сәкегә утырып, тезләренә таянды.

— Баттыңмыни? Мондый коры көнне андый пычракны каян эзләп таптың? Я! — диде.

Әтинең күзләренә карап булмый иде. Мин, башны иеп, сүзсез калдым.

— Я! Телеңне йоттыңмы әллә?

Нишләптер сүзем чыкмый башлады. Әтинең кулы верстактагы аршынга сузылган кебек күренгәч, ничектер, үзеннән-үзе, инеш буе, анда көлеп торучы Закир абый, аның көлгәндә ике катлылана торган сәер ирене күз алдыма килде.

— Закир абый...

— Нәрсә, «Закир абый?» Нишләтте Закир абыең?

Әтинең кулы аршынга сузылмаган икән, тавышы да ул кадәр үк рәхимсез түгел шикелле.

— Ни, Закир абый малайларны инеш өстеннән сикертеп уйнатты.

— Катмый калган турысыннанмы?

— Ие...

— Сикерделәрме соң?

— Ни, Нимҗан сикерде, ул шупырдап суга барып төшкәч, бүтәннәре курыктылар.

— Син курыкмадыңмы?

Башта мин дә курыктым анысы. Итекне дә кызгандым. Ялгыш кына суга төшсәң!.. Тик шунда олырак малайлар, һәммәсе бердәй, үчекләргә тотындылар:

— Үзе яңа итек кигән булган, үзе сикерергә дә курка!

— Әй, бигрәк йөрәксез малай икән бу Гомәр!

— Тап-тар инеш! Шуңа да йөрәге җитми...

— Һи, минем андый яңа итегем булса! — ди берсе, олтан салган итеген күрсәтә. — Минеке шикелле иске итек сикерәмени ул!

Аларга да әллә ни исем китмәде. Тик менә Закир абый сүзләре генә әллә нишләтеп җибәрде. Бер малай да сикермәгәч, ул, кулын селтәп, безнең яннан китә үк башлады:

— Әй, сездән буламыни ул? Андый батыр малайлар безнең очта бармыни соң! Җыен куркак, җыен тавык йөрәк!..

...Әти бармаклары белән верстагында тукылдап алды:

— Шуннан соң сикердең дә суга барып төштеңме?

Мин башымны гына идем. Малайларның егылышып көлүләрен дә әйтәсем килмәде.

Аларга көлке, ә мин тубык тиненнән суда. Мин еларга ук житешкән идем инде, Закир абый тартып чыгарды. Аның ирене ике катлы булуы бигрәк тә шул чакта аермачык булып күземә чалынды.

— Кем басты итегеңне? — ди.

Мин, еламсырап:

— Гыйбаш абый... — дидем.

— Һи, юләр! Гыйбаш баскан итеккә су үтәмени? Бигрәк тә яңа чагында!..

...Тау шуа башлагач, мин боларның һәммәкиен дә оныткан идем инде.

Әти нигәдер миңа түгел, апайга ачуланды.

— Ниямәрсә карап торасың? Чишендер! — диде.

## III

Пәнҗешәмбе кичне, ашап-эчкәннән соң, без һәммәбез дә түр як сәкенең уртасына эленгән җиделе лампа тирәсенә җыела торган идек. Бүген дә шулай булды. Әти үзе түр башындагы ястыкта кырын ята. Ул күзләрен йомар-йоммас, бүтәннәрнең эшләре бетүен көтеп, тыныч кына ял итә.

Ята торгач ул абыйдан ничек укуы турында, мәдрәсә турында сорашырга тотына. Миңа алары кызык түгел. Мин, аягымны бөкләп, әтинең аяк очынарак килеп утырам да аның минем белән дә сөйләшүен көтә башлыйм. Миңа аның әнә шулай олы гәүдәле, зур кеше булуы да, беләкләренең, бармак юанлыгы тамырлардан үрелгән шикелле, ничектер үз алдына сырлы-сырлы булып торуы да бик ошый. Аның бармаклары юан, буынтыклы-буынтыклы. Әни бер вакытны: «Атаңның куллары корычтыр», дигән иде. Миңа аның кулларының корычы нәкъ әнә шул тунмый да, пешми дә торган киң, калын уч төбендәдер, карандаш юанлыгы кадакларны чыдырдатып суырып ала торган әнә шул ялтырап, шомарып торган җәенке бармак битләрендәдер кебек күренә башлый.

Верстагы янында көне буе кисеп, юнып, ышкылап әллә никадәр эш эшләгәннән соң түр башындагы ястыкка кырын ятуы аңа бик килешә иде.

Берәүнең дә атасы, безнең әти шикелле, аркасы сырлы урындыклар, рамнар, такта умарталар ясап, пыялалар куя белми. Мин әтигә тагын да якынрак шуышам.

Әти, бүтәннәр белән сөйләшә биреп, минем я башымнан сыйпап куя, я иңбашыма тиеп ала. Мин чын күңелдән ышана башлыйм: әни дөрес әйтәдер, мөгаен, корычтыр аның куллары. Югыйсә, шул тикле кытыршы да, авыр да булмаслар иде...

Кайбер күңеле күтәренкерәк кичләрне әти минем белән сөйләшкәләп тә алгалый. Шулай түшәмгә карап ята-ята да миңа таба борыла:

— Яле, шәкерт, син кем угылы? — дигән була.

— Мин — Бәшир угылы.

— Мм... Бәшир кем угылы?

— Бәшир Мостафа угылы.

— Аннары?

— Аннарымы? Аның атасы Ибраһим, аныкы Шәфигулла...

— Я, я, арырак киткәч, тегеләй таба ничегрәк бара?

— Шәфигулланың атасы Идрис, аннары әллә кем, аннан да ары Сәмәкәй.

— Менә, менә, төбе-тамыры шул инде. Аның теге ягы бик ерак, караңгы. Ул чакларда бу тирә урман гына булган әле.

Әти бераз нидер уйланып ята.

— Дәү абыең язмады шул шәҗәрәне. Ни әйттем, һәмишә сузды. Тора-бара бөтенләй онытты. Шәкерт булгач, син дә онытырсың әле. Булмас сездән, булмас!

Минем әтине озаграк сөйләштерәсем килә. Шуның өстенә, узган ел гына бездән башка чыккан Вәли абый шикелле, алай тыңлаусыз-сансыз булып әтине борчырга да теләмим.

— Юк, онытмам, — дим мин. — Кызыл, зәңгәр, яшел карандашлар белән үсеп торган алмагач күк итеп ясарым.

Әти мине иңбашымнан сөеп ала. Мин бөтен күңелем белән аның

«улым» дип әйтүен көтәм. Ләкин нигәдер ул, бүтән әтиләр шикелле, алай дәшми... Нишләп икән? Уйлыйсы уйлары бик күпме? Әллә андый сүзне яратмыймы?

Әти минем үзе янында утыруымны бөтенләй онытты бугай. Түшәмгә карап ята да, байтак вакыт узганнан соң, корырак калын тавышы белән тагын бер-ике сүз әйтә:

— Иртәгә ындырдан салам ташып куясы булыр.

Монысы абыйга. Җомгасын да җомга, кайтуын да бер генә көнгә кайткан. Шулай да көн буе сөрән сугып тик йөрисе түгел әле...

Абый, сәкегә менеп баскан килеш, китап шүрлегендә кыштырдап, нидер эзләп маташа иде. Ул кинәт, чырае бозылып, туктап калды. Күрәсең, аның шушы кайткан арада иптәшләре белән йөрисе, бераз гына булса да ирек ачасы килгән иде дер... Әмма әти әти инде ул.

Абый бераз тынып торганнан соң, юаш кына:

— Ташыганы беттемени? — дип куя.

— Беткәнен көтеп терлекләрне ач тотаргамы?

Аннары әти почмак якка дәшә:

— Коймагыңны иртәрәк өлгерт! Көн кыска, җомгага чаклы ташып бетерергә кирәк!

Монысы әнигә.

Әни берни дә әйтми. Бу вакытта ул почмак яктагы чаршау артында дәү кызыл чүлмәккә коймак изеп маташа. Тагын күпмедер тыкырдатып туглый да чүлмәкне мич алдына, җылыга куя. Аннары тавык чүпләп бетермәстәй вак-төяк эшләрен тегесен тегеләй, монысын болай итә дә чаршауны тартып кече якны бөтенләй каплап куя. Җерли торган кабасын алып лампага якынрак, йөзлек буена килеп утыра.

Тик җирләргә һаман ашыкмый. Орчыгын тезләренә куеп озак кына абыйга карап торганнан соң, сузыла төшеп, аның аркасын капшарга тотына:

— Кара бу сөякләрне? Чыраең да бер дә калмаган, — ди. — Акшарлаган мич төсле.

Мин бер абыйга карыйм, бер мичкә.

— Авырттыңмы әллә?

Абый, китабыннан башын күтәрмичә, юаш кына:

— Ю-у-у-к,— дип суза да борынын тартып куя.

Әмма әни аңа ышанмый, күрәсең, аның матур гына борын канатлары селкенгәли башлый, юка иреннәре кысыла.

— Ашарыңа җитмәгәндер әле!

-- Җитмәс! Бер буткалык калды да әле.

Кыш көне без түбән өйдә генә торабыз. (Югары өй бик искергән, аңа утын төткәреп булмый, ди әти.) Түбән өйнең тәрәзә төбе җир белән тигез булганга, ишек алдында уйнап йөрүче җаяүле буран койрыгы белән тәрәзәгә сыйпалып үтә. Кайвакыт, хәле бетеп, тәрәзә төбендә егылып та калгалый.

— Әнә буран да чыккан,— ди әни.— Саламны иртәгә кузгатмыйрак торыргамы әллә? Атнага бер килгән җомга инде ул. Хәмзә дә бер генә кичкә кайткан. Әкренләп ташылыр әле шунда, кечкенә чана белән.

Әти, кулларын баш астына куйган килеш, түшәмгә текәлгән дә үз уйларына чумган. Әллә ишетә ул әни сүзләрен, әллә юк. Аның йөзендә бер генә тамыры да тибрәнми.

## IV

Ул вакытта инде апай да, вак-төяк өй эшләрен бетереп, шул ук лампа яктысына килә. Ул киергесенең бер башын сәкегә куйган да икенче башын тез өсләренә җайлап, алсу төсле ситсыга чынаяк өстеме, нәрсәме, шундый кечкенәрәк бер чигү чигәргә тотына. Көндез тәрәзә янында мин аның шул алсу чүпрәккә карандаш белән тырышып-тырышып

чәчәк бизәкләре төшергәнен карап торганым бар. Менә хәзер апаң, тамбур энәләрен шул карандаш эзләреннән йөртеп, дебеттән яшел, зәңгәр, бишни төсле зур-зур чәчәкләр чигә. Апайның кыска гына, кеч-кенә генә коңгырт бармаклары, бик килешле булып, тегеләй дә болай уйнап кына тора, энәләре бер батырган саен шарт та шорт килә. Аның бармагындагы көмеш балдагы, очкын чәчрәткәндәй, җелт-җелт итәләр. Күзләре озын кара керфекләре астында бөтенләй йомылып беткән шикелле. Чебен эзләре шикелле генә шул нечкә юлларны ничек күрә икән соң ул? Дебетенең күзәнәкләре ничек төшеп калмый да ничек чәчәгеп бозып җибәрми икән!

Ул яз көне, менә хәзерге шикелле, башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл яп-кычлары, кулъяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә. Мин аны, азрак усал булса да, кызганып куям. Менә шулай бер ирек ачмыйча, бөкресен чыгарып, көне-төне чигү чигеп утыру бик туйдыргандыр, ул бик арыгандыр шикелле тоела башлый. Кайчак-ларда әни дә әйтә:

— Утырма көн-төн чүпләнеп! Күзеңне бетерерсең, сукыр калыр-сың! — ди.

— Котың чыкмасын, бернәрсә дә булмас, — ди апай.

Аннары шулай, башы белән киергесенә иелгән килеш, дәшмичә генә чигеп утыра да, бөкрәеп килгән аркасын турайтып, әнинең күзләренә карап тора башлый. — Соң нишлим? Өс-башыма ничек юнәтим? Әти җилкәсенә салынып ятыйммы? Өй тулы җирсез-иманасыз. Ул мескен ничек җиткерсен? Үзең беләсең ич...

Әни белә инде ул, белә. Икмәк салган саен әти аның колагына тукып кына тора:

— Эре иләктән илә, онны күп тотма.

Безнең өйдә әти белән абыйның гына җире бар. Хатын кешеләргә җир бирмиләр, ә мин җир өләшкәч туганлыктан, җирсез калганмын. Җирсез-иманасыз. Әни миңа карап авыр сулап алгалый. Бәлки, ул мине иманасыз булганга кызгануыдыр? Иманасыз...

Кайчагында шулай, җир азлыгы турында сүз чыккач, әти дә әйтеп куйгалый:

— Их, малай-малай! Бер генә атна элегрәк тусаң ни була соң? — ди.

Шундый вакытта миңа бик уңайсыз булып китә. Кеше алдында күл-мәксез-ыштансыз утырган шикелле...

Тик бүген апайның болай беркемгә дә сүз катмыйча, күтәрелеп карамыйча, мыштым гына утыруы бүтәннән булган икән...

Әни орчыгын берничә мәртәбә зырылдатып алуга, апай аңа әллә ничек кенә итеп ым какты. Әни бераз тынып торганнан соң, бу әйткән-нәре үзеннән-үзе телгә килгәндәй, ничектер шома гына итеп, күрше Ибраһим абзыйларның Кибәхуҗага кунакка китүләре турында әйтеп куйды. Кияүдәге кызлары бала тапкан икән дә, шуңа бәби ашы илтә киткәннәр.

— Менә бит гомер дигәнең! Мәймүнәне әйтүем, әле кайчан гына өреп очырырлык ләтчәдәй бер нечкә генә нәрсә иде. Ни арада китүе дә, ни арада бәби табуы. — Ул күз кыные белән генә әтигә карап алды, бармак очына төкергәләп, орчыгын тагын берәр зырылдатты. — Баягы-нак Мәликә аулак өй сакларга Өммикамалны да чакыра кергән иде дә. Иптәш булыр дип...

Әти кеше кайвакытларны әнинең нигә шулай якын юлны ерак итеп, боргалап-сыргалап маташуын сизеп алуга, сүзне тыңлап та бетермәс-тән, кырт кисә торган иде:

— Йөрисе түгел! — дип.

Тик бу юлы алай итмәде, апайга ничектер ягымлырак итеп карап куйды. Әтинең күңелен нәрсә йомшартты икән? Апайның «Кертмәсәң

дә җылап үлмәм әле!» дигән сыман сер бирмичә, үзенә күрә тәкәббер-ләнеп утыруымы? Әллә бик кыен чакларда апайдан үзенең дә акча алып торуы исенә төштеме? Ни әйтсәң дә, начар түгел бит. Аңа салынып ятмый. Шул киндер сугулары, чигүләре белән үз өс-башын үзе карый.

Ни булса да булгандыр, әмма бу юлы әтинең тавышы кырыс ишетелмәде:

— Ярар, керсен...

Апай кеше әле шуннан соң да, ашыкмаган кыяфәт белән, беравык тын утырды. Тик монысы әти әйткән сүзен кире алмагае дип, шигәюдән генә инде аның. «Кара нинди акайды, күзенә ак-кара күренмни! Юньлегә шулай җилкенмидер бу!» дисә, җибәрмәсә нишләрсең?

Итәрсең апайны мондый мыштым! Мин аның аулак өйләрдәге тәңкә салыш, арка сугыш уеннарында, ут борчасы шикелле, уйнаклап кына йөрүен әллә ничә күргәнем бар...

Бераздан аны әни үзе кыстый башлады:

— Бар инде, кер! Кара аны, узынасы түгел! Иртә белән яктырганны көтеп ятма, эш күп.

## V

Абый әллә кайчан ук әзер иде инде. Ул катыргы тышлы калын китапларны янына тезеп куйган да кыяр-кыймас кына әтигә карап алгалый. Әти нәрсә укырга куша бит. Бәлки, ул аңа мәдрәсәдә атна буе укыган сабагын тыңлатыр, я, бәлкем, мулла абзыйлар шикелле, кычкырып коръән укырга кушар. Каян беләсең...

Узган ел җәй көне, рамазан аенда әти абыйга кечке намазга кергәч, тәбарәк укытырга маташкан иде бит. Янәсе, мужик кына булсак та без дә бөтенләй ук төшеп калганнардан түгел. Мулла-мунтагай булмасак та, без дә коръән җырлата беләбез... Шуның өстенә, абыйның тавышы да матур гына икән. Әмма әти бу юлы муллаларның борынына чиертә алмады. Абый укырга җыенып, тамак кыргалап маташкан арада, тәбарәкне мәзин бабай үзе тәгәрәтеп җибәрмәсенме! Өйгә чыккач, әй эләкте абыйга шуның өчен.

— Булмый синнән, җебегән! — диде, төн буе орышып чыкты.

Бу юлы әти аңа китапның зәңгәр тышлысын укырга кушты.

Әни лампаның филтәсен бераз күтәрә төште, яулыгын артка чөеп бәйләде дә колак тирәсендәге чәч бөртекләрен арткарак сыпырып җибәрде. Кеше-кара керәсе юк, әнигә хәзер ул кадәр капланып бетмәсә дә ярый инде. Абый, мәдрәсәдәге шикелле, тезләнеп утырды да, китабының ике канатыннан ике кулы белән тотып, акрын гына укырга тотынды.

Тыштагы суык тәрәзәләргә бозлар катыра, бүрәнәләрне шарт та шорт китерә, аяк баскан саен, тышта кар шыгырдап килә. Ә без менә шулай, бәйрәм алды кичәсе итеп, җылы өйдә, якты лампа тирәсендә рәхәтләнеп китап укып утырабыз.

Миңа әнинең мичкә төшкән күләгәсен карап утыру китап тыңлауга караганда да кызыграк тоела. Әни үзе мич стенасында әллә нинди озын муенлы сәер хайванга атланган бик дәү кеше булып күренә. Аның тәкә башы хәтле орчыгы, үзеннән-үзе айкалып-чайкалып, әле ишеккә таба атыла, әле сәкегә таба. Шул әкәмәтне карап утыра торгач, ул шәүләләр бер дә чын түгелдер, әллә нинди күз буяудыр, я әкияттер кебек тоела башлый.

Утыра торгач, абыйның көйләп-көйләп китап укуы янадан колакка килеп керә. Ул, аз гына атына биреп, укый да укый. Өй эчендә моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәп-сәер ят сүзләр сибелә башлый. Дәгел дип куя, булгай ди, сүз арасында һөд-һөд, дөл-дөл, аргамак, фиргавен дип җибәрә, тагын әлләниләр тезеп китә.

Шунда минем Арча базарына баргач, кибет тәрәзәләрендә кызыктырып яткан төрле төстәге чуп-чуар уенчык әйберләр, кәгазьгә төшерелгән төрле сурәтләр күз алдыма килә. Алар да, мәнә шушы сүзләр шикелле үк, ялтыравыклы, шундый ук әллә нинди сәп-сәер, шундый ук аңлашылмый торган ят нәрсәләр иде. Шунлыктандыр бәлки, алар бер колакка кереп алдылармы, һич онытыласылары килмичә, сагыз урынына авыз эчендә әвәләнә, чәйнәлә башлыйлар: һәд-һәд, дәл-дәл,... төрҗәгун...

Мин шунда, иртәгә урамга чыккач, ачуны китергән малайларның авызына китап сүзләре белән чәпәргә дип уйлап куйдым. Тотасың да:

— Әй, төрҗәгун! — дисең.

Озын сыйраклы икән, дәл-дәл кушасың. Ябык икән, анысын, аргамак дип үртисең. Аңгырарак булса, һәд-һәд булып китә...

Абыйның иңбашы аркылы, борынымны сузып, шул сүзләрнең чыккан урыннарын эзләргә тотындым. Кызык бит: ничек чыгалар икән ул сүзләр? Җентекләбрәк карый башлагач, китап бите өстендә, сукыр черки хәтле генә, кәкре-бөкре кара бөҗәкләр күренде. Озаграк карап торсаң, алар селкенгән шикелле тоела башлый.

Нәкъ шундый кызыклы нәтиҗәгә килгәндә генә абый «шалт» иттереп маңгайга чиертте. Алай да булмагач, эти күлмәк итәгеннән тартты:

— Тик кенә утырасыңмы син, юкмы? Күләткә! Кыбырсык!

Минем үпкәлисем килә башлады: карап торган өчен генә нигә шулкадәр ачуланырга?

Күтәрелеп карасам, шул арада әнинең дә, этинең дә чырайлары, сөрем утырган лампа морҗасы төсле, караңгыланып та өлгергән. Әйтерсең, алар бик тә начар берәр эш эшләгәннәр дә бер усал кеше аларны шуның өчен әрли дә яный: «Мин сезне шулай итәрмен, болай итәрмен!» дип төрле куркыныч сүзләр белән куркыта. Эти, кашларын җимереп, карасына баткан. Әни әледән-әле уфылдап куя:

— И ходаем, бар икән күрәселәребез... — дип, күзләрен сөрткәли.

Эти белән әнинең бер начарлык та эшләмәүләрен мин яхшы беләм. Шунлыктан, китап аша андый куркыныч сүзләр белән янаучы ул явызга минем ачуым килә башлый. Икенче яктан, бу хәл миңа бик тә сәер тоела. Андый куркыта да, җылата да торган начар китап булгач, нигә укыйлар икән соң аны?

Ярый әле, этинең башы җитте. Ул шундый хәтәр сүзләр такылдаган өчен, китапка байтак кына вакыт ачулы күзләре белән карап утырды да абыйга кулын селтәде:

— Ярар, җитте!

Бу вакытта инде минем башым яман да авыраеп, үзеннән-үзе аска таба тарта, күзләрем түзә алмаслык булып йомыла башлаган иде. Син аны тырышып-тырышып ачасың, ә ул яңадан йомыла.

Шунда мин аркамда әнинең җылы кулын сизәм, колак төбендә аның күгәрчен гөрләгәндәй йомшак сүзен ишетәм:

— Карасана, күрмиләр дә торам икән ләбаса! Килеп үк житкәннәр икән бит! Бүген бик күп эшләде шул бу дәү кеше, таулар шуды, кичләр утырды...

Озак та үтми, мин, башым-аягым белән, иксез-чиксез һәм татлы малайлар йокысына чумам.

## VI

Менә бервакыт уянып китсәм, өй эче тып-тын. Бөтенесе йоклаган. Тик мышнаган, борын сызгырган тавышлар гына ишетелә. Бер заман әнә шунда, йөзлек буенда гына, орчык зырылдаганны ишеткәндәй буласың. Үз колагыңа үзең ышана алмыйча, сәерсенеп, башыңны да күтәреп карыйсың. Йөзлек буенда бер кеше дә юк, әнинең кабасы да

күренми. Ә орчык дигәнең, нәкъ кич утыргандагы кебек, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш чыгарып, зырылдый да зырылдый. Менә тамаша!

Курка-курка гына почмак якка карасам, имәнеп киттем. Мич алдыннан ут төсле бер күз чекерәеп миңа карап тора! Ул шундый якты, аның авырттыруына түзә алмыйча, күземне йомам. Әмма ул күз кабаклары аша да үткәрә. Нинди утлы күз икән соң ул? Әгәр мичкә бичура кереп утырган булса? Чормада утырып туңгандыр да өйгә төшкәндер...

Ярыйсы ук шүрләсәм дә, әнине уятырга базмадым. «Һи, куян йөрәк, һи, куркак җан», дисә, иртәгә апаларга әйтеп көлдерсә?

Шунда тәрәзәгә күзем төште. Нәкъ безнең лапас өстендә тулган ай эленеп тора, имеш. Әһә, ул күз әнә нәрсә шәүләсе икән! Мин, батырланып, юрганымны ачарак төштем, маңгайга бәреп чыккан тирләрне сөртеп алдым. Ишек алдындагы, лапас түбәсендәге кар өсте шул тикле якты, ул зәңгәрсу очкын булып, җем-җем итеп тора, күзне камаштыра. Минем хәзер үк ишек алдына чыгып китәсем, шул җемелдек кар өстеннән шыгыр-шыгыр басып, йөгереп йөрисем килә башлады. Тик шунда келәт янындамы, кайдамы, нәрсәдер, бөтен ишек алдын яңгыратып, «шарт» итеп куйды. Анысы тынуга, аз гына торды да өй почмагы шартлады. Аннары әле өй стенасында, әле келәттә...

Ишек алды хәзер көндезге шикелле эчпошыргыч күңелсез түгел. Ул әкияттәге төсле серле булып, ниндидер тылсым дөньясы булып күренә. Беләм, анда, көндез күреп булмастай, әлләниләр бардыр. Күктәге йолдызларның һәркайсы йодрык хәтле булып зәңгәр очкыннар чәчрәтеп тора. Айдагы теге кызый шулкадәр ачык күренә, лапас түбәсенә шундый якын тора, әйтерсең, хәзер иелер дә, көянтә-чиләген лапас кыегына элеп, үзе ишек алдында сикереп төшәр кебек.

Шулай да миңа ул кыз хәзер бик моңсу кебек күренде. Теге вакытта, үги анасының җәберләвенә түзә алмыйча, су алырга төшкән җиреннән айга менеп киткән китүен дә... Күрәсең, хәзер ямансулыйдыр. Бәлки, аның әле кире кайтасы да килә торгандыр. Ни әйтсәң дә, ай өсте җир йөзе түгелдер инде. Салкындыр, шыксыздыр. Әнә аның җирдәге иптәш кызлары, аулак өйләрдә бер-берсенә җырлар әйтешеп, шыпырт сүзләр сөйләп, уеннар уйнап рәхәтләнгәннән соң җылы өйләрдә, йомшак урыннарда ничек тәмле итеп йоклап яталар. Ә ул кызый әнә шул боз шикелле салкын ай өстендә көне-төне бер үзе. Әнә хәзер дә, яшьтәшләренең су юлларына карап, ничек моңаеп тора.

## VII

Иртә белән мине өйдәге шау-шу уятты. Каяндыр, бик еракта кәҗә бәтиенең кызганыч тавышы ишетелә, өйдәгеләр, бу тавышның каян килүен белә алмыйча, арлы-бирле сугылалар. Әни бер ягып җибәргән миче янына бара, бер олы якка йөгереп чыга.

— Ай аллам! — ди ул. — Көн бик суык булгач, җылы апара эчертеп чыгарырмын дип кенә керткән идем. Кая олакты соң? Җир йоттымы әллә үзен?!.

Мич башына да күз салдылар, верстак астыннан да карадылар. Юк кына бит кәҗә бәтие. Ә тавышы торган саен кызганычрак булып ишетелә.

Бер заман әни, коты чыгып, мич каршысыннан читкә тайпылды.

— Әстәгъфирулла, тәүбә! Бу ниткән тамаша!..

Карасак, мичтә янып яткан утлы салам кисәкләре як-якка тузгыды. Шулар арасыннан, ямьсез тавыш белән акырып һәм пошкырып, мендәр хәтле ут төенчеге атылып чыкты. Ул башта мич алдыннан туп-туры минем өскә сикерде, сәкедән верстакка очты, аннан идәнгә атылып, туп-туры сулы ләгәнгә барып төште. Идән лач су булды, борыннарга көйгән йон исе килеп бәрелде.

Әни, каушавыннан, хәле беткән, сәкегә ауды.

— Уф, йөрәгем! Аллаһ гына орган хайван икәнсең. Тфү, тфү!..

Без, тыела алмыйча, тәгәрәшеп көләргә тотындык. Хәтта әтигә кадәр атына-атына көлде.

— Аһ, сине, шайтан токымы! Кара син аны! Үләсе түгел. Мич түренә җылынырга кергән дә, пешә башлагач, атылып чыкмасынмы!..

Иртәнге чәй вакытында бөтен сөйләгәнебез сап-сары булып көйгән шушы өтек кәҗә бәтие булды.

Ул әле һаман да тынычланып җитә алмый иде. Коты чыгып верстак артына поскан да, кечкенә генә тавыш чыкса да, дерт итеп сискәнеп куя, өзлексез койрыгын уйната, әледән-әле бик яман пошкырып ала иде.

Әти белән абый үз эшләренә киткәннән соң мин дә әлеге яңа киез итегемне эзләргә тотындым.

— Йөрисе түгел! — ди апай. — Күрмисеңмени тәрәзәләрне?

Әнинең дә чыгарасы килми икән:

— Өйдә генә уйнап тор әле, улым, — ди. — Урамга соңрак чыгарсың, җылына төшкәчрәк.

Оекбашымны тарткалап, яңадан сәке өстенә менеп киттем. Шырпы тартмаларыннан өйләр, келәтләр ясадым. Анысы туйдыргач, сәке өстен тау итеп шудым, сәкене тезләнеп тә, түш белән дә, мүкәләп тә, аркылыга да, буйга да уздым. Аннары сәке такталарындагы ботакларны санный торгач, иң кызык, иң серле урынга, чаршауның эчке ягындагы дәү генә ботак тишегенә килеп җиттем.

Их, хәзер яз көне булса! Яз көне шул тишеккә берәр нәрсә тыксаң, менә кайчан була тамаша! Ана каз, ачуланып, елан шикелле ысылдарга тотына. Белмичәрәк бармагыңны сузсаң, көт тә тор, өзә дә ала! Ана каз ояда утырганда үзен борчыганны шул тикле яратмый, син киткәннән соң да әллә нигә чаклы тынычлана алмыйча сукранып утыра.

Әгәр инде шул тишеккә тагын бер-ике атнадан, казның бәбиләре чыгар алдыннан, килеп карасаң, күзеңне ала алмыйча рәхәтләнеп карап торасың. Әй тырыша ул чакны ана каз! Ул үзенең җылы оясында гел кыштыр-кыштыр килә. Томшыгы белән күкәйләренең берсен болайга, икенчесен тегеләйгә әйләндереп-әйләндереп сала. Оясының кайбер төшләрен, үзеннән йолкып алган мамык белән мүкләп, тагын да җылыта төшә. Шул арада үзе шыпырт кына, үз алдына сөйләшкәндәй, пышылдап кына: «кый-га-га, кый-га-га» ди. Әни әйтә:

— Ул шулай туачак бәбкәләре белән сөйләшә, ул аларга: «Тизрәк чыгыгыз инде, минем үземә генә бик күңелсез», дип дәшә, — ди.

Менә бер заман, кояш югарырак күтәрелгәч, ата каз килеп өйалды ишеген тыкырдатырга тотына. Әмма күп вакытны әни аны орышып җибәрә.

— Кит моннан, юньсез! Бимазалап йөрисе түгел. Утырсын тыныч кына! — ди ул аңа.

Шунда ата каз, башын салындырып, үпкәләгән кыяфәт белән лапаска таба китә. Тик әнинең күздән югалуы була, ул яңадан өйалды ишегенә килеп җитә.

Бу юлы инде ана каз да тавыш бирә. Шуны гына ишетүгә, ата каз, нишләргә белмичә, әй тотына баскан урынында тыпыр-тыпыр биергә! Үзе бии, үзе, бөтен ишек алдын яңгыратып, «кыйгак-кыйгак» дип кычкырып җибәрә. Шулчакны ата каз миңа аерата матур булып күренә. Тик менә беләсе иде, нәрсә дип кычкыра икән ул?

— «Беразга ишек алдына чыгып кермисеңме? Бик күрәсем килде», дип әйтә ул аңа, — ди әни.

Ата казы шулай бик кыстый башлагач, кайчакларны ана каз, оясының өстен салам белән япкандай итеп, бик ашыгып кына чыгып та кергәли. Алар шунда үзара сөйләшә-сөйләшә, муеннарын боргалыйборгалый ишек алдындагы зур тагаракта кара-каршы торып юынып та

алалар. Тик тышта нихәтле күңелле булса да, ана каз бер дә артык юанмый, йөгерә-йөгерә янадан оясына кереп утыра.

Икенче көнне ата каз тагын килеп җитә. Ана казның бүген дә бик чыгасы килә. Ул инде караңгыда утырудан туеп та беткән, бик ябыккан да.

— Сөяккә генә калды инде, мескенем, — ди әни.

Менә ул, чыкмакчы булып, оясыннан кузгала да башлый. Тик шулчакны нәзек кенә «пип-пип» дигән тавышны ишетүе була, урамга чыгу кайгысын шундук онытып та җибәрә. Әй тотына кайгыртырга, әй кыштырдый, әй сөйләшә башлый ана каз! Бер әкәмәт инде. Томшыгы белән күкәенең кабыкларын китеп-китеп ала, нәни бәбкәсенә «кый-гый-гый» дип тавыш биреп, күкәйдән чыгарга булыша. Чыгып җитүенә ул аны борыны белән аркасыннан, тамак асларыннан сыйпагандай итә, шундук үзенең канаты астына, җылыга кертеп җибәрә. Ул тал бәбчеге төсле яшькелт мамыктан гына оешкан шул нәни бәбкәләренә бик ягымлы итеп, пышылдап кына көне буе казлар телендә ниләрдер сөйли, сөйләп сүзен бетерә алмый.

Тагын бер көннән карыйсың, берсеннән берсе матур нәни бәбкәләр, тупырдашып, идәнгә үк коела башлаган булалар. Менә кайчан кызык була ул почмак яктагы тишектән карап торуы!

Тик хәзергә ул кызыкларның берсе дә юк иде әле. Имән чикләвеген урталай кисеп ясаган бөтерчек, зырылдый торгач, сәке астына төшеп китте, шырпы тартмалары белән уйнау да, ишекле-түрле йөгереп йөрү дә — бөтенесе дә туйдырды.

Мин тагын әнигә сарылдым:

— Чыгыйм инде! Ялгыз гына уйнап буламыни!

Әни, яныма килеп, башымнан сыйпады:

— Бик тә суык бит, улым. Әнә, кара әле, бүген кояш та колакланып чыккан. Күрәсеңме?

Карасам, чынлап та шулай икән. Кара син, әй! Кояшның як-ягыннан, кызгылт-сары булып, дәү-дәү колаклары тырпаеп тора. Әйтерсең, алар суыктан шулай утлы-кызыллы булып яналар.

Әни, минем күлмәк сәдәпләрен төймәләп, тәрәзәгә ишарә итә:

— Әнә андагы урманнарны күрдеңме? Суык бабай әнә нәрсәләр ясап киткән.

Алай икән шул. Без йоклаган арада тәрәзә пыяласына бик матур бизәкләр төшергәннәр. Монда эре яфраклы абага үләне дә бар, чыршы агачлары да. Яфракка да, чәчәккә дә, апайның чигүләренә дә охшаган тагын әллә нинди бизәкләр тезелеп киткән. Бер күз белән карыйсың, алар ут төсле кызыл, күк төсле зәңгәр, самовар төсле алтын булып күренәләр. Икенче күз белән карыйсың, тагын элеккечә көмеш төсле булып калалар.

Апай, җиңнәрен сызганып, самовар агартып маташа. Комга тидергән бармак очы белән самоварга басып бер борып алуы була, түгәрәк тәңкә килеп чыга, тагын борып ала — тагын тәңкә. Бу тәңкәләр дә бик матур югыйсә. Бер яктан карыйсың, бер төсле җемелди, икенче якка чыгып карыйсың — икенче төсле. Шулай да миңа тәрәзәдәге урманнар, гөлләр, чәчәкләр болардан матуррак кебек тоелды. Аларны мин апайга да күрсәттем:

— Апай, болар ничек булган?

Ул, комга буялган бармакларын тазарта-тазарта, бер миңа, бер тәрәзәгә карап торды да янадан үз эшенә тотынды:

— Йөдәтмә әле, — диде. Самоварын коендырды да тагын әйтеп куйды: — Үзе булган.

— Үзе ничек булган?

— Буласы килгәнгә... Син сорасын дип.

Аның урынына әни аңлатып бирде:

— Салкын җилләр ясап киткән аны, улым. Юеш тәрәзәгә салкын җилләр өргән дә шуннан чәчәкләр, агачлар килеп чыккан.

Әни дөресен әйтә инде ул. Мин аңа да ышанам. Тик нигәдер минем ул матур бизәкләрне кичәге ай кызы ясап киткәндер, дип уйлыйсым килә. Безнең йокыдан уянганны көтеп-көтеп йөргәндер дә, айның баер вакыты җиткәч:

— «Бу юлы булмады инде, бу килүемдә күрә алмадым»,—дип, сәлам хат урынына, шушыларны ясап киткәндер. Йокыларыннан уянгач, карасыннар әле бер рәхәтләнеп, дигәндер... Минем хәтта ай кызының безнең ишек алдына төшеп тәрәзәгә тын өреп йөрүләренә кадәр күз алдыма килде.

Абый белән эти бер йөк салам алып кайттылар да икенчесенә киттеләр. Мин моны чана табаннарының тәрәзә яныннан узганда, салкыннан зарлангандай, яман да чыелдауларыннан шәйләп калдым.

Инде кояш та югарырак күтәрелде, тәрәзәдәге бизәкләрнең өске кырыйлары аз гына эри дә башлады. Шуннан сузылган ак ефәк бау төсле кояш яктысына песи кызыл борынын китереп куйды, теге, мичтән өтелеп чыккан кәҗә бәтие корсагын җылытырга тотынды.

Тагын нишләргә икән, дип каранып тордым да, түрдәге сандык өстенә басып, китап киштәсенә үрелдем. Кичә абый укыган шикелле, ике канатыннан тотып, китап укып җибәрү миңа берни дә түгел. Ничек дисәң, кичә абыйның теге сәп-сәер сүзләрне кайсы китаптан чүпләвен яхшы хәтерләп калган идем.

Әлеге зәңгәрсу катыргы тышлы китапны киштәдән тартып төшерүем булды, кече яктан апай тагын чәчрәп чыкты:

— Әй, син, малай актыгы, кая тыгыласың? Кара син аны, тәһарәтсез-нисез китап актарасың!

Ул минем кулдагы китапны тартып алып бер ягыннан ачып та карады.

— Җитмәсә тагын бисмилласын кирле-башлы тоткан! Куй хәзер үк урынына!

Әни аннан рәхәтләнеп көлде.

— Әй, сине, сине! — диде. — Үзең җиткән кыз, үзең шуны да белмисең! Малайларга нинди тәһарәт булсын? Була калса да, ул аларда күпмегә генә түзә алсын!..

Мине һаман да урамга чыгармыйлар иде әле.

Тагын нишләргә икән соң?

## Сандугачны кем үтергән?

### I

Кечкенә вакытта мин эти кешеләр һәммәсе дә кырыс холыклы, каты куллы булалар дип уйлый идем. Күрәсең, ул фикер минем башка әллә каян, читтән килеп кермәгәндер. Мин этинең ачуланган вакытларда яшькелт-зәңгәр күзләренең усал итеп, куркытып каравын, кулларының каты һәм көчле булуын хәтерлим. (Бу кадәресен үз тәнемдә дә сынап караганым бар.)

Мин белә башлаган вакытларда эти илле яшьләр чамасындагы, киң җилкәле, таза гына бер кеше иде. Коңгырт кара чәчендә бер генә бөртек агы да юк, тавышы калын, вак кына тешләре, ап-ак булып, тезелеп кенә торалар. Әмма шул матур тешләрнең җемелдәп яктырып китүе, этинең иһаһайлап кычкырып көлүе, әллә нидә бер генә, бик сирәк, бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә булып, куандыра торган бик тансык вакыйга иде.

Ул йомшаклыкны, изелеп торуны, җебегәнлекне һич тә яратмады. Уңмаган, булдыксыз кешеләрне җене сөйми, андыйлар белән алыш-биреш итәргә дә теләми, исәпләшми дә иде. Әтинең шул ук Хәмзә абыйны җәй көне печән өйгән вакытта: «Җебеп торасың, печәнне тиз генә элэктереп алмыйсың!» дип әвеслек өстеннән сугып төшергәне бар. Абый шактый ук биектән егылса да, әтинең моңа исе китмәде. Абый аягына торып басуга:

— Тиз бул! — дип кенә кычкырды.

Мин аның нинди генә кыен чакларда да зарланганын белмим. Иң каты авырган вакытында да ыңгырашканын ишетмәдем.

Кыш уртасының яман да котырынган көннәренең берсе иде. Тышта буран улый, өйдә морҗалар үкерә. Тәрәзәләр шакыраеп каткан, бернәрсә күренми.

Менә караңгы да төште, кич булды. Өйдә ут алдылар. Әти һаман юк та юк.

Әни, күршеләргә кереп, сорашып та чыкты. Һәммәсе кайтып беткәннәр. Тик базар юлында әтине бер генә кеше дә күрмәгән. Әни минут саен ишек алдына, капка төпләренә чыгып керә. Еларга житешеп, нишләргә белмичә, уһылдарга, арлы-бирле сугылырга тотына:

— Ходаем, дөньяларның асты өстенә килә, тыннар буыла. Күзләрне ачып булмый, ичмасам, бернәрсәләр генә дә күренми! Ниләр генә булды икән? Нишләп кайтмый икән?

Без, бала-чага, мәче балалары сыман, бер-беребезгә сыенып, сәке өстендәге ястык тирәсенә урнаштык. Тыштагы буран бер нечкә тавыш белән елый, бер бүре булып улый. Аның үкерүе күңелләргә шом сала, куркыта. Тышта, ишек алдында, әллә нәрсәләр, әллә кемнәр дию парие-дәй дулап, үкереп, бөтен нәрсәне кырып-җимереп йөриләр сыман. Хәтта абзардагы терлекләргә дә әллә ниләр булыр шикелле.

Буран дулый да дулый, әти һаман юк та юк. Көтә торгач, мин йоклап киткәнмен.

Ярты төннәр узган булыр, бервакыт ишек алдындагы тавышка уяндым. Күземне ачып җибәрсәм, ишектән, бөтен өйне тутырып, башта ургыла-ургыла салкын болыты бәреп керде, аннары шул болыт эчендә дәү бер гәүдә күренде. Әмма аның өсте-башы гел карга баткан, бите белән маңгае урынында тоташ боз гына иде. Кечкенә сеңелем куркуыннан чырылдап җибәрде. Әни, аһылдап, каушап, елый-елый, нәрсәләрдер чишәргә, шушы карлы-бозлы куркыныч өем эченнән әтине йолкып алырга кереште. Әтинең киемнәрен, бүрек белән итекләрен көчкә салдырдылар, сакал-мыегына, кашларына каткан бармак калынлык боз кисәкләрен ватып-ватып алдылар. Боларны карап тору гына да куркыныч иде. Аннары аны бик озак удылар, кайнар чәйләр, тагын әллә нәрсәләр эчерттеләр.

Әмма иртә белән мин торганда ул инде верстагы янында эшләп маташа иде.

Авыр тормышны, күрәсең, бераз гына булса да җиңеләйтергә тырышкандыр. Ул авылда берүзе диярлек бай гына яшелчә белән җимеш бакчасы үстерде, алма, чия, карлыган, кишер, суган, кәбестә кебекләрне үзе житештерде. Малай чакта, билгеле, моның авырлыгы безнең җилкәгә дә төште. Иптәшләрең шау-гөр килеп уйнап йөргәндә, көтү кайткан вакыттан алып караңгы төшкәнче, кечкенә арбага җигелеп, сәгатьләр буе тау астыннан су ташып кара әле! Инеш шактый ук ерак, тау текә, мичкәләр авыр иде.

Әни, һәрвакыттагыча, абый белән мине кызганып, еш кына сүз дә салгалады:

— Җитеп торырмы әллә? Бик ардылар бугай!..

Әмма әтинең җавабы бик кыска булыр иде:

— Я, я! Эшләп ашасалар, тәмлерәк булыр!..

Зуррак булгач, минем әнигә сәер генә сорау биргәнем бар:

— Нигә син яп-яшь башың белән шундый каты куллы олы кешегә кияүгә чыктың? Синең энең, әти кияү булып баргач, «Безнең тәтәй янында нишләп сакаллы бабай утыра?» дип әйткән бит.

Әни, алдына караган килеш:

— Әйтте шул, — диде. — Моны ишеткәч, әни почмак якка кереп елап чыкты.

Әни үз уйларына чумып байтак кына сүзсез утырды.

— Әйтмичә, әйтер дә шул. Элекке хатыны үлеп миңа өйләнгәндә атаң кырык тулган иде. Сакаллы кеше. Өстәвенә, миннән зуррак ике җиткән кызы, бер егет улы бар.

— Бәлки, сине әби көчләп биргәндер?

Булыр аннан, булыр!

Әнинең анасы — Ерак әбинең бик үзсүзле, бөтенесен үз кулында йомарлап тотарга яратучы нык куллы үткен карчык булуын без, балалар, яхшы ук сизә идек. Асламчы карчык иде ул. Тезенә җиткән аллыяшелле бикасап камзулын киеп, сатарга дип алып чыккан сөлге-тастымалын, чиккән намазлыгын, дастар-фәләннәрен төенчеге белән баш өстенә куеп, ара-тирә безгә дә килеп чыккалый торган иде. Аның эше күп, вакыты аз, алыш-биреш итәсе бар, шунлыктан, ул бездә бер кичтән артык кунмый иде шикелле. Тик кадерле кунак булып түр башында гына утыруына карамастан, шул кыска вакыт эчендә дә, беребезнең эшен, икенчебезнең утыру-торуын, ашау-эчүен килештермичә, һәммәсен төзәтергә ярата, бөтенесен үз кубызына биетергә чамалый иде.

— Балаларыңа йомшак торасың, кысыбрак тотмыйсың! — дип әнигә дә эләккәләде.

Безнең әни, алдау-йолдау белән хәйләнең нәрсә икәнен белмичә, һәммәсен турыдан-туры ярып салучы чамасыз да беркатлы кеше иде.

— Юк, үзем риза булмасам, әни көчләп бирмәгән булыр иде, — диде әни. — Яучы җибәргәннән соң, атаң, миңа күренү өченме икән, белмим, киенеп-ясанып безнең урамнан узды. Мин аны коймa ярыгыннан карап калдым. Түгәрәк сакаллы, чибәр генә кеше... Шуннан соң аллага тапшырдым шул аннары...

Минем һаман да бик үк ышанып җитәсем килми иде әле.

— Күрше авылда яратып йөргән бер егетең калган түгелме соң?

Әни, минем якка ачулы караш ташлап, кырт кына яны белән борылды.

— Кайсы лыгырдый аны?.. Юк сүз ул. Булмаганны!.. — Аннары миңа туп-туры карап кисәтеп тә куйды: — Сорашма миннән андый нәстәләрне. Яхшы түгел!

## II

Биш-алты яшькә җиткәч, «әйберләр янында утырып торса да ярар», дип җәй көннәрендә малайларны базарга алып йөргәли башлыйлар. Ул вакытта Арча базары дүшәмбе көн була торган иде.

Менә әни мине эңгер-меңгер вакытта ук уятты да камзулымны киндерде, аннары, бераз икеләнеп торды да, салкынчарак булып, җилләп тә торганга, бишмәтемне дә бирде. Башыма кәләпүшемне сылап куйды. Минем әле йокым туярга өлгермәгән, күзләрем ачыта, чирәмнең салкын чыгында аякларым чытая. Без киенеп маташканда ишек алды уртасында ат җиккән җиреннән әтинең ризасыз тавышы ишетелде:

— Кая, булдыгызмы анда?

Әни, минем кулыма бер телем ипи, бер шакмак шикәр тоттырып, арба янына китерде:

— Хәзер... Менә булдык та.

Әти, бүреген басыбрак киеп, арбаның алдынарак утырды, мин — аның артына. Әни, капканы ике якка ачып, безгә хәерле юл теләп калды:

— Аллага тапшырдык! Исән-сау йөрегез.

Тау урысын[1] узып, Каенсар үрен менгәндә Дәкүчәй алпавытның басуы өстеннән җиз поднос төсле салкын сары кояш күренә башлый. Тик ул җылытмый әле, шунлыктан мин чебиләгән ялан аякларымны саламга төребрәк утырам.

Ул арада аръяктан да, бирге яктан да чыга торгач, безнең шикелле базарчылар биш-алты ук булып китте. Шәбрәк атлы, хәллерәк хуҗалар ярлы-ябагай, я начаррак ат артыннан барырга хурлана да алга чыкмакчы була. Бүтәннәрнең дә тузан йотып, артта сөйрәләселәре килми. Китә шуннан узыш, китә чабыш! Юл казылмалы, сикәлтәле. Арба үрле-кырлы килеп сикергәләргә тотына. Юка гына салам өстендә, арба белән бергә, мин дә бертөзлексез калтырана, дерелди, сикергәли башлыйм. Мин генә түгел, юл буендагы әремнәр, күпер баганалары дерелди, Каенсарның капка төбендә базарчыларны карап торучы апайларына, җиңгиләренә хәтле дер-дер киләләр шикелле. Эчкә кату чыга, күз алмары әлҗе-мөлҗе килә, хәтта күңелләр болгана башлый.

Тешләрне кысып, урәчәгә, я астагы тактага ябышасың. Ләкин тәгәрмәчләр казылмага килеп төштеме, барыбер сине арбаның икенче кырыена ыргыта! Әти кинәт кенә атка сугып җибәрдеме, артка мәтәлеп китәсең. Әти кеше борылып бу хурлыкны күргәнче, берни булмагандай, яңадан үз урыныңда утырган булырга кирәк. Шулай булмыйча, кемнең «җебегән!» дигән сүзне ишетәсе, я мыскыллы карашны күрәсе килсен!?

Ниһаять, менә Айбан, менә Казан суындагы тегермән буасының шаулап торган арыгы, менә Арчаның Кабак тавы. Ул биек тә, озын да. Кара бия арбаны көчкә генә сөйрәп менә. Тау астында тимерчеләр ат дагалый, тәгәрмәчкә шин тарта. Шунда ук тезелеп киткән салат заводларыннан бераз татлы да, азрак төче дә, шул ук вакытта кызарып пешкән ипи катысы исен дә хәтерләтә торган салат исе аңкып тора. Арча кешеләре тәмле йорт сырасын менә шул салаттан пешерәләр инде.

Арчаның базар мәйданы без барып җиткәнче арбалы атлар, җәяүлеләр белән әллә кайчан тулган. Шул кысынкылыкта әти, кайсын тәртә башы белән бәрдергәләп, кайсы-берсенең арбасын күчәр башы белән эләктергәләп, уртага керә дә атка печән салып аркалыгын төшерә.

Китәр алдыннан:

— Арбадан төшәсе булма! — ди. — Аны кара, йоклама!.. Мин хәзер киләм.

— Я, йокламыйм, карап кына утырам.

Әтинең эше бик күп. Буяучыдан киндер аласы, мал-туар базарында терлек бәяләрен белешәсе, тәрәзә рамына ярыр өчен я чыршы, я нарат такталары табасы, пыяла аласы, бакырчыда самовар борынын төзәттереп чыгасы, замазка ясарга киндер мае белән акбур аласы, әллә кемнәргә бурычын бирәсе, әллә кемнәрдән үзе биреп торганны сорыйсы бар...

Як-ягыңа карыйсың, исләрең китмәле! Әллә кайларга хәтле ун-унбиш рәт булып атлы арбалар тезелеп киткән. Бер арбадан икенче арбага сикереп-сикереп китсәң, әллә тагы Арчаның аргы башына, әнә теге яшел гөмбәзле, алтын тәреле чиркәүләргә хәтле барып чыгасы. Нинди

[1] Тау урысы — Березовка яки Арпаяз Яңа саласы дигән күрше рус авылын шулай атыйлар иде.

генә арбалар, нинди генә атлар юк! Чем-кара, тимгел-тимгел тимер күк, алмачуар, кара-туры, арт санына кара бишмәт, түшенә ак алъяпкыч бөркәнгән төсле ала-кола... Арба саен диярлек минем шикелле бер малай кисәге, я кыз бала чөмәшеп утыра. Кайсы авызын тутырып базар калачы ашый, кайсының кулында алма, я кыяр. Кеше ашаганны карап авыз суларыңны йотып утыру яхшы түгел, ди әни. Әти миңа да берәр тәмле әйбер алып килер әле.

Икенче якка карасам, янәшә арбадагы кызыл кәләпүшле малай яшел көпшәле агач мылтыктан шарт та шорт бөке аттырып утыра. Аннан да арырак берсе курай кычкырта, өченчесе сыбызгы сызгырта. Әмма нәни генә бер кыз баланың авыз гармуны уйнатып утыруы барысыннан да бигрәк кызыктырды. Ирennәренә тидереп өрүе була, шул кечтеки генә нәрсә искитмәле матур тавышлар чыгара. Әле яшь этәч кычкырган, әле үрмәкүч тозагына эләккән чебеннәр безелдәгән шикелле.

Әтинең «хәзер» дигәне байтак ук озакка сузылды. Як-ягымдагы бөтен күз күреме җирдә мыжгып, кайнап торган халык диңгезе дә, озак карый торгач, ардыра төште. Нәрсәләр генә, кемнәр генә күзгә чалынмый базарда! Кырыеннан саргылт төлке йоны тырпаеп торган мескен бүрекләр, кара, яшел, зәңгәр кырыйлы төрле картузлар, кызыл, зәңгәр, кара төсле хәтфә кәләпүшләр...

Кояш та югары ук менеп китте. Атлар, печәннәрен ашап бетергәннән соң, чебен белән кигәвен тешләүгә чыдый алмыйча, тып та тып тибеналәр, тынычсызланып башларын чайкый торгач, йөгәннәрен салып, күршеләре белән тешләшергә, чиңашырга тотыналар.

Әтине көтә башлауга инде биш былтыр. Хәзер инде базар шаушуына колаклар тонып бара. Ашыйсы да бик килә, эчәсе дә.

Утыра торгач, агач мылтыклар да онытыла, авыз гармуннары белән сыбызгы тавышы да колакка керми башлый. Ничектер, үзеннән-үзе, чаттагы йортка күз төшә. Аның ишеге өстенә дәү ак чәйнек белән чынаяк сурәте ясап куйганнар. Ачык тәрәзәдән кешеләрнең кызарыпбүртенеп ашап-эчеп утырулары күренә. Ул яктан, бик тәмле булып, борыннарны кытыклап, әле генә мичтән чыккан ак күмәч исе, майга кыздырылган суганлы бәрәңге исе килә. Шул тәмле ризыкларны ашап утыруы нинди рәхәттер... Авыр сулап куясың да тагын читкә борыласың.

Әти киткән якка озак карап утыра торгач, баш, авыр нәрсә таккан шикелле, торган саен авырая башлый. Базарның гүләгән тавышы да акрын-акрын һаман тоныклана, басыла бара...

Менә бер заман колак төбендә генә әти тавышы ишетелә:

— Әй, малай! Эрегәнсең бит! Әйберләреңне алып китсәләр!..

— Юк, әти, мин карап кына утырдым...

Әти миңа күзен тутырып бер карап ала да, тире эчле мескен бүреген салып, кәләпүше белән башын җилләтергә тотына. Аннары өстендәге бишмәтенең, ул бишмәт эчендәге камзулының төймәләрен ычкындырып, күкрәк тирәләрен җилләтергә тотына. Көн эссе. Казаки генә кисә дә бик житкән дә бит, югыйсә. Бервакыт әни шулай дигәч, әти аны пыр туздырып орышып ташлады:

— Казакичән генә йөрергә син мине яшь-җилбәзәк дип белдеңмени? Олы кешегә алай килешми икән шул...

Әти, бераз җилләнгәннән соң, атның аркалыкларын күтәреп, йөгән тезгенен дугага бәйләде:

— Әйдә, Ләвәнти кибетеннән пыяла белән буяу гына алыйк та, бакырчы белән буяучыга сугылгач, чәйгә керербез.

Ләвәнтидә алган бер әрҗә пыяланы әти, яны белән саламга утыртып, арбаның нәкъ урта бер җирендә, бер якка да аумастай итеп нытытып бәйләгәч, буяучыга киттек.

Буяучының арбасы тулы зәңгәргә манган киндер. Алары ирләргә күлмәклек. Арада чәчәкле итеп манганнары да бар. Анысы алача. Буяучы агайның кулы беләгенә тикле зәп-зәңгәр. Ул этидән бармак озынлыгы, урталай ярылган тамгалы сөям кисәген ала да шуның киндер башына тагылган икенче яртысын эзләргә тотына. Тапканнан соң ике яртыны бергә куеп карый да киндерне этигә суза:

— Менә киндер. Мә, рәхәтлән!

Аннары бакырчыдан самоварны алып чыктык. Шуннан соң безнең эш бетә, ырып-ерып урамнан барганда бер авылдаш очрый да алар эти белән киңәшеп алалар.

— Бәшир, син чәйгә кемгә кермәкче? Тау башы Ивангамы, әллә сәгатьче Метригәме?

— Юк, аларга кермибез, — ди эти. — Аларга базарчы куп төшә. Бер тиенлек маржага керик. Очсызгарак та килер, сырасы да тәмле була.

— Әйдә алайса. Аның самовары да зур, чәй эчкәнгә дә бер генә тиен ала.

Чәйгә кергәч, эти белән әлеге авылдаш, үзләре түргә узып, самовар янына утырдылар. Аның малае белән безгә калын гына бер телем калач белән бер стакан йорт сырасы тоттырдылар. Без, чәйгә берәр тиен түләмәс өчен, өстәлгә якын да килмичә, ишек янында гына утырдык.

Кайткан вакытта мин инде арба төбендә үрле-кырлы сикерүдән дә, эчкә кату чыгудан да курыкмый идем. Чөнки эти, пыяланы ватмас өчен, атлатып кына кайта. «Базары уңган» атналарда аның чырае да ачык була. Арбаның үрәчәсенә җайлы гына итеп утыра да, әллә кайдагы еракларга караган килеш, авыз эченнән нидер көйләп тә куйгалый. Ара-тирә миңа борылып берәр җылы сүз дә әйткәли, аркадан сыйпаган чаклары да була...

Шундый вакытта эти миңа алай бик ук каты өрәкле кеше түгелдер шикелле дә тоела башлый. Аңа сеңелбрак утырасы, тагын берәр ягымлы сүз ишетәсе, һич булмаса, дилбегәне сорап алып, атны үзем тотып кайтасы, шулай итеп үземнең «дәү үскәнне», «эшкә ярый башлаганны» да күрсәтәсе килгәли. Тик әллә кыюлык җитми, әллә бүтән берәр нәрсә тыеп тора, нидер «җибәреп» бетерми. Миңа ул турыда уйланып, омсынып кына калырга туры килә иде.

## III

Менә эти озын себерке белән, зур-зур селтәнеп, ямь-яшел ишек алды чирәмен, я урамны себереп йөри. Алмагачлар чәчәккә бөреләнгән. Урам буендагы канәфер куакларының шау чәчәккә күмелеп, бөтен тирә-якка хуш ис бөркеп утырган чаклары. Бу тирәдән узучы яшь җилбәзәк, бигрәк тә кызлар, канәфер чәчәгенең урам якка салынып торган зур-зур тәлгәшләренә сокланып, бу тирәдән аерылып китә алмыйлар. Узып киткән булалар да кыяр-кыймас кына яңадан әйләнеп килләләр. Тыкрыкка кереп күренмәс булалар да бераздан, күзгә чалынмаска тырышып, тагын коймa буена килләләр. Чәчәкне бик сорарлар иде, эти шунда, кыюлыклары җитми.

Канәфер шундый шау чәчәктә вакытларда, кайчакны безнең тирәгә аргы якның Мөхти дигән акылга сайрак бер карт егете килеп чыккалый торган иде. Битен коңгырт сакал-мыек баскан, аягында ыштыр белән чабата, өстендә кулдан суккан ашъяулык төсле кызыл шакмаклы күлмәк. Ул кайчандыр кышкы буранда адашып аяк бармакларын өшеткән дә хәзер, әллә ничек, бик җайсыз итеп, алга таба йөгенеп, бер атлаган саен калкынып, аягының ярты табанына гына басып йөри. Шулай да үзе бик таза, җәй буе кетү көтә, чыбыркыны бик хәтәр шартлата.

Шул Мөхти этинен урам себерә торгач бакча турысына килеп житүен көтеп тора да балалар шикелле ялынырга тотына:
— Карале, Бәшир абзый! Миңа шул чәчәгеңне кечтеки генә өзеп бирче, ә?
Эти егетне кире борып та җибәрми, бик ашыгып чәчәк чемнәрен дә сындыртмый. Себерүен һаман дәвам иттереп:
— Ниямәрсәгә кирәк соң чәчәк сиңа? — дигән була.
Мөхтинең йөзендә, елмаюны хәтерләтердәй, бер яктылык күренеп китә. Ул нәрсәдәндер уңайсызланган, оялган да шикелле. Кесәсеннән кечерәк бер шешә дә чыгара. Үзе, кыенсынып, читкә караган килеш, нигәдер бөкрәя төшеп кет-кет көләргә тотына:
— Әнә, кызлар ич, Бәшир абзый, кызлар! Без сиңа кияүгә чыгабыз, диләр, хи-хи-хи. Тик перван башта туйга тикле син безгә шул чәчәктән ислемаи ясап бир, дип йөдәтәләр, хи-хи-хи...
Эти, себерке сабына таянып, Мөхтигә карап тора башлый.
— Ярар, бирим инде алай бик кирәк булгач. Тик туеңа мине дә чакырырсыңмы икән соң?
Мөхти, куанычыннан нишләргә белмичә, кулларын уа-уа, баскан урынында тыпырдарга тотына.
— Чакырам, Бәшир абзый, җир йотсын, чакырам! Син түр башында булырсын.
Эти, койма аша үрелеп, Мөхтигә өч-дүрт чем канәфер чәчәге өзеп бирә.
Мөхти, чәчәкне йомарлап бүреге эченә тутырганнан соң, бик канәгать кыяфәттә үз ягына төшеп китә. Тыкрыкка керүе була, кычкырып җырлап җибәрүе була:

Яшел сабыным,
Зәнгәр сабыным,
Улак башында, жанкаем...

Бер сүзә да, җырының кайтавазын ишетергә теләгәндәй, беравык тынлап бара. Аннары җан-фәрманга тагын шул ук җырны кабатлый.
Узган ел да шушы ук җыр иде, быел да шул ук. Аның сүзләре артмый да, кимеми дә. Шул җыр сабан туе кичендә кызлар уенында җырларга да ярый, басуда көтү артыннан йөргәндә дә.
Шунда яшь-җилбәзәктән берәрсе көлеп җибәрсә, андыйларны эти һич ошатмый иде:
— Ниярсәгә тешеңне ыржайттың? Кем көлкерәктер бит әле — синме, диванамы?

## IV

Безнен урам буендагы агач бакчасына, әллә андагы ямап да үчарланып үскән шомырт агачына, әллә карт миләшкә, сандугач ияләнгән иде. Аны ел саен көтеп ала торган булдылар. Кичләрен сандугач сайравын якын-тирә күршеләр белән капка төбенә җыелып яратып тыңлыйлар. Әгәр берәр кичне сандугач моңы ишетелмирәк торса, борчыла башлый торганнар иде.
Җәй башының бер иртәсендә сандугачны үле хәлендә таптылар. Миңа, ялан аяклы пырдымсыз бер малайга, монда искитәрлек берни дә юк иде. Бакчаларда, әвен тирәләрендә андыйны азмы очраткан! Әмма этинең зур гәүдәсе, сакаллы башы белән шушы кеп-кечкенә кошчыкның үле гәүдәсе өстенә иелүен, аны дәү куллары белән кадерләп тотуын күргә, мин сәерсенеп калдым.
— Кайсы имансызының эше бу? — ди эти. — Кемгә дөнья тарайган? И наләш! Муеннары сынгыры!
Озак кайгырышкан, уйлашканнан соң, сандугачны Әхәт дигән күрше егете үтергәндер дигән фикергә килделәр. Аларча моның нигезе дә бар

икән. Безнең апайның аулак өйләрдә, кичке уеннарда шул усал егет белән бергәрәк булуы, бер-берсенә ниндидер шыпырт сүзләр әйтүләре минем дә күзгә чалынганы бар. Моны әти белән әни дә беләләр, тик апайның бу эшен һич өнәмиләр икән. Ник дигәндә, әгәр эш зурга китә калса, апай шул йортсыз-җирсез батрак егеткә чыгып харап булмагае дип куркалар.

Менә шул Әхәт кичен апай белән сөйләшеп утырганда, сандугач тавышы боларга сөйләшергә уңайсызлаган да, янәсе, егет аны агач башыннан бәреп төшергән була. Әти шундук аны:

— Һи, зимагур, кансыз! — дип, кат-кат сүгеп ташлады.

Әгәр Әхәт бу йортка тагын берәр тапкыр аяк басасы булса, әти аны уңлы-суллы яңакларга булды. Монысы мине сагайтты да, кызыктырып та куйды. Әти яңаклаганда Әхәт нишләр икән? Яшьрәк чагында әти суккач, аның бармак эзләре фәлән кешенең яңагында әллә ни көнгә кадәр кара көеп, күпереп йөргән, диләр бит.

Сандугачны шомырт төбенә әти үз кулы белән күмде, каберен учлары белән тигезләп куйды. Әхәтләр ягына йодрык күрсәтеп тагын бер янап алды:

— Бер килеп капмассыңмы әле, ристан! Мин сиңе!..

Әти лапас тирәсенә китеп күренмәс булуга, югары өйдән елардай булып апай килеп төште. Әнинең иңбашына ябышып:

— Нахак, нахак! — дип пышылдады. — Ходаем! Белмәгән, күрмәгән көйгә! Нишләп ул тисен? Ничек кулы барсын? Юк, юк! Килгәне дә юк, тигәне дә юк! Нахак бу! Нахак!..

Күреп торам, әни ышанырга да, ышанмаска да белмичә ике ут арасында калды.

— Тик торганда ник үлгән соң?

— Мин каян белим? Я карчыга типкәндер, я әҗәле җиткәндер...

Әни белән апай шуның белән баш ватып торганда, күрше кызлары мине, пышылдап, үз яннарына дәштеләр. Нигә бу хәтле әтәләнәләр, нигә бик ягымлы сүзләр әйтәләр? Юкка гына түгел икән. Койма ярыгыннан күзләрен елтыратып, берсен берсе бүлдереп юмаларга тотындылар:

— Гомәр җаным! — диләр болар. — Шул тирәдән эзләп карасана: сандугачның канатымы, я булмаса, берәр каурыемы төшеп калмадымы икән?.. Бик тә кирәк иде, бик тә!

Мин моның сәбәбен соңыннан гына белдем: сандугач канаты — сөйдергеч икән! Әгәр сандугачның я каурые, я канаты белән егетнең берәр җирен сыйпасаң, ул егет кызны шул сулышта ук ярата башлый икән...

## Язгы сабан туйлары

### I

Сабан туен, язның бу шау-шулы, ыгы-зыгылы һәм шатлыклы якты бәйрәмен без, малайлар, кар җепшекләнә башлагач ук көтәргә тотына идек. Менә шәкерт малайлар мәдрәсә белән ике арада шакы-шокы агач башмак сөйри башлый, мәдрәсәдән кайтышлый урам тутырып кар атышалар. Ул чагында инде күз «тышта кала», күк йөзенә күтәрелеп карасаң, күзләрең чагыла. Көн уртасында тып-тып түбәдән тамган көмеш тамчыларда яз кояшы чагылып китә, түбәдән ватылып төшкән боз кисәкләренең зыңгылдавында да күптән үк сагындырган яз авазы яңгырый.

Иртә белән чыксаң, тыкрык буендагы сәрби агачында боргалана-боргалана эшләки сайрый:

— «Эшләки, эшләки, эшләмәсәң хаста ки», — ди. Җимеш бакча-

сына, түр тәрәзә каршындагы миләшкә, шомырт агачына кызылтүшләр килә. Ул көяз кошларның әле мамык бүрекләрен күпертеп, әле кызыл түшләрен киереп тәрәзә каршында боргаланулары сабан туе күлмәген күрсәтергә чыккан купшы кызлар көязлегенә охшамыймыни?

Алар артыннан озак та үтми, беркөнне йокыдан торуыңа, укалы муеннарын елтыратып, сыерчыклар кайтып төшкән була. Алар ерак илләрдән кайта торгач, бик арыганнар, ябыгып беткәннәр. Шулай да өйләренә кайту шатлыгыннан сайрамыйча түзә алмыйлар. Чыгалар өйләрдән апайлар, җиңгиләр, бала-чагалар. Китә куану, соклану. Кайсы карга тәгәрәп китә, кайсы:

— Авырлыкка җиңеллек! — дип сикергәләргә тотына.

Беркөнне карыйсың, мәчет янындагы мәйданда кар эреп беткән дә ашъяулык кадәр генә җир чыккан. Салкын кар суы ялан аякны өтеп-өтеп ала. Соңыннан аягың чебилисен дә, моның өчен өйдәгеләрдән эләгәсен дә беләсең. Шулай да кайсы гына малайның, аяк киемен салып ыргытып, эссе табага баскандай, шул юеш, йомшак җир өстендә сикергәләгәне юк икән?..

Ә сабан туе һаман килә, һаман якыная бара.

Менә беркөнне, кичкә таба, тау астындагы тын инешкә кинәт әллә ни була. Ул, авыр эшкә тотынган сыман, уфылдый, көчәнергә керешә. Ул да түгел, кыш буе өстен каплап, тынын буып яткан калын бозны шатыр-шотыр китереп ватып ыргыта да кабарынып, бүртенеп өскә бәреп чыга. Килеп чыга да, күрәсең, яз кояшы аның башын әйләндерә торгандыр, ул шунда котырына, тилерә башлый. Шашынудан кая барып бәреләсен белмичә, башта авыл уртасындагы күпергә, аннары зират янындагы тегермән буасына ташлана. Берни дә каршы тора алмый котырынган ташуга! Юлында нәрсә очрый, һәммәсен, сыер теле белән ялагандай, сыпырып кына алып китә: карт өянкеләрне сындырып ыргыта, күпер төбендәге тау-тау тирес, кар, боз өемнәрен кубарып ала, иске мунчаларны, печән кибәннәрен агызып китә.

Шул кичтән башлап авыл тынлыгына яңа аваз өстәлә: ташу шаулавы. Иртән торып чыгасың — шаулый, төнен тыңлыйсың — шаулый. Китә шуннан сәлам яндырып ут көймәләре агызулар, китә су буенда чыр-чу килеп сикерешү, шаярышулар.

Ул арада инде түбәрәк урыннар бөтенләй ачылып, җир өсте ала-кола була, тик басу юллары гына эреп бетә алмыйча, боргаланган соры елан булып, сыртларын тырпайтып яталар. Сәрби агачларының ябышкак бөреләре бүртеп чыга. Кыяр-кыймас кына борын төртә башлаган чирәмлектә малай-шалай сабан туе алдыннан көч сынашырга тотына. Бер мактанчыграгы икенчесенең каршысына басып, нәкъ әкият батырлары сыман:

— Алыштанмы, салыштанмы? — дигән була.

Каршы чыгасы малайның да сер бирәсе килми. Ыштанын күтәргәләп, я бүреген төзәтеп:

— Алыштан да булыр, салыштан да!.. — дип куя.

Бер-берсенең биленнән кысып алалар да әй тотыналар әйләнергә. Әйтерсең, чын батырлар. Әле берсе алып карый, әле икенчесе...

Сабан туе дигәнебез юлдасын юлда инде. Шулай да килеп җитми әле. Әмма ул бер көн узган саен, гел якыная бара. Аның якынаюын кешеләр генә түгел, хәтта атлар да сизә. Яшь айгырлар, байталлар, чабыш атлары, аран тәрәзәләреннән башларын сузып, озак-озак кырлардан, болыннардан агылган җылымса яз һавасын иснилэр. Иснилэр дә дәртләнеп, дулкынланып кешнәргә тотыналар.

Мәйдан тотасы атларны бер эшкә дә җикми башлыйлар. Эчләре җыелып килсен, сулышлары иркен булсын өчен, аларга ипи белән солы гына ашаталар. Койрыкларын кыска гына бәйләп, аякларын «кызды-рырга» йөртәләр. Алар басу юлы белән иртүк чыгып китәләр дә әллә

кайлардан әйләнеп, тирләп, тартылып, тез тинентен пычракка батып кайталар.

Чабыш атлары узып барганда без, уеннарны онытып, тып-тын кала идек. Шулар арасында кайсыдыр канатлы булса? Атның канатлылары да була ди бит. Болай карап торырга гел безнең сука атлары шикелле ук алар. Әмма андыйларның яшерен канаты була, имеш. Ул канатын беркемгә дә, хәтта хуҗасына да күрсәтми икән. Тик төнлә йоклаганда гына иркенләп канатын җәеп сала, ди. Шуның өчен шул төнлә белән ат янына чыкканда ерактан ук тамак кыргалап, дәшкәләп, ничек тә тавыш биреп барырга кирәк. Югыйсә, кинәт өстенә барып чыксаң, ат канатын җыярга өлгерә алмыйча, гарипләнеп кала икән дә, аннан соң гомер буена мантымый, имеш ди.

Әнә, сөйлиләр бит. Әллә безнең авылның, әллә икенче авылның бер кешесе шулай дәшми-тынмый гына аранга барып кергән икән, атның нәкъ канатларын җәеп йоклап яткан чагы булган. Шунда аты телгә килеп әйткән, ди:

— И Сәйфетдин, Сәйфетдин, үз бәхетеннән үзең кадерен белмәдең. Моннан соң гомергә дә юньле ат чырае күрмәссең, — дип. Үзе бераздан ук чирләп үлеп тә киткән, ди.

Канатлы ат, экияттәге корчаңгы тай шикелле, күрер күзгә бик тә ябык, бер дә күз төшерерлек, кеше кызыгырлык булмый, имеш ди. Без, ике күзебезне дүрт итеп, шундыйрак атка текәләбез: шунысы түгелме икән, әллә менә монысымы икән?.. Ник дисәң, һәрбер малайның күңел түрендә мавыктыргыч бер яшерен уе бар: дәүрәк үскәч, ул шундый канатлы атка атланып, әллә кайларга, икенче бер ямьле, матур дөньяга очасы бар кебегрәк сизенеп йөри...

Һаман якыная сабан туе, менә килеп тә җитә. Үзенең көрәшчеләре, чабыш атлары, төрле төскә буялган күкәйләре, колга башындагы кызыл башлы сөлге-тастымаллары, эрбет чикләвекләре, чуклы конфетлары һәм гомергә онытылмаслык гармун көйләре, уен-җырлары, кыскасы, бөтен шау-шуы һәм бизәкле, чуп-чуар төстәге төрле куанычлары белән дәп-дәү булып, шаулап, ыгы-зыгы кубарып безнең авылга сабан туе әнә шулай килә иде...

## II

Иртәгә сабан туе дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән! Көне буе урамнан кайтып кергән юк, телең чыгардай булып арылган. Инде күзләрең дә йомылып, йоклап та барасың. Юк, кая ул! Йоклыйм гына дигәндә, күрше малайларының сабан туена дип тектергән яңа күлмәкләре, камзуллары, я булмаса яңа кәләпүшләре күз алдына килә. Кайсысының кәләпүше чем-кара, кайсысыныҗ зәңгәр хәтфәдән. Чуклы кызыл кәләпүш булса, анысы инде бигрәк тә күзне кыздыра. Сузылып кына үзеңнең баш очына әзерләп куйган киемнәреңне капшап карыйсың да авыр сулап куясың.

— Йокла, улым, йокла, — ди әни. — Юып җибәргәченнән, хәзер синең кәләпүшең дә бер дә ичмасам яңадан ким түгел!

Өммикамал апай белән алар казанда иртәгә бала-чагага өләшәсе күкәйләрне, суган кабыгы салып, буяп маташалар.

Койма буеннан, чулпыларын чылтыратып, үзара көлешә-чыркылдаша, кызлар узып бара. Баш очындагы тәрәзәдән язгы җылымса җирнең бераз гына татлырак, бераз гына ниндидер үлән исләрен дә хәтерләтә торган ягымлы исе бөркелә башлый да, шушы рәхәткә тирбәлеп, йоклап та китәсең.

Иртә белән шыгырдап ишек ачылган тавышка уяндым. Кая ул бүтән көннәрдәге шикелле ялкаулану, киерелеп-сузылып, иркәләнеп яту! Күлмәк белән чалбарны эләктереп, сикереп тә төштем, киенеп тә алдым.

Кичтән никадәр генә хәстәрләнеп ятсам да, барыбер соңга калганмын. Әни кемнәр беләндер сөйләшә, ишек янында кемнәрдер кыштырдый. Аларның шәүләләре генә күренә. Ник дисәң, әле таң яңа беленеп килә. Бүтән көнне булса, болай караңгыда кармаланмаслар, ут алган булырлар иде. Әмма мин бүген юри ут кабызмыйлар дип уйлыйм. Чөнки әгәр яктыртсаң, сабан туе иртәләрендә генә була торган бу үзалдына бер моңсу мизгел юкка чыгар да балалар куанычының кайсы ягыдыр китек булыр кебек иде.

Ул арада тагын бер төркем килеп керде. Әни күчтәнәчләрен ала да ишек янында шәүләләре генә шәйләнеп торган эреле-ваклы балалар каршысына килеп баса:

— И оланнар, сезне кем балалары дип кенә әйтим соң? — ди.

Тегеләрнең тыелып кына хихылдаулары ишетелә. Шаян гына балалар тавышы:

— Танымыйсынмыни? — ди. — Бәдернисә белән Хәерниса, Халисә белән Мәликә ич без!

Әни бот чабып үкенергә тотына:

— Әй аллам, мена син! — ди. — Оятлы була язганмын лабаса! Туганнар икән бит сез!

Берсе артыннан берсе икешәр, өчәр, дүртәр булып керә торалар, күчтәнәч алып чыга торалар. Аларның якынлыкларына карап, әни күбесенчә кызыл башлы тастымаллдан әтмәлләгән кечкенә капчыкларына, я йомырка, я кызыл билле прәннек, я ак төш салып чыгара. Туган-тумача, кардәш-ыруга кергәндә үзеңә дә шундыйрак күчтәнәч бирәләр. Базар прәннеге алырга, я ак төш пешерергә хәленнән килми икән, төш дигәнне арыш оныннан да куырып куялар. Сабан туенда нинди генә күчтәнәч бирсәләр дә гаепләштән, үпкәләштән булмый. Хәзинәдә бары. Ни генә булса да ихлас күңелдән.

Шулай таң тишегеннән торып, күрше-күләнгә, аргы һәм бирге очтагы кардәш-ыруга кереп-чыгып йөри торгач, кояш чыга, көн була. Апай пешергән бәйрәм коймагын аннан-моннан гына капкалап урамга ашыгасың.

Капка төпләре тулы бала-чага. Китә мактану, китә кәпәренү. Кем күпме йомырка җыйган, кызылы күпме дә, бишнис күпме? Әчтерхан чикләвеге белән конфетлар кемнәргә эләккән? Мактанчыграк малайлар, көрәшчеләр кебек кыланып, күкәйләрен чарт та чорт маңгайларына бәреп ваталар да шундук мүкелдәтеп ашап та куялар. Маңгай кызара кызаруын, кайберсенең күбеп тә чыккалый. Һи, аның ише генә! Сабан туе бит!..

Ул арада инде урам тагын да җанлана төшә. Аллы-гөлле яңа күлмәкләрен киеп, бидәр-бидәр эре чәчәкле чуар алъяпкычларын ябып капка төпләренә курчак шикелле кечкенә кызлар килеп чыга. Уникешәр бала итәкле зәңгәр, яшел, алсу күлмәк кигән купшы кызлар, күз-күз басып, чулпыларын чылтыр-чылтыр китереп каядыр йомыш белән баралар. Ак, зәңгәр, я алсу сатин күлмәк өстеннән җинсез кара камзул киеп, күләпүшләрен кыңгыр салган мут егетләр, гармунчыны ияртеп, каядыр үз юллары белән китәләр. Капка төбенә бәйрәмчә киенгән картлар чыгып баса.

Тагын бераздан урамнар атларының ял-койрыкларына кызыл чуклар таккан егетләр, яшүсмер малайлар белән тула. Алар йорттан-йортка кереп, шау-гөр килеп, йомырка җыеп йөриләр. Шул арада, гармун тартып, җырлап та җибәргәлиләр. Сабан туеның беренче көнендә шул йомырка белән мәйдан ачыла. Башта балалар көрәшә, аннары олылар тотына. Йөгерешәләр, чүлмәк ваталар, аркан тартышып уйныйлар, хәтта ат чабышлары да булып ала.

Әмма болар һәммәсе дә сабан туеның бисмилласы гына әле.

Безнең Арча ягында сабан туеның каймагы, иң шау-шулы, иң күңелле өлеше, көрәш белән чабышларның да иң кәттәсе икенче көнне башлана.

III

Менә бер заман югары очтан, үзенең салпы колаклы, дәү корсаклы күк алашасына атланып, Гыйбаш абзый килеп чыга. Аның кулында озын гына ап-ак сөян колга. Бүген инде ул кичәге шикелле үзенең егетләре белән өй борынча кереп йөрми, юк. Бүген алар ике сабан туе арасында килен булып төшкән яшьләргә, житкән кызларга гына туктыйлар.

Без, малайлар, койрыкларына тагылгандай, шушы атлылар артыннан теркелдибез. Алар чаба икән, без йөгерәбез, берәр йортның капка төбенә килеп туктыйлар икән, койма ярыкларына, киртәләргә сарылабыз.

Мин үзем, күбесенчә, Гыйбаш абзый тирәсендә бөтерелә идем. Зерә дә кәмит кеше ул Гыйбаш абзый. Кайчан гына булмасын, башына туз-мый да, иңармый да торган шул ямьшәйгән ак киез эшләпәсен, өстенә ачык изүле зәңгәр киндер күлмәген кияр, аның өстеннән озын киндер алъяпкычын ябар. Аягында сабан туе хөрмәтенә әле беренче генә тапкыр киеп чыккан озын кунычлы ап-ак оек, яңа кәвеш кебек, баскан саен шыгырт-шыгырт итә торган өр-яңа чабата. Дәү битле, озын гына борынлы, түгәрәк сакаллы, борын эче белән тыңкышланып сөйләшүче аз сүзле, салмак кына бер пошынмас бәндә. Аның бүтәннәргә охшамаган юньле яклары да күп кенә. Сабан туенда йомырка белән сөлгетастымалны, анысын инде — ташка тамга салган — һәр елны ул җыя. Җир бүлгәндә, печән өләшкәндә шобага белән сажин таяклары да аның кулында була. Тик аның белән генә бетми. Гыйбаш абзый, халыкка йөрергә якын да, җайлы да булсын дип, тау кырыйларын казып яңа юл сала; кырын-ярын юлларны әледән-әле тигезләп тора, язын-көзен томалана башлаган чишмәләрне ул тазарта, «мал эчерергә дә кирәк, урак өстендә үзебезгә дә су якын булыр» дип, әллә кайлардагы басу түрләрендә яңа чишмәләрне ул казып чыгара. Бу изге хезмәтләре өчен аңа рәхмәт яудыралар, аны бөтен авыл ярата.

Әмма олылар аның турында бүтәнчәрәк тә сөйлиләр. Имештер, шундый эшләр белән бик озак мавыккан көннәрдә Гыйбаш абзыйның хатыны еш кына тавыш күтәрә икән:

— «И, хода бәндәсе! Ягарыңа утының, ипи салырга оның юк. Кая йөрисең? Ни пычагыма дип бөтен көчеңне алабай койрыгы астына ташлыйсың!» — дип пыр туздыра, имеш.

Олылар, мыек астыннан гына елмайгалап, аның киез итекне бик оста басуы турында да сөйли торганнар иде. Гыйбаш абзый баскан итек, никадәр генә озак киелмәсен, берничек тә тузмый, дөресрәге, бөтенләй туза алмый, кешенең гомере буена җитә, ди. Тик шул ягы гына шәп үк түгел, диләр, бу баскан итекне киюче бик сирәк була икән. Ник дигәндә, Гыйбаш абзый йонны да алып кала, басып бирергә вәгъдә дә итә, тик басарга гына ашыкмый, имеш. Кайчакларны аның вәгъдәсе хәтта әллә ничә елга сузыла, йонны чормада көяләр турап бетерә, ә итек дигәнең һаман басылмый да басылмый, ди. Шунысы кызык, аннан барыбер өмет өзмиләр, хәтта ачуланмыйлар да, тик, көяләргә азык итеп, яңа йон гына китерәләр икән.

Хәзер менә шул абзый, җиткән кызлар, яшь киленнәр саен туктый торгач, ялкау алашасына чөңгерә-чөңгерә, безнең капка төбенә килеп туктады.

Безнең апай сөлге-тастымал сугуы, төрле йорт әйберләрен оста чигүе белән дан тоткан кыз булганлыктан, бүтәннәрдән уздырып, сабан туена ел саен берәр зат әйбер бүләк итә торган иде. Менә хәзер дә

капка төбенә килеп бөялгән егетләр, атларын биетеп, тәрәзәгә карыйкарый яман да телләренә салынырга тотындылар:

— Кая сон? Өммикамал өйдәме? Сөлгеләре чөйдәме?

— Егетләр! Бәшир абзый үзе чыккан, зурлаган!

— Зифа тәтәй, нихәлләр? Көттегезме? Без килдек!

Әни, авызын каплый төшеп, елмаебрак өйалды ишегеннән карап тора иде. Атлы егетләр арасында Әхәтне күргәч, ул этигә текәлеп сагаеп калды. Әхәт турында әйтеп куйган сүзе бар лабаса. Каты бәрелмәгәе! Әмма этинең елмаюын күргәч, әни, йөзе ачылып, рәхмәт әйткән сыман башын игәләргә тотынды.

— Шуна сәерсенеп торам, — диде эти. — Яшь килен безгә төшмәде ич, әнә, күршедә! Монда ялгыш туктадыгыз түгелме?

Алдарак торган егетләр шаркылдап көлделәр.

— Ха, ха, ха! Инде дә, Бәшир абзый, хитри син! Бер дә ялгыш түгел, тач өстенә бастырдык.

— Елнын елында шулай бит!

— Өммикамалнын бүләге бөтен сабан туена ямь бирә!

— Кая сон үзе, ник чыкмый?

Апай әллә кайчан ук әзер иде. Ул шәл яулыгынын бер почмагын авызына кабып, йөзен бераз яшеребрәк килеп чыкты. Бүләк итәсе чигүле ашъяулыгын, ике башыннан тотып, баш очына күтәрде. Күе яшел болын уртасында зур чәчәк түтәле, почмакларына тагын шундый алмкызыллы чәчәкләр үскән.

Моны күрүгә, егетләр, берсен берсе бүлдереп, бүләкне күкләргә чөеп мактарга тотындылар:

— Егетләр! Монда карагыз!

— Ай, ай, ай! Иллә дә зурладын, Өммикамал!

— Күзеннен явын алырлык!

— Жепләре ефәктәндер монын, инәләре көмештер!

Кайсы-берсе шау-шу арасында:

— Бәрәкалла, ай рәхмәт! — дип кычкырып җибәрә.

— Бер урынына ун булсын, эшләрен гел ун булсын!

Апайнын өсте-башы матур, йөзендә шатлык уйный. Ул хәзер берәүдән дә битен яшермичә, мактаганга кыләнеп, бөтенесенә елмаеп тора иде. Бәлки, ул арттарак басып торган Әхәт абыйга шулай елмайгандыр?..

Шулай шауладылар, гөрләделәр дә, атларын уйнатып, күрше йортка таба кузгалдылар. Бер шаяны кыла-килешкә:

— Егетләр! Тәрәзәдән кызыл башлы сөлге күренә, сөлге! — дип кычкырды.

Икенче берсе ана ышанмаган булды.

— Син сон каян беләсен? Әллә сөлге, әллә тастымал! Әллә ун ягы белән торган килен, әллә хәтәр төшләр күреп уянган!

— Кит аннан, нигә сөлге бирмәсен? Авызыннан җил алсын! Әзәк иле хәтле Әзәк иленнән килепме? Фагыйлә шикелле унган килен була торыпмы?

Өй эчендә ыгы да зыгы. Бала-чага, яшь җилкенчәк баскыч төбендә, ишек алдында сибелә. Кызлар, чырык та чырык, тәрәзә тирәсендә бөтерелә башлый. Килен үзе, сабан туе бүләген әллә кайчан ук әзерләп куйган булса да, бераз каушый төшә. Шулай исемене бөтен урамга шаулатып, телләренә салынып торучы шул хәтле егет-җилән, ир-ат каршысына ничек оялмыйча чыгып басарга? Әмма чыкмыйча да булмый, һаман дәшәләр, һаман такылдыйлар.

Менә, ниһаять, яшь килен, кызарынган йөзен яулык почмагы белән каплый төшеп, баскыч төбенә килеп чыга. Анын кулындагы кызыл башлы сөлгене күрү белән китә соклану, китә мактау, китә һай да һу!

— Егетләр, күрдегезме сез моны? Сөлге! Сөлге!

— Әйтәм бит, Әзәк иленнән төшкән кыз сынатмас, сер бирмәс дип әйтеп! Тәки рас чыкты!

— Һай рәхмәт, килен! Сер бирмәде килен, маладис!

Яшь килен, күңеле күтәрелеп, үзе дә бер-ике сүз әйтеп куйды:

— Сынатырга, без кемнән ким? Бездән генә калмаган, әби-бабай йоласы. Бәхетле егеткә насыйп булсын инде! Гаеп итмәгез!

— Нәрсә син тагын? Кая инде ул гаеп!

— Ул турыда тешеңне дә агартма! Нинди гәеп тә, нинди кыек ул?!

— Колганың башына эл, Гыйбаш абзый! Беренче килгән атка бу!

— Кайда да ярый! Хет батыр калганга бир, хет баш килгән атка!

— Әйе, әйе, гомерләре озын булсын, бала-чагалары мул, абзар тулы мал, авызлары бал да май булсын. Аллаһы әкбәр, амин!

Гыйбаш абзый үзе, гадәтенчә, бер сүз дә әйтми, тик аты өстендә авызын ерып, «әйе, әйе!» дигән сыман, сакалын гына селки, сөлгене колганың иң югары очына ук бәйләп куя да кат-кат битен сыпырырга тотына. Аннан соң тагын шаулап-җырлап, бөтен төркеме белән, икенче яшь килен йортына китеп баралар. Без — алар артыннан...

Әмма яшь киленнәр ул елны шактый ук күп төшкән, күрәсең, безнең түземлегебез озакка җитмәде. Күтәрелеп карасак, кояш әллә кая менеп киткән. Шуның өстенә, өздереп ашыйсы да килә икән, тик кызыкка мавыгып кына онытылып торган.

Капкадан керсәм, өй алдыннан үзенчә бик сәер генә итеп, көйләп-көйләп сөйләгән саңгырау гына ягымлы тавыш ишетелде. Кибәхуҗаның Җиһан тәтәй тавышы бит бу! Аның шикелле шулай мәзәк кенә көйләп, ике сүзнең берендә бик озын итеп «и-и-и» дип сузып сөйләүче бүтән беркем дә юк. Шул, шул!..

## IV

Дөрес икән, табынның түрендә үк, аякларын бөкләп, Шиһаб җизни утыра. Ап-ак күлмәк өстеннән җиңсез камзул кигән, башында зәңгәр кәләпүш, бармагында көмеш балдак. Матур да, бик көяз дә ул безнең җизни. Башка тегүчеләр кебек, ул да ак чырайлы кеше болай, тик хәзер, йөзе килгән бодай коймагы төсле, шактый ук кызара төшкән. Ник дисәң, эти янындагы бал чиреге яртыга гына калган. Шиһаб җизни ике тезенә таянып тамагын кыргалады да, башын чайкый-чайкый, җырлап җибәрде:

Хәмер эчү харам диләр
Мөхәммәт өммәтенә.
Җырламас җиремнән җырлыйм
Син бажай хөрмәтенә...

Аның янында минем әни шикелле үк озын буйлы, озынча чибәр йөзле, әмма аннан бераз яшьрәк тә, житезрәк тә Җиһан тәтәй утыра. Мине күрүе булды, бөтен чырае кояштай яктырып та китте. Күз тирәләре бигрәк тә.

— Ай аллам, Гомәр түгелме соң бу, Гомәр үземе? И-и-и, ходаем, танымыйлар да торам, — дип башлады да тәтәй, әй китте берзаман матурлап! Әллә сөйли, әллә җырлый, әллә икесе дә бергә. Тик эреп кенә китмә! — Җизнәсе, күр әнә, бер генә кара монда, Гомәр кайтты ич, Гомәр! Карасана, егет булып җиткәнсең ич! Җизнәсе, әйтсәнә әле, урамда очраган булса, танымаган булыр идең бит, билләһи менә!

Кая инде ул! Әгәр, үземне генә очратса, Шиһаб җизни һич таныйсы түгел икән. Күрешми торган арада мин шул тикле дә үскәнмен!..

Җизни миңа елмаеброк карап торды да кесәсеннән нидер эзләргә керешә. Башта ян кесәләренә кереп чыкты, аннары күкрәк кесәсенә. Тора-бара чалбар кесәсен дә актарды. Ниһаять, сәгать кесәсенә дә сузылды. Ләкин эзләгәнен таба алмагач, «Син нитмә, бер җаен табарбыз

әле аның!» дигән сыман итеп ым какты да яңадан әти белән сөйләшә башлады.

Жизни Әтнә ягындагы Җүлби авылында язны язлап, тегүдән кайтып килә икән. Менә, өйләнеч булса да, безгә сугылырга булган. Күптән күрешкәннәре юк лабаса. Ә үзләре бәҗәйлар, бәҗәйларның да ниндиләре әле!

Жиһан тәтәй, мине сөйләштерә-сөйләштерә, чигүле читекләрен чыгырдатып, әни янынарак килеп утырды:

— Каяле, килче әле яннарыма, бер сөйимче әле!

Аларның ул вакытта үз балалары юк иде шикелле. Бәлки, шунлыктандыр, бәлки, бик бала җанлы булгангадыр, Жиһан тәтәй һаман минем белән булаша, мине сөйләштерә иде.

— И-и-и, гомерләр, гомерләр! Әле кайчан гына бишек баласы иде. Кайчан гына әлли-бәлли, ди-ди, миләш сиртмәләрдә тирбәтеп киткән идем. Менә син, ходаем...

Жиһан тәтәй минем, арык атның оча сөяге шикелле, әллә кая турсаеп торган шыксыз калак сөякләремә кагылгалап, ябык аркамнан сыйпаштырып, сөяргә тотынды.

Дөресен генә әйткәндә, Җиһан тәтәйне мин үзем дә бик ярата идем. Аның әнә шулай үтә ягымлы булуы миңа бик ошый, шулай бөтен барлыгы белән балкып, ничектер, бөтенләй чишелеп бетеп, чын күңелдән, үз итеп көлә белүе аның үзен дә сөйдерә иде.

Шулай сөйгәләп утыра торгач, Җиһан тәтәй кинәт кенә нидер исенә төшеп, кесәсен актарырга тотынды.

— Ай аллам, ходаем! Нәрсә күңелемне кытыклап, бимазалап тора дисәм! Онытып торам икән лабаса! Кая әле соң, каяле!

Ул күлмәк кесәсенә тыгылды. Кулына күп булып ияреп чыга башлаган чуклы конфетларның байтагысын кире төртеп төшерде дә ике-өчләбен миңа сузды.

Табында сыйланырлык хәтсез генә тәмле әйберләр күзгә чалынды. Бик күп суган салып, өстенә мул гына борыч сибеп китергән бер коштабак калҗа белән түбәләмә бер таба кетердәвекле карабодай коймагы кызыктырып тора. Әмма минем эшләр бик тәжел [1] иде. Билгеле, миннән башка мәйдан да ачылмаячак, атлар да чабышка китмәячәк, көрәш тә башланмаячак... Шуның өстенә, ишек төбендә, борынын тартып, Хәкимҗан ашыктырып тора. Аннан-моннан гына капкаладым да тагын чыгып йөгердем.

## V

Бакча артына йөгереп чыксак, аргы якның җил тегермәне янында — мәхшәр! Ындыр артларын, киндер җирләрен, тегермән тирәләрен — бөтенесен халык каплаган. Үзе чәчәкле болын өсте төсле чуп-чуар, әрлебирле кузгалып, кырмыска оясыдай гел кайнап тора. Шул халык дингезе өстендә иң күзгә бәрелгән нәрсә — озын колга, шул колга башында, бөтен дөньясына ямь биреп, күрәшкә дәшеп җилфердәп торган аллыгөлле сабан туе бүләкләре. Колга башындагы шул кызыл башлы сөлгеләр, тастымаллар, күлмәклек һәм чиккән дәстәрханнар: «Әйдәгез, тизрәк җыелыгыз инде!» дигәндәй һавада болганып, үзләренә дәшеп торалар. Бөтен халык — яше-карты — ишек алларына, бакча артларына чыгып карыйлар да:

— Әнә, мәйдан ачылган! — дип шул якка ашыга башлыйлар.

Хәкимҗан белән без дә киттек.

Хатыннар, кызлар, үзләренә зур бер төркем булып, җил тегермәне тирәсенә җыелганнар. Ул тирәләр — кып-кызыл да ямь-яшел. Гармуннарының колагына чиккән яулыклар бәйләгән гармунчы егетләр алар

[1] Ашыгыч.

яныннан, кызларның йөрәкләренә ут салып, уйнап-җырлап узалар. Күрше авыллардан мәйдан тотарга килгән көрәшче егетләр дә күбрәк шул тирәдә чуала. Алар узып барганда, кызлар, күзләрен елтыратып, берберсенең кабыргаларына төртешәләр:

— «Әнә, әнә!» — дип пышылдап калалар.

Хәкимҗан белән без, бөтен мәйданны айкап бер әйләнеп чыкканнан соң, атлар янына килеп туктадык. Чабышка барасы атлар тирәсендә үз ыгы-зыгысы. Атлар түземсезләнеп башларын чайкыйлар. Атланып барасы малайлар, «бераз булса да җиңелрәк булыр» дип, аяк киемнәрен салып, оекчан гына калалар. Колакларына җил кермәсен өчен, башларына яулык бәйлиләр. Ат хуҗалары атларының йөгәнен рәтләп, ялларын тараган булалар, тынычсызланып сыйпаштыралар.

— Булыр, алла боерса, баш килерсез, ходай боерган булса, — диләр. Малайга аерата ягымлы булырга тырышып тәмле тел белән соңгы киңәшләрен бирәләр: — Чыккач ук бик каты кауламасаң да ярар, үз җаенарак куй. Хайван үзе чамалый ул. Аягың белән кысма, башына сукма, алай итмә, болай итмә, диләр. Малайның аркасыннан кагып:

— Алла насыйп итеп баш китерә алсаң, бүләктән эш калмас, рәнҗетмәм, — диләр.

Бер кырыйгарак чүгәләп, боларның һәммәсен күзәтеп утыручы олы кешеләрнең үз гәпләре бар:

— Быел атларны каян җибәрмәкчеләр икән? — ди берсе. — Нурмаданмы, әллә Мончалка башыннанмы?

— Һә, таптың сүз! Мончалка башыннан буласы ди сиңа! Син нәрсә, кәҗә тәкәләрен чабыштырам дип белдеңме? Әнә нинди аргамаклар бар анда! Минҗан турысы үзе генә дә ни тора!

— Һай, һай, мин әйтәм, суырылган да инде Минҗанның турысы. Нинди нечкәргән! Корсак ничек җыелып килгән!

— Әйе, сөлек тә сөлек, бу да сөлек инде!

— Аның каравы күкрәк киң, сулыш киң! Корсак нечкә, күкрәк киң! Менәтерәк! Кара күкрәкне! Менә, бер колач!

— Байлыкта инде хикмәт. Икмәктә. Менә безнең үзебезгә дә такытокы. Ә ул кыш буе аңа күпме солы, күпме икмәк ашаткандыр дисең!

— Һе, солы, имеш! Бер ише атка солы ашатмагаең, әнә әлбә тугылап бир! Булмаганнан барыбер булмый ул. Нәсел дисәң, токымы шундый дисәң, әле анда тагын бер хәер.

— Әйе, шундый җиңел сөяклеләре була, канатланып кына оча диярсең.

Тагын шул серле сүзләр... Менә шул атлар арасында берәрсе канатлы булса, ә?! Күзләребез белән тагын чабыш атларының күкрәк тирәләрен, сырт өсләрен капшый башладык...

## VI

Мәйдан уртасына озын буйлы, сирәк кенә коңгырт сакаллы староста килеп чыкты. Өстендә кара казаки, аягында читек-кәвеш. Беркемгә дә сәлам дә бирмәде, берәүгә дә күз дә салмады, Гыйбаш абзыйга гына ым какты. Гыйбаш абзый:

— Күкрәк астына кермә, хәрәмләшмә! — ди-ди малайларны көрәштереп ята иде. Ул аяк чалып маташкан бер малайның түнкәеп чыккан арт ягына салмак кына итеп таягы белән сукты да староста янына килде.

— Маташма шул малай-шалай белән! — диде староста. — Олыларны көрәштерергә кирәк!..

— Соң, башларбыз, вакыт бар ич әле.

Гыйбаш абзый, таягы белән кешеләрнең аягына суга-суга, мәйданны киңәйтергә тотынды.

— Чиген, чиген! Күрмисезмени, кысып бетердегез! Нигә тораташ булып каттың? Киңәй, киңәй, диләр!

Әрсезләнә, кысыла торгач, теләккә ирештек: көрәшчеләрнең кунадай киң җилкәләре, бер-берсенең иңбашына терәлеп кан чыгардай булып бүртенгән кызыл йөзләре безгә дә күренә башлады. Ул арада кайсыдыр «һайт!» дип кычкырып та җибәрде, һавада ике аяк айкалып та китте, аякларның хуҗасы «дөп» иттереп, барып та төште. Төште генәме әле? Бөтенләй тәгәрәп үк китте. Әллә ничә урыннан:

— Булды, булды! — дип аваз салдылар. — Шәп салды Айбан, малатчина! Сызгырып кына барып төште!..

Әмма икенче яктан бүтән төрле кычкыра башладылар:

— Дөрес түгел, хәрәмләштеләр!

— Нәрсә лыкылдыйсың тагын?

— Хәрәмләшми, икесе дә Айбаннар бит! Күрмисезмени, яклашалар. Юри егылды ул, юри!

— Яңадан, яңадан!

Җиңелүче егет, кулларын болгый-болгый, кызарынып-бүртенеп, нидер әйтергә тырышып караса да булдыра алмады, тыңламадылар, яңадан көрәшергә куштылар. Теге егет тагын бер атып бәрде.

Җиңүче егет, халыкның усал сүзенә ачуы килгәндәй, сөлгесен кулында бөтерә-бөтерә, күкрәк киереп мәйдан уртасында айкалырга тотынды.

Әмма озак көттермәделәр. Гәүдәгә базык кына, киң җилкәле бер егет чыкты. Өстендә сары күлмәк, изүләре чишек, куллары озын, әллә тагын тезләреннән үк узып торалар.

— Кәче егете чыкты, Кәче! — диештеләр.

— Менә бу Айбанның сыртын сындыра да сындыра инде!

— Һа! Сындырмаска, — диде Сарник Галимҗан, — күрмисеңмени? Кручник ич ул! Ана нәрсә? Егерме потны уйнатып кына йөртә ул.

Солдат Мөхәммәтҗан кәкре башлы тимер таягына таянып, чүгәләп утырган килеш, Сарникка, җилкәсе аша, күз кырые белән генә карап алды:

— Арттыра төш! Минем егерме биш пот күтәргәнне күргәнем бар!

— Һи! Бетте алай булгачыннан Айбаның! Кая, сөякләрен тутырырга капчык алып килдеме икән соң?

Беркавым гөрләшеп, көлешеп алдылар.

Халык дулкынлана, гөжли, тора-торгач үзеннән-үзе кычкырып җибәрә, эһелдәп куя. Көрәшнең иң кызык сулышын — берәрсенең җирдән суырып алып күтәреп чөйгән вакытын күрмичә калмас өчен, бөтен дөньяларын онытып, берсен-берсе кысып, этә-төртә эчкә таба керә.

Ләкин без барыбер күрми калдык. Халык «аһ» итеп бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда Айбан егете әллә кая, мәйдан кырыена ук барып төшкән иде.

Җиңүче егет, ашыкмыйча гына, салмак кына атлап кырыйга барып чүгәләде. Гыйбаш абзый аңа ике йомырка илтеп тоттырды. Көрәшче аларны «чык» иттереп кенә берәм-берәм тешләренә бәреп алды да, башын артка ташлап, авызына агызды.

Кайсыдыр телен чартлатып куйды:

— Әй-әй таза бу, үләт еккыры! Кара ул муенны! Кара ул беләкләрне! Бот юанлыгы!

— Һе, таза булмаска ни! Яз буе ничә сарыкның башына җитмәгәндер дисең син аны!

Сарник Галимҗан, бакыр төсле кызыл башын кашыштыргалап, тагын әйтеп куйды.

— Без дә ашап карыйсы иде дә бит ул сарык итләрен. Безнең сарыклар көтүдән кайтмый йөдәтә шул, муеннары сынгыры!

Мөхәммәтҗан солдатка Сарникның бу сүзе дә ошамады.

— Әзерләп куйганнар, ди сиңа, тот капчыгыңны! Синең шикелле авызын ачып күктән яуганны көтеп ятучы ачарбаклар белән дөнья тулган.

Гыйбаш абзый, таягын бәрә-бәрә, борын эченнән мыгырданып узды:

— Синеке белән минеке кайтмас, Сарник! Юкка сузма нәфесеңне! Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый, ди. Ишетмәдеңмени?

— Әйтәләр бит сезгә Кәчеләр кручниктә акчаны күп эшли дип!

Сарник Галимҗанның теле бик кычыта иде, күрәсең, як-ягында утыручыларга борыла-борыла тагын сөйләнергә тотынды:

— Беләсезме, ничек сыйлый аларны купислар? Әйтик, ярминкәгә-мазарга ашыкканда? Әйткән вакытта бушатырга алына икән кручник, әйтә купис: менә сиңа бер чиләк аракы, менә сиңа сарык түшкәсе! Тыгына бир! Белдеңме? Ник юан булмасын ул муен?!.

Мөхәммәтҗан җизни тезләренә суга-суга рәхәтләнеп көлде:

— Ну, буш бугаз да инде син, Сарник! Күрше булсаң да әйтим. Синең бит ындыр артыннан да узганың юк! Алырсың эт авызыннан беленне! Ай саен ничә кручник муенын сындыра, ничәсе арка умыркасы чыгып егылып үлә. Менә анысын белмисең син. — Аннары ул, Кәче егетенә каршы көрәшкә чыгучы һаман да күренмәгәч, пошынып: — һи, эшмени бу? Кая соң безнең егетләр? — дип кычкырды.

Шуннан барысы берьюлы Әхәт абыйны димли башладылар:

— Я, чык инде, Әбделәхәт, хур итмә Яңа саланы!

Әхәт абый, халыкның өндәвенә бөтенләй игътибар итмәгән кыяфәт белән, бер читтәрәк сөйләшеп тора иде. Халык бик төбәп кычкыра башлагач, ул кулын селтәде. Шуннан соң аны тагын да ныграк кыстый башладылар:

— Әйдә, нигә көттерәсең тагын!

— Я, я, зарыктырма халыкны, чын күңелдән әйтә бит, якын итеп!

Әхәт белән тыныша алмаган Кәлим дигән егет бар иде. Явыз телләр ул Әхәттән көнләшә, алар Өммикамал өчен ызгышалар дип тә чәйниләр. Кәлимнең теле көрмәкләнә башлаган, күзләре тегеләй дә болай тәгәрн. Халык артына поскан җиреннән яшелле-күкле тавышы белән ул да кычкырды:

— Шүрли ул, шуңа чыкмый! Аның тез буыннары әттәхияткә[1] китәргә тора.

Бер ишесе шаркылдап көлешеп алдылар, әмма Кәлим күбесенең ачуын гына китерде.

— Юкны шапылдамасана! Әдәм көлкесе! Әйтер сүзең булгач, кеше артына посып әйтмә, каршысына барып әйт!

— Син, Кәлим, кеше чәйнәгәнче, сагызыңны гына чәйнә!

— Аһ, алла, исең киткән икән! Егылсаң, марҗа астында яту түгел ич! Егылырсың да торырсың.

Кәче егете хәзер торып баскан иде инде. Ул Әхәт абыйга күз генә төшереп алды да, бер кулы белән биленә таянып, халык өстеннән әллә кайларга карап тора башлады.

Мөхәммәтҗан җизни аңа карап торды да шап иттереп тезләренә сугып алды:

— Таза бит, шельма, аю күк! Менә дигән шахтер чыгасы үзеннән!

Күп кыстый торгач, Әхәт абый күнде. Өстендәге бишмәт кебек нәрсәсен кемгәдер ыргытты да ашыкмыйча гына мәйдан уртасына юнәлде. Әгәр дөрес әйтсәләр, безнең сандугачны бәреп төшерүче егет шушы була инде. Тик хәзер минем аңа ясмык кадәр генә дә ачуым юк иде. Кәче егетен ничек тә җиндерәсем килә башлады. Безнең авылның мәйданы уртасында, корсагын киереп, «Мин кем?» дип масаеп тормасын әле.

[1] Әттәхият — намаз укыганда тезләнү.

Әхәт абый Кәче егетенә караганда гәүдәгә бераз кәйрәк икән, буйга да кыскарак, муены да тегенеке шикелле юан түгел. Шулай да җилкәгә киң, бары белән нык кына күренә. Юка гына коңгырт-сары мыегы да, кәләпүше астыннан кабарып торган бодай саламы төсле чәче дә килешле генә, күз карашы да батыр сымак.

Ул сөлгене кулына ашыкмыйча гына урады, урады да, теге егетнең билен алыр алдыннан, тегермән ягына карады. Безнең апай да күреп тормыймы икән дип, өметләнеп карагандыр инде. Мин Әхәт абыйның җиңүен чын күңелдән тели башладым. Әйдә, тик малайлар «җизнән» дип үртәсеннәр! Җизни булмаслык егетме әллә ул?!

Алыша гына башлаганнар иде, тагын тотынды халык гөжләргә. Әллә тегене «сала алмас» дип борчылудан гөжли, әллә «булдырыр әле безнең егет» дип ышанып гөжли. Шайтан белсен!

Мәйдандагы халыкның һәммәсе дә диярлек, куәт биреп, төрле яктан кычкыра башлады:

— Бирмә билне, Әхәт, бирмә!

— Нык бас аякларны, җиргә сеңдереп!

— Менә шулай, менә шулай!

Әхәт абый аякларын киң җәеп, сыртын кабарткан да раван йөри[1] тирбәлә-тирбәлә. Кәче егете күтәреп алмакчы булып карый да, шуа китә тегенең кулы. Кемнәрдер көлеп тә җибәрде:

— Һа-һа-һа! Тәтеми шул! Калҗасы симез!

— Аркасын майлап чыкканмы әллә югыйсә безнең Әбделәхәт!

Ул шулай салмак кына тирбәлгәләп йөрде, йөрде дә кинәт тегене бөтереп тә алды.

— Һоп, һоп! Сал инде, Әхәт, сал! Чөеп җибәр!

Әмма Кәче егете дә уяу шул, каһәр. Ул моны чытырдатып кыскан килеш нәкъ өстенә генә килеп төште. Әхәт абый җирдән көчкә генә күтәрелде.

— Их, күкрәккә төште бит теге албасты! — диде берсе.

— Ай мескен, көм-күк булып күгәреп китте Әхәт, бичара.

Ул да түгел, Сарник Галимҗан кызыл башыннан кәләпүшен сыпырып алды да тамагы ертылырдай итеп чырыйлап җибәрде:

— Җәмәгать, юри өстенә төште, күкрәгеи сытыйм дип! Хәрәмли Кәче, хәрәмли! Нәрсә карап торасыз?

Әмма Мөхәммәтҗан солдат та, бүтәннәр дә аның авызын тиз томаладылар:

— Юк ла инде, нәрсә чәрелдисең юкны? Оят кирәк әз генә!

— Үзе кычкырамыни ул? Балы кычкыра аның!

Көрәш озакка сузылды. Егетләрнең әле берсе тилпенеп карый, әле икенчесе йолкып алмакчы була. Барып чыкмый гына бит! Гыйбаш абзый, борчылып, башын чайкап куйды:

— Их, Әбделәхәткә кичтеки генә ит-май кергән булсачы! Әллә кайчан алып чөйгән кеше инде ул Кәчене.

— Һи! Батракка ит-май тагын! Әле авызы икмәккә туямы диген!

Шунда кешеләр артыннан тагын Кәлимнең калынлы-нечкәле тавышы ишетелде.

— Ник, ичмасам, булмастайга көчәнә! Арт ягы сыек икән, ник батырлар арасына кысыла?!

Кәлим сүзен әйтеп кенә бетерде, Әхәт абый «һоп!» дип кычкырып та җибәрде, Кәче егетен суырып та алды. Халык дәррәү урыныннан торды. Инде тотып ата дигәндә, Кәче егете кулын күтәрде.

Кәлимне төрткәләп бөтенесе мәйдан уртасына ташландылар.

— Ай, маладис, Әхәт туган! — диештеләр. — Ай куандырдың!

— Ура! Ура! — батырга! Бил бирмәде, сынатмады!

[1] Раван йөри — йөри бирә бер килеш.

Кайсыдыр шаяртып бөтенесеннән дә ныграк кычкырды.
— Рәхмәтне Кәлимгә әйтегез! Ул ачуын китерде!
Бу шау-шу бәлкем бик озакка сузылган булыр иде. Төрле яктан:
— Атлар килә! — дип аваз салдылар.

## VII

Без Хәкимҗан белән алгарак чыгарга маташкан арада, беренче ат тар гына юлдан выжлап узып та китте. Аннары башкалары. Минә иң арттан килүче ат та күренде. Ул, мескен, ап-ак күбеккә төшкән, аның кып-кызыл борын тишекләре баш сыярлык булып киңәйгән. Аңа атланган малай, уңга-сулга селтәнеп, җан-фәрманга һаман атның кабыргаларын «яра».

Йодрыклары белән янап, малайга як-яктан кычкыра башладылар:
— Кыйнама хайванны, кибәкбаш, рәнҗетмә!
— Сугып төшерергә кирәк юньсезне!
— Ни пычагыма дип куасың? Арттан караганда барыбер син беренче килдең бит!
Аңа шаулап бер көлешеп алдылар.
Арттан килгән атның туктый башлавы булды, аны төрле яктан йөгерешеп килгән әбиләр, җиңгиләр сарып алды. Алар кулларындагы берике аршын ситсыдыр, яулыктыр, тастымалдыр кебек бүләкләрен атның ялына, маңгай чәченә, йөгәненә тагарга тотындылар.
— Улым солдаттан котылса дип нәзер әйткән идем, — ди берсе.
— Эчемә кату чыкканга түзәр әмәлләрем дә калмаган иде. Арттан килгән атка бүләк бирер идем дип нәзер әйткәч, аллага шөкер, әйтмәгәнем генә булсын...
Тагын берсе, кызым баладан исән-сау котылса, дип, икенчесе, сыеры тана бозау китерсә, дип адарынган икән.
Мөхәммәтҗан җизни, кәкре башлы таягына таянып, шушы хәлләрне карап торды да башын чайкап куйды.
— Их, безнең томаналык! — диде. — Томаналык, наданлык!..
Шулай диде, эшләпәсен басыбрак киеп, авылга кайтып китте. Сарник Галимҗан аның артыннан тешен ыржайтып калды.
— Әй, зимагурдан юньле сүз чыгамы соң? Һе, суык аяк.
Хәкимҗан минем җиңемнән тартты.
— Җизни таш йөрәкле кеше икән. Арттан килгән атны бер тамчы да кызганмый...
Ул арада, һәммә халыкны борчуга салып, мәйданга хәвефле хәбәр таралды:
— Каенсар җирәне буйлаган! — дип кычкырдылар. — Малаен егып калдырган да авылына качкан!..
Бөтен мәйдан берьюлы кайгырыша башлады:
— Ай алла, малай нишләде икән, малай? Имгәнмәдеме икән?
— Кеше җибәрергә кирәк! Кая, староста нәрсә карый? Кем бара?
Кайсыдыр старостаны эзләп китте, кайсыдыр авылга ат җигәргә йөгерде.
Тик озак та үтмәде, мәйданның бер кырыеннан икенче кырыенача тынычландыргыч хәбәр таралды. Буйлаган атны иске зират янында тотып алганнар. Малай да исән калган, тик егылганда иңбашы гына бераз суелган булып чыкты.
Мәйдан бетүгә ал-кызыл, яшел, зәңгәрдән киенгән чоп-чуар кызхатыннар төркемендә ияреп, авылның урманга таба сузылып менгән югары очына, бормалы су буендагы Бөйдә болынына киттек.
Болын өстен әйткән дә юк, тау кырыйларына хәтле чоп-чуар. Яшьрәк киленнәр, апайлар, җиңгиләр, һәммәкие бала-чагалар белән, баскыч-баскыч булып, тау кырыена тезелгәннәр. Астагы яшьләр уены моннан, уч төбендәге кебек, аермачык күренә.

Мин Хәкимҗанны тауга түбән төртеп җибәрдем дә, күңеллерәк булсын өчен, аның артыннан үзем дә тәгәрәп киттем.

Хәкимҗан миннән бер яшькә олырак булса да, шуның өстенә сөйләшмәве белән ачуны китерсә дә, ничектер без аның белән гел бергә уйный торган идек. Бәлки, ул үзенең әрсез түземлеге белән ошагандыр? Берәрсеннән кыен ашыймы, дөүрәк малайлар аяк чалып егамы, аягына шырпы кадаламы, муен тамырына учлап тузан тутыралармы, Хәкимҗан беркайчан да еламас, тик челт-челт күзләрен генә йомар иде. Шуның өстенә тагын Хәкимҗан иптәш малайларына бүләк бирергә бик ярата иде. Ул миңа ниләр генә бирмәде, нинди тәмле ризыклар белән сыйламады! Анасы пешергән коймак, бөккән, бавырсак дисеңме, әбисе җыйган урман чикләвеге дисеңме. Моның өчен бабасы пеләш Миңлебайның аны әллә ничә тапкыр кыйнаганы бар. Менә бүген дә әле ул миңа бер чуклы конфет, ике-өч кызыл билле прәннек алып төшкән. Мин прәннекне ашаганда үзе, күзләрен мөлдерәтеп, минем авызга карап утырды. Әмма бер прәннекне үзенә сузгач, башын гына селекте.

Кыш буе шыгыр-шыгыр кар ерып, борыннарны, колакларны туңдырып иза чиккәннән соң, салкынча бер хуш ис аңкытып яткан йоп-йомшак шул дымсу җир өстендә, әле генә борын төртеп чыга башлаган яшь чирәмдә бер-берең белән әүмәкләшеп аунау үзе бер рәхәт иде.

Тәгәрәшеп төшүгебезгә, кызлар белән егетләрнең нәкъ пар-пар булып тезелешеп торган урыннарына туры килдек. Кызык бит! Безнең апайлар монда, ничектер, үзгәреп, олысымакланып киткәннәр димме? Башка вакытта, бүтән урыннарда, өмәләрдә, урак өсләрендә, егетләр белән чырык та чырык килеп шаярышып туймыйлар, һаһайлап көлеп җибәрәләр. Хәзер исә шундый да оялчан, шулкадәр кыюсыз булып кыланалар, исләрең китмәле! Авызларын шәлъяулык почмагы белән каплаганнар да, оялып кына читкә карап баралар. Ә күзләре барыбер елтырый, куллары да егетләр кулында. Баскан саен чылтыр-чылтыр чулпы тавышы ишетелә. Аргы баштагы чишмәгә хәтле шулай пар-пар булып салмак кына атлап баралар да шунда тезелешеп туктап калалар. Бу яктан икенче пар барып җиткәч, янадан монда борылып кайталар. Кичке салкын төшә башлауга карамастан, өсләрендә юка күлмәк белән иңбашы күпертмәле бер алъяпкыч кына, әмма кулларында кыш өчен бәйләнгән йон пирчәткә. Әни әйтә, гадәте шундый, ди. Пирчәткәсез егетләр кулын тотсаң, әдәпсезлек була, ди.

Егетләр, кызлар тирәсендә буталып йөри торгач, әллә кайсының гына шәлъяулыгы читеннән, очкын чәчрәгәндәй, бер сөрмәле күз сирпелеп китте. Карасам, үземнең апай! Мин моңарчы күрмәгән ниндидер зәңгәрле-яшелле яңа күлмәк кигән, аның баскыч-баскыч булып бик күп бала итәкләре тезелеп киткән, иңбашлары күпереп тора. Башында да ал чәчәкле өр-яңа зәңгәрсу шәлъяулык.

Аның янында бая гына мәйдан тоткан Әхәт абый басып тора. Якынтирәдән узган яшьләр һәммәсе аңа якын итеп елмаеп үтәләр. Ә ул үзе кырыс чырайлы.

Апай читкәрәк борылды да нык кына минем аркама төртте.

— Нәрсә калган сиңа монда? — дип пышылдады. — Бар, йөрмә буталып! Ишетсен колагың, әни алдында тешеңне агартасы булсаң, бел аны!

Һе, белмәссең бар! Белмичә генә кара! Кайткач тәгаен әләгә. Мин инде китеп барырга да җыенган идем, Хәкимҗанның торaташ булып катып торуына гаҗәпләнеп, туктап калдым. Ул Әхәтнең чалбар якасына шаккаткан икән. Бер әкәмәт инде! Ул үзе зәңгәр төсле, үзе бик киң. Шундый киң, Әхәтнең бөтен корсагын каплап тора. Шуның өстенә аңа, бундан-бунга, эреле-ваклы бик күп күн кесәләр тезелеп киткән, аннан нечкә көмеш чылбырлар да асылынып тора. Каян алды икән ул

аны? Батыр калганга бирделәрме әллә? Ул миңа бик ошады. Болайга киткәч, мин инде Әхәт абыйның җизни булуына да каршы түгел идем. Ул кесәләрдә ниләр генә булмас дисең?..

Безнең китә алмый торуыбызга апай борчыла ук башлады. Безгә иелеп хәтта пышын-пышын юмаларга тотынды:

— Барыгыз, җаннарым, әни янына менегез! Мин сезгә кайткач буяулы күкәй бирермен.

Әһә! Болайга киткәч, азрак наянланырга, бераз ялындырырга да була иде инде.

— Бик кирәге бар! Әле үзебез җыйганны да ашап бетермәгән. Әйеме, Хәкимҗан?

Хәкимҗан, минем сүземне ныгытуын белдергәндәй, борынын тартып куйды.

— Алайса, эрбет чикләвеге бирермен.

Монысына ни дип әйтергә өлгерми калдык. Әхәт абый әлеге мәзәк чалбарының бер кырыеннан дүрт-биш конфет чыгарды.

— Мәгез әле, энекәшләр! Ә-ә-әнә тегендә, тау башына менеп суырып карагыз да бик ошап китсә, тагын да килерсез. Булдымы?

## IX

Бераздан без инде, икебез әнинең ике канаты астына сыенып, тау кабыргасында утыра идек. Әни кичке кояш яктысында берөзлексез шаулап-гөрләп, төрле-төрле гармун көйләренә җырлаган кызыл-чуар болын өстенә карап тора-тора да хәйран булып башын чайкый:

— Ай-һай-һай, ни тикле халык! Нинди уеннар! — ди. Аның юка гына борын канатлары сәер генә булып селкенгәлиләр, аксыл-зәңгәр күзләре тирәсенә ягымлы җыерчыклар җыела. Нәкъ Җиһан тәтәй йөзендәге төсле, нәкъ! Мин әнинең култык астына тагын да сыенарак төшәм. Аның үзенә генә, бик якын итеп, нindидер матур сүзләр әйтәсе, я берәр күңелле нәрсә сөйлисе килә башлый.

Безнең янга күрше хатыны Гыйльми тәтәй килеп утыргач, тагын да күңеллерәк булып китте. Ул һәммәсен күреп, белеп тора икән.

— Кызларың кая басканнарын белмиләр! Егетләре янында аккошлар булып кына йөргалыйлар! — Ул, авызын ерып, әнинең кабыргасына төртеп алды. — Миңзифа, карасана! Өммикамал да бер чибәрен элэктергән түгелме соң?

Әни, Гыйльми тәтәйнең бу сүзләрен өнәмәгән сыман, кашын җыерды:

— Шундадыр, шулайдыр. Кайда булсын тагын кыз бала? Җиткән кыз лабаса! Аллага шөкер, кылдый-былдый гәүдәле түгел. Буе-сыны — күз генә тимәсен, чибәрлеге тагын бар. Уңганлыгын әйтеп тә тормыйм. Быел кыш өстеннән, сөлге-тастымал сугып, өстен-башын да чын ярау итте.

Гыйльми түти «әйе, әйе!» дигән сыман башын гына игәләде.

Ул да түгел, әни авыл ягына шигәеп күз салды да урыныннан кузгала башлады.

— Ай-һай, әллә кайтыйкмы икән, балалар? Бик күңелле дә күңеллесен...

Гыйльми тәтәй аның кулыннан тартып кире утыртты.

— Бәшир абзый кайтыр дип шулай кыбырсыйсың инде син. Кире борылып китмәс Бәшириең, котың очмасын!

Әни, утырыр-утырмас:

— Карыны да ачып кайтыр... — диде.

— Сабан туе көнне берәү дә ач булмый.

— Үзенә генә күңелсез дә булыр...

— Күңелсез булса, менә монда, синең янына төшәр! Китче, кит!

Гомер буе якты дөньядан йөз чөереп, өтермәндәге шикелле бикләнеп ятмас кеше, усак яфрагыдай дерелдәп.

— Әйтергә ансат та бит...

— Ансатмы, түгелме, әзрәк үзеңчә дә бул! Әнә, балаларың җитеп килә инде.

Әни, авыр сулап, кире утырды. Шундук, борчуларын онытып, болын өстенә текәлде.

— Әттә-тә, карагыз гына әле, карагыз, ничек бөтереләләр!

Болын уртасында түгәрәк уен башланган да ул шуннан күзен ала алмый икән.

Кызлар-егетләр, бер-берсенең кулларыннан тотышып, зур түгәрәк ясаганнар. Менә уртада торган гармунчы янына ялт итеп бер егет килеп керде. Килеп керүе булды, әй китте бөтерелеп, китте сикерә-сикерә пыранлап, аягына күзләр дә иярми. Егет ашкына, аннан да битәр гармунчы ашкына. Әни Хәкимҗан белән мине култык астына тагын да ныграк кысты.

— Ай-һай-һай! Шул тикле дә өздереп салыр икән!

Кем белә, бәлки аның бу уеннарны күргәч, кыз чаклары исенә төшкәндер? Әнә бит, аның йөзе, Җиһан тәтәйнеке шикелле, яңадан матурланып, ачылып китте.

— Гыйльми түти! Монысы кем булды соң? Безнең авылныкына һич охшамаган.

Гыйльми түти үзе дә шул якныкы иде шикелле, ул чыннан да белә икән:

— Кем булсын, Әзәк илләре ич! Минем якташлар! Яна көй чыгарганнар дагын шуны биеп күрсәтәләр. Әнә Кәчеләр белән Айбаннар дагын җырлап-уйнап әйләнделәр ич. Үнәрләрен күрсәтеп. Кайсы авылныкы шәбрәк чыга, шунысын отып та калалар... Шуннан бөтен илгә тарала.

Ул арада егетләрнең берсенә каршы зәңгәр күлмәкле, ал яулыклы, яшел алъяпкыч япкан бер кыз чыкты. Монысы Гыйльми түтигә аеруча ошады.

— Һай, вактан да турый инде, әй, рәхмәт төшкере!

Бу кыз шундый җитез бөтерелә, шундый җиңел пырылдый, ул миңа абый ясап бирә торган салам курчак биюен хәтерләтте. Салам курчакларны подноска бастырып, аның кырыена суккалап торсаң, алар да берсе-берсенә әле якын ук килеп, әле ерагая төшеп, нәкъ әнә шулай биләр.

Гыйльми түти, утырган җиреннән кулын чәбәкләп:

— Әйттер шуны, сиптер шуны!.. — диде. — Инде лә, инде лә! Аргы якның керәшен кызы бу. Кем генә соң әле, аты җиткере?..

— Әһә! Әйтәм җирле бик чая кылана. Безнең мөселман кызы түгелдер шул.

## X

Инде, кояш баеп, эңгер-меңгер дә җитте. Бөйдә болынының урманга таба башында ястык тикле генә томан кисәкләре дә күренгәли, бераз салкын да төшә башлады.

Әмма болындагы уен, андагы биюләр, гармун тавышлары һаман кыза гына барды.

Менә бер заман тау кырыеннан, кычкыра-кычкыра балалар йөгерешкәне күренде:

— Качыгыз, кач! Мәчет картлары төшә!

Гыйльми түти ачуыннан шапылдатып тезләренә сукты:

— Чәнчелеп кенә китте! Инде йөриләр дә соң шул карт үләтләр сару кайнатып! Ник муеннары гына сынмый шуларның чокыр-чакырда!

Карасак, тыкрыктан биш-алты чалмалы килеп чыкты. Ул да түгел, алар, атлый-йөгерә, таякларын болгый-болгый, яшьләр өстенә ташландылар. Аларга коточкыч каргау сүзләре яудырдылар.

— Каяле, бәдбәхетләр, имансызлар, мөртәтләр! Кара син аларны! Монда җыелып азып-тузып яталар! Кая гармуннары? Ват шул иблис музыкасын, сытып ташла, дәхете калмасын!..

Китте чыр-чу, китте тавыш, йөгереш, качыш. Ләкин кая инде ул әлсерәгән мәчет картларына кылдый-былдый аяклары белән яшьләр артыннан җитү! Егетләр, минут эчендә инеш аркылы чыгып, аргы якның тау битенә сибелде. Кызлар, танытмас өчен битләрен каплап, кача-поса су буеннан шылдылар.

Картлар арасында староста да бар икән. Башында чалма, кулында яшел таяк. Анысы, сирәк сакалын сәлпәйтеп, тау кырыенда утыручы хатын-кызлар өстенә килә башлады. Килә-килешенә яман да хурларга, янарга тотынды:

— Сезгә ни калган? Ә? Ни битегез белән монда, шайтан уенын карап, язык җыеп утырасыз? Имансыз каласыгыз киләме? Ирләрегезгә хәрам буласыгыз киләме? Сыртларыгызны ярырга кирәк сезнең! Җәһәннәм кисәүләре, битсезләр, денсезләр!..

Әни бөтенләй каушап төште. Безне кулларыбыздан эләктереп алды да өскә таба әйдәргә тотынды.

— Харап кына булдык! Беттек! Әйдәгез тизрәк, әйдәгез! Әтиегезгә ишетелсә, нишләрбез? Ходаем, ни җаваплар бирербез!

Шунда Гыйльми түтинең батырлыгы бөтенесенең исен китәрде. Каушамады, нитмәде, старостаның каршысына ук килеп басты:

— Бер дә алай җайлы-җайсыз кешенең иманына тиясе түгел иде сиңа, Йосыф абзый,— ди-ди, ашыкмыйча гына итәкләрен каккаларга кереште.— Андый эшәке сүзләр белән мыскыл итәргә нишләгән без ул тикле? Патшага тел озайтканмы, динне хурлаганмы?! Я, нишләгән?

Безнең эти старостаны бервакытта да исеме белән атамыйча, я «закон» дип, я «сыбызгы борын» дип кенә йөртә иде. «Сыбызгы борын» агарынды, күгәренде. Хәтта читек-кәвешле аягы белән, гайрәтләнеп, җиргә тибеп алды:

— Ә, нәстә? Ничек? Кара син аны, ыштыр битне, кара оятсызны! Кара нәстә әйтә олы кешегә! Тының чыкмасын!

Болайга киткәч, Гыйльми түти дә кыза башлады. Аның күзләре усалланды, бөтен кыяфәте, әллә ничек, батыраеп китте.

— Әйтмәскә, әллә телем юкмы минем? Һе, олы кеше дигән була! Олы кеше булсаң, үзеңне олы тот! Үз урыныңда тор! Ат аягын дагалаганда бака да ботын кыстырган, ди. Ниемә дип җыеп төштең монда ул җыен мәчет өрәген! Ни пычагыма дип кысыласыз яшьләр эшенә? Сезгә монда ни калган?

Староста үз ачуына үзе буылып:

— ...Язык, хәрам, иблис уены!..— дип кенә кычкырырга өлгерде, Гыйльми түти, аңа суларга да ирек бирмичә, янадан элеп алып китте:

— Харап икән!.. Уйныйлар да җырлыйлар икән! Шуның өчен дә яшьләр ич алар! Аларның шундый чаклары. Менә сез бик уйнар идегез дәгән, тәтеми шул, булдыра алмыйсыз! Әнә, аякларың кәкрәеп каткан, үзең дә, суга баткан таракан төсле, шәлперәеп төшкәнсең! Шуңа эчең тырныймы, шуңа йокың кермиме? Юньле карт булсаң, үз гөнаһыңны үзең белеп, иманыңны яңартып, түр башында гына утырыр идең син!

Әни, коты чыгып, Гыйльми түтинең җиңеннән сөйрәргә тотынды:

— Ай аллам! Җитте сиңа, ходай хакы өчен тукта! Харап буласың бит! Башыңны баструкларда чертерләр!

Бу кызыкка күп булып җыйналган хатын-кызлар пырх-пырх көләргә тотындылар. Староста хурлануыннан ярылырга житеште, нидер әйтергә җыенган сыман, авызын бер ачты, бер йомды.

— Теленә тилчә... Азгын, имансыз!.. Авызыңа шайтан төкергән! Бик нитсәң, патша кешесенә тел тидерсәң, арт сабагыңны укытам әле мин синең, беләсеңме?

Моны ишеткәч, Гыйльми түти, йодрыкларын йомарлап, старостаның өстенә ук бара башлады:

— Һе, шулай дисеңме? Куркытмакчы буласыңмы?! Булдыра алмассың! Арт ягың юеш синең, арт ягың! Усаллыкка китсәме? Усаллыкка китсә, бугазыңнан китереп буам мин синең! Авылдан кудырам мин сине! Беләм мин синең кай төшеңнән китереп кысасын, беләм! Халыктан яшереп попларга авыл җирен саттың! Татар авылының башына ук китереп шул җиргә чиркәү салдырдың! Татар да түгел, урыс та түгел, паганый син, паганый, паганый!..

Старостаның күзләре акайды, ул тыны кысылып, бер авыз сүз әйтә алмыйча, арт ягына китереп типмәгәйләре дигәндәй, курка-курка түбәнгә таба чигенә башлады.

Гыйльми түти тау башында торып калды.

— Бар әйдә, бар! Исән чакта тай тизрәк. Тагын да өсти башласам, я паларич сугып кәкрәеп төшәрсең.

Якын-тирәгә җыелган хатын-кызлар, шаккатып, бот чабып, Гыйльми түтине кайгырта башладылар. Барысыннан да бигрәк безнең әни борчылды.

— И ходаем, телләреңне генә әйтер идем! Бигрәк тә каты бәрелдең! Белмисеңмени, бөтен түрәләр анда сыйлана, бөтенесе аның яклы. «Патшага тел тидерде», дип Себергә җибәрттерсә, нихәлләр итәрсең?

Гыйльми түти шаркылдап көлде генә:

— Һе, җибәртте, ди, менә, җибәртмичә! Миннән башка, азрак, ди, Себердә катыржан! Мин генә җитмим, ди! Һе! Шуларга үземне үзем басымчак иттерәм менә!..

Авыл башына менеп җиткәч, һәммәбез дә борылып карадык. Әле генә шаулап торган күңеллелектән берни дә калмаган, болын өсте буп-буш иде. Әни авыр сулап куйды.

— И, әрәм генә иттеләр, бигрәк тә күңелле иде.

— Калалгырлары, — диде Гыйльми түти. — Йөриләр ич шунда кан бозып. Җыен кара таракан... Әле ярый, ичмасам, егетләр гармуннарын качырып өлгерделәр. Әнә, тавышы да чыга башлады түгелме соң?..

Аның сүзен дөресләгәндәй, аргы якта егетләр гармун тартып җибәрделәр.

## Чәңки-чәңки, чәңки җылан

### I

Беркөнне урамга чыксак, куанычтан сикерешергә тотындык: авылга өч-дүрт йөк товар төяп кызыл малчылар килгән! Мәчет янындагы чирәмдә атларын тугарып, тәртәләрен югары күтәреп бәйләгәннәр дә мәш килеп арбаларын чишеп маташалар. Без, бөтен өеребез белән, шунда чаптык.

Арадан бер олырагы, аягына читек-кәвеш кигән кара мыеклысы, урам уртасына чыгып, кычкырырга тотынды:

— Әхмәт, Әхмәт!

Әхмәт безнең арада юк иде. Дәшүче булмагач, теге кеше бездән сорады:

— Малайлар, кая Әхмәт?

Шул арада олырак малайлар үзара пышылдашып алырга да өлгерделәр:

— Тургайлар Әхмәтен сорый. Ел саен шул дәшеп йөри бит.

— Менә быел йөрмирәк торсын әле!

Теге кеше яңадан дәште:

— Я, кая Әхмәтегез, нигә әйтмисез? Телегез юкмыни?

Кем турында сүз баруын яхшы белсәләр дә, малайлар белмәмешкә салыштылар. Шунда безнең якның иң алдакчы малае — Нимҗан алгарак чыкты.

— Бездә Әхмәтләр ярты дистә. Кайсы Әхмәтне сорыйсың, абый?

— Теге шәп тавышлы, матур җырлый торган малай. Әй, аты җиткере, кем Әхмәте соң әле?

Мыеклыны байтак азаплаганнан соң, Нимҗан үзе әйтеп бирде:

— Тургайлар Әхмәтеме әллә?

— Соң сез аны белмәскә? Шул инде, шул!

Нимҗан күзен дә йоммыйча алдый бирде.

— Әәә... Тургай Утарга утырмага китте. Әллә кайта, әллә чак кына кунак була...

Малайлар, авызларын каплап кына, көлешеп алдылар. Кара мыеклы борчуга төште:

— Кара син, әй, чәнчелеп киткере!..

Ул нидер мыгырдый-мыгырдый кар төсле ак яулык белән борын асларын, мыекларын, муеннарын сөртте-сөртте дә бармагы белән ишарәләп безне үз янына дәшеп алды. Без, җим салган урынга йөгерешкән кош-корт шикелле, этешә-төртешә шул кеше янына җыелдык. Тик ул безне куандырмады. Корсакларыбызга шапылдатып суга-суга, һәммәбезне бер карап әйләнде дә безнең эше кечерәкләрне:

— Батмый, бәләкәй! — Я булмаса: — Кечкенә — чебеш кенә!.. — диди, муеннарыбызга чиерткәләп, читкә куып бетерде. Янында калган олырак малайларны, тамаклары ертылганчы, кычкыртып карады. Аңа ошаган малай зәңгәр күзле, дәү борынлы, сипкелле Ахун гына булып чыкты. Аның яше дә зуррак, тавышы да шәбрәк иде. Теге кеше, Ахунны атка атландырырга гына торганда, йөгерә-йөгерә тыны-көне бетеп Әхмәт үзе килеп чыкмасынмы! Мыеклы, безгә бармак янап, Ахунны куып җибәрде дә кыңгыраулы туры байталына Әхмәтне атландырды. Урам буйлап халык дәшәргә китте Әхмәт. Бераз гына бара да сузыпсузып кычкырып куя:

— Мә-чет яны-на кызыл малчы-лар килде. Та-вар алырга барыгыз!..

Без кәтүебез белән аның артыннан киттек. Безнең кызыгуның, көнләшүебезнең чиге дә, чамасы да юк иде. Шулай булмыйча, бәйрәм бит бу, бәйрәм! Шундый кыңгыраулы шәп атка атланып урам әйләнү үзе ни тора! Синең тавышыңны ишетүгә бөтенесе йөгереп чыга, бөтенесе күреп тора. «Кем малае кычкыра, фәлән малае кычкыра»!.. Бөтенесе синнән сорап калырга ашыга:

— Кемнәр килгән? Нәрсәләре бар?..

Аннан да бигрәк, бушка гына кычкыртмый, акча да бирә бит әле. Әмма без өметне өзмәдек. Безнең һәркайсыбыз болар икенче килүдә хәбәр салучы булып үзе чыгарга дип адарынып куйды.

Тик безнең бу хыялыбыз озакка түзә алмады.

Менә Әхмәт, атын акрын гына атлата биреп, шулай сирәк-мирәк кычкыргалап барды да, түбән очка төшеп тегеләргә күренмәс булгач, бик моңлы итеп җырлап җибәрде:

Иртә генә торам, кырга чыгам,
Ак куяннар эзли, — тал тапмый;
Өйләргә дә керәм, тышка чыгам,
Ятим башкайларым ямь тапмый.

Моңарчы ялан аяк белән юл тузаны ерып, шаулашып барган малайлар берьюлы тындылар. Әхмәттән көнләшеп, юл буе аны үчекләп килгән Нимҗанга тикле телсез калды. Әхмәтнең тавышы бик тә моңлы,

анын жыры тәннәрне чымырдатып куя иде. Узган ел Әхмәтнең анасын урман кискәндә агач басып үтерде. Дүрт бала өстенә килгән үги аналарын әниләр шәфкатьсез, миһербансыз дип, ятимнәрне сораныйрга куып чыгара дип әледән-әле орышалар.

Әхмәт картлар шикелле бөкресен бүлтәйтеп, барды-барды да моңлы күзләрен зиратка төбәп тагын жырлап жибәрде;

Агыйделкәйләрнең ярларыннан
Агадыр ла сулар тавышсыз;
Бар микән соң жирнең куркрагендә
Яшәүчеләр моңсыз, сагышсыз.

Әхмәтнең жырлавын ишетеп капка төбенә чыккан хатын-кызлар, башларын иеп, күзләрен сөрткәлиләр:

— И нарасый, — диләр. — Инде дә үзәкләрне өзә, инде дә йөрәкләрне телгәли шул моңнары белән

— Өстен-башын гына кара син аның. Әнә ни хәлләргә төшергән баланы теге зобаный!..

Әхмәтнең өстендә әллә кайчан уңып беткән иске киндер күлмәк, ыштан ертыгыннан тез башы күренеп тора. Башындагы кәләпүшенең әллә кайчан ук киярлеге калмаган.

Хәкимжан, Әхмәтнең артыннан йөгереп барып, аңа үз кәләпүшен сузды. Әхмәт атын туктатып аны киеп карады.

— Әйбәт, таңкаләре дә бар. Миңа мондыйлар эләкми. Башка да мач кына. — Әхмәт кәләпүшне бик озак әйләндергәләп торды да Хәкимжанга кире сузды. — Ярамый. Бабаң кыйнар, эт итәр.

Без Әхмәтне тау башына кадәр озата бардык та кире борылдык. Хәзер беребезнең дә шаярасы килми иде.

## II

Без кире кайтканда, йөкләрнең өстен ачып сатарга ук тотынганнар иде.

Ул андагы төрле ситсы товар, кием тышлыгы, яулыклар, чаршаулыклар! Тамаша инде. Ул төсләре, — күзеннең явын алырлык. Бөтен урамга, борыннарны кытыклап, бездә булмый торган бик тә хуш бер ис — кала исе таралды.

Жыела башлады хатын-кыз, яшь-жилбәзәк, карчык-коры. Кайсы күлмәклек караган була, кайсы кием тышлыгы сорый. Акчасы булмаганнары алъяпкыч итәгенә йомырка төяп килгәннәр.

Арба саен перкәшшек. Ап-ак күлмәк өстеннән кара камзул киеп, кәләпүшләрен кыңгыр салганнар, алларында — ап-ак алъяпкыч. Аршыннары кулларында уйнап кына тора. Күкрәк кесәләрендә көмеш кайчылар. Ситсының әле яшелен, әле бишнией, әле кызылын суырып алалар. Алалар да жәеп салып, әле куллары белән шапылдатып куялар, әле беләкләренә эләләр дә, кояшка ялтыратып, мактарга тотыналар. Берсе ошап бетми икән, икенче, өченче кибен тартып чыгаралар, апа һәм жиңгиләрнең ничек кенә булса да күңелләрен табарга, ничек кенә булса да яннарыннан жибәрмәскә тырышалар:

— Нәрсә тектереп жибәрәсез соң, чибәркәйләр? — ди берсе. — Күлмәклек дисәгез, шундый-шундый ун төрле, унбиш төрле сатин бар, ситсы бар, ыштанлык дисәң икән, кып-кызыл француз белән бурлат бар. Алъяпкычка бидәр-бидәр чәчәк төшкән бишәр тиенлек кенә менә бу ситсы килешә. Кайсын үлчик, күпме үлчик?..

Икенчесе, арбасы алдында биеп торгандай, аягын алмаш-тилмәш басып үз жырын такмаклый:

— Их, тавары ла, тавары! — ди. — Ефәк тә ефәк, бу да ефәк! Алып жибәрсәгезче, жиңгиләр! Алып жибәр, тегеп жибәр, күргәннәрнең күзе үт булсын! Күрмәгәннәрнең төшенә кереп йөдәтсен! Бүтәнкәрне әйтмим

дә инде, хәләл җефетегез шаккатсын: «Туктале, мондый чибәр, мондый көяз минем җәмәгатемме соң? Ай-һай-һай!» дип бот чапсын.

Апайлар, җингиләр, авызларын каплый төшеп, тыйнак кына көлгәләп куялар. Кызлар, мәзәк сүзләргә пырх-пырх көлеп, берсе артына берсе качалар. Әллә алырга килгән алар, әллә купшы перкәшшекләрне күзләргә.

Апайларның берсе, өстә яткан ситсыга бармак очы белән генә төртеп, сорап куйган була:

— Ни бәя соң менә бусысы?

— Очсыз, җинги җаныем, очсыз! Гупчи дә юк инде, шалкан бәясе! Һи, бәясеннән торылмас, кем, җинги, ул ягына калгач, килешербез! Күпме үлчик?.. Бисмиллаһи!..

Сатучы, ялт иттереп, ситсының очын аршын башына элеп тә ала...

Соравын сорыйлар, каравын да карыйлар, тик алырга гына ашыкмыйлар.

— Бик аласы да бит кана, — ди безнең күрше Гыйльми түти. — Алмасын эт ялаган бит әле аның, мур кыргырысы.

— Җәй буе бер яңгыр төшкәне юк. Әнә анда игеннәр көеп бара. Нәрсә ашарбыз, кышны ничек чыгарбыз?

Перкәшшек, аршынын арлы-бирле уйнаткалап, юатмакчы булып та карый:

— Булыр, алла боерса, булыр! Яңгыры да булыр, игене дә. Әйдәле, үлчик әле!..

— Боерса шул әле, боерса! Әллә боера бит әле, әллә борып ташлый...

Шулай да арбалар тирәсендә хатын-кыз халкы гөж килә. Зарлангалап, ялындыргалап булса да аз-маз үлчәткәлиләр.

III

Ул да түгел, «Чишмә буенда яңгыр боткасы пешерәләр!» дигән хәбәр таралды. Без, һәрвакыт салынып төшеп мазалый торган киндер ыштаннарны күтәрә-күтәрә, бер-беребездән узышып тау астына тәгәрәдек.

Ул елның җәе бик коры килде. Олы кешеләр моңа байтактан бирле кайгырышып йөриләр иде инде. Капка төпләрендә, чишмәдә ат эчерткәндә ике-өч кеше бергә очрадымы, сүз һаман шул турыда була. Яңгыр яумый. Корылык! Уфылдыйлар, телләрен чартлатып куялар. Кызу мич алды шикелле эссе бөркеп торган саргылт күккә карап, башларын чайкыйлар.

— Их-ма, нишләргә инде? Игеннәр көя башлады бит, — диләр.

— Болайга китсә, арыш тиен тырнагы тикле генә булып өлгерер. Ачка үләрбез микәнни?

— Сабаннарның да рәте-юне юк. Чыккан да каткан. Бодайны әйткән дә юк, әнә анда солы белән арпа да кашык буе гына.

— Бер килсә, килә бит, әй. Карабодайны да эссе сукты. Уф-уф-уф...

Корылык бер елны да ялгызы гына йөрми. Ул, үзенә ияртеп, хайван үләте, эч авырулары, балалар чире алып килә, коточкыч янгыннары белән авылларны кара күмергә әвереләдерә иде.

Эссе көннәрне кайсы якта булса да берәр авыл өстеннән, шомлы булып, кап-кара төтен күтәрелгәнне күрәсең. Тора торгач, шул коточкыч төтен болыты эченнән, кызыл ялкыннары белән актарыла-актарыла кайнап, ургылып җанны өшеткеч янгын телләре бәреп чыга. Олы кешеләр ындыр артына җыелып башларын чайкыйлар, телләрен чартлаталар. Читтән торып күршеләрнең кайгысын уртаклашырга тотыналар.

— Һай, мескеннәр! Харап кына булдылар! Бөтен авылы кырылды.

— Кая, бетте инде. Ун-унбиш елсыз аякка баса алмыйлар инде.

— Алла сакласын, башыңа киләсе каза булса, кызыл сыер әнә шулай ялый да ала...

Кайсыдыр: «Барып сүндерешергә кирәк иде», — дип карый. Ләкин икенче берсе: «Үзебездә ут чыкса, нихәл итәрбез?» — дип шом сала. Әле бик теләсәң дә барып буласы түгел икән. Тикшерә башлагач, насос суны аттырмый, мичкәләр дә коргаксып беткән булып чыга.

Шунда гына исләренә төшеп, бөтен авылда мунча яктырмый башлыйлар. Көндез икмәк салырга да ярамый. Морҗадан тәтен чыкканны күрсә, дисәтник шундук килеп сүндерә, әгәр каршы килеп маташсалар, хәтта морҗаны да ишеп төшерә.

Шул көннәрдә мәчет картлары белән мулла яңгыр теләп, кырда дога кылып кайткан. Керәшен ягының побы, балаклы тәреләр белән чыгып, бик озак игеннәр арасында улап йөрде, диләр. Алай да яумагач, картлар борынгы гадәт буенча, яңгыр боткасы пешереп карарга булганнар. Әлеге шул Гыйбаш абзый инде. Үзе шикелле шундыйга һәвәс кешеләр белән халыктан ярмасын, тозын, дигәндәй, җыйган да зур казан белән тау астында яңгыр боткасы пешергән. Без, малай-шалай, кашыкларыбызны әзер тотып, ботка пешә башлаганчы ук казан тирәсен әйләндереп алган идек. Кем әрсезрәк, шуңа күбрәк эләкте.

Казан төбендәге касмакны кыра гына башлаганда, урамнан, чиләк күтәреп, тыны-көне беткән Нимҗан йөгереп төште.

— Малайлар, чүлмәчлеки! — дип кычкырды. Ләкин малайлар аңа ышанмадылар. Ник дигәндә, Нимҗанның авылда иң ялганчы малай булуын бөтен кеше белә. Ул ничектер бик килештереп, бик яратып, алдауның тәмен белеп ялганлый иде. Бервакытны аның алтмыш яшьлек бабасын: «Апай үлеп ята, сине чакырганнар», — дип, сигез чакрымдагы Айбан авылына җибәргәне, «Әнине елан чаккан», — дип атасын әллә кайдагы Ушара тамагына йөгерткәне бар. Болар өчен аны бик нык кыйнаганнар. Әмма ул икенче көнне үк янадан ялганларга тотынган.

Безнең арадагы иң зур да, иң усал да булган малайларның берсе — аргы якның Шәйхел башта Нимҗанның үз башына су койды.

— Алдыйсың! — диде.

— Валлаһи алдамыйм!

Нимҗанның башына өч чиләк салкын су коеп, антын өч тапкыр кабатлаганнан соң гына ышандык.

Йөгердек өйләргә, алдык кем кечкенә чиләк, кем зур чүмеч, киттек чыгып очраган бер кешене коендырырга! Бала-чагамы ул, апа-җиңгиме — барыбер. Әмма кыз-кыркын, я үзебез шикелләрәкләр очраса, күңеллерәк инде аңысы. Ул ишек алдына керсә, ишек алдына, өйгә керсә, артыннан өйгә кереп башыннан ук коендырасың. Китә чыр-чу, китә кагыну, кибенү, башлана юри генә орышу, тиргәү. Шунысы кызык, чыланган кеше никадәр генә кычкырмасын, нинди генә усал сүзләр әйтмәсен, аңа һич исләре китми. Ник дисәң, аның үзенең дә авызы ерыларга гына тора. Чөнки йоласы шундый, борын-борыннан, бабайлар заманыннан ук шулай килгән. Бу — бер-береңә ачулана торган чак түгел. Бөтенесендә бертөрле борчу. Бөтен илгә яңгыр кирәк, яңгыр! Шундый изге ният белән коендырган кешегә ничек ачуланасың? Ярамый, килешми. Аннары, кем белә? Бәлки, аның берәр хикмәте дә бардыр? Борынгы бабайлар бер дә шулай мәгънәсезгә бер-берсен коендырып йөрделәрме икәнни?..

Баштарак кызыл малчылар тирәсендә чуалмыйлар иде әле. Күрәсең, башка авыл кешеләре дип яхшысынмаганнардыр. Әмма тора-бара егетләрдән кайсыдыр аларга да житеште. Йөгереп барды да арба янында җыелып торучы кызларга бер чиләк су тондырмасынмы! Башлаганны гына көтеп торганнар икән, аның артыннан икенчесе, өченчесе коендырды...

Кызып киткәч, күзгә ак-кара күренәмени? Перкәшшекләрнең үзләренә дә эләкте. Әллә ялгыш, әллә юри генә ачып салган малларына да бер-ике чиләк тондырдылар, теге кара мыек та коры калмады. Кузгалды тавыш! Сатучылар эссе табага бастылар. Әлеге мыек бигрәк тә каты ачуланды.

— Харап итәсез! Товарны бозасыз! — дип аһ та ваһ килеп, арбаларын капларга тотынды.

Карасак, алар янында бер генә кеше дә калмаган! Ул арада сатучыларның бер-икесе чиләкле малайлар артыннан йөгерде. Кара мыек безнең арттан китте. Үзе куа, үзе сүгенә:

— Хәерче токымы, ыштансыз йолкышлар! Тотыйм гына мин сезне, тотыйм гына!..

Кая инде ул андый мышкылдыкка безне куып житү! Минем белән янәшә Миңниса исемле бер ялан аяклы кыз да йөгереп китте. Толым очындагы көмеш таңкәләре чылтыр-чылтыр килә, үзе миңа карап чырык-чырык көлә. Шуның белән элдертәбез генә.

Теге кеше, терсәкләрен бик кызык тырпайтып, аякларын чатыйнчотыйн атлап бик тырышып йөгерсә дә, барыбер артта калды. Өстәге урамга менеп житкәч, без Миңниса белән Хәкимжаннарның мунчалары артына постык. Бу безгә бик тә көлке тоелды. Тагын пырхылдап алдык. Менә без нинди, янәсе! Олы кешегә дә тоттырмадык.

Бер-беребезнең өс-башыбызга күзебез төшүгә, тагын көлешергә тотындык. Җеп бөртегенә кадәр чыланганбыз! Күлмәкләр тәнгә сылашкан, ыштан балакларыннан тамчылар тамып тора.

Шушы кара тут йөзле, кара коңгырт чәчле бөтерчек кыз белән менә шулай яшеренеп тору нигәдер минем күңелемә бик хуш килде. Якынтирәдә бер кеше дә булмаса да, мин аңа шыпыртлап:

— Курыкмадыңмы? — дидем.

Яман бер серле эш турында сүз баргандай, ул да миңа шыпыртлап җавап бирде:

— Ичмасам, менә моның тикле генә дә курыкмадым! — Миңниса, чәнчә бармагының очын ясмык кадәр генә итеп чеметеп күрсәтте. — Әллә син курыктыңмы?

Мин, ул турыда хәтта авыз ачып сүз әйтүне дә ваклыкка санап, борынымны гына пошкырттым.

Сатучылар әллә кайчан үз эшләренә керешкәннәр булса кирәк. Чүлмәчләеки дә сүрелгән булырга охшый. Ник дисәң, урамда тавыш-мазар тынган иде инде. Ә безнең шул мунча артында яшеренеп торган урыннан һаман да кузгаласы килми иде әле. Миңниса башын кырын салган да, ара-тирә мутлык белән елмаеп, миңа карап алгалый. Янәсе, менә бит ничек, икәү генә калдык... Мин шуннан аның да кузгаласы килмәвен сизәм. Миңа аның кояшта коңгырт төскә кергән түгәрәк кенә бите, колак яфрагында селкенгәләп торган кечкенә зәңгәр кашлы алкасы, кыска гына, йомры гына нәни бармаклары бик тә матур, бик тә сөйкемле шикелле күренә.

Шундук мин эчтән генә: «Нигә минем шундый сеңелем юк икән?» дип тә уйлап алдым. Әгәр Миңниса минем сеңелем булса, мин аны үз янымда гына йөртеп, малайлардан һич кыерсыттырмас идем. Әти биргән алманың да иң матурын, чиянең дә иң тәмлесен, кара кучкыллысын аңа бирер идем...

Мин, юмартланып китеп, Миңнисага тагын да ниләрдер бирергә җыенганда — бүлдерделәр. Урам ягыннан мине кычкырып эзләп йөрүләре ишетелде.

*(Дәвамы бар.)*

*Сәйфи Кудаш*

## Әйдә, тамсын

*М. Б. гә*

Җитмеш яшькә җиту уен түгел,
Аны син бик яхшы беләсең,
Элеп кенә келәт келәсен
Ята торган җылы куен түгел.
Тик шулай да,
        бик телисең икән
Гомернең шул көнен күрергә,
Яшьләреңнең хәтта санын онытып
Абына-сөрене һаман йөрергә,
Комсыз җанның
            һаман да бик килә
Гомер арканнарын ишәсе,
Кичелмәгән юллар кичәсе,
Эчелмәгән сулар эчәсе.
Әйдә, туган,
        атлыйк әле без,
Соңгы шәмнәр балкып янсыннар.
Оҗмахына җитмәсәк җитмәбез,
Тәмуглары артта калсыннар!..
Әйдә, тамсын маңгай тирләребез,
Атлаганда хезмәт урләрен.
Әйтмәсеннәр иде киләчәктә:
«Таптылар, — дип, — ансат гүрләрен».

*1965.*

## Кайгыртам

Кайгыртмаска киңәш бирәсең син
Бер шелтәләп,
        я бер үпкәләп.
Телләреңнең төбен аңлыймын мин,
Тик шулай да китә күпкәрәк.
Безнең көннәр ансат узмадылар,
Билләр биртенделәр кайгыдан,
Шул кайгылар
        килер буын өчен
Әзрәк калсын диеп кайгыртам!..

*1966.*

●

Бик чәнчешеп уткач үзәгемә,
Сабырлыгым беткәч түзәремә —
Йөрәгемне ачып карадым.
Ышанмыйча торам күзләремә,
Чыгалмадым санап исәбенә —
Андагы ук, энә, яраның...

Нинди тешләр аны талагандыр!
Нинди телләр энә кадагандыр!
Кемнәр агулы ук аткандыр;

Боз бизләре ясап көрфекләрен,
Беркелдереп зәһәрле утләрен —
Кемнәр шулай чәнчеп баккандыр?!

Усал куллар салган яраларны
Дәваларга таптым чараларны, —
Бик килеште халкым мәхәббәте.
Тик юк икән әле дару җирдә,
Һәм дәвалап булмый икән бер дә —
Дуслар теле салган җәрәхәтне...

## Карт бөркет

Гасырлар җиленнән чарпаланган
Урал тавының текә кыясында,
Гомере юлда узган юлчы сыман,
Карт бер бөркет утыра оясында...

Әйтерсең, ул аның җөен эзли,
Тырнакларын карый сөртеп-сөртеп,
Борынының катылыгын сыный,
Чакма ташка ала төртеп-төртеп...

Канатларын җилпеп-җилпеп карый,
Сирәгәйгән чылгыйларын саный.
Гүя тәненең ертыкларын ямый,
Укмашкан йоннарын тарый-тарый...

Еракта күкрәгән шартлаулардан
Сискәнә дә тирән уйга кала.
Күзләре чагылгач яшеннәрдән,
Болытларны уеп, карап ала.

Гүя тәүге ашкынудан ярсып
Бәхет таңы көтә көрфек какмый.
Каурыйларның какшавына бакмый,
Һаман да очарга мизгел саклый...

*1966.*

●

Ак сакалын селкә-селкә,
Маңгай тирен сөртә-сөртә,
Бик китереп кенә шартын;
Фуганкасын чыжылдатып,
Йомычкасын бызылдатып
Такта шомарта картым.

Ашар ашын ашап беткән,
Эчәр суын күптән эчкән,
Серенҗегән бер карт булгач;

Уйладым мин:
иплән кенә,
Үз буена тиңләп кенә,
Ясый дип ләхтенә капкач.

Ә ул баксаң онытып кышны
Ялан кулга тоткан ышкы.
Эш җыры шыңгырый йортта.
Балаларча зәвыкланып,
Язның тәүге көнен сагынып
Оя ясый сыерчыкка...

*1966.*

## Юлда барганда

«Язмагандыр инде безгә бу җирдә
Буш кул белән юлда рәхәт йөрергә,
Барсак-кайтсак тау аркалап аркага
Йөк ташыйбыз, дөя кебек, гомергә!»

Юлчыларның ишеткәч шул моң-зарын,
Бушатасым килде йөктән кулларын,
Бик аласым килде михнәт тауларын,
Һәм чишәсем килде биштәр бауларын.

Өлгермәдем тик шулай эшләргә мин,
(Белми калдым бу минут нишләргә мин).
Тик шулай да кычкырдым бар тавышка
Ишеттерен юлдагы кешеләргә мин:

«Атлаганда гомернең зур юлында
Булмаса йөк аркаңда һәм кулыңда,
Юлчы түгел син, тик юлның тузаны,
Юлчыларга иң җайсызлый торганы!

Күкрәгеңдә йөрәгеңне тетрәтеп
Ялкын йөге йөртмәсәң син дөрләтеп,
Ул чагында юк, һич юлдаш түгелсең,
Кабынмаска мәңге сүнгән күмерсең!

Булмаса уй диңгезләре башыңда,
Аркалап алмасаң максат тауларын,
Юлчы түгел син заман сукмагында,
Бәлки язмыш җиленең бер камгагы![1]

Җир-җиһанны шаулатып ил кәрваны
Кешелек язына киң юл ярганда, —
Буш кул белән юлга чыккан һәр бәндә
Юлчы, йөкче түгел безнең кәрванда!»

*1966.*

## Кала икән

Төс ташласа әгәр яшь аргамак,
Авыклардан чабып бәйгедә.
Бер селкенсә туган җирдә аунап
Аргамакка тагын төс керә;
Атлан да чап иртән бәйгегә!

Авыр икән, әгәр бер өшәнсә
Ераклардан чапкан чаптарың.
Кала икән өзелеп сагынырга
Бәйгеләрдә ярсып чапканын,
Җилдәй җитез, чая чакларын!

*1966.*

[1] Камгак — җил үләне.

*Мөхәммәт Садри*

# Пушкин Одессада

Идел бозы кузгалмаган иде,
Шәрә иде әле һәр агач,
Алмагачлар монда чәчәк аткан,
Кошлар туен котлый сандугач.

Таң яктыра. Диңгез өсләренә
Куе кызыл нурлар коела.
Алар миңа Бишенче ел аккан
Кан шәүләсе булып тоела...

Кичә кичен Казан бакчасында
Булган идем Тукай янында,
Бүген таңда Пушкин каршы алды
Одессада, диңгез ярында.

Саумы, Пушкин, таңга карыйсыңмы?
Сулыйсыңмы диңгез һавасын?
Нинди уйлар бүген кичерәсең,
Нинди хисләр белән янасың?

Күзәтәмсең Ватан йөрәгенең
Диңгездә дә дәртле типкәнен,
Корабларның Куба ярларына
Дуслык йөге алып киткәнен?

Беләсеңдер, ерак туганнарның —
Вьетнамның утта янганын,
Күрәсеңдер, безнең кәрваннарның
Шунда ярдәм юлы салганын?

Төзәлдеме, Пушкин, яраларың?
Син дә бит бу диңгез портында
Ватаныңны зурлап яшәгәнсең
Дөрләп янган сугыш утында.

Партизан! — дип, курыккандыр фашист,
Һәйкәлеңне төндә күргәндә.
Үч алгандыр синнән, Россияне
Җиңәлмичә шашып йөргәндә.

Күпме генә дошман котырмасын,
Күпме генә сиңа атмасын,
Син дошманнан өстен булып, илнең
Яклап калдың алтын капкасын!

# Данко

Яшь солдат ята җирне кочаклап,
Нидер сөйләнеп, аңын югалтып.
Кара «юлбарыс» яна якында,
Сөрем таратып, төтенгә батып.

Әйе, «юлбарыс» яна тончыгып,
Ишләре урман артында улый.
Ә егет инде башкаларын да
Куып баргандай әлсерәп сулый.

Саташа егет, әйтерсең, бүген
Идел янында чирәмдә ята,
Иркәли сыман майның кояшы,
Алмагач аңа чәчәкләр ата.

Ишетә кебек сандугач җырын,
Сандугач сайрый, канатын кага...
Кинәт кузгалып атлый башлый ул
Җемелдәп торган Иделгә таба.

— Хальт! — дигән тавыш, автомат уты
Туктата аны барыр юлыннан.
Күкрәк канына кушылып ага
Кайнар каннары аяк-кулыннан...

Таш багана күк басып тора да
Кулын күтәреп, карап еракка,
Йөрәген тотып кинәт баһадир
Ава яңадан салкын туфракка.

Бинокль белән карый командир,
Карый солдаты егылган җиргә.
Туплар тавышы, танклар уты,
Ур-р-ра! — авазы кушыла бергә.

Безнең танклар, безнең солдатлар
Егет янына тауга меннәр,
Канлы гәүдәсен танкка салып,
Кара урманга бәреп керәләр.

Шомлы, дәһшәтле кара урманның
Висла ягына ачыла юлы.
Каберда кала йолдыз балкытып,
Яңа бер Данко — чал Идел улы.

# Крейсерда сандугач

Рәисә Билаловага

Балтикны болыт каплаган,
Җил усалланып өрә,
Дулкыннар шашкан аюлар
Көтүедәй үкерә.

Исе дә китми җилләрнең
Бу давыллы җырына
Адмирал катеры бара
Киров крейсерына.

Ак аюлар үкерешә:
Алам, дип, кочагыма.
Ә катер алар өстеннән
Кош кебек оча гына.

Оча ул язгы бакчага
Омтылгандай рухланып,
Һәм сыена крейсерның
Янына ук тукталып.

Туплары тыныч корабның
Брезент кием кигәннәр.
Без баскан саен ялтырап,
Чыңлый корыч идәннәр.

Тулды матрослар корабның
Астагы зур залына.
Идел сәламен китердек
Без диңгез дусларына.

Көз түгел, кораб эчендә
Бүген яз чәчәк ата,
Кубрик бакчага әйләнеп,
Сандугачлар сайрата.

Сәйдәшевның сандугачы
Сайрый монда моңланып,
Аннары Алябьев җырын
Тыңлыйлар таңга калып.

Чыңласын дип һәр тамчымда
Яз һәм дуслык җырлары,
Кул чабуларга кушыла
Балтикның дулкыннары.

Катер китә. Батыр кораб
Безне озатып кала.
Яңа язлар дауларгамы,
Ул үзе дә кузгала.

*Мөхәммәт Мәһдиев*

# *Этюдлар*

## САБАНТУЙ КӨНЕНДӘ

Анын исеме Кәрим икән. Мәҗлескә ул һич тә көтмәгәндә, кинәт кенә килеп керде. Безне, шәһәр кунакларын, күргәч, бераз гына уңайсызланды, аралыкка кереп, мич алдында ризык белән чыш-пыш кайнашкан хуҗа хатынга нәрсәдер пышылдады. Күлмәк итәкләрен бераз күтәреп кыстырып куйган, мич эссесеннән йөзе кып-кызыл пешкән хуҗа хатын бик гайяр генә Кәримне өстәл янына китереп утыртты.

— Мин болай гына, сабантуйдан кайтышлый хәлегезне белергә генә кердем, — дип Кәрим тартынып маташты.

— Әйдә бар, түргә үк кереп утыр, — диде катгый тавыш белән хуҗа хатын. — Чакырып килгәннең аты зур, сөеп килгәннең хакы зур. Бу — минем бертуган энем, Урта Бирәзәдән. Сабантуй саен бер әйләнеп китә ул.

Калын гәүдәле, киң күкрәкле олы бер ир кереп утыргач, өстәл тирәсе тараеп китте. Без ике егет — авыл сабантуе турында газетага очерк язарга дип кайткан ике аксөяк, Кәрим янында ничектер үзебезне уңайсыз хис итеп, бер-беребезгә караштык. Мәҗлес әле башланып кына килә һәм бу йортта квартирада торучы ике укытучы кыз да компаниядән гаять канәгать кыяфәттә безне чымырдап торган әче бал белән чын-чынлап сыйлый башлаганнар иде. Без инде берәр стаканны аллага тапшырып, бүгенге кичне күңелле генә уздырырга дип исәпләп тора идек. Барыбер сабантуй турында юньле очерк чыкмаячак. Авыл бик кечкенә, сабантуе да нибары өч сәгать дәвам итте. Батыр калган егетне дә очеркның үзәгенә салып булмаячак. Ул каяндыр шахтадан кайткан шушы авыл кияве булып чыкты. Булсын иде ул шушы колхозның көтүчесе яки механизаторы. Кыскасы, без редакциягә материалсыз кайтып керәчәкбез. Анысына инде без риза идек... Иптәш егетем белән безнең сүзсез калуны сизеп, самовар янындагы хуҗа агай бу бушлыкны тутырмакчы булды, ахрысы.

— Я, егетләр, нәрсә борыннарыгызны салындырдыгыз? Алтмыш яшьлек Каюм абыегызның җырлап биргәнен көтәсезме? — дип кулына стакан алды. Аннан тамагын кырып, карлыккан тавыш белән җырлап җибәрде:

Ленинград бигрәк ерак,
Башындай чүкеч-урак шул,
Башындай чүкеч-урак.
Кемне күрсәм дә аерылалмыйм
Сезнең хәлләрне сорап.

— Инде менә да эчмәсәгез, хәзер каенегә тапшырам эшне, — диде Каюм агай. — Энисе, кая әле, каенеңнең струментын алып кер әле.

Хуҗа хатын чоландагы бүлмәдән тузан сарган мандолина күтәреп кергәч, без гаҗәпләнешеп бер-беребезгә карадык: Кәрим һәм ман-

долина... Бу, нигәдер, башка сыеп бетми иде. Нигәдер, бу нечкә инструмент Кәримнең уч төпләре бирчәеп беткән каты, зур кулына килеп керү белән шартлап сытылыр сыман тоелды. Аннан, аның бармаклары! Алар шундый юаннар, тәмәке төтененә саргайган тырнаклары — нәкъ инде өлгереп коелган урман чикләвеге кабыгы. Баш бармагы кайчандыр балта тиюдән урталай ярылган булганмы, анысының төтенгә көйгән зур тырнагы май коңгызының сыртыдай җөйләнеп тора... Әнә шул кеше мандолинаның тузанын сөртеп, аны зың-зың чиртеп көйли башлады.

Безнең кызларыбыз, ахрысы, Кәримнең уйный алачагына шикләнмиләр иде, инде кайсы көйне уйнату турында бәхәс башладылар.

— Кәрим абый, зинһар, «Ике аккош»ны уйна!

— Юк, юк, башта «Зәңгәр төймә»не!

— Куйчы, шул көйнең нәрсәсен таптың, аны уйнаганчы «Ромашкалар»ны!

Кәрим аларны тыңладымы, юкмы, мандолинаны көйләп бетергәч, өстәл кырыннан бераз гына читкә китеп утырды да, аягын аяк өстенә куйды. Аннары бераз гына башын артка ташлады. Кинәт кенә бөтен кылларын бәреп аккорд бирде. Йөзенә елмаю чыкты. Ләкин мин шул вакытта аның күзләренә игътибар иттем: күзләр елмаймыйлар иде. Иптәшем, мәҗлеснең бу юлга кереп китүеннән бик тә канәгатьсезләнгән кыяфәттә, ачык тәрәзә янында тәмәке тартып дәшмичә утыра бирде.

Тирбәлгән кыллар зыңгылдавына Кәримнең йомшак, ягымлы тавышы кушылды.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары коела кулләргә шул.
Үзе дә юк, җылы сүзе дә юк
Калды сагынып кына сөйләргә...

...Бу көйгә мин тетрәнеп киттем. Хыялым мине еракка-еракка — бала чакның бер язына чигерде. Без, малай-шалай, әти-әниләребездән мең төрле хәйлә белән качып, кичләрен тау башына — егетләр-кызлар җыелган җиргә бара идек. Ул елны яз бик матур килде. Язның караңгы төнендә аста чурлый-чурлый аккан ташу тавышын тау өстеннән тыңлап торуы бик рәхәт була иде. Борынга парлы җир исе, тирес исе бәрелеп тора, язгы су чылтыр-чылтыр каядыр ашыга. Безнең капка төбеннән төшкән гөрләвек тә аңа кушыла. Безнең елганы Казанкага, ә Казанканы Иделгә коя диләр. Димәк, безнең абзар кырыеннан узган сулар Каспийга ук китәләр... Шуны уйлавы бик рәхәт тә, моңсу да була иде. Әнә шул елны тау башында безнең авыл егетләре шушы көйне өйрәнделәр. Аны кунак булып барган җиреннән, күрше авылдан кемдер өйрәнеп кайткан, имеш. Ул егетләр барысы да ат җигеп колхозда эшлиләр иде. Барысы да эреләр, барысы да шушы Кәрим кебек киң җилкәлеләр. Һәр кичне шунда тау башына җыелалар да, гармунчы килгәнне көтеп, ара-тирә сөйләшкәләп тәмәке тарталар. Кайсыдыр югары очтан ук ташу суына ут җибәргәли, боз өстендәге бер кочак утлы салам елтырый-елтырый бормалы су буйлап агып китә... Тальян моңы язгы кара төндә бөтен авыл урамнарыннан аккан гөрләвек тавышына кушыла. Һәм ат җигүче егетләр тирбәлә-тирбәлә салмак кына җырлыйлар:

Һаваларда очкан кошлар кебек
Ярсый-ярсый канат кагынып лай,
Туган илем, кайттым мин талпынып,
Дус-ишләрем, сезне сагынып...

Жыр төн урталарына кадәр шулай дәвам итә. Бу көй, без малайларны моңландырган кебек, ул егетләргә дә моңлы тоелгандыр, ахрысы. Бер кичне шулай безнең күрше егете Гаффан гармунчының җилкәсенә кулын куеп:

— Их, ичмаса өзмә үзәкне шушы көйне уйнап, — дип, егетләрдән аерылып кайтып китте.

Язгы сулардан ясалган яраларын җир әле төзәтеп кенә килә иде. Көтмәгәндә сугыш... Атна эчендә авылда ул егетләрнең берсе генә дә калмады. Сугыш башланганга ике ай дигәндә авылга беренче кара хәбәр килде: Гаффан бомбежкага эләгеп һәлак булган. Эре сөякле, юан беләкле егетләрнең сугыштан нибары берсе култык таяклары белән әйләнеп кайтты...

Бу көйне минем шуннан бирле бер генә тапкыр да ишеткәнем булмады. «Үзе дә юк, җылы сүзе дә юк...» Никадәр моң, никадәр фаҗига! Тукта, бу Кәрим каян белә әле моны? Һәм, гомумән, тупас куллы, ситса күлмәкле, кирза итекле, кырыктан узган бу кеше нечкә кылларны ничек алай моң белән җылата ала?

Мин инде ихтыярсыз Кәримнән күземне алмый карап утыра идем. Ә ул, берни дә сизмәгәндәй, төпсез күзләрен тәрәзә өстенә табарак терәгән дә, мандолина кылларын чирткән уңайга башын калтыратып, аякларын көйгә селкетеп йортка моң сибә:

Сезне уйлап иртән, һай, кичләрен,
Тыныч көннәр бер дә күрмәдем...

Ясап куйган чәйдән бер йотым авыз иткәч, Кәрим, урыныннан торып, барыбыздан да гафу үтенде. Каюм агайга, мич алдында әле дә мәш килгән апасына кат-кат рәхмәт әйткәч, аларны кунакка чакырды.

— Соңга калмагыз, иртәгә нәкъ сәгать уникегә, — диде. Аннан безгә карап:

— Сезне дә чакырам, безнең авыл сабантуен карарсыз, өебез дә, күңелебез дә иркен, — диде.

Без нәрсә әйтергә дә белмәдек. Апасы аны озата чыгып киткәч, Каюм агай шыпырт кына бер стаканны әйләндерде дә, бер пәрәмәчне тәмләп кенә юк иткәч, сөйләп китте.

— Каене бик задор егет минем. Шәп егет, һай-һай алтын кеше. Пачум зрә харап иттеләр бит үзен теге вакытта. Укытучы иде... Менә сезнең кебек яшь-яшь көе кырык бердә үзе теләп военкоматка китте. Унтугыз да тулмаганые әле ул чакта. Госпитальдә ятканда пленга эләкте малай. Шуннан үзегез беләсез. Кайткач укыта гына башлаганые — чакыртып алалар районга. Вәт, шулай-шулай, диләр, мондый эшкә ярамыйсың син, диләр. Ә бу бик шәп укытучы иде. Прәме бөтен авыл ярата иде үзен. Менә унсигез ел инде леспромхозда агач кисүче булып эшли. Алдынгы гел. Анда да яраталар. Почет тактасыннан төшкәне юк. Хатыны белән дә бик шәп торалар, молодец ул минем каене. Хәзер яңа закун дип әйтәләр дә, ызначит, үзе теләсә стажын кайтарып мәктәпкә керсә була дип. Юк, ди, бер иләнгән эштән китмим инде, ди. Иптәшләрдән уңайсызланам, эшемне дә яратам, ди...

Төнгә каршы ике кызны өйдә калдырып, без иптәшем белән һава суларга дип чыгып киттек. Ындыр артына чыгып бик озак йөрдек. Ул да, мин дә дәшмәдек. Ахрысы, без икебез дә бер нәрсә турында уйлый идек. Урманчы Кәримнең моңлы тавышы, мандолина кылларының өзгәләнеп тибрәнүләре белән тулган күңелне беребезнең дә ташытасы килми иде һәм без ындыр артында таң атканчы йөрдек тә йөрдек.

# КЕШЕ КҮҢЕЛЕ

Мәгъфүрә апа бик яшьли тол калды. Балалары да юк иде, гомере ялгызлыкта үтте. Ул мәктәптә каравылчы булып эшли иде. Йорт-жире, мал-туары да булмаганлыктан, үзенең бөтен рухи һәм матди дөньясын мәктәпкә бәйләде. Мәктәп янындагы кечкенә өйдә үзенә бер почмак ясады, чаршау корды, стенасына конфет кәгазьләре ябыштырды. Стена сәгатенең герен такта чәй укасына төреп асты. Аны вакытында су жылытмагансың дип тә, мәктәп бакчасына тавыклар кергән дип тә ачуландылар. Ә директор һәр алла бирмеш көнне иртән бер, кичен бер мәртәбә орышып килде. Һәр орышуының ахырында ул: «Эшлисең килсә эшлә, эшлисең килмәсә, дүрт ягың кыйбла, как хотите», дип тәмамлый иде.

Ләкин Мәгъфүрә апа үз гомерендә бер тапкыр да күз яшен күрсәтмәде. Аны ачуланучы күп иде, әмма дәшмичә генә мәктәп хуҗалыгын алып баручы ул үзе генә булды. Аның турында: «Мәгъфүрә жылый белми ул, аның ялгызлыктан күз яшьләре кипкән», дигән сүз дә йөри иде.

Гомерләр узды, көз айларының берендә мәктәп коллективы тантаналы рәвештә Мәгъфүрә апаны пенсиягә озатырга жыена башлады. Бер кичне мәктәпнең коридоры өлкән класс укучылары, укытучылары, мәктәп хезмәткәрләре белән шыгрым тулды. Местком председателе кечкенә өйгә кереп Мәгъфүрә апаны халык жыелган коридорга култыклап алып чыкты. Жыелган халык Мәгъфүрә апаны басып каршы алды. Баянда марш уйнап жибәрделәр. Барабан кагып, быргы кычкыртып тордылар. Мәгъфүрә апаны кызыл жәйгән өстәл артына утырттылар.

Мәктәп директоры сүз алды. Ул көр тавыш белән укып жибәрде:

«Мәктәп буенча приказ. 135 нче номерлы. Параграф беренче. Мәктәптә утыз ел буенча каравылчы хезмәтен намус белән башкарганы өчен Мәгъфүрә Зиятдиновага рәхмәт белдерәм.

Параграф икенче. Ялгызлыгына карамастан утыз ел буе тырыш хезмәт итүен искә алып, каравылчы Зиятдинованы бер күлмәклек штапель белән бүләклим».

Директор сүзне местком председателе Сибгатуллинга бирде.

— Иптәшләр, — диде Сибгатуллин, түшәмгә карап, — безнең кичәге утырышның карарын укыйм. «Протокол номер уңдүрт, 19 сентябрь. Тыңланды: пенсионерка Зиятдинованы яңа квартирага күчерү турында. Карар кылынды: Зиятдинованың утыз ел буе намуслы хезмәтен искә алып, аны, 21 сентябрьдән дә соңга калдырмыйча, укытучылар өчен салынган квартираның Нәжмиевләр белән тоташ ягына күчерергә. Карар бер тавыштан кабул ителде».

Приказлар укыганда һәм бүләкләр тапшырганда бер өзлексез баян уйнап, быргы кычкыртып, кул чабып тордылар.

Ниһаять, Мәгъфүрә апаның үзенә сүз бирделәр. Ул басты, иплэп кенә тамагын кырды, халыкка озак итеп карап торды да... кычкырып елап жибәрде.

Бу — тәбрикләүләргә каршы аның жавап сүзе иде.

# ТОРМЫШ ДУЛКЫННАРЫ

Дөнья безне таратты... Хәер, моның шулай булачагы безгә көтелмәгән хәл түгел иде. Институтның беренче курсында вакытта ук әле, бүмази чалбар, зәңгәр вельветка белән йөргәндә үк, бер-беребезнең истәлек дәфтәрләренә мондый сүзләрне язып куйган идек: «Тормыш

дулкыннары безне бервакыт таратыр, шул чагында син дә бу альбомны алып...» Менә альбомның беренче битендә үк Ишбулат истәлеге. Ишбулат — группада бердәнбер шагыйрь иде. Булачак агроном һәм шагыйрь... Бу инде бик оригиналь хәл иде. Безнең караватлар рәттән иде һәм Ишбулат белән серләшеп таң аттырган төннәр аз булмады. Шул чагында аның белән гомергә дус, сердәш булырга, киләчәктә дә кайгыбызны, шатлыгыбызны уртак бүләргә йөзләрчә тапкыр антлар биреште. Аерым яшәүне күз алдына да китерә алмый идек ул вакытта...

Альбом минем күңелемне йомшартты һәм, шәһәргә килгәч тә, Ишбулатны күрми кайтмам дип сүз бирдем.

Ишек какканда үк йөрәгем типкәнне ишетеп тордым. Биш ел вакыт — уен түгел. Үзгәрде микән? Чандыр гәүдәле дустым ни хәлдә икән?

...Җылытылган ишек шуып кына ачылды һәм ишек тутырып пижамлы бер гәүдә күренде. Ишбулат! Без кочаклаштык. Мин үземне баобаб кочаклаган эфиоп кебек хис иттем. Ишбулат та моны сизеп:

— Нәкъ йөз дә биш кило,— диде.— Пальто илле алтынчы. Миндә давление бит, давление.

Кухня ягыннан чуар халатлы, кыйгач кашлы, яшь шөпшәдәй нәзек билле, сөякчел ханым килеп чыкты. Минем кытыршы кулыма бер уч сөяк килеп керде. Чибәр ханым:

— Я, син, түргә чакыр кунакны, сквозняк бәрмәсен, — дип, Ишбулатны бүлмәгә таба этте. Мин бик шатланып диванга чумдым. Биш ел бит. Кайсы почмагыннан тотып сүз башларга? Үземнең ерак бер авылда ел буе ужымнар, камыллар, кар, тузан, пычрак арасында йөрүемнеме, колхозның бу елда ничек алдынгылар рәтенә чыгуы турындамы сөйләргә?

— Син минем шигырьләр җыентыгын алдыңмы әле?

Сүзне шулай итеп Ишбулат башлады.

— Менә өченче җыентыгым чыкты. Хәзер магазиннарда юк. Авыл хуҗалыгы темасын белеп язучы бик кадерле хәзер. Менә Мәскәү өчен берне әзерләп утырам. Көн саен хат килә, ашыктыралар. Уфада да чыгып ята берсе. Хәзер менә «Молодая гвардия» белән договор төзедем. Авыл темасы бик кадерле бит хәзер әдәбиятта...

Мин нәкъ шул турыда үзем дә сөйләмәкче идем. Әйе, хезмәт кешесен җырларга кирәк. Менә, мәсәлән, безнең колхозда...

— Ә авылга кайтырга һич вакыт юк, — дип бүлдерде Ишбулат. — Һаман шул китаплар белән. Берсен бетерәсен, уф дигәнче икенчесен күтәреп торалар. Аннан соң минем давление бит, чыгып йөреп булмый.

Мин инде Ишбулатка материал булырлык үзебезнең колхоздагы кайбер хәлләр турында сөйләргә дип авызымны гына ачкан идем: менә мин бирәм инде сиңа материалны, мин әйтәм. Биш ел буе агроном булып эшләгән кешене тыңлап кара әле син. Ләкин Ишбулат көтмәгәндә:

— Әйдә бер мат куйыйм әле үзеңә, — дип, шахмат күтәреп килде.

Үен башыннан ук кәефсез барды. Чөнки Ишбулат һәр адымын йөргән саен:

— Менә без моны чигерәбез дә сиңа шах бирәбез!

— Менә хәзер без сине китереп терибез. Я әле, чыгып кара!

— Әһә, эләктеңме! Менә ике ходтан мат була, — дип миңа авыз да ачырмады. Шуның өстенә, мин дәшмичә генә тегеме, бумы адымны ясарга торганда, кухня ягыннан теге кәтүк хәтле генә чандыр ханым килеп чыга да:

— Әтисе, син аңа атыңны бир!

— Әтисе, син аның пешкасын аша хәзер! — дип киңәш биреп тора.

Төнге сәгать унбер булды. Без инде дүртенче партияне уйныйбыз. Инде чәйләребез дә суынып бетте. Хуҗа хатын, үзенең вазифасын бөтенләй онытып, Ишбулатның тезенә утырган да котчыккыч энергия белән уенга катнаша. Ялгышрак адым ясаса, Ишбулатны сүгә, фигурасын урынына кире куйдыра.

— Җүләрме син, күрә торып офицерыңны бирергә? — ди.

Минем кәеф чигеннән чыгып кырылган иде, дүртенче матны куйгач, Ишбулат тагын бергә кыстады.

Сәгать төнге бердә мин гостиницага кайтып егылдым. Төне буе саташып йоклый алмыйча чыктым. Төшемдә чуар халатлы чандыр ханым кулына ферзь тоткан да, имеш, минем корольгә таба үреләә, шөпшәдәй, һаман колак төбендә әйләнә:

— Әтисе, мат! Җиңелде, мат! — дип кычкыра, үзе шаркылдап көлә.

Мин иртәгесен авылга кайтып киттем.

Дөнья безне шулай итеп таратты.

## ГАЛИЯБАНУ

Бу көнне халык ай ярым көтте. Кемнең кайсы рольне, нәрсә киеп уйнаячагы, кайсы пәрдәдә нәрсә булачагы барысы да мәгълүм иде. Чөнки авыл халкы кечкенә клубта репетиция барганда ай ярым буе актив катнашты, киңәшләр биреште ләр, колхоз хисапчысы Фәсхине инде Исмәгыйль, укытучы Алсуны Галиябану дип кенә йөртәләр иде. Утыз йортлык авылда өй эченнән спектакльгә кешесе катнашмаганнар самовар, читек, камзул, себерке күтәреп килеп сәхнәне әзерләштеләр, клуб янындагы өйдә Галиябануны бөтен авыл хатыннары җыелып бизәндерде.

Спектакльгә ферма каравылчысы Гарифулла белән сукыр Миңсафа карчыктан башка бөтен кеше килде. Мич артында, сәхнә буенда, тәрәзә төпләрендә балалар сырышкан, инә төртерлек тә урын юк иде.

Спектакль шома барды, суфлер тавышын уйнаучылардан берәрсе ишетми торса, залда утыручылар әйткәләп җибәрә тордылар. Тик соңгы пәрдәдә, Фәсхинең бер атна буе эш ташлап РТС мастерскоенда ясап яткан алтатары гына спектакльне бозды. Ягъни, Фәсхи шырпыны сызуга, алтатарның көпшәсенә төйгечләгән кәгазе чыгып китте. Моннан соң инде «шарт» итеп ату турында уйларга да ярамый иде, һәм көпшәдәге дары чыжылдап янып та бетте. Фәсхи бөтенләй өметсезлеккә бирелеп суфлерга пышылдады:

— Чукынып кына китсен, шартлатып булмады, нишлибез?

Халык, моны ишеткәч, тетрәнеп, тынсыз калды. Ләкин берничә секундтан арттагы рәттә тавыш куптардылар:

— Гыйлемханга йөгерергә кирәк!

— Гыйлемхан кайда, чык әле тиз бул!

— Аның өе ерак бит, Нурида да бар ул!

— Чыксын, чыксын, Гыйлемханны чакырыгыз!

Иң алгы рәттә, куян мамыклы шәл бөркәнгән хатынына сыенып, тальян гармунын тоткан аучы Гыйлемхан утыра иде. Эшнең төбен аңлап алгач, гармунын хатынына бирде дә артка таба кузгалды. Сәхнәдә Хәлил егыла алмый калган иде, шул хәлдә пәрдәне яптылар.

Сәхнәгә ирләр җыелды. Алтатарны әйләндерә-әйләндерә карадылар, Фәсхигә киңәшләр бирделәр. Берәүләр, Гыйлемхан озак торса, дары урынына шырпы күкерте генә салырга кирәк, диделәр. Аста утырган хатын-кызлар кечкенә балаларын җитәкләп клуб артына барып килделәр.

Бер янчык дары күтәреп Гыйлемхан килеп җиткәндә, клубта булган бөтен кешенең шырпыларын кырып алтатарны корып куйганнар

иде инде. Пәрдә ачылганчы дип, ашыга-ашыга, дәррәү түбәнгә төшеп киттеләр. Ыгы-зыгы арасында кемдер Фәсхинең кабызырга тиешле шырпысын алган икән, пәрдә ачылуга:

— Фәсхеттин, мә шырпыңны, — дип сәхнәгә ыргытты. Фәсхи шырпыны сызды. Шартлау тавышына кечкенә балалар сискәнеп киттеләр. Хәлил дә сузылып барып төште. Кайсыдыр, халыкны тынычландырды:

— Үлмәде ул, үлмәде, ядрәсе юк аның!..

Спектакль беткәндә халык:

«Рәхмәт төшсен сезгә, артистлардан да яхшы уйнадыгыз», — дип таралды.

## АЛЛА БАРМЫ?

Сәхнәдәге өстәл артында өч кеше — аксыл мыеклы галим, яшь чырайлы галим, сары чәчле, маникюрлы, кып-кызыл иренле чибәр кыз утыра. Алланың юклыгы турында инде ике галим дә озаклап сөйләгәннәр, сораулар бирүне көтеп утыралар. Клуб — шыгрым. Беренче рәттән алып соңгы рәткә кадәр яшьләр утыра, алар көне буе колхоз басуында бәрәңге чүпләгәннәр дә түземсезлек белән бу кичәнең тәмамлануын көтәләр. Югыйсә, танцыга вакыт калмый. Өлкәнрәклардән клубта берничә кеше генә катнаша. Шуның берсе — бригадир Зиннәт. Ул ишек янагына сөялгән, яхшы ук кызмача. Бәрәңге җирендә ул бүген шәһәрдән килгән галимнәр белән танышкан иде, дин турында сораулары күп булганлыктан, аның лекция вакытында бәхәскә керәсе килә иде. Әнә шунда кыюрак булыр өчен клубка килешли ул берәү белән дә бүлешмичә бер яртыны сындырып килде. Иң алгы рәттә Муллагали карт белән Мәрьямбикә түти. Муллагали агайга 92 яшь, ул сары туннан, каешланган күн бүректән. Ул, дөм-чукрак ук булмаса да, сүзнең күбесен ирен кыймылдауга карабрак тотып алырга тырыша. Берәр кеше аңа сүз башлаганда ук инде ул «Нәрсәме?» — дип сорап куя. Мәрьямбикә түтинең колак та яхшы ишетә, күз дә әйбәт күрә. Чөнки аңа 86 гына яшь әле. Ләкин бер бәласе — авыз эчендә им өчен генә дә бер теш калмаган. Кеше сүзен тыңлаганда ул да, ни өчендер, авызын метмелдәтеп тора.

Җыелыш озакка сузылды. Ак мыеклы галим борчылды — сорау бирүче күренми. Бөтен өмет бригадир Зиннәттә иде. Инде мөселман алласы, христиан алласы, будда һәм башка аллалар турында ике сәгать буе сөйләнгән, Вольтер, Ницше, Аристотельләрдән өзекләр китерелеп беткән иде.

— Я, колхозчы иптәш, сезнең нинди дә булса соравыгыз булырга тиеш? — диде ак мыеклы галим. Зиннәт аркасын ишек янагына ышкып алды, аның битләре чөгендер кебек кызарган иде, ул нәрсәдер әйтергә теләп авыз ачты. Ике сәгатьлек лекцияне ул башыннан ук тыңлаган иде.

— Минә миндә бер сорау бар, — диде Зиннәт, бераз алга узып. — Ничек дип кенә әйтергә инде. — Ул фуражкасын салып башын кашып алды. Галимнәр җанландылар. Карт галим чибәр кызга борылып:

— Надя, яз! — дип әмер бирде.

— Минә сез сөйләдегез инде, — диде Зиннәт, — ә шулай да әйтегез әле: дингә ышанырга ярыймы, юкмы?

Шуны гына көткәндәй, өстәл артындагы яшь галим сикереп торды.

— Академик Бартольд, — дип башлады ул үзенең сүзен, — болай дип яза...

— Нәрсәме? — дип җыерылды Муллагали агай.

— Әйе, академик Бартольдның бу фикере Бэкон фикерен юкка чыгара. Бэкон — урта гасырлар философы болай ди...

— Нәрсәме? — дип Муллагали агай алга таба бөгелде.

Яшь галим кызып-кызып Герценга килеп җиткәндә, Мәрьямбикә түти белән Муллагали агай торып ишеккә таба юл тоттылар.

— Әй, әй, сез кая болай? — дип, карт галим сикереп торды. Муллагали агай аңа борылып: «Нәрсәме?» — дигән арада, Мәрьямбикә түти сүз алды:

— Без карт белән, — диде ул, — алла турында сөйлиләр дигәч кенә килгән идек. Үзегез беләсез, утызынчы елда мәчетне япканнан бирле алла турында бер сүз ишеткәнебез юк. Ә сез монда әллә ниткән кәмидикләр сүзен генә сөйлисез икән. Белгән булсак, карт белән телевизор янында гына утырасы икәнбез. Бүген анда «Кигәвен» дигән кина күрсәтәселәр иде. Әйдә карт, карабрак атла...

Алар ишектән чыгып киттеләр, клубта олыраклардан бер Зиннәт басып калды. Ул кыюланып китеп:

— Рөхсәт итсәгез, миндә тагын бер сорау туды. Шулай да, алла бармы, юкмы? — диде...

## АХИРИ

Сез Яңа Бистәнең Баһауны беләсезме? Белмәсәгез, күп нәрсә югалттыгыз дип уйлагыз. Нәрсә, әллә сезнең кибетләрдән берәр әйбер эзләп тә, таба алмый йөргәнегез юкмы? Булса — Кул урамда яшәүче Баһауны күрегез. Баһау белән танышу — теге, сез эзләгән әйберне табу дигән сүз. Танышкан вакытта Баһауның менә кай якларына игътибар итегез.

Аңа исеме белән дәшәсе түгел. Аның иң яраткан сүзе — ахири. Үзеннең дусларың турында әйткәндә — әшнә. Директор, управляющий, мөдир, начальник урынына — хуҗа. Акча дип әйттеңме — бетте диген. Аның гомуми исеме — корт. Уңлык — бер акча, йөз сум — бер багана. Ике йөз дә егерме сум дип әйтәсе түгел — ике багана, ике казык. Әйберне саттым түгел, ә биеттем. Йөз граммны да эчтем түгел, дөпәдем. Тәмәке — дохан. «Син мөселман, мин мөселман, әйдә, ярар инде, чорт с ним», — дип тә җибәрсәң, Баһау — синең мәңгелек дустың. Баһау элегрәк иске пристаньда ларекта эшли иде. Пароход юк вакытта Баһау — күңелсез генә бер кеше. Ларегындагы иске гәзитләрне укып, доханлап тик утыра. Гәзитне ул рәттән укый. Анда Англия королевасының туган көне дә, Гвинеядәге бер егетнең буар еланны үтереп тиресен салдыруы да, Франциядәге почта хезмәткәрләренең забастовкасы да Баһау тарафыннан бертигез кызыксыну белән укыла. Ләкин... ах! Пароход килеп җитте бит! Менә инде шунда Баһау бөтенләй үзгәрә. Ул салам эшләпәсен киеп куя, битенә ярты уч одеколон сибә, ларек алдына куйган күн бүрекләрне, эш бияләйләрен щеткалый башлый. Кәрзин күтәреп җиләк сатарга килүче Ослан марҗаларын, Тәмте татарларын, чия сатарга килүче чувашларны Баһау ерактан чакырып ала.

— Агай-эне, пакъ сиңа дип кенә калдырган бер бүрек бар!

— Сеңелем, этиеңә менә бу эшләпәне алып җибәр, актыгы!

— Абзый кеше, артыш агачыннан ясалган бик һәйбәт трубка бар! Гомереңә рәхмәт әйтерсең!

Һәм, ни хикмәт, пароход халкы Баһауга чиратка тезелә. Тузанланып беткән, бәясе төшерелгән күн бүрек, әле җиләгеннән бер тиен табыш тапмаган абзыйның башына инде менеп утыра, кырык җиденче елгы реформага кадәр үк промкомбинат эшләп чыгарган трубка инде чия сатарга килгән Бәчи агайның сары мыегы астында тирбәлә. Ә Баһауның күзләре елтырый, йөрәге дөп-дөп тибә, шатлыктан куллары калтырый. Ул арада булмый, бер читтә кыюсызланып торган

яшүсмер егетне чакырып ала да күз ачып йомганчы тегенең чәченә одеколон бөркә:

— Әйдә, син мөселман, мин мөселман, игелеген күр, менә бу синеке, — дип, аның башына салам эшләпәне киертеп тә куя. Пристаньда Баһауның танышы — чутсыз. Сыра сатучы хатын анын ларегына графин белән салкын сыра китерә. Баһау аңа ишеккә кагарга ун метр лампа филтәсе бирә. «Бүтән бер жирдә дә юк, ахири итеп кенә бирәм», — ди. Галантереяда эшләүче Котдус узышлый гына аңа бер пар замша перчатка калдыра — Баһау аңа сигез килолы банка белән ак буяу тоттыра.

— Кортын иртәгә китерермен, күпме тора? — ди Котдус.

— Әйдә күп сөйләшмә, син мөселман, мин мөселман, акча белән башма баш, — дип елмая Баһау.

Халык таралганда Баһауның ларегында тычкан башын ярырлык бушлык була. Ул, инкассатор килгәнне көтеп, тагын күңелсез генә иске газитләрне укып утыра. Бу — элегрәк шулай иде.

Заманнар үтте, Баһау сату иткән жирләрне Идел каплады. Яңа пристаньда яңа, якты кибетләр ачылды, затлы товарлар күбәйде. Ләкин Баһау пыяладан төргән бу якты кибетләрдә эшләргә кызыкмады. Хатыны аны үз янына заводка алдырды. Чир бетәр, гадәт калыр, диләр. Баһауда да нәкъ шулай булды. Баштарак, заводтан арып кайткан көннәрдә, ул төне буе төшендә сату итте. Еш кына:

— Сигез сум кырык биш тиен.

— Нәкъ жиде тәңкә, — дип сөйләнә иде. Хатыны да, моны тыңлап, иртәгесен заводка барганда:

— Әй, дим, сигез сум кырык биш тиен нәрсә бәясе, — дип сорый. Баһау ике дә уйламыйча:

— Күн бүрек, — ди.

— Ә ике сум алтмыш тиенлеге нәрсә?

— Салам эшләпә, — ди Баһау һәм авыр итеп сулый. Бу вакытта ул иске пристань ягына таба моңланып карап та ала. Заводта ул, дөрес, алдынгы эшчеләрдән берсе саналa. Шулай да фикере белән чын эшче булып бетә алмый Баһау. Иптәшләре эштән кайтышлый стадионга билет алырга чиратка басалар. Баһау исә, «Монда минем бер эшнә бар» дип, билетны арттан гына ала да чыга. Кеше гастрономга кереп берниңди чиратсыз селедка үлчәтеп ала — Баһау алай итми. Ул бер селедка алыр өчен берәр таныш кибетчесе очрагaнчы шәһәр буенча йөри. Очратса:

— Кая, ахири, юньлерәген алып чыгып бир әле, — дип, йомарланып беткән берлекне кассага түләми, кешегә күрсәтмичә генә эшнәнең кулына төртә. Тиен-миенне кайтарып алмый. Хатыны шимбә көн кер сабыны, тоз, шырпы күтәреп кайтса — Баһауның кәефе кырыла.

— Ник үземә генә әйтмәдең, суконныйда минем бер эшнә эшли, шуннан үзем юньлерәген алыр идем, — ди.

Күптән түгел генә Баһауны үзем дә очраттым.

— Бер табак яхшы пыяла кирәк иде, чава-то таныш малай килмәгән эшкә, — дип, хуҗалык товарлары кибетендә пыялалар өеме янында тора иде.

Әнә шундый инде ул Баһау.

——□——

*Гамил Афзал*

## Җанга якын урыннар

Җырларыма инеп,
Уйларыма тулып,
Хисләремне тарткан урын бар:
Дулкынланып торган диңгез булып
Тәрәзәмә карый уҗымнар.

Шул басуны ярган,
Бормаланган,
Бабайлардан калган юл үткән.
Гомер-гомер
Кулы яргаланган
Ач кешеләр ачы тир түккән.

Басу юлы.
Рәшә зәңгәрлеген
Чыклы таңда кемнәр таптаган!
Биштәр асып чыгып киткәннәрнең
Кайсы кайткан,
Кайсы кайтмаган!?

Кай җирләрдә яттың, җанкаем, дип,
Сине сагынып елыйм таң саен, дип,
Кайтмый калганнарның моңын көйләп
Юл буенда боега ак каен.

Ургып,
Кайнап торган сары ташу
Җилгә шаулый, җилгә тирбәлә.
Иңкүлекне иңләп килгән басу
Тәрәзәмә килеп терәлә.

Шул басуны ярып,
Borгаланып
Зур юл китә кырлар түренә.
Җирнең күккә тигән җиренә барып
Шау чәчәкләр белән күмелә.

Әйләнеп кайт тизрәк, дускаем, дип,
Мин көтәрмен сине көн саен, дип,
Яшь егетләр киткән юлга карап
Яшел яулык болгый ак каен.

Уңга-сулга авышып күләгәләр,
Якты таплар йөгерә тоташтан.
Басу артындагы әрәмәләр
Агыйделгә барып тоташкан.

Басу юлы,
Ашлык китеп бара,
Яшел машинага төялеп.
Апа-жинги озак карап кала,
Амбар ишегенә сөялеп.

Боегып калган камылларны тарап,
Әремнәрне кагып жил исә.
Соры бушлык тәрәзәмә карап
Оныттыра торган көн кәтә.

Күкне басып куксел болыт ята,
Вак иләктән янгыр яудырып.
Киек казлар китә жылы якка,
Тын кулләрнен ямен калдырып.

Басу юлы,
Шыксыз спас кәрә.
Лыч-лыч янгыр сибә көн саен.
Өзеп-өзеп игкән ачы жилдә
Өзгәләнеп утыра ак каен.

Тәрәзәдән карыйм ужымнарга:
Яшь ужымнар жилдә кипмәгән.
Жанга якын булган урыннарга
Кемнәр килеп,
Кемнәр китмәгән!

## Китабым

Киңәшчегә мохтаж кәнемдә
Сине кулыма алам.
Минеке дә бит син, түгел дә, —
Башка чыккан балам.

Син таңнарда кундың кулыма
Ак күгәрчен булып.
Гөлләр булып үстең болында
Хыялымда туып.

Мин егылган, жингән мәйданда
Син көрәшем минем,
Төннәр буе лампа янганда
Тамган яшем минем.

Син йөрәк түрендә яралдың,
Төн йокымны алдың.
Син халыкка китеп таралдың,
Ә мин карап калдым.

Юлларында язлар яшәрсен
Якты хисләр өчен!
Ил өстендә янгырап яшәрсен,
Минем көйле хөчем.

## Кичке моң

*Фәридә Кудашевага*

Башым катып ыбыр-чыбыр эшләр белән,
Урам буйлап пычрак ерып кайтып киләм.
Соры эңгер песи булып эчне тырный,
Бүген мине бер нәрсә дә кызыктырмый.

Моңайганда кырыс дөнья юк-барыннан,
Моң сибелде кичке авыл йортларыннан,
Моң сибелде көмеш таңга чәчкән кебек,
Күңелләрне әллә кая дәшкән кебек.

Дәшкән кебек аяз күкле еракларга,
Нурлар элеп хушбуй исле куакларга.
Яшерен янган хыялларым якын килеп,
Күз алдымда дөрләп бара ялкын кебек.

Моң тарала ашкындырып, юатып та,
Болыннарны, су буйларын буйлатып та,
Сандугачлы, тал-тирәкле Идел кебек;
Тын алуы рәхәт кебек, җинел кебек.

## Туган телем

Тарих таңы.
Яулап алган якты иртә.
Кирәк икән кояшка да кулым җитә.
Акыл көче йолдызларга очкан илдә
Кеше түгел, машина да гелгә килә.
Халыкларга хөрлек биргән туган илем,
Сине җырлап итәгенә башым идем.
Җырла диеп бирде миңа туган җирем.
Тукай телен,
Такташ телен,
Җәлил телен.

Шуны җуйсам, булам телсез бәрән генә,
Бәрәннәргә җан азыгы эрәм генә.
Ялгашыма карап кына яшәү кала
Шөкер итеп силос белән бәрәнгегә.

Ил тезүче
Алтын куллы оста үзем,
Җырым белән, сүзем белән якты йөзем.
Онытсам мин
туган телем —
бетә сүзем;
Якты көн дә кирәк түгел,
чыксын күзем!

# Гөлҗимеш

Әллә ялгыш,
Әллә язмыш кушып,
Баш калкытып дала уртасында,
Айга чаклы үрелергә тырышып
Бер гөлҗимеш үсте юл чатында.

Килә иде аның ачык җилдә
Кояш нурын эчеп көн күрәсе.
Кояш шаһит:
Якты аяз көндә
Таптап китте арба тәгәрмәче.

Җиргә сыгылып төште зифа буе.
Яшел каны тамды юл чатына.
Йөрәгендә ачу, нәфрәт тулы,
Тагын басты юлның уртасына.

Өмет туды аның йөрәгендә,
Хаклык килер, диде, золым бетәр.
Шул вакытта яшел күлмәгенә
Дегет сылап китте кара күчәр.

Ә гөлҗимеш үксеп елап калды:
Кайда шәфкать җирдә?
Кайда хаклык?
Бөдрә башын чайкап уйга талды.
Янгыр явып китте.
Менә шатлык!

Ул су эчте.
Яшел күлмәгеннән
Дегет табын сөртте җиргә ятып.
Әкрен искән дала җилләреннән
Дөнья хәлен белде.
Чәчәк атып,

Горурланып торды көчен сизеп,
Тамырлары тармакланып үскән.
Кибеп калмас өчен җиргә сеңеп,
Спорт кебек михнәт кирәк икән.

Аны тагын арба таптап үтте,
Бу юлы ул фәкать иелеп торды.
Дала буйлап көзге җилләр исте,
Ә гөлҗимеш рәхәт җиләс тойды.

Нужа күргән саен ныгый төшеп,
Көчле тамырларын кадап җиргә,
Иркә гөлләр сулган чакта өшеп,
Ул җимешен бирә ачы җилдә.

*Басыйр Рафиков*

## Хәтер саклый

Авыл ул чак тын була,
Йолдыз аткан төн була.
Гармун гына еракта
Серләр сөйли колакка.
Сагыш күңелдән ташып,
Уйлар китә адашып.
Бала чакның көннәре
Килә кебек алмашып.
Менә минем туган йорт,
Ындыр арты, яшел сырт.

Менә арыш кырлары...
Күктә сабан тургае.
Алтын таңнар атуы.
Әбиемнең катыгы.
Гаҗәп әкиятләр тыңлап,
Ат ашатып ятуы.
Ялан аяк әле мин,
Тормыш әчесен белмим.
Таң нурында шул чакта
Мин барасы юл ята.

## Кай арада

Кай арада бу малайлар
Егет булып җитешкән?
Бик җитди кыяфәт белән
Кайтып баралар эштән.

Кайтып баралар эштән,
Буй-сыннары килешкән.
Олылык та, горурлык та
Килгән боларга эштән.

●

Таш кыяны
Тимер тамыр белән
Тишеп үткән нарат.
Үз буыным турысында
уйлыйм,
Шул наратка карап.

## Төнге утлар

Бер-берсенә кушылганнар
Кебек йортлар.
Серле генә тирбәләләр
Төнге утлар.

Татлы йокыга уралгач
Кичке калам.
Соңга калып, урам буйлап
Кайтып барам.

Җилкенәм мин, кабындымы
Төнге утлар.
Алар мине чакыралар
Сирпеп уклар.

Мине тарткан тәрәзәдә
Ут бар, ут бар!
Маяк булып яна миңа
Төнге утлар.

●

Төн күзәтә мең күз белән,
Көн күрә бер күз белән.
Мәхәббәт күп сүз күтәрми, —
Әйтелә бер сүз белән.

## Бәхет юлы

Бәхет эзләп
Арт ишектән йөрмиләр.
Гадел хезмәт,
Белем аша үрлиләр.

## Картлыгыма нәсихәт

Чәч бәсәрү
Бик күп кенә
Бурыч куя.
Һәр кеше дә
Өлкәннәрне
Үрнәк тоя.

Чәч бәсәрү
Түгел әле
Ат казану.
Кирәк аны
Горур итеп
Йөртә алу.

## Урманчы истәлегенә

Агач арасыннан
Бөре исе агыла.
Буйга житкән чыршы
Кырынмаган бите белән
Миңа кагыла.
Йөрим делянкала,
Исемә төшерәм сине,
Син юк инде, —
Миңа күңелсез...
Чыршыларың үскән —
Син аларда
Яшисеңдер кебек үлемсез.

——□——

*Нурихан Фәттах*

# УЛЫМ ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

## Мөгез

Минем улым инде бик зур булды. Аңа хәзер ике яшь тә ике ай һәм фәлән көн! Ул безнең күз алдында үсә бара, һөнәрләрен арттыра бара, әледән-әле шуклыклар уйлап чыгара, исне китәрә...

Яз җиту белән мин улымны авылга кайтарып куйдым. Кайтуның беренче көнендә үк мин аны ишек алдына алып чыктым да шундагы барлык кош-корт һәм мал-туар «халкы» белән таныштыра башладым.

Сыерны аның әле беренче мәртәбә күрүе. Шуңа күрә ул сыерга бик озаклап, исе китеп карап торды.

— Менә, улым, бу сыер дип атала,— дидем мин аңа.— Сыер безгә сөт бирә. Сөтне ул әнә теге җиленнәнә җыя... Әнә аның да күзләре бар, борыны, колаклары бар. Әнә теге, башындагы очлы шома нәрсә мөгез дип атала.

Икенче көнне мин иртүк улым белән тышка чыктым. Чыксак, кызыл сыер башын чиләккә тыккан да, чиләк бавын шалтырата-шалтырата, нидер ашап тора. Улым кичәге танышын күрде дә шатланып кычкырып җибәрде:

— Мөгез ашый! — диде.

## Җиләк

Җәй азаклары иде. Беркөнне кичкә таба без улым белән икәүләп ындыр артына, басу ягына чыгып киттек. Җир башындагы кечкенә болын инде чабып алынган иде. Шулай да чыршы төпләрендә, түмгәк тирәләрендә куе үлән торып калган иде. Без улым белән шул үләннәр арасыннан хуш исле чәчәкләр җыйдык, Тукай бабайның бала белән күбәләк турындагы шигъри юлларын такмакладык.

Шулай чәчкә җыеп йөргәндә чыршы ботагы астында бер зу-ур җиләк күреп алдым. Җәйнең бу вакытында шундый эре, шундый кып-кызыл җиләк табу үзе бер бәхет.

— Карале, улым, җиләк! — дидем мин, куанып.

Улым миннән дә ныграк куанды. Нечкә генә, йомшак кына бармаклары белән җиләкне шундук шырт итеп өзеп алды да уймак кадәр генә учына йомды.

— Аша, улым. Куяннар аны сиңа дип калдырганнар,— дидем мин.

Шуннан соң без ары китеп бардык. Бераз йөрдек тә өйгә таба борылдык. Мин улымны кулга күтәрдем.

Кайта торгач, улым кинәт көйсезләнә башлады. Җиргә төшәргә сорый бу.

— Нәрсә булды, ник төшәсең? — дидем мин.

— Төсәм! — диде улым, шыңшып.— Зиләкне югалттым... Әннәгә алып кайта торган зиләкне югалттым!

## Бака

Беркөнне мин улым белән Җәлилне, ягъни улымның күршедәге яшьтәшен ияртеп дә авыл янынннан гына ага торган елга буена китеп бардым. Елга дигәч тә, аны алай елга дип әйтерлек тә түгел: сай гына, тар гына. Шулай да без чишендек тә су керә башладык.

Бераздан мин балаларның икесен дә түбәнгәрәк, суның тирәнрәк төшенә алып киттем. Күрәсең, безнең якынлашканны сизенеп, шул чак яр читеннән суга бака сикерде. Улым баканың суга чумганын күреп калды, туктады да гаҗәпләнеп карап тора башлады.

Озакламый без өйгә кайтып киттек.

Икенче көнне төштән соң кетмәгәндә улым юкка чыкты. Күршеләргә кергән идем, Җәлил дә өйдә юк. Мин бөтен җирнең астын-өскә ките-

реп балаларны эзләргә тотындым. Ләкин, никадәр генә эзләсәм дә, бер җирдән дә таба алмадым. Бераздан ничектер күңелгә килде: туктале, елга буена китмәделәр микән болар, дидем дә ашыгып шунда йөгердем.

Барсам, Җәлил белән улым икәүләп яр астыннан менеп киләләр! Үзләре нидер сөйләнәләр, үзләре ашыккан булалар. Икесе дә анадан тума шәп-шәрә — күлмәк-ыштаннарын кулларына тотканнар, чыланып, пычранып беткәннәр.

Балаларның елга буена качып китүләре һәм чак-чак кына суга батып үлми калулары ул көнне безнең өчен бик зур вакыйга булды.

Шушы вакыйгадан соң берничә көн үткәч, мин җайлап кына улымнан:

— Ник бардыгыз анда елга буена? — дип сорадым.

— Без, әттә, суга баткан баканы эзләлгә балдык, — диде улым.

## Баганалар

Бер кечне улым белән урам йөрергә чыктык. Улым урам читендәге электр баганаларын күрде дә, исе китеп:

— Баганалал нинди зул булып үскән! — диде.

## Мичне аударам!

Мин ике куллап мичкә тотындым да, шаяртып:

— Мичне аударам! — дидем.

Плитә янында торган улым чыркылдап кычкырып җибәрде:

— Аудалма! Сөтне түгәсең! — диде.

Карасам, плитә өстенә аның өчен сөт җылытырга куйганнар икән.

## Авылдан кайтканда

Көзгә таба, поездга утырып, Казанга кайтып барабыз. Шулай бара торгач, улым ниндидер гаҗәп нәрсә күреп алды.

— Калале! — диде бу кисәк кенә.

Мин ул күрсәткән якка әйләнеп карадым. Карасам, каршыда улым кебек бер кечкенә кызый басып тора. Аның нәрсәсенә гаҗәпләнде икән соң? Ике куллап тоткан зур, алсу алмасына микәнни? Күрәсең, шуңадыр.

Чыннан да, минем икенче якка борылуым булды, улым кинәт минем җиңнән тартты.

— Алманы капты! — диде, коты алынып.

Күп тә үтмәде, тагын кычкырып җибәрде:

— Ашый башлады! — диде һәм... еларга ук кереште.

——□——

*Габдрахман Әпсәләмов*

# УНСИГЕЗ ЯШЬ

*Очерк*

Зур башлы, ябык кына малай, чыбыркы сабын тотып арбага баскан да, күзләре белән торналар төркемен озата. Моңлы итеп кычкырып, тонык кургаш төсендәге күк буйлап җылы якларга очалар алар. Сугышның бер елын башыннан кичергән Миңнулла икенчесе никадәр авыр буласын йөрәге белән нык сизә. Җитмәсә, әтисе дә фронтта, әнисе алты бала белән берүзе торып калган. Балаларның иң өлкәне ул, Миңнулла, аңа инде унҗиденче яшь. Ләкин буйга бик кечкенә, шуның өстенә ашау ягы да бик такы-токы булганга, бөтенләй үсмер бала гына булып күренә. Шулай да ул ир кисәге. Әгәр чөелдерек яки аркалык өзелсә, хатын-кызлар аны чакыралар. Капчыкның да авыррагы аңа эләгә.



Сүз арасында шуны да әйтеп китик, Миңнулланың чын исеме Миңнулла түгел, ә Хикмәтулла. Бу турыда әче катып көлә-көлә әнисе сөйли торган иде: Хикмәтулла акыл иясе дигән яхшы сүздән алынган булса да, гади халык арасында аның шаян ягы да бар икән. Тузга язмаган эшләр эшләүчеләрне дә шулай диләр икән. Бер тапкыр, бала вакытында, Хикмәтулла бик каты авырып киткән. Билгеле инде, ул чакта якын-тирә авылларда врачфәлән булмаган. Тирән борчуга төшкән ата-аналар мәхәллә мулласын чакырганнар. Мулла шунда гаҗәп «акыллы» диагноз куйган: янәсе, исеме җисеменә туры килмәгәнгә күрә бала авырган. Бу хәл баланың ата-анасын тагын да зуррак куркуга салган, алар бик гозерләп мулладан җисеменә туры килә торган исем кушуын үтенгәннәр. Исем кушкан чагында мулла, гадәттә, дога укый, башын әле уңга, әле сулга борып, балага фәлән-фәлән исем бирелә дип, әкрен генә кычкыра, аннары шуны ук баланың колагына пышылдый. Бу юлы бөтенләй гадәти булмаган хәл башкарылганлыктан, мулла хуҗалардан самовар трубасы сорап ала һәм, фәрештәләр игътибар итсен диптер инде, трубаны әле уңга, әле сулга борып, баланың исеме алмаштырыла, ана яңа исем — Миңнулла бирелә, дип кычкыра. Әмма үзе метрикада төзәтергә оныта. Соңыннан, күп еллар үткәч, комиссиягә баручыларның исемлеген төзегәндә аңлашылмаучылык килеп чыга: митрика буенча караганда Куки авылында Миңнулла дигән малай гомумән юк, Хикмәтулла дигән малай гына, әмма ул малайның кая киткәнен берәү дә белми...

Беркөнне күрше чуваш авылына бәрәңгегә барырга дип, бәләкәй чана төзәтеп

утырганда, өстенә иске тун кигән, йөзен сакал-мыек баскан бер кеше өйгә килеп керде. Миңнулла бу ябык һәм авыру кешегә танымыйча бик озак карап торды. Ахырда аның күзләре зур булып ачылып киттеләр:

— Әти! — дип кычкырып җибәрде ул.

Әтисе чолганышта калган булган икән, ачлыктан бик каты газапланган, аннары, фронт аша чыкканда, дошман пулясы кулбашын яралаган. Бәхеткә каршы, ниндидер бер рус карчыгы аны яшереп тоткан. Җае чыккач, үзебезнең якка үткән, хәзер аны хәл алыр өчен авылга җибәргәннәр.

1942 нче елның апрелендә әтисе янадан фронтка китте. Аны озатканда Миңнуллага бик тә кыен булды, ләкин шул ук вакытта ул эченнән горурлана да иде: әтисе янадан фашистларны кыйнаячак...

Шул ук елның сентябрендә коточкыч авыр хәбәр алдылар: фронтта әтиләре һәлак булган. Өйдә елау-сыкрау купты. Миңнулланың да елыйсы килде, ләкин сеңелләренә күз яшен күрсәтергә ярамый иде, ишек алдына чыгып, бик озак бер ноктага текәлеп утырды. Аннары аны колхоз идарәсенә чакырдылар. Элеваторга ашлык ташырга куштылар.

Миңнулла шулай иртә таңнан кичке караңгыга кадәр колхозда эшләде. Буйга да ярыйсы гына үсте, иңбашлары да киңәйде. Үзен-үзе тотышы да үзгәрде аның. Күп нәрсәне аермачык төшенә башлады, әнисенең күзләрендә яшь күрсә, инде хәзер электәге кебек читкә борылмады. Ул күз яшьләре күңелендә моңарчы булмаган бик күп тойгылар уяттылар.

Тормыш никадәр авыр булмасын, вакыт тукталып тормый. 1943 елның язы да килде. Бу вакытта сугыш барышында зур үзгәрешләр булды. Сталинград эпопеясы Совет Армиясенең җиңүе белән тәмамланды.

Томанлы һәм җылы апрель көннәренең берсе иде. Ул елны яз иртәрәк килде, чәчүгә дә башка елларга караганда иртәрәк чыктылар. Ләкин бу елны Миңнуллага чәчү тәмамланганчы колхозда калырга туры килмәде. Атларны ял иттерергә дип тукталганнар иде, авыл ягыннан ялан аяклы бер кыз бала йөгереп килде:

— Абый, — диде ул Миңнуллага, — сиңа авыл Советына килергә куштылар, военкоматтан повестка бар...

Егетнең йөрәге сулкылдап куйды. Ул үзен кинәт зур итеп, солдат итеп сизде. Шунда аны хатын-кызлар сырып алдылар, берсе берсеннән уздырып кызгана башладылар: янәсе, бу балаларны кая алалар, алар анда, фронтта, нишлиләр инде? Миңнулла олы күренергә тырышып кашларын җыерды да сүрән генә:

— Кирәк булгач, алалар аны! Атларны карагыз, яме, — дип, беркемгә дә карамыйча, авылга таба китте.

Безнең халык юл кешесен хөрмәт белән озата. Илне сакларга китүчеләрне бигрәк тә инде. Әмма бу елларда юлга җибәрергә хәтта икмәк тә юк иде. Колхоз председателе дүрт килограмм вика бирде. Миңнулланың әнисе шул виканы табада кыздырды. Миңнулла аның да яртысын сеңелләре белән энеләренә калдырды. Юл капчыгына ул мичтә пешкән бәрәңге белән бер пар чабата салды да дәһшәтле сугыш давылына чыгып китте. Бу вакытта аңа унсигезенче яшь иде...

Фронтка Миңнулла 1943 елның азагына таба гына эләкте. Җәй буе Мәскәү янындагы запас полкта сугыш эшенә өйрәнделәр. Җитез һәм һәрнәрсәне белергә тырышучы Миңнулла, ару-талуны белмичә, авыр солдат йөген тартты да тартты. Урыны туры килсә, шаян сүзләр кыстыргаларга да, шаян такмаклар җырларга да ярата торган иде ул. Русча «чыктым аркылы күпер» дип кенә сөйләште, родларны бар дип тә белмәде. Әмма политрукларга аңардан да күп сораулар бирүче кеше булдымы икән! Ул барысын да белергә һәм төшенергә теләгән иде. Тышкы кыяфәте дә Миңнулланың шактый алмашынды. Дөрес, буйга әллә ни күтәрелмәде, әмма теләсә кемне келәшчәдәй нык итеп кысып алырга көче җитә иде.

Ниһаять, аларны фронтка озаттылар. Эшелоннан төшкәч тә, Миңнулла тирә-ягына бик озак карап торды. Шул була икән инде Украин җире. Әтисе бу җир турында күп сөйләгән иде шул. Чыннан да тәмам җәрәхәтләнеп беткән икән, һәр карышы үч алырга чакыра кебек.

Командирлар килделәр. Нинди частька алырлар икән? Артиллериягә алмаслар да

алмаслар, буең кечкенә диярләр. ПТРга да ярамас, мондый кәрләгә шундый озын мылтык бирәләр димени. Пулемет белән миномет шулай ук авыр булыр. Автомат дисәң тагы. Һәм Миңнулла Гыйззәтуллин Егерменче гвардия бригадасының автоматчысы булып китте. Мото-укчы батальонда аны взвод разведкасына билгеләделәр.

Беренче сугыш алдыннан Миңнулла бик нык дулкынланды, кирәгеннән артык ыгы-зыгы килде, борчылды, кызды. Туплар ата, самолетлар үкерә, җир урыныннан куба башлагач, Миңнулланың бөтен эчке әгъзалары бугазына килеп тыгылды, күкрәге мондый киеренкелеккә түзә алмас, ярылыр кук тоелды. Күзләре очкынланып кабынды. Тора-бара калтыравы бетте. Взвод командиры гвардия лейтенанты Ефремов урыныннан торгач, Миңнулла да аңа иярде. Ефремовка күп булса кырык яшьләр булгандыр, ә унсигез яшьлек егеткә ул күпне күргән ир булып тоелды. Миңнулла аңа җаны-тәне белән ышанды.

Разведка — командирның күзләре белән колагы диләр. Миңнулла бу сүзләрне күп мәртәбәләр ишетте, әмма сугышта моның ничегрәк буласын күз алдына китерә алмады. Гвардия лейтенанты Ефремов разведчикларын әйләнеч юллардан алып бара башлагач, тәҗрибәсез Миңнулла хәтта пошына калды. Ул үзе сугышның уртасына кереп, һәлак булган әтисе өчен дә, әнисе белән сеңелләренең кайнар күз яшьләре өчен дә үч алырга теләде.

Безнең гаскәрләрнең һөҗүме иртән башланды, ә кич белән Миңнулла Гыйззәтуллин кебек сугышта беренче мәртәбә катнашкан кешеләр өчен беренче мәртәбә Верховный Башкомандующийның рәхмәте килде. Әчкә сыймаслык зур шатлык яшь солдатның күңелен биләп алды. Ул үзендә бик зур көч һәм гайрәт сизде: әйдә, буйга барып чыкмаса да, акыл белән алдыра ул. Монысы иң кыйбаты!

Хәзер инде сугышлар көнен дә, төнен дә дәвам итәләр. Еш кына йокыны, ялны, ашау-эчүне дә онытырга туры килә. Әле пычрак ерып шуышалар, әле тын да алмыйча яталар, әле дошман өстенә ташланалар. Кирәк белән дә аз эшләмәделәр алар. Миңнулла бер нәрсәне бик нык төшенде: сугыш барыннан да элек кайнар эш икән. Ә эшне Миңнулла кече яшьтән ук татып үсте.

Бер тапкыр кыска ял вакытында өлкән генә разведчик Миңнулла янына утырды да махра төрә-төрә:

— Син, энекәш, начар сугышмыйсың икән, — диде, — кыю да, батыр да икәнсең. Моның өчен мактарга да ярый. Ләкин бераз шальной син. Сугышта бу һич ярамый. Төшенәсеңме минем ни әйткәнне, Мишутка, ә? [1]

Миңнулла кызарды. Әлбәттә, разведчикның тел төбен ул төшенде: кыза шул ул. Аннары иптәшләре куркак дип әйтмәсеннәр өчен дә тырыша. Түземлеге дә житенкерәми аның. Хәер, командиры Ефремов берничә тапкыр аны мактап телгә алды. Дөрес, болар барысы да кызу эш арасында гына булды, махсус строй алдына чакырмады. Ләкин җылы сүз таш эретә диләр бит.

Ефремов баштарак бурычны кат-кат аңлата, аннары, дөрес аңлаганмы дип, янә кат-кат кайтарып сорый торган иде. Кыю, зиһенле Миңнулла мондый төпченүне бер дә өнәмәде. Командирның кыска гына итеп:

— Миша, алга! — дип әйтүе аңа житкән иде. Командирны кул хәрәкәтеннән, күз карашыннан, ярты сүзеннән аңламасаң, нинди разведчик син. Ул, күз ачып йомганчы, куаклар арасында югала һәм шулай ук командир алдына тавыш-тынсыз калкып, аңа сугышчан бурычның үтәлүе турында егетләрчә рапорт бирә иде. Ләкин егеткә караганда тәҗрибәләре әллә ничә мәртәбә артыграк булган иптәшләре аңа сиздермичә генә ярдәм кулын сузмаса, мин-минлегенә тимичә генә аңа солдат һөнәрен төшендереп тормаса, Миңнулла исән булыр идеме икән. Моны ул үзе дә бик яхшы сизә һәм уңайсызлануын яшерер өчен, ак тешләрен күрсәтеп, көләргә тотына иде.

— Башым ярык минем, акылым коелган, — дип русча вата-сындыра әйтеп куя иде. — Миңа дигәнне автоматым төшенә.

Сугыш бит ул сугыш инде, кайчакта һөҗүм итүче гаскәргә дә бик кыенга туры килә. Бер карыйсың, дошман аларны алган җайлы позицияләреннән бәреп чыгара, икенче карыйсың, югалтуларның исәбе-хисабы юк, взвод та, батальон да, хәтта брига-

[1] Сугышчан дуслары кайчак Миңнулланы Мишутка дип тә йөртәләр иде.

да үзе дә туздырылган сыман. Мондый сәгатьләрдә, кайчакта, хәтта кеннәр буе да уяны-сулны белә алмыйсың. Сугышчы, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, эш йөртә белергә тиеш. Гомумән, сугыш бик күп билгесезлекләрдән торган хисап мәсьәләсе икән, акылың, өлгерлегең булмаса, монда берни дә кыра алмыйсың. Бигрәк тә разведчик, чөнки күп вакыт аның янында командиры да булмый. Ул аерым-аерым кисәкләрдән бер бөтенне тәшкил итәргә тиеш. Дошман бит юләр түгел, карталарын ачып куймый, киресенчә, яшерә генә. Аннары тагын шунысы да бар: разведчик автомат, граната һәм хәнҗәр белән генә эш итә белергә тиеш түгел икән. Кирәк икән ул артиллерист та, сапер да, пулеметчы да була белсен...

Иптәшләре Миңнулланы гел шаярталар иде. Миңнулланың аңа хәтере калмый, шаярып җавап та кайтара белә. Җырлый башласалар, ул шулай ук читтә калмый. Аның тавышы башкаларныкыннан аерылып тора — саф, яңгыравык.

— Каян чыга бу тавышың, шайтан малай, — дип гаҗәпләнәләр иде аңа кайбер иптәшләре.

Кыска, бик кыска була разведчикларның ял сәгатьләре. Күбрәк алар хәрәкәттә, алда. Бик еш сугышчан дусларын югалталар. Кемне булса да исемсез сукмаклар буенда я җирләп калдыралар, яки плащпалаткаларына салып алып кайталар. Взводта Миңнулланың якташы бар иде, аны да яраладылар. Бу югалту яшь егеткә бик авыр булды, ул туган җире белән үзен бәйләп торкан нечкә җепнең өзелүенә бик көенде.

Ничектер бер дә сиздермичә генә кыш үтеп, 1944 елның язы килде. Хәер, март аенда Татарстанда әле кар була, кырлар ап-ак. Бирегә, Буковинада исә, бөтен нәрсә яшеллек эчендә. Составына Егерменче бригада кергән генерал Катуковның танк армиясе, дошманның каршылыгын сындырып, чамасыз пычрак ерып, ташыган елгачыкларны кичеп, зур су — Днестрга якынлаша иде.

Разведчиклар Днестр ярына беренче булып җиттеләр. Мул сулы елганың аръягында, текә ярда, яшел агачлар эчендә курорт шәһәре — Залещики күренә иде. Миңнулла Гыйззәтуллинның гомерендә курортларда булганы юк, ул хәтта кешеләрнең берни дә эшләмичә, ял итеп кенә торуларын башына да сыйдыра алмый иде.

— Өйләре нинди матур! — диде Миңнулла, сокланып. Бу шәһәр аңа кызганыч булып тоелды. Тиздән сугыш уты аны тәмам яндырып, җимереп бетерер бит.

Ул әле яңарак кына комсомол җыелышыннан кайтты — аны комсомолга алдылар. Миңнулланың күңеле моңарчы булмагандай сугышка атлыкты, ләкин бу матур йортларны бер дә ватасы, җимерәсе килмәде. Ул үзенә хас бер дәрт белән:

— Шәһәрне тизрәк азат итәргә, җимерергә ирек бирмәскә кирәк, — диде.

— Чү, тик кенә тор, шальной, — диде олы яшьтәге бер разведчик. Шул чакта дошман яры меңләгән туплар белән үкереп алды. Тын елга өстеннән ут давылы үтте.

Ефремов йөгереп килде.

— Булса, көймәләр, булмаса, кул астындагы башка әйберләрне табарга кирәк, — диде ул. — Понтоннар артта калган, аларны көтеп, вакыт үткәрүдә мәгънә юк.

Һәрвакыттагы кебек, беренче булып, елганы разведчиклар кичәргә тиеш иде. Караңгы төшкәнче, алар яр буйларын тикшерделәр. Көймәләр юк иде, тик салга яраклы аерым агачлар, такталар, ялгыз бүрәнәләр генә таптылар. Ниһаять, алар тәмәке тарттылар да саллары янына киттеләр. Тәмәке тартырга өйрәнмәгән һәм шуна эшсезлектән ялыккан Миңнулла беренче булып салга сикерде.

Гитлерчылар ничек туры килсә, шулай гына аталар, кайчакта аларның снарядлары белән миналары суда да ярыла иде. Вакыт-вакыт ракеталар кабынып китә. Мондый чакта безнең разведчиклар немецлар ягыннан көчле ут көтәләр. Ләкин атышлар юк, әллә аларны күрмиләр, әллә хәйлә коралар. Тагын бераз көткәч, тәвәккәлләделәр. Елганы хәвеф-хәтәрсез кичеп, берьюлы ярга сикерделәр. Тып-тын. Дулкыннар һәм сирәк ату тавышлары гына ишетелә. Разведчиклар, барлык көтелмәгән нәрсәләргә әзер булып, ярдан мөмкин кадәр ераграк китәргә тырыштылар. Бераздан инде яр башында аларның автомат тавышлары яңгырады. Миңнулла әле шуышып барды, әле автоматтан сиптерде, әле бөтен көченә граната томырды. Беренчеләрнең берсе булып, ул траншеяга бәреп керде, каршы очраган ике гитлерчыны атып үтерде.

Төне буе разведчиклар кызу сугыш алып бардылар, төне буенча безнең гаскәрләр Днестр аръягына күчә тордылар. Күчкән берсе шунда ук сугышка да керде. Таң

алдында разведчиклар Залещики шәһәренә аяк бастылар. Алар артыннан калмыйча гвардиячеләр барды. Дошман белән каты бәрелештән соң, алар Залещики шәһәрен тулысынча азат иттеләр.

Гитлерчылар моның белән килешергә теләмәделәр. Совет сугышчыларын Днестр артына алып ташлау һәм оборона өчен җайлы позицияләрен кайтарып алу нияте белән алар кабат-кабат контратакага күчеп карадылар. Ләкин аларның һөҗүмнәре барысы да кире кайтарылды. Ниһаять, Залещики тирәсендә атышлар тынды. Ул арада Мәскәүдән шатлыклы хәбәр дә килеп төште: бик яхшы сугышканы өчен Егерменче гвардияче механикалаштырылган бригадага Залещики исемен бирергә!

Миңнулла бу сөенечле хәбәрне медсанбатта ишетте: ул мина кыйпылчыгы тиеп яраланган иде. Шатлык өстенә шатлык өстәп, аның беренче сугышчан бүләк — «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүе турында да хәбәр иттеләр.

Ничек булса да тизрәк взводына кайтып китәсе килде аның. Әйе, хәзер бөтенләй башка бит инде. Әтисе аның җиңү шатлыгының тәмен татый алмады. Ул иң авыр чакта — чигенгән вакытта һәлак булды. Ә Миңнулла инде бүтән солдат, җиңүче армия солдаты, азат итүче. Менә шуңа күрә аның күңеле дә күтәренке. Күңелең көр икән, яра тиз төзәлә ул...

Миңнулла яңадан үз частена кайтты. Ләкин взводта элекке разведчиклар бик аз калган иде: гвардия өлкән сержанты Александр Калашников, әзербәйҗан егете гвардия рядовое Рөстәмов һәм тагын биш-алты кеше генә. Калганнары барысы да яңалар. Взвод командиры Ефремов та юк инде, ул батырларча һәлак булган...

Яңа взвод командиры гвардия лейтенанты Бандура кечкенә буйлы Миңнулладан аз гына калкурак иде. Яше дә әллә ни күп түгелдер. Күкрәгенә «Батырлык өчен» медале таккан разведчикка бераз карап торды да ул, сул күзен кысып, әкрен генә елмайды. Ак, тигез тешләрен күрсәтеп, Миңнулла да елмайды. Бу танышу иде.

1944 елның 16 июлендә Беренче Украина фронты гаскәрләре Львов юнәлешендә һөҗүмгә күчтеләр. Ут валы артыннан кузгалган совет пехотасы, дошман оборонасының беренче полосасын җимереп, гитлерчыларның «Принц Евгений» дип исемләнгән икенче оборона сызыгына килеп чыктылар. Немец командованиесе бу линияне һич тә бирергә уйламый иде. Баш-күз алгач, алар бик күп танкларга ышыкланып, үзләре һөҗүмгә күчтеләр. Ләкин гитлерчыларның язмышы хәл ителгән иде инде. Каты сугышлардан соң, безнең гаскәрләр немецларның икенче оборона сызыгын да алдылар.

...Лейтенант Бандура көннәрнең берендә берничә разведчикны сайлап алды. Миңнулла Гыйззәтуллинны һәм тагын бер разведчикны баш дозорга билгеләде, калганнарын ян дозорларга.

— Тавыш-тынычыз булмасын,— диде ул.— Дошман тылыннан барабыз.

Караңгы төште. Әле урман, әле кыр буйлап бардылар. Миңнулла күңеленнән горурланып атлады: әйтүе генә ансат, алар артыннан бөтен бригада бара бит! Аның күзе һәрнәрсәне шәйли, колагы һәр тавышны ишетә. Бармагы — автомат чакмасында. Ләкин атарга ахыр чиктә генә мөмкин.

Киеренкелек ару-талуны оныттыра. Шулай да Миңнулланың яралы аягы үзен шактый нык сиздерә иде.

Төне буе бардылар. Җәйге төн бик тиз узды. Әнә күк йөзе аллана да инде. Урманга кергәч, тагын караңгылатты. Шунын өстенә монда аеруча сак булырга кирәк. Алда урман каравылчысы өе күренде. Миңнулла кулын күтәреп иптәшләрен туктатты.

— Әнә, кара! — диде ул иптәшенә, тәбәнәк читән ягына күрсәтеп.— Немец аты.

Ишек алдында бер генә түгел, алты немец аты тора иде. Арбалары да шунда ук, арбалар өстендә гитлерчылар йоклый. Өйдә офицерлар ял итә булса кирәк. Автомат тоткан часовой баганага сөялгән. Аның да башы салынып төшкән — аяк өсте килеш йокыга киткән.

— Болай гына алыйк! — дип пышылдады Миңнулла.

Агачлар арасыннан әйләнеп үттеләр дә бәрәңге бакчасы аша ишек алдына кerделәр. Немецлар автоматларын бер читкәрәк сөяп куйганнар. Миңнулла коралларга ишарәләп иптәшенә күрсәтте дә, үзе, аяк очларына гына басып, сакчы янына китте һәм аңардан ике адымда туктады. Тиз генә фашистның эшен бетерергә мөмкин иде, ләкин

шул чак Миннулланың каны уйнап китте. Аяк очларына басып, ул немецның каскасын түбән басты да әкрен, ләкин нык тавыш белән:

— Һальт! — дип кычкырды.

Гитлерчы күзләрен ачкач, каушап калды, автоматы төшеп китте, калтырана-калтырана кулларын күтәрде. Аннары бүтәннәрен дә уяттылар. Йокы аралаш берни аңламыйча, алары да кулларын күтәрделәр. Һәммәсен сарай почмагына алып киттеләр. Бирeдә разведчикларның берсе гитлерчыларны саклап калды. Миңнулла, автоматын әзер тоткан килеш, ишекне кагарга кереште. Өйдән ике офицер атылып чыкты. Аларга да, үзләренә төбәлгән автоматны күргәч, кулларын күтәрүдән башка чара калмады.

Шулай итеп, берничә минут эчендә, разведчиклар 22 немец солдатын һәм офицерын, алты ат, арбалар һәм коралларны кулга төшерделәр. Аннары, аларны арттан килүче группага тапшырып, дозор яңадан алга кузгалды. Хәзер аеруча сакланып бардылар. Кайдадыр алда зуррак төркем булырга тиеш. Шуның өстенә көн дә шактый яктырып бара иде.

Чыннан да шулай булып чыкты. Урман сакчысы өен узып берничә километр баргач, разведчиклар бер алан авызында агачларны аударып юлны бүлгән урынга килеп җиттеләр. Алан янында — бик күп машина эзләре. Димәк, кайдадыр, якында гына, әйләнеп үтәргә мөмкин. Бу турыда ядрога хәбәр иткәч, дозор вакыт оту өчен турыдан китте. Бераз киткәч, урман межасына барып чыктылар. Димәк, әйләнеч юл бирeдә зур юл белән тоташырга тиеш. Урман тынлыгына колак салып, беравык торгач, разведчиклар тагын кузгалдылар. Кояшның беренче нурлары яктырткан җинел томан эчендәге урман гаҗәеп матур иде. Һәр яфрак, һәр үлән өстендә энҗе бөртекләре булып чык тамчылары ялтырый. Әйе, мондый матурлык кочагында берничә минут булса да ял итәсе килә, ләкин разведчикларның моңа вакытлары бармы соң?..

Кыр — күз, урман — колак, дип тикмәгә генә әйтмиләр шул. Еракта ниндидер гөрелте тавышы ишетелгәндәй булды. Миңнулла кинәт туктады. Кулын күтәреп, иптәшен дә туктатты. Җиргә ятып та тыңлап карады. Әйе, ялгышмый.

Бераз алга киттеләр. Гөрелте ачыграк ишетелә башлады.

Миңнулла үзе алга китте, иптәшенә бераз арткарак калырга әйтте. Әлбәттә, юлдан читкә чыктылар, юан агачлар артына яшеренеп бардылар.

Шул рәвешчә 200—300 метрлар киткәч, Миңнулла кинәт туктады: юлда бөтен бер автоколонна тора иде! Туплар таккан уннарча автомашиналар! Колонна буйлап өч часовой йөренә. Берсе хәтта күңелле генә итеп ниндидер көй сызгыра. Менә сиңа мә! Шулай да әлеге гөрелте кайдан килә соң? Миңнулла яшеренә-яшеренә алгы машина турысына кадәр барды. Машина тәгәрмәчләре белән чокырга туры килгән икән. Моторы эшли, ә шофер, кабинадан озын аякларын сузып, хырылдап йоклап ята. Өсте ябык җиңел машинада офицерлар йоклап яталар.

Миңнулла кырыктан артык машина һәм туп санады. Солдатлар белән офицерлар барысы өч йөзләп булыр. Мондый группаны тавыш-тынсыз гына алырмын дип уйлама. Ләкин юл тар, әгәр алгы һәм арткы машиналарны шартлатсаң, калганнары капчыкта торып калырлар, борылырга да урын калмый.

Миңнулла иптәше янына китте. Аннары взвод командирын чакырдылар. Гыйззәтуллин аңа барысын да сөйләп, башында туган планы белән уртаклашты. Бөтен взвод берьюлы һөҗүм иткәндә берәр машина гына тиячәк иде.

Бандура бу план белән килеште. Менә 37 разведчик, куләгәләр кебек үтеп, колонна буйлап яттылар. Иң киеренке минутлар. Барысын да разведчикларның кыюлыгы һәм әрсезлеге хәл итәргә тиеш. Гыйззәтуллин белән Бандура күзгә күз карашып алдылар. Вакыт! Миңнулла, күтәрелә төшеп, баш машинага танк гранатасы томырды. Каты шартлау йокыга талган урманны тетрәтеп җибәрде. Шуның артыннан ук разведчикларның автоматлары тырылдарга тотындылар. Миңнулла инде аякка баскан килеш җиңел машинадагы офицерларны кыра иде.

Сугыш озакка сузылмады. Разведчиклар кырыкка якын төзек машина, 16 туп һәм ике йөзләп әсир алдылар. Аннары яңадан дошманны куу башланды. Һәр җайлы урында гитлерчылар каты каршылык күрсәттеләр. Бигрәк тә су буйларында нык тордылар. Ә гвардиячеләр һөҗүм иткән полосада эреле-ваклы елгалар һәм елгачыклар бик күп иде. Шулай да төп саклану урыны итеп немецлар мул сулы Висла елгасын

сайлаганнар һәм төп көчләрне мөмкин кадәр тизрәк аның көнбатыш ярына чыгарырга уйлыйлар иде. Безнең сугышчылар исә немецларны артларыннан калмыйча эзәрлекләргә тырыштылар. Алар, гитлерчыларның җилкәләренә атланып дигәндәй, Сан елгасын кичеп чыктылар һәм аның аръягындагы бик күп авылларны азат иттеләр.

Бандура разведчиклары янадан дошман тылына үтеп керделәр. Менә алар зур бер авыл читендә яталар. Авылда гитлерчылар мәж килә, берсе дә китәргә җыенмый шикелле, күрәсең, биредә совет сугышчыларын тиз генә көтмиләр. Бер читтәрәк ялгыз ярым таш йорт тора. Авыл артында сирәк-мирәк автомат тавышлары. Аларга берәү дә игътибар итми, гадәти өйрәнү атышлары булса кирәк.

Разведчиклар беравык күзәтеп ятканнан соң, әлеге ялгыз йортны тикшереп карарга булдылар. Алга өч кеше — гвардия сержантлары Анисимов белән Шиянов һәм гвардия рядовое Гыйззәтуллин киттеләр. Взвод куе куаклык эчендә калды.

Ерактан караганда ялгыз йорт буш сыман күренә иде, әмма Анисимов белән Гыйззәтуллин, ашеренеп, йортка якынлашкач, анда әледән-әле офицерлар кереп-чыгып торуын күрделәр. «Әттә генәсе, — дип уйлады Миңнулла, — штаб түгелме соң монда? Әйе, әнә лапас ышыгында часовой йөренә. Вакыт күпме соң әле? Әһә, 16.00».

Шактый күзәтеп, обстановканы ачыклаганнан соң, часовойны юк итәргә һәм штабка һөҗүм итәргә дигән фикергә килделәр. Озак та үтми, разведчиклар йортны чолгап алдылар. Гыйззәтуллин часовойны юк итте. Шуның артыннан ук тәрәзәгә гранаталар очты. Кара төтенгә уралып, офицерлар өйдән атылып чыга башладылар. Ишек төбендә аларны башына ак кубанка кигән совет разведчигы каршы алды.

— Я әле, тизрәк булыгыз, атмыйбыз. Каршылык күрсәтү файдасыз, сез камап алынган, — дип кычкырды ул.

Өйдән 26 кеше чыкты. Шуларның икесе рядовой, калганнары барысы да офицерлар, алай гына да түгел, алтысы генерал иде.

Шулай кәпә-көндез совет разведчиклары немец частеның борын төбеннән бөтен бер штабны туздырып киттеләр.

Әлбәттә, гел шома гына бармады. Гвардиячеләргә бик кыенга туры килгән чаклар да булмады түгел, күп булды. Бер тапкыр, поход колоннасы белән барганда, якындагы куаклыктан чыгып, искәрмәстән немец «Пантера»сы һөҗүм итте, пулеметлардан сиптереп, берничә минут эчендә бөтен взводны аяктан екты. Аннары «Пантера», кырт борылып, туп-туры безнең автомашиналар колоннасы өстенә китте, аларны чылбырлары белән сытып, уты белән ялап алды. Миңнулла башын күтәреп караган иде: бер үзе калган! Янында бер кеше юк, тик тирә-якта яралылар гына ыңгыраша. Әллә кайдан гитлерчылар ябырылып чыкты. Алар безнең яралыларны котырынып кыра башладылар. Миңнулла йомарланып чокыр төбенә сеңде. Йөрәге сулкылдап типте, гүя менә хәзер аны да эләктерәчәкләр. Тереләй, әлбәттә, бирелмәс, ләкин...

Күп дигәндә ике адымда гына гитлерчылар үтеп китте һәм... Миңнулланы күрмәделәр. Ул монда караңгы төшкәнче ятты. Шау-шу тынган иде инде. Атыш тавышлары шактый ерактан ишетелә. Миңнулла тирә-якка каранып алды да чамалап сулга таба юнәлде. Таң алдыннан чолганыштан чыгучы бер төркем сугышчыларга очрады. Араларында бер лейтенант та бар иде. Ул командалар бирә башлады. Бер-ике сәгать эчендә сиксәнләп кеше җыйналды. Ләкин арыганлык һәм киеренкелекнең йомшаруы үзенекен эшләде, Миңнулла, агач төбенә сөялгән килеш, йоклап китте. Ә янадан күзен ачып, тирә-ягына караганда, янында бер кеше дә юк иде. Уятмаганнар, караңгыда берсе дә күрмәгән, ахры.

Шулай итеп төннең калган өлешен аңа ялгыз үткәрергә туры килде. Яктыра башлагач, урман эченнән сакланып кына барганда, ул русча сөйләшкән тавышлар ишетте. Бераз тыңлап торды да адымнарын кызулатты. Болар күрше армиянең танкистлары булып чыкты. Билгеле инде, Миңнулланы урап алдылар һәм барысын бәйнә-бәйнә сораштырырга тотындылар. Бер танкист, егетнең чамасыз арыун күреп булса кирәк, кружкасын тутырып аракы салды да Миңнуллага сузды:

— Эч, егет!

— Мин аракы эчмим, — диде Миңнулла.

— Ул чагында нинди егет син!

Әмма Миңнулла барыбер аракыны алмады. Әтисенең әйткән сүзләре исенә төште: бер тапкыр аракыны кеше үзе эчә, икенче тапкыр инде аракы кешене эчә.

Көндез, Миңнулла инде үз подразделениесенә кайтып җиткәч, юлда әлеге төнге лейтенантны күрде. Алар әле яңа гына чолганыштан чыкканнар иде.

— Кара әле, нишләп син безгә юл күрсәтмәдең, — диде ул, гаҗәпләнеп.

— Ә миннән сораучы булдымы соң? — дип, Миңнулла кашын сикертте.

Безнең гаскәрләр инде Висла елгасына якынлашалар иде. Сугышлар кызганнан-кыза барды. Вислага илтә торган барлык юллар гитлерчыларның техникасы һәм җанлы көчләре белән тулган. Безнең авиаразведка Вислага таба немецларның бөтен бер танк колоннасы — иләләп машина барганлыгын хәбәр итте. Залещики бригадасы дошманның юлын кисәргә боерык алды. Бригада командиры моның өчен 140 кешелек отряд билгеләде. Отряд, приказны үтәп, әйләнеч юлдан дошман тылына чыкты. Ташландык траншеяларга һәм блиндажларга урнашты. Әнә, дошман танклары гөрли түгелме?..

Бераздан тау башында танклар үзләре дә күренделәр. Өсләренә пехота утыртканнар. Арада автомашиналар һәм үзйөрешле артиллерия дә бар.

Күренеп тора: көчләр тигез түгел, ләкин озак юанып торырга вакыт юк, гвардиячеләр кулларында булган барлык төр кораллардан көчле ут ачтылар. Артта куаклар арасына яшеренгән җиңел туплар да телгә килделәр.

Немец танкистлары килгән уңайга ата-ата, зур тизлектә траншеяларны үтәргә маташтылар. Безнең ПТРлар да танкларга ут яудырырга керешге. Танкларның кайберләренә ут капты. Траншеяларны үтеп чыккан танклар өстенә яңа торган сыекча тутырылган бутылкалар очты. Хәзер инде танклар траншеялар алдында да, артында да яналар иде.

Ниһаять, сугыш тынды. Сугыш кырында немецларның 27 яндырылган танкысы һәм 500 ләп үле фашист калды. Гвардиячеләрнең югалтулары күп түгел иде.

Миңнулланың күкрәгеп икенче «Батырлык өчен» медале бизәде.

1944 елның 30 июлендә Егерменче Залещики бригадасы Висла ярына килеп җитте. Миңнулла каскасы белән салкын су чүмереп алды да туйганчы эчте, аннары битенбашын юды. Висла аңа кайсы ягы беләндер Кама елгасын хәтерләтте. Тик Кама һәрвакыт әкрен ага, иркәли һәм үзенә чакыра. Висла исә караңгы чырайлы, анда әледәнәле снарядлар, миналар ярыла. Аннары аның аръягындагы җирләр дә ят.

Миңнулла һәм башка разведчиклар, мул сулы Вислага, билгесезлек һәм ут белән тулы аргы якның текә ярына текәлеп караган килеш, үзләренең авыр солдат уйларын уйладылар. Елганы бүген үк кичә башлардыр инде, тик беренче булып кемнәр барыр...

Гвардия өлкән сержанты Шаляпин, иң гади солдат эшен эшләгәндәй, разведчиклар арасыннан биш кешене сайлап алды.

— Хәзер үк комбат янына!

Барысы да берьюлы төшенеп алдылар: әйе, алар икән! Чыннан да комбат моны раслады. Ул Висланы кичү турында приказ килгәнлеге, беренчеләр булып разведчиклар барасын әйтте.

— Сезнең хәрәкәтне бригада штабы күзәтәчәк, — диде ул ахырда. — Бурыч — елга аръягында дошманның көчен һәм позицияләрен белү. Елганы чыгу белән тизрәк тылга үтәргә тырышыгыз, сугышка кермәгез. Элемтә — рация аркылы. Погоннарыгызны һәм документларыгызны калдырыгыз... Миңа сорауларыгыз бармы? Барысы да аңлашыламы?

Сораулар юк, тик менә иңнәрдән погоннар салынгач, гимнастерка кесәсендә кызыл армеец кенәгәсе дә, комсомол билеты да, хәтта бүтән бер кәгазь кисәге дә калмагач, күкрәк таныш медаль һәм орденнардан бушагач, аяк астында туган җирнең соңгы карышы югалып, күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда билгесезлеккә йөзә башлагач, солдат күңеле үзенә бер төрле моңланып китә. Солдат гомерендә Миңнулла Гыйззәтуллин моны ничә тапкыр кичерде инде, тик мондый чакларда салкын канлы булып калырга өйрәнә алмады.

Ярда көймәләр юк иде. Кул астындагы материаллардан кечкенә генә сал ясадылар. Монысы, иң элек, сугыш припаслары һәм рация өчен. Разведчиклар үзләре исә

бүрәнәләргә тотынып йөзәргә булдылар. Юеш һәм шугак бүрәнәләр белән елганы чыгу бик кыен буласын белделәр, ләкин бүтән чара юк иде. Шуңа күрә булса кирәк, Миңнулла яр буен җентекләп карап чыкты һәм, бер чокырда автомобиль шины аунап ятканын күргәч, бик шатланды.

— Мин бәләкәй, мине генә күтәрер әле, — дип сөйләнде ул камераны кия-кия. — Алай-болай булса, куллар буш, ата алам.

Немецлар ерактагы һәм якындагы туплардан һәм минометлардан бу як ярга һаман атып торалар. Ләкин елганы кичәргә әзерләнүчеләрне абайламыйлар булса кирәк, атышлары тәртипсез иде.

Тәмам караңгы төшкәч, комбат:

— Я, вакыт, — диде. Ул разведчикларны озатырга үзе килгән иде.

Соңгы мәртәбә куллар кысылгач, алты разведчик Висланың кара суына керделәр. Дулкын бүрәнәләрне башта ук читкә бәрә башлады. Миннулла аяклары һәм куллары белән хәрәкәт итеп, иптәшләреннән калышмаска тырышты. Менә разведчикларның баш турысында гына миналар ярыла башлады. Миналарның берсе нәкъ алдагы бүрәнәгә тиде, разведчик күз ачып йомганчы упкын төбендә югалды. Аннары икенче разведчикны да үтерделәр. Ләкин рация куелган сал һәм исән калган разведчиклар һаман алга йөзделәр. Салга тотынып йөзгән радист та яраланды. Миңнулла, салның җитәкчесез калуын күргәч, тиз генә аңа таба йөзә башлады. Салны югалту — рацияне югалту, ә аннан башка разведчиклар берни дә эшли алмаячаклар — штаб белән элемтәгә керел булмаячак.

Елганы кичкәч, яралы иптәшләрен яр буендагы куаклар арасына яшереп, рация белән сугыш припасларын аркаларына астылар да, разведчиклар ярдан ераккарак киттеләр. Бәхеткә каршы, бу урында немецларның оборонасы су буйлап ук үтми икән, кайдадыр яр башыннан уза. Өстәвенә тоташ та түгел шикелле.

Таң сызылып килгәндә, разведчиклар Висладан шактый еракта иделәр. Штаб белән сөйләшеп алгач, алар тагын да арырак киттеләр. Бара торгач, алда бер поляк авылы күренә башлады. Авылга якынрак килеп, күзәтергә керештеләр. Үткен күзле Миңнулла шунда ук ялгыз кешене шәйләп алды. Үзара киңәшкәч, аның янына барып сөйләшергә булдылар.

Бер поляк карты булып чыкты ул. Башта ул киемнәре юеш һәм пычрак булган сәер кешеләрне күреп бик курыкты.

Бу авылның ничек аталуын, немецларның кайда икәнен сорадылар.

— Бу — безнең авыл, — диде карт, авылның исемен әйткәч. — Дөрес, бездә немецлар юк, безнең авыл кечкенә, алар күрше авылларда.

Ул үз авылларында байтак украин егетләре һәм кызлары яшеренүен әйтте. Гитлерчылар аларны Германиягә куып алып бара торган булганнар, поляклар аларга качарга булышканнар, аннары шул авылга яшергәннәр.

— Сез аларның берәрсе белән безне таныштырмассызмы? — дип сорадылар разведчиклар.

Поляк шактый уйлап торды да:

— Сез советныкылар булгач, нишләп таныштырмаска, — диде.

Бераздан разведчиклар карт полякның өендә утыралар иде инде. Ул аларны хәзинәсендә бары белән сыйлады.

Аннары карт күршеләренә кереп, полякча киенгән өч украин егетен алып килде. Салкын гына исәнләштеләр. Башта тынып торган егетләр, сүз иярә сүз чыгып, яхшы ук ачылып киттеләр. Ахырда Шаляпин приказ биргәндәй итеп:

— Менә нәрсә, егетләр, күп сөйләшеп торырга вакыт юк. Карта ясый беләсезме? Тирә-якны кәгазьгә төшереп, кайда нәрсә барын күрсәтегез, — диде.

Егетләр үткеннәр булып чыкты. Картаны ярыйсы төгәл һәм тиз сыздылар, кайда, нинди немец частьлары торганын да күрсәттеләр. Карт поляк үзеннән дә күп нәрсә өстәде.

Совет Армиясенә ничек кенә булса да булышырга омтылып торучы бу кешеләргә ышанмаска нигез юк иде. Ләкин разведчикларның алтын бер кагыйдәсе бар: кешегә ышан, ә үзең тикшер!

— Рәхмәт, дуслар, — диде Шаляпин, урыныннан торып. — Хәзер сез күрсәткәннәрне кабат тикшереп карыйк. Безнең белән барасызмы?

— Корал бирәсезме? — дип сорады егетләрнең берсе.

— Биредә коралны сугышта гына табарга мөмкин, — диде Шаляпин.

Егетләр бер-берсенә карашып алдылар да риза булдылар.

Соңыннан барысын да урында тикшереп, сөйләгәннәрнең дөреслегенә ышангач, разведчиклар янадан таныш поляк карты өенә кайттылар. Чормага менеп, барлык мәгълүматларны штабка тапшырдылар. Аннан рәхмәт әйттеләр, безнең частьларны шунда көтәргә куштылар. Ләкин мондый кызу чакта разведчиклар кул кушырып тик ята алалармы соң! Алар үзләре күрсәткән объектларга безнең авиаторларның бомба ударларын күзәттеләр дә, карт һәм егетләр белән саубуллашып, янадан ярга таба киттеләр. Хәзер инде алар үзләре кирәк тапканча хәрәкәт итә алалар иде. Елганы кичүнең хәлиткеч вакытында разведчиклар гитлерчыларга тылдан һөҗүм иттеләр. Немец траншеяларына якын ук шуышып килделәр дә, гранаталар ыргытып, үзләре дә сикерделәр. Бу сугышларда Миннулла Гыйззәтуллин бер үзе генә дә егермедән артык фашистны дөмектерде. Әлбәттә, иптәшләре дә аңардан калышмадылар.

Гитлерчылар акылларына килгәнче, байтак вакыт үтте. Соңыннан алар югалткан позицияләрен контратакалар белән кире кайтармакчы булдылар. Ләкин разведчикларны траншеядан бәреп чыгару ансат түгел иде. Елганы кичеп өлгергән совет сугышчылары да аларга ярдәмгә килде. Разведчикларның бу һөҗүме безнең гаскәрләрнең Висланы уңышлы, югалтусыз кичүенә зур ярдәм булды. Елганы беренче булып кичкән һәм елга буенда батырларча сугышкан өч разведчикка, шул исәптән Миннулла Гыйззәтуллинга да, 1944 елның 23 сентябрь указы белән иң югары хәрби бүләк — Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Аннары сугышлар тагын дәвам итте. Сугышларның берсендә Миннулла Гыйззәтуллин икенче тапкыр яраланды. Дәваланганнан соң янадан үз взводына кайтты. Бу юлы да аңа таныш сугышчылар взводта бик аз калган иде. Взвод белән элекке сержант командалык итә. Аңа офицер званиесе биргәннәр. Миннуллага да озакламый сержант исеме бирелде.

Егерменче бригаданың разведчиклары Одерны кичкәндә тагын бер тапкыр егетлек күрсәттеләр. Миннулла мондагы батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Ул фашистларның ояларын туздырасы көнен дә күз алдына китерә иде инде. Хәтта рейхстаг өстенә Кызыл Байрак кадау турында да хыялланмады түгел. Ләкин эш ул уйлаганча барып чыкмады. 1945 елның 30 апрелендә Миннулла кабат яраланды. Ә аңына килгәндә... сугыш беткән иде инде.

Ике елдан соң Миннулла Гыйззәтуллин армиядән демобилизацияләнде. Шуннан соң аның тормышында яңа чор — хезмәт чоры башланды. Ул Казанда тимер-бетон заводына эшкә урнашты. Аның белгән һөнәре юк иде, ләкин ул кайгырмады: баш сау булса, һөнәрне үзләштерәсең аны. Һәм ул чыннан да электросварщиклыкка өйрәнде һәм Миннулла бу һөнәрне бик яратты. Бүгенгә чаклы ул шул эштә.

Иртәләрен, бик күпләр белән бергә, эшкә барганда ул үзләре ясаган панельләрдән зур-зур торак йортлар, предприятиеләрнең гигант корпуслары үсүен күреп, эченнән шатлана. Ни әйтсәң дә, һәрбер панельдә аның да кул җылысы бар бит. Күкрәгендә Алтын Йолдыз булган элекке сугышчы хәзер коммунистик хезмәт ударнигы.

Миннулла гаҗәп тыйнак кеше. Җиңү көненең егерме еллыгын бәйрәм иткәнгә кадәр иптәшләре үзләре белән бергә эшләгән Миннулланың Советлар Союзы Герое икәнен дә белмәделәр.

Миннулла авылдашы Асия исемле кызга өйләнде. Хәзер алар Казан читендә торалар. Сигез балалары бар! Иң өлкәнентә инде унсигез яшь. Әтисе фронтка китеп, Советлар Союзы Герое исемен алган яшьтә ул хәзер.

Миннулла Гыйззәтуллин бик еш пионерлар һәм комсомолецлар белән очраша. Ул коммунист һәм җәмәгать эшлеклесе. Карап торырга ул хәзер дә бик яшь сыман, тик чәчләрендә генә инде чал бөртекләре күренә. Елмаюы һаман яшь чагындагыча саф һәм якты. Кечкенә кара күзләрендә дә, әүвәлгечә, ялкын һәм дәрт ялтырый. Аларга карыйсың да уйга каласың: ниләр, ниләр генә хәтерләтми алар!..

## Совет властенең 50 еллыгына

*Мидхәт Мөхәррәмов,*
*Азат Әхмәдуллин*

# «ЭШ» ГАЗЕТАСЫ БИТЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Вакытлы матбугат — халык тормышының көзгесе диләр. Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте, бу көзгенең саф һәм тутыкмас булуына ирешү өчен, революциянең беренче көннәреннән үк бөтенесен дә эшләделәр һәм хәзер дә бертуктаусыз кайгыртып торалар. 1918 елның 12 мартында чыга башлаган «Эш» газетасы[1] шундый кайгыртучанлык нәтиҗәсендә туган татар совет матбугатының беренче карлыгачы иде. Ул большевикларның һәм совет оешмаларының халык арасындагы эшчәнлеген киң һәм дөрес күрсәткән, татар хезмәт ияләренең бу еллардагы рухи дөньясын, эшчәнлеген тулы чагылдырган көзге булды. Шул ук вакытта «Эш» яктылык чыганагы да иде. Ул чәчкән нур татар тормышының иң ерак, иң караңгы почмакларына да үтеп керде. Газета битләрендә бөек чорга күчү көннәренең дулкынландыргыч вакыйгалары теркәлде.

Газета чыга башлап, берничә ай вакыт узгач, илдә гражданнар сугышы уты кабынды. Коммунистлар партиясе һәм бөек Ленин хезмәт ияләрен изге көрәшкә — яшь Совет Ватанын саклап калырга чакырдылар. Англия, Америка, Франция интервентларының һәм эчке контрреволюциянең берләшкән көчләрен тар-мар итү өчен, көчле регуляр армия төзергә, аны коралландырырга, киендерергә, азык-төлек белән тәэмин итәргә кирәк иде. Үзеннән беркадәр вакыт соңрак чыга башлаган башка татарча газеталар — Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларның Үзәк бюросы органы «Эшче» һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе газетасы «Кызыл Армия» кебек үк, «Эш» тә игътибарын, иң беренче, шушы тарафка юнәлтте. Шул ук вакытта газета яңа тормышның башка тармакларына да әһәмият биреп килде. Шундыйлардан берсе — әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре иде.

Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы вакытында киң колач җәя барган культура төзелеше бик катлаулы һәм күп тармаклы процесс иде. Совет властеның язмышы хәл ителгәндә һәм «кем кемне?» соравы әле көн тәртибендә торган бер вакытта бу процессны анык эзгә салып, аңар җитәкчелек итү, ныклы юнәлеш бирү Коммунистлар партиясенең зирәклеген һәм даһи акылын, алдан күрә белүчәнлеген раслаучы фактларның берсе. Эшче, кызылармеец һәм крестьян массаларына Коммунистлар партиясенең, бөек Ленинның идеяләрен җиткерү, мәктәпләрне һәм башка уку йортларындагы эшләрне яңа нигездә кору, наданлыкка каршы мәрхәмәтсез ут ачу, яңа эчтәлекле сәнгать һәм әдәбият тудыру, театр коллективларының эшен революцион дәвер таләп иткән югарылыкка күтәрү — болар барысы да культура революциясе чылбырының әһәмиятле һәм без күзәтә торган чорда инде шактый нык эшләнгән буҗралары. Бераәм-бераәм сүтеп караганда, аларның нигездә бер нәрсәгә — хезмәт ияләрен коммунизм рухында тәрбияләү максатына буйсындырылган булулары ачык күренә.

Яңа, социалистик культураны, аның казанышларын пропагандалау еш кына буржуаз милләтчеләрнең бу өлкәдәге сатлык политикасының чын йөзен фаш итү аша алып барылды. «Эш» үзенең беренче көннәреннән үк милли һәм хәрби шурачы-

[1] «Эш» 1920 елның июленә кадәр, барысы 410 сан чыкты. Кызганычка каршы, газета беркайда да тулы килеш сакланмаган. Аның Казан, Мәскәү, Ленинград китапханәләрендәге һәм архивларындагы нөсхәләрен барлап чыкканнан соң, 27 санның җитмәве беленде. Ул саннар, бәлкем, аерым кешеләр кулында саклана булыр?

ларга, «Болак буе җөмһүрияте» оештырып маташкан милләтчеләргә каршы ут ачты. Күренекле революционер, атаклы әдип Галимҗан Ибраһимов «Иҗтимагый революция һәм татар зыялылары» исемле зур мәкаләсендә (1919 ел, 10, 11, 12 март саннары) милләтчеләрнең уйларына һәм тоткан юлларына тирән анализ ясый. «1905 елда кып-кызыл танчы, с.-р. булган Гаязның (буржуаз милләтче, соңыннан эмигрант Гаяз Исхаков турында сүз бара — авторлар) бу революциядә иң беренче сүзе, иң беренче язуы «Берләшегез, мөселманнар!» дигән сүздән гыйбарәт булды, — дип яза ул. — Казанда Туктаров, Уфада Терегулов шул шигарьне эләктереп алдылар. Россиянең һәммә шәһәрләрендә тагы шул 1905 елдагы Мөселман иттифакына «охшаш» «комитет» тудырырга, шунда байны, ярлыны, капиталист белән эшчене, җирсез крестьян белән алпавытны бергә җыеп «дини, милли ботка» пешерергә тотындылар».

Сүз уңаенда әйтеп үтик. «Эш» газетасы политик сизгерлекләре җитәрлек булмаган кайберәүләрнең башын әйләндерүче бу «мөселманнар берлеге» мөрәҗәгатенең асылын үз укучыларына җае туры килгән саен төшендереп, кирәк икән ачы тәнкыйть уты белән көйдереп торды. Мәсәлән, 1918 елның ноябрендә Мамадышта чыга башлаган «Мамадыш тавышы» газетасы үзенең беренче саннарында «Берләшегез, үз кул көче белән көн күрүче бөтен дөнья мөселманнары!» дигән саксыз чакыру ташлаган иде. «Эш»нең моңа реакциясе тиз һәм кискен булды. 13 ноябрь санындагы редакцион мәкаләдә бу лозунгның провокацион максатларга, дини-милләтчеләрнең мәкерле концепцияләренә хезмәт итү мөмкинлеге, зарарлыгы, интернационализмга каршы булучылыгы ачык аңлатыла.

Газетаның һәр бите дошманнарны тар-мар итеп, гадел сугышта җиңеп чыгуга омтылу рухы белән сугарылган. Кызыл фронтка ярдәм итүдә ул көн белән бергә атлый, бу җәһәттән яңадан-яңа нәтиҗәле чаралар уйлап таба белә. Җиңүгә нык ышаныч бөркелеп торган ялкынлы публицистик мәкаләләр, яшь совет дәүләтенең халыкара хәлен һәм эчке тормышын яктырткан политик хәбәрләр, революция дошманнарының омтылышын аңлаткан үтергеч фельетоннар, үткен агиткалар, көндәлек сорауларга кичекмәстән җавап бирергә тырышып язылган шигырьләр газетаның эчтәлеген, рухын билгели. Редакциядә эшләүчеләрнең тапкырлыгын, политик сизгерлеген һәм массаларга якыная белүен күрсәткән тагын бер мисалны китереп үтик. Фронтларда хәл аерата кискенләшкән бер чорда була бу. 1919 елның 1 маенда «Эш» II армия каршындагы «Кызыл көрәшче» газетасының икенче саны белән кушылып чыга. Идарә бу хакта шундый игълан бирә:

«Эш» газетасы бу көннән башлап Колчакка каршы сугышучы каһарман кызылармеецлар сафына керә. «Эш» газетасы үзен-үзе мобилизовать итә һәм гражданский газеталардан чыгып, кызылармеецлар газетасы була һәм «Кызыл көрәшче» исемендә исемләнә.

...Тиз заманда тыныч тормыш кайту белән «Эш» тагын да үз эшенә керешәчәк».

Дөрес, газета бу хәлендә озак яшәми, Колчак җиңелә башлап, фронтларда хәл йомшаргач, 18 майдан үзенең иске исеме белән чыгуын дәвам иттерә. Әмма төп хикмәт, безнеңчә, анда түгел. Бу — киң халык массаларына якынаюның уңай бер формасын эзләү иде һәм ул мәсьәләнең җитдилеген хезмәт иясенә җиткерүнең отышлы бер чарасы булды.

Менә шундый аек һәм төпле политик нигезләргә корылган газетаның культура, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә карашы да эшче сыйныф идеологиясенең төп таләпләренә җавап бирә иде. «Эш» тирәсенә тупланган авторлар, журналистлар һәм язучылар әдәбиятны һәм сәнгатьне көндәлек тормыш сораулары яктылыгында бәяли беләләр, шуңа буйсындыра беләләр, аларның үзенчәлекләрен яңа гасыр таләпләреннән чыгып аңларга омтылалар иде.

Бөек Октябрь әдәбият һәм сәнгать тарихының өр-яңа битен ачты. Халыкка хезмәт итү сәнгатьнең барлык тармаклары өчен дә иң зарури, беренче чиратта торган бурычка әйләнде. Пролетариат диктатурасы дәверендәге сәнгатьнең чиксез үсү мөмкинлекләре С. Сәетгалиевнең «Безнең сәнаигъ нәфисәбез» исемле зур мәкаләсендә ачык чагыла. «Совет хөкүмәтенең сәнаигъ нәфисә турысында тоткан максаты ошбу нәрсәләрдән гыйбарәт, — дип язды ул. — Беренче, сәнаигъ нәфисәне акча җыю нияте белән булган эксплуатациядән коткару. Икенче, сәнаигъ нәфисә белән байлар гына, ягъни бер сыйныф кына файдаланмыйча, бөтен халык аннардан файдалануын күз алдында тоту...». Советлар хакимлеге шартларында культура һәм сәнгать үсеше өчен туган киң мөмкинлекләр җирлегендә, дип язды автор «...безнең сәнаигъ нәфисәбез аякка басар; һәм аны парник ящигыннан алып, чиксез киң бакчага утыртып, аны кояш нурында йөздереп үстерергә кирәк...» (1919 ел, 20 август).

Газета редакциясе һәм аның тирәсенә тупланган алдынгы язучылар, журналистлар, хәбәрчеләр киң халык массаларын тәрбияләүдә сәнгатьчә сүзнең бөек көчен яхшы аңлап эш иттеләр. 1919 елның 31 гыйнварында басылган редакцион мәкаләдә:

«...Бездә әдәбият кытлыгы шикәр кытлыгыннан мең өлеш куәтле... Татар пролетариатын шикәрсез чәй эчү харап итмәсә дә, әмма рухани ачлык харап итүе бик мөмкин», диелгән иде. Монда сүз гомумән әдәбият һәм матбугат турында баруы аңлашылса кирәк. Шул ук елның 7 мартында чыккан санда югарыдагы фикерләр тагын да тирәнәйтелә һәм ачыкландырыла: «Халыкка икмәк берлә су никадәр кирәк булса, хәзерге көндә рухани азык та шулкадәр кирәк».

Революциянең бөек үзгәртү көченә тирән ышануы һәм әдәбият-сәнгатьнең үсеше мәсьәләләрен үзара бәйләп каравы белән дә «Эш» политик өлгергәнлек күрсәтте. 1919 елның 5 февраль санында урнаштырылган «Әдәбият мәсьәләләре» исемле мәкалә бу яктан гаять характерлы: «Шөбһә

юк, хәзерге революция татар халкын киләчәк заманга хаким карашы белән карый алырлык вә хак баһадир, вә граждан булырлык халыкка әвереләдерәчәк. Күрербез: заманалар тынычлангач татар халкы, бүтән халыклар кебек үк, көчле туфан шикелле һиҗаплы вә шау-шулы хәяткә биреләчәк. Аның эченнән зур сәнаигъләр, шагыйрьләр, рәссамнар, артистлар, музыкантлар вә галимнәр килеп чыгар».

Әлбәттә, андый көчләр үзләреннән-үзләре һәм кинәт кенә килеп чыкмаячак, аның өчен һич кичекмәстән, революциянең тәүге көннәреннән үк, эш башларга кирәк иде. Шуны яхшы аңлап, «Эш» газетасы югары сыйфатлы әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен тудыруга көндәлек әһәмият бирә килде. Ул татар язучыларының революция файдасына әйтелгән сүзләренә һәрвакыт киң урын бирә, аларның нинди һава белән сулауларын сизеп ала, тиешле юнәлешне күрсәтеп, алдынгы көчләрне революция һәм халык файдасына эшкә җигә белде. Аның битләрендә Г. Ибраһимов, С. Сәетгалиев, Г. Камал, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, В. Шәфигуллин, Ф. Бурнаш, С. Җәләл, Г. Кәрәм, Ф. Сәйфи, Ш. Әхмәдиев, М. Сөбхи, И. Кули, М. Дулат-Али, С. Сүнчәләй һәм башка язучыларның, күренекле революционерларның мәкаләләре, әдәби әсәрләре, тәнкыйть материаллары һәм революцион чыгышлары еш басылды. «Эш» Әбрар Сәгыйди, Кәрим Әмири, Мәхмүт Максуд кебек яшь көчләргә каләмнәрен чарларга булышты. Афзал Шамов, Бари Рәхмәт, Мансур Крымов кебек язучы, шагыйрьләргә беренче адымнарын атларга ярдәм итте.

Үткәндә тупланган мираска мөнәсәбәт мәсьәләсе бу дәвердәге әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге катлаулы мәсьәләләрнең берсе төсендә көн тәртибендә торды. Алдан ук шуны искәртик: «Эш» үзенең битләрендә искене вату, җимерү, элекке җәмгыятьтән калган һәрнәрсәне тулаем кире кагу рухындагы мәкаләләргә урын бирмәде. Шулай да кайбер материалларда «элекке әдәбият һәм сәнгать буржуазиягә генә хезмәт итте» кебегрәк хата фикерләргә юл куярдай сүзләр очраштыргалады. Икенче яктан, аерым мәкаләләрдә «буржуазия, байлар хәятен төзү эшенә эшчеләрне кушкан кебек, пролетариат хәятен төзү эшенә дә буржуйларны без хәзер эшкә кушарга кирәк», яңа культураны тудыру һәм алга үстерү юлында сыйнфый аерымлык бернинди роль уйнамый, «иҗади эшләрдә сыйнфый дошманлык игътибарга алынмаска тиеш» дигән кебек каршылыклы һәм хата фикерләр дә урын алгалады. (1919 ел, 17 январь. «Иҗади көчләрне бергә җыю» исемле редакцион мәкалә.) Бу фикерләрнең тамыры капитал ялчыларының «сыйнфый хезмәттәшлек» турындагы уйдырмаларына барып тоташырга мөмкин иде.

Әмма, кабатлап әйтәбез, «Эш» газетасының әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге политикасын югарыдагылар билгеләмәде. Буржуаз җәмгыятьтән калган мирасның аерым әсәрләрен кире какканда, иң әүвәл, аларның революцион көрәшкә мөнәсәбәте, яңа культурага ни дәрәҗәдә хезмәт итә алуы күз алдында тотыла.

«Эш» революциянең асыл максаты вату, җимерү түгел, ә төзү, яңаны булдыру икәнен аңлады һәм үз укучыларына җае туры килгән саен шушы хакыйкатьне төшендереп торырга тырышты. Моны раслау өчен, 1918 елның 27 ноябрендә басылган «Театр вә сәнаигъ нәфисә мәсьәләсе» исемле мәкаләне күрсәтергә була. Монда ачыктан-ачык шулай диелә:

«Революция вакытында иске тормыш вә яңа тормышка комачаулый торган киртәләр бер яктан җимерелә барса, икенче яктан яңа тормышка нигез дә салына бара.

...бер нәрсәне вату-җимерү никадәр җиңел булса, аның урынына яңасын кору аңа караганда ничә өлеш авыр, шуның өчен, табигый уларак, яңаны кору өчен бик күп көч сарыф итәргә туры киләдер».

Бу фикерләр шигырьләрдә дә урын алды. Менә «Тәлгать»[1]нең «...мен мин» дип аталган шигыре.

**Җир өстендә, җир астында,**
**Диңгезләрдә гизәрмен мин.**
**Көчле колларга салынган**
**Коллык бавын өзәрмен мин...**

**Өзәрмен дә... колларымны**
**Изге эшкә җигәрмен мин,**
**Эш сөймәүче, кан коючы**
**Дошманнарны җиңәрмен мин...**

**Җир йөзендә эш тормышын —**
**Якты тормыш төзермен мин...**
**Дус-туганлык дөньясында**
**Рәхәт-тыныч яшәрмен мин,**
**Инсаният бәхете өчен**
**Эшләрмен дә эшләрмен мин[2]...**

Редакция әдәбиятның яңа җәмгыять үсешендә тоткан ролен аңларга һәм аңлатырга тырышкан материалларга киң урын бирә. Бу мәсьәләдә аның позициясе принципиаль һәм анык. «Әдип» имзасы белән басылган «Ихтилал һәм татар әдәбияты» исемле мәкаләдә бу турыда менә нинди сүзләр бар:

«Бу вакытларда (ягъни, революция чорында — авторлар) көрәшергә кирәк, эшләргә кирәк, сугышырга кирәк, яңа иҗтимагый тормыш корырга кирәк, тартышырга кирәк, җиңәргә кирәк, яңа тормышның нигезен ныгытырга кирәк. Мондый вакытта нәфис әдәбиятның урыны кая соң? Аның роле бик билгеле, ул да булса ярдәмче — хезмәтче роле. Мондый вакытта әдәбият һәм сәнаигъ нәфисә ихтилалны (...) ныгытырга, аны тирәнәйтергә хезмәт итсәләр генә яши алалар. Аларга шул дәрәҗәдә генә юл бирелә. Рәсем сәнгате ихтилал вакытында күбрәк плакат рәвешендә дөньяга чыкса, әдәбиятта агитационный шигырь һәм тенденциозный хикәя рәвешендә мәйданга чыга.

Безнең татар әдәбияты да шул юлдан китте. Махсус сәнаигъ нәфисә юлыннан

[1] «Тәлгать» — Мәхмүт Максудның псевдонимы.
[2] «Эш» газетасы, 1919 ел, 8 июнь саны.

бара торган әдәбият сүнә төште: аның урынына ихтилалга махсус әдәбият чәчәк атты» (1920, 20 январь).

Күренә ки, мәсьәлә беркадәр гадиләштереп, әмма гаять кызыклы куела. Газета әдәбиятка халык көрәше күзлегеннән карап бәя бирүне алга сөрә. Революция чорындагы татар әдәбиятының үзенчәлеген дә дөрес тотып алган ул.

«Эш» редакциясендә атаклы драматург һәм шагыйрь Галиәсгар Камал эшләде һәм бу чорда гаять зур активлык белән шигырьләр, шигъри пародияләр, эпиграммалар һәм куплетлар иҗат итте. Аның иҗатында политик лирика үзенең алга таба үсешен тапты. Бу елларда ул йөздән артык тезмә әсәрләр язып бастырды. Үзенең шул вакыттагы эшчәнлеге хакында язучы соныннан: «Гражданнар сугышының кызган чоры. Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин, кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә куның эшли идем», — дип искә алды (Г. Камал. Әсәрләр, 2 том. Казан, 1951, 19 бит).

В. И. Ленин рекрут җырлары турында сөйләшкәндә Демьян Бедныйга азатлык сугышы хакындагы яңа фикерләрне халыкка ансатрак җиткерү өчен традицион формаць киң файдаланырга киңәш биргән иде. Яңа әдәбият алдына тормышның үзе тарафыннан куелган бу таләпне «Эш» редакциясе һәм аның актив бер члены булган Г. Камал яхшы төшенеп эш итәләр. Моны язучының үз шигырьләрендә дә, газетада басылган башка әсәрләр мисалында да күрергә мөмкин. «Яңа тәкый гаҗәп», «Тагын гаҗәп китабы», «Ак» ка шөкер китабы», «Бакырган китабы», «Кызыл алма китабы», «Яңа типта халык җырлары» һ. б. шигырьләрендә Г. Камал иске әдәбиятта киң таралган форманы революция дошманнарыннан көлү, аларның чын уйларын һәм асыл йөзләрен фаш итү максатына яраклаштыра. Бу әсәрләре белән язучы татар совет әдәбиятында сатира жанрының тууына һәм үсүенә зур өлеш кертте.

Сүз җаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Г. Камалның «Эш»тә басылган әһәмиятле әсәрләренең кайберләре әле дә аның җыентыкларында урын ала алганы юк. «Имля», «Бары да кача», «Безнең файда», «Әсир моңы», «Ярлының җыруы» кебек югары идеяле әсәрләре бүгенге көн укучысына җиткерелергә лаеклылар. Г. Камалның «Эш»тә берничә псевдоним белән язуы («Ишангали», «Азат», «Кызыл», «Әгъли», «Матрос») мәгълүм. Бу да тиешенчә өйрәнүне сорый торган, яңа фактлар ярдәмендә язучы иҗатының байлыгын тагын да тулырак күз алдына китерергә мөмкинлек бирә торган моментлар.

«Эш» сатирага күп әһәмият бирде. Революцион халыкка үз дошманнарын танып-белүдә ярдәм итү ягыннан бу гаять әһәмиятле бурыч иде. Сатирик шигырьләрдән тыш газета битләрендә әдәби фельетон характерындагы әсәрләр киң урын алды. Шулай ук аерым хикәяләр дә («Һиҗрәт», «Буржуй мулла», «Спекулянт», «Бәйрәм чәе» һ. б.) бәреп төшерелгән югары сыйныфтан һәм хезмәт иясенә каршы көчләрдән көлү рухында булып, алар сатирик башлангыч белән нык сугарылганнар иде.

Әмма газета редакциясе әдәбиятның роле искене фаш итү белән генә чикләнмәвен, аның асыл максаты яңаны раслауда икәнен яхшы аңлап эш итә. Шуңа күрә дә революциянең һөҗүмчән рухын раслаучы, алдынгы көчләргә дан җырлаучы, яңа тормышны пропагандалаучы әсәрләргә киң урын бирелә.

**Рәхәтләндерә йөрәкне ирек җилләре,**
**Нинди нурлы безнең ирек илләре,**
**Турайды эшченең бөгелгән билләре,**
**Ни өчен бу сәгадәт моннан йөз ел**
**элек килмәде, —**

дип җырлады Г. Камал «Таң» шигырендә (1918, 119 сан). Исмәгыйль Закири шундый ук күтәренкелек белән:

**Күр әнә син хөр җиһанны, ул хәзер**
**нинди матур,**
**Нинди ямьле һәм күңелле, һәр**
**җирендә балкый нур.**
**И фәкыйрь син, ярлы эшче, кан**
**җылама, инде көл!**
**Алда киләчәк көннәрең нинди матур:**
**ал да гөл... —**

дип, яңа җәмгыятькә мактау язды («Ярлы халкыма», 1919, 9 декабрь).

«Эш» газетасының идея-политик юнәлешен билгеләүдә зур роль уйнаган редактор В. Шәфигуллин үзе дә әдәби әсәрләр яза. Аның әдәби эшчәнлеге әле безнең тәнкыйть күзенә эләккәне юк. Хәлбуки, ул — «Әүлия» псевдонимы белән дистәләгән шигырь («Курку юк», «Тәбрик», «Адвокат», «Минем җырым» һ. б.), Г. Камал белән берлектә («Әүлия һәм аның компаниясе» псевдонимы астында) көннең кадагына сугучы агиткалар һәм сатирик парчалар иҗат иткән язучы. В. Шәфигуллинның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлегенә дә әһәмият бирелергә тиешле. Аның кулы белән язылган баш һәм редакцион мәкаләләрдә, принципиаль тәнкыйтендә әдәбиятның һәм сәнгатьнең Совет җәмгыятендә тоткан роле, алар алдында торган бурычлар нигездә дөрес билгеләнгәннәр, алар яшь татар совет әдәбияты һәм матбугатының партия таләп иткән юнәлештә үсүенә билгеле бер күләмдә ярдәм иттеләр.

Газетада басылган әдәби әсәрләрдә революция һәм гражданнар сугышы тематикасы киң урын били. Әсәрләрнең күпчелеге татар укучысын зур көрәшләрдә яулап алынган революцион казанышларны саклап калырга чакыра. Көрәшнең асыл максаты эшчеләр һәм крестьяннар өчен чын азатлык алып бирү икәнлеге, бу изге эштә интернациональ дуслыкның зур роле тасвирлана аларда. Шигырьдә революция символы буларак Кызыл байрак төрле варнацияләрдә алынып сурәтләнә. Революцион чор шулай ук аерым төшенчәләрне яңадан карарга, аларга яңа мәгънә салырга мәҗбүр итте.

«Эш»тә яңа чыккан әсәрләргә һәм җыентыкларга рецензияләр дә басыла. 1919 елның 5 февраль санында «Әдәбият мәсьәләләре» исеме астында басылган рецензиядә, мәсәлән, Вакыйф Җәләлнең шигырьләр җыентыгы төпле тәнкыйть ителә. Артык җәелеп сөйләп тормастан, шуны гына әйтеп үтик. Монда әдәбият һәм сәнгать алдына куела торган төп таләпләрнең берсе гадилек, самимилек булуы ачык итеп куелган. Һәм, шул ноктадан карап, шагыйрьнең сүз сайлаудагы, җөмлә төзелешләрендәге, шигырь техникасындагы чатаклыклар тәнкыйть ителә. Мондый рецензияләр татар совет әдәбиятының төп принципларын ачыклауга җитди ярдәм күрсәтәләр иде.

Газетаның игътибар үзәгендә торган сәнгать тармакларыннан берсе театр булды. Анда татар театрының торышы, аның алдында торган бурычлар, репертуар мәсьәләләре, аерым артистларның уен осталыклары, декорацияләр, костюмнар хакында бик күп мәкаләләр һәм рецензияләр басылды. Алда торган бурычларның иң әһәмиятлесе һәм иң авыры — театр репертуарын революцион чор таләп иткән югарылыкка күтәрү иде. Газета тарафыннан бу юлда җитди адымнар ясалды. Бу юнәлештәге эшен ул, бер яктан, революцион чынбарлыкны дөрес һәм тирән чагылдырган әсәрләрне пропагандалау ярдәмендә алып барды. Классикларның әсәрләре куелу, революцион эчтәлекле яңа спектакльләр иҗат ителү «Эш» тарафыннан һәрвакыт уңай билгеләнеп узылды.

Икенче яктан, «Эш» идея-эстетик дәрәҗәсе түбән яки зарарлы пьесаларны тәнкыйтьләде, аларны репертуардан кичекмәстән алып ташлауны таләп итте.

Казандагы татар театр труппасының даими җитәкчесе булган тәҗрибәле артист һәм оста драматург Кәрим Тинчурин, «Эш» газетасы битләрендә басылган күп санлы мәкаләләре белән сәхнә сәнгатенең үсүенә күп өлеш кертте. Без бирегә К. Тинчуринның «Вак милләтләр театры хакында бер-ике сүз» дигән мәкаләсенә тукталып китү урынлы булыр дип саныйбыз. Бик тыйнак аталган бу «бер-ике сүз» асылда культурабыз тарихында зур урын тоткан артист һәм драматургның Октябрь революциясенә кадәр булган театрның авыр хәле, хөкүмәт башыннан капиталист һәм помещикларны бәреп төшергәч, сәнгать осталары өчен туган уңай шартлар турындагы тирән уйлануларыннан гыйбарәт.

«Иске заманда, ягъни капитализм хөкем сөргән дәвердә, — дип язды К. Тинчурин, — театр, үзенең туры вазифасын җуеп, бакалейный кибет төсен алган иде... Файданы күбрәк алу максаты белән, халыкны кызыктырыр өчен сәхнәдә нинди генә эшләр эшләнми иде!.. Мең, мең шөкер, хәзер театр ул купецлар кулыннан күчеп, Мәгариф комиссариаты хозурындагы хосусый театр шәгъбәсе карамагында калдырылды. Бу исә сәнгатьнең, театрның тәрәккые өчен бик зур адым булды...

...Ләкин бу якты көндә әүвәлгедән артыграк көч сарыф кылырга, эшләргә кирәк... Татар театрының хәзерге дәвере эшләр өчен иң күңелле бер дәвер. Татар театрының хәзерге барышы көткәннән артык файдалы нәтиҗәләр тудырачак. Бары эшләргә кирәк, эшләргә, эшләргә!..» (1919 ел, 6 февраль).

Бу елларда пьесаларга кытлык зур иде. Шуңа күрә тәрҗемә әсәрләргә мөрәҗәгать итү тагын да ешайды. Бу уңай күренеш иде. Әмма кайвакытта труппалар, рус һәм чит ил әсәрләрен татарчалаштырганда, вакыйгаларны һәм геройларны турыдан-туры татар җирлегенә күчерәләр, шулай эшләгәч татар тамашачылары спектакльне яратыбрак карый, күбрәк йөри, дип уйлыйлар иде. Мондый мавыгуларның нигезсезлеге һәм ялгышлыгы турында Г. Кәрәм «Беренче карлыгач» спектакленә язган рецензиясендә күрсәтеп үтте:

«Рус театры галәмендә азмы-күпме исеме мәгълүм булган мөхәррирләрнең әсәрләрен «татарчалаштырып» мәсхәрәлекләр итәргә моннан соңра юл куелмаска кирәк, — ди ул. — Мин рус әсәрләрен тәрҗемә итмәү тарафында түгел. Тәрҗемә ителсен, уйналсын. Ләкин нигә хаҗәт аңа татар фамилияләре биреп аны татарчалаштыру... Андый «тәрҗемәләр» әсәрнең рухын бозалар һәм «Беренче карлыгач» әсәре дә рус рухында уйналса, бәлки карарга лаек бернәрсә булып чыккан булыр иде» (1919 ел, 27 январь).

Театр эшенең башка якларына да игътибар ителде. Мәсәлән, Г. Камал 1919 елның башында Казанда куелган «Икенче кат яшьлек» спектакленә анализ ясаганда алда торган әһәмиятле мәсьәләләргә тукталды. Шундыйларның берсе, ди ул, ана телен яхшы белү. «Сәхнә телгә дә хезмәт итә торган бер урын булганлыктан, артист вә артисткалар телне бик яхшы белергә, аның хосусиятен аңларга тиешләр. Ләкин, тәәссефкә (кызганычка — авторлар) каршы, хәзергә татар театрында уйнаучыларның күбесендә телгә саксызлык күренә... Театр эшенә ничек сөйләсәң дә, нәрсә сөйләсәң дә ярый, бары тик тукталып кына калма, дигән карашны күптән ташларга вакыт җиткән булса кирәк», — дип, Г. Камал артистларны армый-талмый укырга, үз осталыкларын тагын да югарырак күтәрергә чакырды (1919 ел, 3 февраль).

Шул чорда чыккан башка газеталар кебек үк, «Эш»тә Габдулла Кариевның татар театрын оештыруда һәм үстерүдә керткән өлешен югары бәяләде. Танылган сәхнә осталарыннан Сатирә Латыйпова (1919 ел, 6 август), Гөлсем Болгарская (1919 ел, 31 март), Әшрәф Синяева (1919 ел, 27 январь), Габдрахман Мангушев (1919 ел, 19 ноябрь), Мохтар Мутин (1918 ел, 19 декабрь, 1919 ел, 10 апрель), К. Тинчурин, Колмәмәт һ. б. турында күп санлы мәкаләләр басылды. Бу сәнгать эшлеклеләренең театр тарихындагы роле, аерым образны тудырудагы иҗади уңышлары хакында сөйләүче мондый мәкаләләр бүген дә үз кыйммәтләрен саклыйлар. Аерым артистларның уеннары турында гына түгел, ә бәлки кайбер әсәрләрнең куелышы, хәтта

әчтәлекләре хакында бердәнбер чыганак булуларын да исәпкә алсак, бу мәкаләләрнең әһәмиятләре тагын да арта.

«Эш» методик характердагы әйберләр басуга да игътибар итте. Газетаның 1920 ел 3 май санында басылган «Авыллардагы һәвәскәр актерлар дикъкатенә» исемле мәкалә шул юлдагы беренче уңышлы адымнардан булды.

«Эш» — чыннан да бай һәм кызыклы газета. Без монда аның битләрендә урын алган кайбер материалларга гына тукталдык. Фактларны тагын да арттырырга мөмкин булыр иде әле. Газета битләрендәге материалларның күбесе псевдонимнар астында биреләләр һәм аларның кайберләре әле һаман ачылмаган. Әдәбият тарихы галимнәре алдында «Эш»тә очрый торган дистәләрчә псевдонимның кемнәрнеке икәнен өйрәнү бурычы тора. Бу псевдонимнарны ачу һәм ул әсәрләрне конкрет өйрәнү поэзиягә, прозага һәм тәнкыйтькә революция тагын да нинди яңалыклар — яңа фикерләр һәм поэтик бизәкләр алып килүен ачыкларга ярдәм итәчәк. «Мәһди», «М. Каразадә», «Тимер ага баласы», «Кызыл солдат» кебек псевдонимнар белән язылган хикәяләр, «Байки», «Зәки», «Крестьян», «Эшче», «Совдеп», «Ярлы шәкерт» һ. б. шундый имзалар куелган яки бернинди имзасыз шигырьләр, поэмалар, «Әбдәз», «Г. Бәди», «Театр сөюче эшче» мәкаләләре, рецензияләре әдәбиятыбыз тарихы өчен гаять кызыклылар һәм әһәмиятлеләр. Шуна күрә дә «Эш»тә яшерен имзалар белән тагын да кемнәр язышуын анык белү бик мөһим. Шунсыз, бу әсәрләр турында җәелеп сөйләп тору урынсыз булыр иде.

Йомгак төсендә шуны әйтергә кирәк. «Эш» газетасында басылган әсәрләр яңа әдәбиятның башлангыч адымнарыннан берсен тәшкил итәләр. Аларда инде яңа әдәбиятның төп үзенчәлеге ачык күренә: кешелектән качып, үзенең шәхси интим кичерешләр дөньясына кереп чумарга омтылучы кеше түгел, ә җәмгыять өчен яшәүче шәхес, революциядәге кеше бу әдәбиятның объект үзәгендә тора. Шундый рухтагы әдәби әсәрләре белән, иҗат мәсьәләләрен асылда дөрес яктыртучы күп санлы материаллары белән газета социалистик реализмга нигезләнгән татар әдәбиятының һәм сәнгатенең нигез ташларын салышуга булышты.

——□——

Рафикъ Гарәфетдинов

# ТАТАР ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ДЕМОКРАТИК ХӘРӘКӘТЕ ТАРИХЫННАН

*(1910—1914 еллар)*

Татар хезмәт ияләренең демократик хәрәкәтенә социал-демократларның йогынтысын ачыклаган материаллар, документлар тарихчылар тарафыннан моңа кадәр дә шактый өйрәнелде, тикшерелде, бу мәсьәләгә карата күп кенә хезмәтләр язылды. Ләкин бу хезмәтләрдә татарлар арасында 1910—1914 еллардагы революцион-демократик хәрәкәт җитәрлек чагылыш таба алмаган. Әлбәттә, моның үз сәбәбе бар: бу елларга караган архив материаллары тулысынча сакланмаган. Казан суд палатасы, Казан губернаторы канцеляриясе, хәрби-округ суды архивлары һ. б. материаллар 1918 елда акчехлар тарафыннан яндырылган [1].

Икенчедән, җирле властьлар, үзләрен «чиста» итеп күрсәтү, «чүп-чарны тышка чыгармау» нияте белән революцион хәрәкәткә бәйләнешле күп кенә документларның копияләрен үзәк органнарга (полиция департаментына, Мәскәү, Петербург охранка бүлекләренә һ. б.) җибәрми калдырганнар.

1907 елдан 1914 елга кадәр Идел буе охранка бүлегенең үзәге Саратовта була һәм Казан губернасындагы барлык революцион һәм демократик хәрәкәткә кагылышлы документларның копияләре ул вакытта шунда җибәрелеп барыла.

Саратов өлкәсе дәүләт архивы фондларында саклана торган документлар 1910—1914 елларда татарлар арасындагы революцион һәм демократик хәрәкәт тарихына кагылышлы күп кенә сәхифәләрне күз алдына китереп бастыра.

Билгеле булганча, 1905 елгы беренче рус буржуаз-демократик революциясе чорында Казанда татар социал-демократлары оешмасы төзелә һәм аның членнары үзләренең эшләрен реакция елларында да дәвам иттерәләр [2]. Бу оешма РСДРП директивалары нигезендә эш алып бара, татар телендә прокламацияләр, брошюралар бастырып тарата, эшчеләрдән һәм укучы яшьләрдән социал-демократик түгәрәкләр оештыра. Оешманың эшчәнлеге бер Казан шәһәре белән генә чикләнми, ул үзенең идеяләрен агитаторлар, пропагандистлар аша Уфа, Чиләбе, Оренбург, Саратов, Астрахань, Баку, Пермь шәһәрләренә, Кавказ һәм башка урыннарга да җәелдерә.

1910 елда Казанда татар эшчеләреннән һәм интеллигентларыннан торган яшьләр түгәрәгең университет студентлары Хөсәен Ямашев һәм укытучы Гафур Коләхметов җитәкли. Дөнья әдәбияты (М. Горький, Л. Толстой, А. Пушкин, Г. Гейне, Г. Гете, Руссо, В. Гюго һ. б. ларның әсәрләрен) эзлекле өйрәнү нәтиҗәсендә, түгәрәк членнарында дөньяга алдынгы караш формалаша. Алар демократик идеяләрне матбугат аша пропагандаларга «сул юнәлештәге журнал һәм газета чыгарырга» [1] телиләр. Ләкин бу теләкләрен тормышка ашырырга мөмкинлек булмый. Яшьләр җәй көне төрле якларга каникулга таралалар.

Түгәрәкнең эше көз көне яңа көч, яңа дәрт белән башланып китә. Бу турыда җирле властьлар да язалар. Түгәрәк белән шул ук Х. Ямашев җитәкчелек итә. Аның составында Г. Коләхметов, Рабига Габитова, Әминә һәм Мәдинә Терегуловалар, Гарифә Арсланова һәм башкалар була. Түгәрәк укучы яшьләр белән тыгыз элемтә тота. Казанда ул вакытта урта уку йортларында Әбрар Мусинов һәм бертуган Аитовлар җитәкчелегендә укучылар түгәрәкләре дә [2] эшләп килә. Х. Ямашев тырышлыгы белән юрист студентлар түгәрәге дә оеша. Бу түгәрәкнең максаты, жандармерия күрсәтүенчә, патша законнарын фаш итү, шул юнәлештә пропаганда алып бару мәсьәләләре була [3].

Х. Ямашев һәм Г. Коләхметовлар татар яшьләре түгәрәген социал-демократик оешмага әверелдерергә тырышалар. Түгәрәк һәртөрле милләтчеләргә каршы кискен көрәш алып бара. Буржуаз һәм милләтче элементлар түгәрәктән чыгарыла. Жандармерия агентурасы губернаторга

---

[1] «Пути революции» журналы. № 1, Казан, 1922 ел. 185—186 бит.

[2] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань, 1964 г.

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 1 фонд, 1 опись, 44 эш, 1911, 81 бит.

[2] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, 44 эш, 81 бит.

[3] Шунда ук. 98 бит.

Х. Ямашев һәм аның яклыларның түгәрәккә марксистик тенденция бирергә тырышуы аркасында кайбер членнарның түгәрәктән чыгуы турында хәбәр итә[1]. Буржуаз һәм милләтче элементлардан арынгач, түгәрәк 26 июльдә әдәби-политик журнал чыгарырга карар бирә. Г. Тукай, Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан һ. б. лар бу журналда эшләргә ризалык белдерәләр[2]. Түгәрәк икенче бер утырышта халыкның идея остазларын, прогрессив карашлы яшь кадрлар әзерләү мәсьәләсен күтәрә. Г. Коләхметов татар яшьләре өчен һөнәргә өйрәтү мәктәпләре ачу тәкъдимен кертә[3].

Түгәрәк бүтән шәһәрләрдәге, шул исәптән Киевтагы мөселман студентлары оешмалары белән элемтәне ныгыта[4].

1912 елның 9 октябрендә Киев оешмасы членнарының берсе (бу оешма җитәкчеләреннән берсе Г. Ибраһимов була) Казандагы түгәрәк членнарына болай дип яза: «Мин революциягә... ышанам... Мин — революционер, изелгәннәрнең, җәберләнгәннәрнең һәм кимсетелгәннәрнең яклаучысы. Мин хәзерге халне кулга корал тотып җимерергә, барлык изүчеләрне, коллыкка төшерүчеләрне юк итәргә әзер торам»[5].

Казан түгәрәге членнары даими рәвештә Г. Ибраһимов белән хат язышып торалар. Г. Ибраһимов Казандагы студентларның берсенә: «Мин нәрсәдән башларга икәнен үзем дә белмим. Мөгаен, бу турыда соңгы хатымда барысын да язганмындыр»,— дип яза[6]. Димәк, Г. Ибраһимов та аларга еш кына хат яза торган була.

Г. Ибраһимов күрсәтмәсе буенча булса кирәк, Киевтан Казанга бер студент килә һәм ул, Киев оешмасы исеменнән, интернациональ социалистик оешма төзү идеясен белдерә. Мөселман түгәрәкләре программасын эшкәртү-тикшерү, аларны берләштерү өчен Киевка Казан оешмасыннан вәкил чакыра.

Киев оешмасыннан Казанга делегат килгәнгә кадәр үк, Г. Ибраһимов 1912 елның 13 декабрендә язган хатында Казанга китәчәк Киев студенты миссиясенең, идея күзлегеннән караганда, бик әһәмиятле булуы турында әйтә[7].

Казандагы татар студентлары киевлыларның чакыруына кушылалар. Киевта үткәрелгән съездга Казан университетының бер студенты сайлана, аны ике паспорт белән тәэмин итәләр.

1913 елның 17 апрелендә Киевта делегатларның утырышы була. Анда башлыча тактик һәм программа мәсьәләләре тикшерелә. Утырышта татар социалистик партия органы булган газета чыгару мәсьәләсе дә кузгатыла. Жандармерия документларыннан күренгәнчә, газетаның редакторы «революцион фикерле» татар, «һәр нәрсәгә әзер торган» Г. Ибраһимов булырга тиеш була»[1].

Әмма бу утырыш җирле властьлар тарафыннан туктатыла. Оешманың барлык членнарын һәм читтән килгән делегатларны тентиләр, кулга алалар. Галимҗан Ибраһимовның кульязмалары, тенденциоз характердагы китаплары һәм брошюралары конфискацияләнә. Үзен, беркадәр вакыт төрмәдә тотканның соңында, ашерен күзәтү астында, туган ягына — Уфага җибәрәләр.

1913 елның августында Казан яшьләре «Аваз» исемле кечкенә генә көндәлек журнал чыгарырга карар кылалар. Бу журнал апрель аенда Киевта кузгатылган мәсьәләне — социалистик партиянең матбугат органын булдыру мәсьәләсен тормышка ашырырга тиеш була. Журналда эшләү өчен Уфадан Г. Ибраһимовны чакырырга уйлыйлар. 1913 елның сентябрендә Г. Ибраһимов чыннан да Казанга килә һәм «Аң» журналына секретарь булып эшкә урнаша. Ул түгәрәкнең сул агымы составына керә һәм Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Г. Сәйфетдиновлар белән берлектә актив эшкә керешә.

Бу агым, югарыда әйтелгәнчә, Х. Ямашев исән чагында ук барлыкка килә. Жандарм управлениесе бу агым турында болай дип яза: «Бу агым узган елны сизелә башлады, ә хәзерге вакытта ул «Шәрык клубы» членнарының гомуми җыелышында аеруча кискен күренде»[2].

Оешманың утырышлары башлыча Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан, Ф. Мөхәммәдьяров, Г. Ибраһимов һ. б. лар квартираларында үткәрелә. Бу утырышларда политик, экономик һәм социаль мәсьәләләр күтәрелә. Шулар белән бергә алар күптән түгел үлгән шагыйрь Г. Тукай исемендәге җәмгыять оештырырга карыйлар[3]. Оешма членнары бу җәмгыять тирәсенә татар яшьләренең демократик элементларын тупларга уйлаганнар булса кирәк. Ләкин бу җәмгыятьне оештырырга җирле властьлар рөхсәт бирми.

Оешма татар халкы арасында демократик идеяләрне тарату өчен «Шәрык клубы»н файдалануга зур игътибар бирә. Жандарм управлениесе: «алар ике куллары белән «Шәрык клубы»на тотындылар һәм аны үзәк пунктка әверелдерергә телиләр», — дип яза[4]. «Шәрык клубы» җыелышларының берсенә татар яшьләре оешмасы үзенең бөтен составы белән катнаша. Провокаторлар татар яшьләре группасының милләтчеләргә каршы агитация алып баруы турында жандарм управлениесенә хәбәр итәләр[5]. Татар яшьләре оешмасы

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, 44 эш. 114 бит.
[2] Шунда ук. 1912. 59 бит.
[3] Шунда ук. 1913. 56 бит.
[4] Шунда ук. 63 бит.
[5] Шунда ук. 193 бит.
[6] Шунда ук. 194 бит.
[7] Шунда ук. 194 бит.

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, 25 эш, 1913 ел, 255 бит.
[2] Шунда ук. 353 бит.
[3] Шунда ук. 353 бит.
[4] Шунда ук. 490 бит.
[5] Шунда ук. 353 бит.

«Шәрык клубы»н татарларны иҗтимагый эшкә тарта алырлык агарту учреждениесенә, үзенә күрә «халык университеты»на әверелдерергә омтылалар [1]. Жандарм управлениесе бу оешманың Х. Ямашев, Г. Коләхметов җитәкчелегендәге әдәбият түгәрәгеннән үсеп чыкканлыгын кабат-кабат басым ясап әйтә [2].

Татар яшьләре оешмасы башка шәһәрләрдәге вакыйгаларны да җентекләп күзәтеп бара. Петербургта озакламый мөселман укытучылары съезды җыйнала. Анда татар яшьләре исеменнән милләтче Ф. Туктаров чыгыш ясый. Казан яшьләре аның чыгышыннан бер дә риза булмыйлар һәм аңа каршы матбугатта чыгыш ясыйлар. «Безнең, Казан университеты студентларының, — дип язалар алар, — Ф. Туктаровның кыланышларында һичнинди катнашыбыз юк һәм аның үз-үзен тотышы безне бик гаҗәпләндерә...» [3].

Татар яшьләре оешмасының эшчәнлеге торган саен көчәя бара. Хезмәт халкы арасында аның популярлыгы артканнан арта.

Бу вакытта милләтчеләр татар яшьләре арасында киң җәелгән прогрессив хәрәкәткә киртә куярга маташалар. Матбугат битләрендә татарларны «үзара дошманлашмаска, милләтнең гомуми дошманнарына каршы көрәш өчен берләшергә» чакырган мәкаләләр басыла [4]. Алар моның белән милләтчелек идеяләрен таратырга, татар халкын интернациональ тәрбияләүне тоткарларга тырышалар. Җирле милләтчеләр җыелышларының берсендә татар эшчеләренең бәйрәмнәрдә руслар белән бергә ял итүләренә дә каршы чыгалар. Большевик Г. Сәйфетдинов бу җыелышта эшчеләрне бәйрәм ялын бергәләп үткәрү мәсьәләсенә дини күзлектән карамаска чакыра. «Диннең эшчеләр мәсьәләсенә бернинди катнашы юк, — ди ул. — Сыйнфый интереслардан чыгып эш итәргә кирәк. Барлык эшчеләрнең дә интереслары бер үк һәм атнага бер мәртәбә булган ял көне рус эшчеләре өчен дә, татар эшчеләре өчен дә зур әһәмияткә ия» [5].

Аннары Г. Сәйфетдинов, профессиональ оешмалар мисалында, эшче сыйныфының гомуми дошманы белән көрәштә бердәмлекнең әһәмиятен ачып бирә.

«...Рус приказчиклары, — ди ул, — якшәмбе көнне профессиональ оешмаларының җыелышларын үткәрәләр. Әгәр татарлар бу көнне эшлиләр икән, татар приказчиклары җыелышка бик соңарып килергә мәҗбүр булалар. Ә профессиональ союзларны милләткә карап оештыру — бу приказчиклар интересына бер дә туры килми» [6].

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, 44 эш, 1912, 71 бит.
[2] Шунда ук. 71 бит.
[3] ТАССР Үзәк дәүләт архивы. 1 фонд, 4 опись, 6187 эш, 1914 ел, 8 бит.
[4] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, 44 эш, 1912 ел, 71 бит.
[5] ОР Үзәк дәүләт архивы, фонд ДПОО, свк. бер. 5, 28 бит.
[6] Шунда ук.

Г. Сәйфетдиновның бу чыгышына каршы милләтчеләр залда шау-шу, гаугa куптаралар. Г. Сәйфетдинов һәм аның иптәшләре җыелышны ташлап китәргә мәҗбүр булалар.

Чыныккан большевик үзенең партия эшен дәвам иттерә, төрле җыелышларда ялкынлы чыгышлар ясый, татар яшьләренең идея үсешенә һәрьяклап ярдәм күрсәтә. Мәсәлән, 1914 елның 20 февралендә артист Г. Кариев квартирасында үткәрелгән татар интеллигенциясе җыелышында Г. Сәйфетдинов зур речь белән чыга. Жандармерия документларыннан күренгәнчә, ул җыелышка катнашучыларны «идея эшенә» кушылырга чакыра [1]. Бу җыелышта кайберәүләрнең татарларның демократик хәрәкәтенә тар милли рамкаларда гына юнәлеш бирергә, татарлардагы милләтчелекнең социал-революционерлар һәм социал-демократлар өйрәтүенә туры килә дип ышандырырга тырышуларын Г. Сәйфетдинов кискен кире кага һәм гомуми революцион пролетар көрәшкә чакыра. «Социалистлар идеяләренең Гаяз Исхаков нярченнәренең максаты белән һичнинди уртаклыгы юк», — дип белдерә. Документта Г. Сәйфетдиновның речен җыелыштагылар бердәм хуплап каршы алуы турында әйтелә. Шул ук җыелышта Г. Сәйфетдинов тәкъдиме буенча, «һәртөрле милләтчеләргә каршы» юнәлдерелгән җыентык чыгарырга карар кылалар. Җыентык большевик Хөсәен Ямашев истәлегенә багышланырга тиеш була.

Яшьләр оешмасы тарафыннан оештырылган мондый җыелышларны большевиклар марксистик революцион лозунгларны пропагандалау өчен трибуна итеп файдаланалар. Мондый җыелышларның тәрбияви әһәмияте турында «Правда» газетасы (1913 ел, 24 ноябрь): «Җыелышларга йөз кеше килә икән, аның нәтиҗәсе меңләгән кешеләргә күренә», — дип яза.

Әлбәттә, ул җыелышларда большевикларның саны күп булмый, ләкин аларның хезмәт иясләренә йогынтысы әйтеп бетергесез зур була. В. И. Ленин болай дип яза: «Партия — сыйныфның аңлы, алдынгы катламы, аның авангарды. Бу авангардның көче аның санына караганда, 10, 100 тапкыр зуррак» [2].

Билгеле булганча, күптән түгел Үзәк партия архивында РСДРП Үзәк Комитетының Н. К. Крупская тарафыннан төзелгән адреслар кенәгәсе табылды. Андагы исемлектә Галимҗан Сәйфетдинов фамилиясе дә бар.

Хәзергә кадәр тарихчыларга Г. Сәйфетдиновның Гассан, Баязит һәм Баязитов дигән партия кушаматлары гына билгеле иде. Шул псевдонимнар белән ул большевиклар оешмасында тора һәм җирле матбугатта мәкаләләрен бастыра. Октябрь революциясенең Үзәк дәүләт архивында

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 опись, эш 25. 1913, 590 бит. ОР ҮДА. ДПОО ф., 1914, оп. 240, эш 32, 28 бит.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. 24 том, 34 бит.

саклана торган материаллардан күренгәнчә, ул «Ибниәмин» дигән партия кушаматы белән эш алып барган. РСДРП Үзәк Комитетына да, партиянең Үзәк матбугатына да аның бу кушаматы билгеле булган. Ул шул исем астында Үзәк белән элемтәдә торган, аннан партия әдәбияты һәм большевикларны кызыксындырган күп санлы сорауларга җаваплар алган. 1913 елның январенда язган хатында ул «Правда» газетасына «Социал-демократиянең бу күренешкә (рус һәм татар эшчеләренең бергәләп бәйрәм итү мәсьәләсенә) мөнәсәбәте нинди булырга тиеш! — дип мөрәҗәгать итә. — Минем бу мәсьәләгә карата кигезле, аерым бер карашым юк, социал-демократиянең бу мәсьәләгә карашын ачык итеп язуыгызны үтенәм, социал-демократлар, берләшү максаты өчен, татар эшчеләрен христиан бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә чакыра алалармы! Сезнең җавабыгызны көтәм... «Ибниәмин» [1].

Казан губерна жандарм управлениесенең 1913 ел, 4 мартында язган документларының берсендә «Ибниәмин»нең танылган социал-демократ Галимҗан Сәйфетдинов икәнлеге ачык күрсәтелә [2].

Моңа кадәр РСДРП Үзәк Комитетының Казан большевикларына җибәргән күрсәтмәләре генә билгеле иде. Югарыда күренгәнчә, димәк, бу бәйләнеш ике яклап та алып барылган. Бу бәйләнеш В. И. Ленинның һәм РСДРП Үзәк Комитетының татар халкының демократик вәкилләренең идея үсеше турында даими кайгыртып торуын өстәмә рәвештә раслый.

В. И. Ленин идеяләре рухында тәрбияләнгән Г. Сәйфетдинов чын пропагандист, актив агитатор булып җитлегә. Ул «Правда» газетасы идеяләрен киң пропагандалый. Казан губерна жандарм управлениесенең 1913 елның 4 мартында полиция департаментына җибәргән донесениесендә болай дип хәбәр ителә: «Ул (Г. Сәйфетдинов — Р. Г.) социал-демократларның легаль органы «Правда»ны ала, үзенең танышларына, иптәшләренә аны яхшы газета дип тәкъдим итә» [3].

Г. Сәйфетдинов «Правда»ны пропагандалап кына калмый, татар хезмәт ияләренә мөрәҗәгать итеп, мәкаләләр белән аның битләрендә чыгышлар да ясый. Мәсәлән, 1913 елның 25 январенда чыккан «Правда» газетасының 20 санында күренекле татар большевигы Г. Сәйфетдиновның татар эшчеләренә мөрәҗәгате басылып чыга. Бу мөрәҗәгать турыдан-туры В. И. Ленин һәм РСДРП Үзәк Комитеты күрсәтмәсе нигезендә язылa һәм басыла. Бу мөрәҗәгатьтә бер Г. Сәйфетдиновның гына түгел, барлык татар большевикларының политик карашлары чагыла.

Бөтен татар пролетариаты өчен гаять зур тәрбияви әһәмияткә ия булган бу мөрәҗәгатьне тулысынча китереп үтәбез:

«Татар эшчеләренә.

Россиядәге һәр милләт эшчеләренең туган телләрендә эшче газеталары бар. Рус, еврей, поляк, латыш һ. б. милләтләрнең эшче газеталары чыгып килә. Бары тик татар эшчеләренең генә эшче газеталары юк, ә бит Россиядә, бигрәк тә Казан, Астрахань һ. б. Идел буе шәһәрләрендә, шулай ук Урал һәм Себердә, татар пролетариаты бик күп.

Капитал власте астында безнең барыбызга да тормыш авыр. Хуҗаларыбыздан—эксплуататорлардан безгә күпме кимсенү, мәсхәрәләү кичерергә туры килә. Без болар турында дәшмибез, чөнки безнең үзебезнең мохтаҗлыкларыбыз турында язарлык, үзара берләшергә ярдәм итәрлек туган телебездә эшче газетабыз юк.

Казанда татар телендә өч газета чыга, ләкин алар вак буржуйларның интересларын гына яклый торган буржуаз газеталар. Яңа чыга башлаган көндәлек «Кояш» газетасының нәширләре байлар — сәүдәгәр Кәримовлар. Эксплуататор хуҗалар чыгара торган газетаның безнең интересларны яклавын көтү беркатлылык булыр иде...

Киләчәктә без, һичшиксез, үзебезнең эшче газетасын булдырырбыз. Без үзләренең хезмәт тиеннәренә зур тырышлык белән «Правда» газетасын тудырган рус эшче иптәшләребездән үрнәк алырга тиешбез. Ләкин безгә хәзер дә күңелебезне төшермәскә кирәк: безнең арабызда русча укый-яза алырлык кешеләр бик күп һәм мондыйларның саны артканнан арта бара. Шуңа күрә мин рус телен аңлаучы барлык иптәшләргә эшче газетасы «Правда»га булышлык күрсәтергә тәкъдим белән мөрәҗәгать итәм.

Бу газета рус эшчеләренең генә түгел, милләтенә карамастан, барлык пролетарийларның, рус, еврей, татар эшчеләренең — капитал изүе астында булган барыбызның да интересларын яклый. Рус хуҗа да, татар хуҗа да бер үк дәрәҗәдә эксплуатацияли. Без капитал белән көрәштә үзебез кебек үк рус эшчесенә кул сузабыз.

Иптәшләр, бу газета тиражына берләшик! Бу газетага үз хаҗәтләрегез, үз тормышыгыз турында языгыз! Русча укый белгәннәрегез аңа язылыгыз, аны һәр җирдә таратыгыз, анда язылганнарны русча аңламаучы иптәшләргә татарчага тәрҗемә итеп укыгыз.

Ибниәмин».

Г. Сәйфетдиновның бу мөрәҗәгате газетаның алгы битенә эре хәрефләр белән басыла.

1910—1914 елларда ул Казан губернасында гына түгел, Идел буенда, Уралда да иң зур, әзлекле большевикларның берсе булып җитешә.

Шулай итеп татар яшьләренә ул елларда большевикларның йогынтысы зур була һәм аларның политик үсешен нык тизләтә. Татар демократларының алдынгы өлеше, большевикларның тырыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә, халык арасында марксистик идеяләрне таратуда партиянең ыша-

[1] ОРУДА. ф. ДПОО, 1913 опись, сак. бер. 5, бүлек 28.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

кычлы ярдәмчеләре булып житешәләр. Ш. Әхмәдиев, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ. б.лар әнә шундыйлардан. Нәкъ әнә шулар татарлар арасында милли-азатлык хәрәкәте тудырган политик мәсьәләләрне җәмәгатьчелек алдына бөтен кискенлеге белән куялар.

Шундый мөһим мәсьәләләр тикшерәсе җыелыш 1914 елның февраль башында Г. Кариев квартирасында үткәрелергә планлаштырыла. Җыелышка Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов һ. б. лар чакырыла. Г. Ибраһимов анда «Татар яшьләре алдында торган бурычлар» дигән темага доклад ясарга тиеш була[1]. Ләкин, ни сәбәптәндер, бу җыелыш үткәрелми кала.

Күп кенә фактлардан күренгәнчә, җыелыш инициаторлары Казан татар яшьләре арасында партия ячейкасы оештырырга уйлаганнар булса кирәк. Жандарм управлениесе документларында Г. Ибраһимовның чыннан да социалистик мөселман оешмасы булдырырга тырышканлыгы күренә. Ул: «Россиядәге социалистик партияләр юнәлешендә партия оештырырга туры килер, моның өчен аларның эшчәнлекләрен, программаларын һәм уставларын яхшылап өйрәнергә, тәҗрибәләрен файдаланырга», — кирәк дип сөйли.

Әмма 1914 елның 13 февралендә Г. Ибраһимов кинәт кенә Казаннан китә. Җирле матбугат аның китүен төрлечә аңлата. Берәүләр иҗат эшен дәвам иттерү теләгеннән сәбәп итеп китерәләр, икенчеләр исә моны оешманың кайбер членнары белән конфликтка керүдән күрәләр. Ләкин сәбәп аларда гына түгел булса кирәк. Шәһид Әхмәдиев тарафыннан «Аваз» журналында эшләргә чакырылгач та, ул Казанда кышка гына калырга риза була; әгәр журнал оешмаса, кыш җиткәнче үк китәргә уйлый. «Аваз» журналы чыкмый, ә буржуаз матбугатта эшләргә ул теләми. Шуңа күрә Г. Ибраһимов 13 мартта Киев, Одесса, Сухуми маршруты белән сәяхәткә китә. Җирле властьлар «Г. Ибраһимовның сер итеп саклый торган максаты бар», дип уйлыйлар[1], аның сәяхәтен политика белән бәйлиләр. Аның Казаннан кинәт кенә китүе чыннан да революцион эшчәнлеге белән бәйләнгән булырга тиеш.

Г. Ибраһимов 1912 елны ук инде патша самодержавиесе өчен прогрессив язучы буларак кына түгел, революционер буларак та куркыныч фигурага әверелә һәм шуңа күрә җирле жандарм управлениесе аны көчле яшерен һәм ачык күзәтү астына ала.

Шулай итеп 1905—07 елгы буржуаз-демократик революциясенең беренче көннәрендә үк барлыкка килгән социал-демократик оешма членнары үзләренең политик пропаганда эшләрен революциядән соңгы елларда да эзлекле дәвам иттергәннәр.

Архив документлары шуны күрсәтә: 1917 елны М. Вахитов тарафыннан төзелгән Мөселман Социалистик Комитеты белән Х. Ямашев җитәкчелегендәге социал-демократик оешма арасында турыдан-туры бәйләнеш булырга тиеш. Татар яшьләре оешмасында актив эш алып барган Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Кариевләр белән М. Вахитовның дуслыгы, аларның 1917 елда Мөселман Социалистик Комитеты составына кертелүләре дә шушы фикер файдасына сөйли кебек.

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 5 фонд, 1 опись, эш 25, 561 бит.

[1] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 5 фонд, 1 опись, 25 эш, 585 бит.

—— □ ——

# ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

*Фәләх Насыйров*

## ХЕЗМӘТЕНӘ КАРАП ХӨРМӘТЕ

*Очерк*

Смена ахыры якынлашып килә иде. Сания оеган гәүдәсен язарга теләп, тураеп басты. Цехтагыларга күз йөртеп чыкты. Шул вакыт аның күзләре Вера Васильева тирәсендәге ташландык күн өеменә төште: «Саксыз кылана кызый. Никадәр материалны әрәм иткән!»

Сания беравык кызның ничек эшләгәнен күзәтеп торды. Ахырда, түзмәде, кулына алган күнен урынына куеп, аның янына китте.



— Верочка җаным! — диде ул, борчылып. — Ташландыкларың бик күп чыга бит. Кара, күпме өелгән!..

Кыз дәшмәде, башын гына түбән иде: күп шул, бик күп! Моны Вера үзе дә белә. Нишләргә соң?..

— Әллә ничек кенә кисәсез, сез, Сания Сабировна, — диде кыз, ниһаять. — Ә миннән булмый, барып чыкмый...

— Булыр, булыр! — диде аңа Заһирова. — Синең кебек кызлар да булдырмагач... Чак кына уйлап эшләргә кирәк. Күнне кулыңа алгач, иң элек ничек кисәргә кирәклеген күңелеңнән чамала. Ә син аның урта бер җиреннән кисә башлагансың. Алай ярамый. Менә моннан, кырыйдан тотын. Я, хәзер үзең кисеп кара.

Кыз тырышып-тырышып Сания күрсәткәнчә кисә башлады. Әмма аның хәрәкәтләрендә төгәллек, үз-үзенә ышаныч җитеп бетми иде әле.

— Хәзергә шулай дәвам ит. Эштән соң минем яныма килерсең. Үземнең ничек кискәнлегемне күрсәтермен, — диде Сания һәм өстәп куйды: — Өеңә кайтырга ашыкмасаң, дияем.

Ашыгамы соң! Вера, әлбәттә, калачак. Тик өйрәтсеннәр генә.

Әнә, Факия Фатыйхова, Клавдия Капитонова, Рауза Хафизовалар хәзер ничек оста кисәләр. Кайчандыр аларга да Сания апа булышкан бит.

Вера эштән калып, Сания апасы белән якыннанрак танышкач, ул аның өлгерлегенә гаҗәпләнмичә булдыра алмады. Ничек җитешә диген барына да? Дүрт баласы да бар бит әле аның. Дөрес, олысы инде кияүдә. Ә калганнары ир балалар, барысы да укыйлар. Алары өстенә иренең дә сәламәтлеге әйбәт түгел, кайта да урынга ава. Җитмәсә Санияне смена тәмамлангач, Вера кебек яп-яшь кызлар да тоткарлый. Кемнең эше авырдан бара, ул аларның берсе өчен дә вакытын кызганмый.

Читтән караганда, кисү эше бик гади күренсә дә, аның да үз рәте, үз җае бар. Шуның рәтенә төшенеп, җаен белеп эшләгәндә генә бер ягына кирәкле күн товары өелә, ә икенче ягына аз гына булып ташландык җыела. Ә тәҗрибәсез кисүченең, киресенчә, ташландыклары тау-тау булып өелә, ә күн товары бик аз чыга. Менә шуны күргәч, Саниянең йөрәге түзми. Эшен ташлап, иптәше янына ашыга.

Әнә шулай, тормыш ямен, хезмәт тәмен иптәшләренә булышуда күрә Сания Заһирова. Уйлап-исәпләп карасаң, цехтагыларга аның ярдәме аз булмады, күп булды.

Бервакытны унты һәм мех итекләр өчен каеш кисү кешеләрнең тәмам үзәкләренә үтте. Бик вак, четерекле эш иде бу.

Абдулла Гыйниятуллин да «булмый», дип ташлап качты. Аңардан соң берсенең дә бу эшне аласы килмәде.

Нишләргә? Каешлар бик кирәк!..

Цехта җыелып киңәштеләр дә каешларны чиратлашып кисәргә диган карарга килделәр. Ягъни, бер айда берсе, икенче айда икенчесе кисә...

Беренче булып Факия Фатыйхова белән Вера Богобцева үз чиратларын уздырдылар. Әмма икесе дә:

— Җүнсез эш икән бу! — дип сукрандылар.

Ә бит алар тәҗрибәсез эшчеләр түгел, бик оста кисүчеләр. Шулай да сменага 470 пар каеш бирә алмадылар, күннең яртысы чүпкә ташланды. Ул гынамы, киселгән каешның байтагын кире кайтардылар. Болар барысы да цехның хезмәт җитештерүчәнлегенә һәм, беренче чиратта, кисүче кесәсенә суга торган нәрсәләр иде.

Ул көннәрдә Сания тынычлыгын тәмам җуйды. «Кайчанга кадәр бу эш бригаданы җәфалар?» — дип әрнеде ул эченнән.

Әмма кисү эшендә 20 елга якын тәҗрибәсе булса да, капыл гына бу эшне үз өстенә алырга батырчылык итмәде.

Көн арты көн үтте, ләкин каеш кисүдә алга китеш күренмәде.

Ниһаять, Саниянең түземлеге чигенә җитте.

— Кая әле, кызлар, булмаса, үзем эшләп карыйм,—дип, каеш кисәргә кереште.

Авыр, бик авыр булды беренче атналарда. Нормасын үти алмады, ташландык та күп чыкты. Шулай да Сания чигенмәде. «Моның ничек тә берәр җае булырга тиештер бит инде!..» — дип үзен юатырга тырышты, күнне төрлечә үлчәп, кискечләрне төрлечә куеп карады.

Шулай эзләнә, тырыша торгач, эш бераз җайлана башлагандай булды. Ниһаять, ул айлык планны үтәүгә иреште.

Үтүен үтәде, әмма моның өчен никадәр көч, никадәр тырышлык куйганын ул үзе генә белде.

Ул арада чират пенсиягә чыгарга торган Нәфисә апа Хәбибуллинага җиткән иде.

— И-и, кызлар! Сез мине бу җәфалы эштән коткарсагыз иде! — дип үтенде ул цехтагылардан.

Кисүче хатын-кызлар: «Нишлибез?» дигән сымак, бер-берсенә караштылар. Әмма берсенең дә бу эшне үз өстенә аласы килмәде.

— Ярар, Нәфисә апа, — диде Сания. — Бу айда синең өчен үзем эшләрмен.

Икенче айда инде Заһирова эшне җиңелрәк башкарды. Шулай да каеш кисү шактый акрын бара иде әле. «Ничек итеп бу эшне тизләтергә? Моның өчен нинди юллар табарга?..» — Санияне әнә шундый сораулар борчыды.

Бервакыт ул кискечләр эленә торган урынга игътибар итте. Кискечләр уң якта эленеп торалар. Эшләгәндә аларны уң кул белән алып, сул кулга күчерергә кирәк. Кискәннән соң, яңадан уң кулга күчереп, элеп куясы. Смена буена биш йөзгә якын шундый хәрәкәт ясала. Һәр хәрәкәткә 2 — 3 кенә секунд вакыт китсә дә, эш дәвамында байтакка җыела. Әгәр бу кискечләрнең урынын уң яктан сул якка күчерсәң?

Бу фикер башка кисүчеләргә дә ошады. Шулай эшләделәр дә. Бу яңалык барысына да җиңеллек китерде.

Икенче айда Сания нормасын арттырып үтәде. Көнгә дә азмы-күпме экономия ясады. Әлбәттә, элекке күнегелгән эш нәтиҗәләре белән чагыштырып булмый иде әле моны.

Элекке эшенә күчәргәме, юкмы?

Кисүче хатын-кызлар телләре белән әйтмәсәләр дә, күзләре белән:

— Үзең генә эшләсәңче, Сания! — дигән сымак үтенеп карыйлар.

Заһированың йөрәге аңлый бу карашны. Бик яхшы аңлый.

— Әгәр бу эштә үзем генә калсам, сез каршы килмәссезме, кызлар? — диде ул бер көнне, уены-чыны белән.

— Кала гына күр, Сания! — дип шатланыштылар кисүчеләр.

— Карагыз аны, соңыннан, сорасагыз да бирмәм, — диде ул, елмаеп.

Шулай итеп Заһирова мәшәкатьле каеш кисү эшендә калды. Бу хезмәтне тизләтү һәм аны камилләштерү өстендә көн-төн баш ватты ул. «Тамчы таш яра», дип халык белми генә әйтмәгән. Уйлана торгач, тагын бер фикер туды аның башында. «Әгәр ике кискечне баш-башларыннан тоташтырсаң? Уртасыннан пычак сыярлык кына урын калдырсаң? Алай иткәндә каешны хәзерге кебек сыңарлап түгел, ә парлап кисәргә мөмкин булачак. Кискечләр арасында ташландык күн дә калмый».

Эштән соң ул технолог Сания Шакирова янына барып, үзенең уйлары белән уртаклашты.

— Бик яхшы фикер бу! — диде технолог. — Беренчедән, бу экономия ясарга мөмкинлек бирәчәк. Икенчедән, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрәчәк. Юк, синең эшеңдә генә түгел. Вак детальләр кисүдәге башка эш урыннарында да кулланырга мөмкин бу методны.

Саниянең бу тәкъдиме дә производствога кертелде. Аның эше тагын да җанлана төште. Айлык план системалы рәвештә арттырып үтәлә иде инде. Көнгә дә ул шактый экономия ясый башлады. Ә брак дигән нәрсә бөтенләй юкка чыкты. Хәзер Сания әзер продукцияне контрольсез, үз клеймәсен сугып кына тапшыра иде.

Тагын өч ел үтте. Тагын өч салкын кыш артта калды. Җир яшәргән, табигать җанланган язгы матур көннәрнең берсе иде. Кәтмәгәндә кисү цехына производство берләшмәсе җитәкчеләре килеп керделәр. Аларның шулай кинәт кенә җыелышып килүләре эшчеләрнең күңеленә шом салды.

— Ни бар?.. Әллә брак-фәлән киткәнме?..

Цех начальнигы кешеләрне тиз генә үз янына чакырып алды да:

— Иптәшләр! — диде ул тантаналы бер тавыш белән. — Бүген СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән безнең цех эшчесе Сания Сабировна Заһировага Социалистик Хезмәт Герое дигән исем бирелде.

Бу хәбәрне ишетүгә, цехтагылар шатлыклы гөжләп алдылар. Беренче шатлык дулкыны үтүгә, цех начальнигы сүзен дәвам итте:

— Иптәш Заһирова безнең цехта эшләгән 18 еллык хезмәт дәверендә 5864 квадрат метр күнгә экономия ясады. Икенче төрле итеп әйт-

кәндә, бу 26 мең пар күн итеге тегәргә җитәрлек материал! 7 еллык планны ул 5 ел 4 айда үтәде. Болардан тыш, үзегезнең күз алдыгызда, ул бик күп яшьләрне күн кисү осталыгына өйрәтте, бик кыйммәтле камилләштерү тәкъдимнәре кертте. Кыскасы, үзенең тырыш хезмәте белән илебез, халкыбыз каршында ул зур хөрмәт казанды.

Цехны алкышлар басты. Сания үзе исә аптырап, каушап калды. Тукта әле, ничек була инде бу?.. Герой булырлык нәрсә эшләде соң әле ул кадәрле? Гап-гади бер авыл кызы. Әле күптәнме кара бөдрә чәчләрен ике толымга үреп, зур күзләре белән һәрнәрсәгә кызыгып карый-карый Казан урамнарына беренче тапкыр аяк баскан иде. Бу 1934 елда иде бугай... Уйлап карасаң, шактый гомер үткән шул инде. 32 ел узып та киткән!

Әйе, әйе, моннан нәкъ 32 ел элек, 16 яшендә, ул менә шушы «Спартак» фабрикасына эшкә килде. Ә берничә елдан соң Вазыйх фабриканың капка төбендә биш көн рәттән аның чыгуын көтте. Фин сугышыннан кайткан чагы гына иде егетнең.

Ул чакта типсә тимер өзәрлек очучы-лейтенант иде Вазыйх. Аны үзе белән китәргә күндерде. Киев, Львов, Бессарабия... Ә бер елдан соң Ватан сугышы... Шул көнне үк Сания күкрәк баласын алып, юлга чыкты. Мең газаплар чигеп, ул көч-хәл белән үзенең туган авылы — Олы Мәңгәргә кайтып төште. Аннан Казан... Яңадан «Спартак» фабрикасы. Шатлык һәм борчулар белән тулы хезмәт еллары...

Бер караганда әле генә булган кебек ул көннәр. Баксаң, күпме еллар узган, күпме сулар аккан... Ул чакта туплар шартлавы астында күкрәгенә кысып чапкан Люциясе хәзер үзе ана булды. Сания инде әби булырга да өлгерде. Кызык бит: әби һәм герой!.. Аның йөрәгенә көчле шатлык дулкыны килеп бәрелде. Шунда ук ул ташкынны ниндидер курку хисе алмаштырды. Уен эшмени? Герой бит!.. Иптәшләр аны тәбриклиләр, кочаклый, үбәләр... Цехның иң яшь эшчесе Валя Факиева аңа бик зур чәчәк бәйләме китереп тоттырды. Кай арада табып өлгергәннәр диген! Саниянең күзләренә яшь тыгылды. Юк, ул үзенең хезмәтенә шундый зур бәя көтмәгән иде.

Ул дулкынланып, иптәшләре каршына чыгып басты. Шатлыгының чиге юк иде. Партиягә, хөкүмәтебезгә һәм үзенең «Спартак» коллективына бик зур рәхмәтләр әйтте, киләчәктә тагын да тырышыбрак эшләргә, бишьеллык планны дүрт елда үтәргә сүз бирде.

Смена бетүгә, Сания янына беренче булып Анастасия Бәдретдинова килде.

— Котлыйм, Сания җаным, тагын бер тапкыр, — диде ул, аны култыклап.

— Рәхмәт, Настя апа, күңел әле һаман да ышанып җитми...

— Бик зур хөрмәт шул, Сания, бик зур шатлык. Кара, онытып торам икән. Минем дә шатлыгым бар бит әле! — Бәдретдинова кулындагы хатны күрсәтте. — Улымнан. Барыгызга да сәлам әйткән. Цехны бик сагынам дип яза.

Бу Сания өчен дә шатлыклы хәбәр иде.

Армиягә хезмәт итәргә киткәндә, Настя апаның улы алар цехында кисүче булып эшләде. Бервакыт егет наянланып бозылып китте бит. Эштән дә иртәрәк китә, нормасын да үтәми, әнисен дә тыңламый башлады. Шуннан, цехта җыелып, кыздырдылар үзен. Шифасы тиде, егет рәтләнде.

Менә хәзер шул егет үз цехын сагына башлаган. Димәк, иптәшләренең сүзен дөрес аңлаган, димәк, коллективның яхшы, матур яклары күңеленә сеңеп калган.

— Әйтеп яз үзенә, кайтсын. Туп-туры үзебезгә кайтсын, — диде Сания. — Эш сөйгән кешегә хезмәте дә, хөрмәте дә җитәрлек бездә.

# ГӨЛЛӘР ЧӘЧӘК АТА

*Очерк*

Минем каршымда чәчәкләр. Бик матурлары бар: күзләрне камаштырырдай кызыллары да, йомшак җилдәй иркәләүче аклары да, карап туйгысыз зәңгәр һәм күкләре дә.

Мин аларга тыныч гына карый алмыйм. Алар күңел хатирәләрен уятып, мине узган еллар кочагына илтеп ташлыйлар, барыр көннәрне күз алдына китерәләр.

Менә, әле бүген дә, бөркелеп үскән чәчәкләргә карап утыра торгач, үземнең бер танышымны хәтерләдем. Юк, бүген генә түгел, мин аны һәр елны гөлләр чәчәк аткан чакта исемә төшерәм. Чәчәкләр һәм кеше... Кеше һәм чәчәкләр...

Мин аның белән моннан 9 ел элек Әгерҗедә очрашкан идем. Аны һәр көн вокзал каршындагы бакчада күреп:

— Бу нинди армас хатын икән? — дип уйлый идем.

Куллары аның һәрчак балчыкка буялган, күлмәк итәкләре иртәнге чык белән юешләнгән була иде.

Бакчадагы гөлләр чәчәк ата башлагач, минем күңел гел шул якка тартыла башлады. Анда барган саен, бакчачы апа миңа үзенең гөлләргә булган мәхәббәте турында сөйли, үзенең шатлык һәм кайгыларын уртаклаша. Тора-бара минем үземә дә гөл «җене» кагылды. Вокзал медпункты каршындагы буш урынны чүп-чардан тазарттым да гөлләр утырттым. Бервакытны ул гөлләр чәчәк атты. И-и, шул чакта минем ничек шатланганлыгымны белсәгез иде! Үзең утырткан гөлләр чәчәген күрү — чиксез зур шатлык һәм бәхет китерә икән ул кешегә.

Хәзер инде ул бакчачы апа Әгерҗедән китте. Тормыш дулкыннары мине дә икенче якка илтеп ташлады. Әмма мин анда үскән гөлләрнең орлыгын үзем белән алып киттем. Ел саен мин аларны утыртам. Ел саен алар чәчәк аталар, һәм ел саен алар әнә шул бакчачы апаны хәтергә төшерәләр. Әйе, аның сөйләгәннәре һәм Әгерҗедәге күренешләр барысы, барысы да бүгенгедәй хәтердә әле.

... Менә станциягә поезд килә. Пассажирлар вагоннарыннан ашыгып төшәләр дә, бакчага җиткәч, шундый матур, шундый нәфис чәчәкләрне күреп, туктап калалар. Күзләре очкынлана, йөзләре елмая.

Поездның туктап тору минутлары санаулы. Ә пассажирларның бакчадан аерыласылары килми. Мөгаен, чәчәкләр аларның да йөрәк түрендә яшеренеп яткан бик матур, бик кадерле хатирәләрен уята торгандыр.

Поезд китә. Перрон тынарга да өлгерми, киткәне урынына икенчесе, аннан өченчесе килә. Тәүлек буе хәрәкәт дәвам итә. Тәүлек буе бакча яны тынып тормый. Чәчәкләр кояшка ничек тартылсалар, кешеләр дә ул бакчага шулай тартылалар.

... Наталья Васильевна Кречетникова ул чәчәкләргә карап үзе ниләр уйлый торгандыр? Үзенең яшьлеге турында уйлыймы? Әллә Ватан сугышында һәлак булган кадерле ирен юксынамы? Я булмаса фетнәчеләр тарафыннан үтерелгән сөекле комсомолка апасын хәтерләп сагышланамы?..

Аның апасы да гөлләрне бик ярата иде шул. Чәчәкләргә карап, киләчәк тормышының матурлыгы турында хыяллана торган иде. Аның хыяллары тормышка ашты, чынбарлыкка әверелде. Тик үзе генә бүгенге матур тормышны күрә алмады. Качса да булыр иде. Качмады шул. Фетнәчеләр комсомолларны үтерә башлагач, ул үзе урамга атылып чыгып:

— Сез ялгышасыз, абзыйлар! — дип кычкырды. — Сезгә кем җир бирде? Кем ирек бирде? Совет власте бит! Әнә шул егетләр тырышлыгы бит! Сезне кулаклар алдыйлар. Алданмагыз!..

Әмма ул сүзен бетерә алмады. Каршында басып торган кулак аны сәнәккә элде.

Шуннан соң кечкенә Наташа, апасы утыртып калдырган гөлләргә карап, яшьләрен аз түкмәде, аз сызланмады.

Ул гөлләр ел саен шытып чыктылар. Ел саен бөреләнеп чәчәк аттылар. Ел саен Наташа аларны карап, тәрбияләп үстерде. Ул чәчәкләрдә революция өчен корбан булган сөекле апасын, һәм аның белән бергә һәлак булган унбер көрәшчене күргәндәй була иде.

Моңа инде кырык ел вакыт узды. Күп сулар акты, хәтсез җилләр исте. Наталья Васильевна белем алды, укытучы булды. Үзенең бөтен тормышын балалар тәрбияләүгә багышлады. Менә ике-өч елдан ялга, пенсиягә чыгарга тора. Ләкин йөрәгендәге хатирәләр онытылмады, чәчәкләргә булган мәхәббәте сүрелмәде. Тормышы ямьләнә, матурая барган саен чәчәкләргә булган мәхәббәте һаман үсә, һәмен арта барды. Тормышның бүгенге яме, киләчәкнең матурлыгы әнә шул чәчәкләрдә чагылыш тапкандай булды. Җир йөзендә гөлләрнең күбрәк һәм төрлерәк булуын теләде ул.

... Өгерҗегә килгәч тә ул гөлләр үстерүен ташламады. Март башында ук инде аның кечкенә генә бүлмәсе ящиклар, чүлмәкләр белән тулды. Үзенә урын тарайды. Бөтен буш вакытын гөл үсентеләренә бирде. Көн саен аларга су сипте, күтәреп яктыга куйды, ә көннәр җылына башлагач, ишек алдына ташыды, кичләрен яңадан өйгә кертте. Аларны яшь баладай итеп карады, тәрбияләде. Мәктәп тирәсен гөлләргә күмәргә теләде ул. Балаларны чәчәкләр өзмәскә, аларны үстерергә, тәрбияләргә өйрәтте. Шул чәчәкләр белән бергә ул аларның күңелендә хезмәткә мәхәббәт уятырга тырышты.

Ләкин, гөл үсентеләрен парникларга күчереп утыртырга вакыт җиткәч, биология укытучысы:

— Минем рөхсәтемнән башка бер генә төп гөл дә утыртасы булма, парниклар яшелчәләр өчен кирәк. Кеше эшенә тыгылма, — дип аны кисәтеп куйды.

Наталья Васильевнаның иң кадерле, иң нечкә хисләре җәберләнде. Йөрәге сыкрап-сыкрап әрнеде. Ни өчен? Ни өчен?!. Мәктәп тирәсе чәчәкләргә күмелсә, начар булыр идемени?! Балаларның гөлләр үстерергә өйрәнүләре начар эшмени? Алар өчен үз хезмәтләренең беренче чәчәкләрен күрүдән дә зуррак шатлык бармыни?!

Ул гөл орлыкларын Мәскәүгә хәтле барып, зур кыенлыклар белән тапкан, үз акчасына сатып алып кайткан иде бит. Хәзер ул аларны кая куйсын?

Нигә соң ул, гөл үстерәм, дип шулкадәр борчыла, шулкадәр азаплана? Моның өчен биологларның башлары авыртсын, алар борчылсын. Әгәр аңа ирек бирмиләр икән, үзенең гөл үсентеләрен базарга да чыгарып сата ала бит ул.

Юк, юк! Гөл үсентеләрен ул сата алмый. Аның максаты — табыш алу түгел, ә чәчәкләр аша балалар күңелендә хезмәткә мәхәббәт ялкыны кабызу. Әйе, аның бөтен максаты шул!

Ә вакыт көтми. Ни мәшәкатьләр белән үстергән гөл үсентеләре, иркенлек, яктылык даулыйлар.

Наталья Васильевна, директор кабинетыннан чыккач, кайнар яшьләрен йота-йота, тимер юл станциясенә китте. Андагы ялангач перроннарны, ташландык бакчаларны күреп, күптәннән йөрәге әрнеп йөри иде аның.

Гөл утырту турында сүз чыккач, станция җитәкчеләренең авызлары колакларына җитте.

— Менә бәхет! — диделәр алар. Ел саен бишәр йөз сумлык гөл үсентеләре алып, бер генә елны да пассажирларга чәчәк күрсәткәннәре юк иде. Саклый, үстерә алмыйча алҗыйлар иде. Ә бу укытучы үзе утыртып, үзе үстереп бирергә риза. Чүп-чардан тазарта алса, әнә, рәхәтләнсен, бакчасы да, перроны да аның карамагында. Ала гына бирсен!

Станция җитәкчеләре шулай дип әйтсәләр дә, күңелләреннән ышанып ук җитмәделәр. Бер тиенсезгә шундый зур эшне кем башкарсын ди? Чәчәкләрнең нинди тәрбия сорауларын, үз тәҗрибәләреннән чыгып, бераз гына булса да беләләр бит алар. Бер укытучы нәрсә эшли алсын?...

Ләкин Наталья Васильевна башлаган эшеннән чигенмәде. Иң башта ул укучылар арасыннан үзенә ярдәмчеләр эзләде. Чәчәк үстерүчеләр түгәрәге оештырды. 5 һәм 6 класс укучыларыннан Зоя Маркова, Нурия Алиева, Ира һәм Алик Усмановлар, Ганиева һәм Башаровалар гөлләр үстерергә аеруча теләктәшлек белдерделәр. Наталья Васильевна аларның ата-аналары белән дә сөйләште. Алар да каршы килмәделәр.

Җир әле йомшап та өлгермәгән иде. Ул Әгерҗедән өч чакрым читтә гөл туфрагы эзләп тапты. Аны, үзенең яшь дуслары белән, станциягә ташыды, эретте. Өендәге гөл үсентеләрен шунда илтеп, күчереп утыртты. Аннан соң, күршедәге совхоз директорыннан рөхсәт алып, аларның парникларыннан файдаланды. Гөл утыртасы түтәлләрне эшкәртү җиңел булмады. Чәчәкләрнең төренә, төсенә, зурлыгына карап, тиешле тәртиптә утыртырга кирәк иде. Утыртып кына да эш бетми әле. Аларга иртә-кич су сибәргә, чүп үләннән тазартырга, сакларга, карарга да кирәк. 15 мең төп гөл үстерү уен эшмени! Бу үзе зур бер бакча дигән сүз бит.

Зур хезмәт һәрвакыт зур шатлык китерә. Бакчадагы гөлләр бөркелеп үстеләр, тирә-якны балкытып, шау чәчәкләр аттылар. Вокзал тирәсе Әгерҗенең иң матур, иң ямьле почмакларының берсенә әверелде. Ул чәчәкләргә карап, яшь бакчачыларның шатлыклары эчләренә сыймады. Алар сикерештеләр, биеделәр. Ата-аналарын алып килеп:

— Менә без нинди бакча булдырдык! Карагыз, нинди чәчәкләр үстердек! — дип, аларны әле бер, әле икенче сукмактан алып кереп, күрсәтеп йөрделәр.

Станция җитәкчеләре дә бу уңышка шаккатканнар иде. Алар, чәчәк үстергән яшь бакчачыларга һәм Наталья Васильевнага зур рәхмәт әйтеп, кыйммәтле бүләкләр бирделәр һәм барысын да Мәскәүгә экскурсиягә җибәреп кайтардылар.

Поезд көткән арада һәркем вакытын шушы бакчада, чәчәкләр арасында уздырырга ярата. Анда ул аларның яшь хуҗалары белән таныша, аларга рәхмәтләр белдерә. Вакыты булганы тәкъдимнәр дәфтәренә язып калдыра. Анда язылган рәхмәтләрнең саны ике йөздән артып китте. Ә күңелдән генә әйтелгәннәренең санын кем генә белгели алыр икән?!

Чәчәк үстерүчеләр үзләренең бакчаларын «Дуслык» бакчасы дип атадылар. Бу исем аның җисеменә туры килә иде. Чөнки ул бакчаны үстерүдә кемнәр генә катнашмады! Рус, татар, удмурт балалары, бертугандай дуслашып, иңгә-иң эшләделәр. Шунысы да бар: алар шушы бакча аркасында кемнәр белән генә дуслашмадылар! Бу дуслык хатлар аша әле дә дәвам итә.

Ижевск, Свердловск, Сарапул, Рига, Владивосток һәм башка бик күп шәһәрләрдән хатлар килде. Аларның берсен дә яшь бакчачылар җавапсыз калдырмадылар. «Быел да Әгерҗе аша кайтам. Чәчәкләрегезне бик сагындым!» — дип язды аларга Ерак Көнчыгышта хезмәт итүче матрос Мансур Хәсәнов.

Сызылып җәйге таң ата. Балкып кояш чыга. Кояш нурларына иркәләнеп, «Дуслык» бакчасындагы гөлләр уяна. Шул вакыт Наталья Васильевнаның кулларын кысып, аңа кат-кат рәхмәтләр әйтәсе килә.

КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР

*В. Монасыйпов*

# СУЙДЫЛАР

*Скетч*

**КАТНАШАЛАР:**

Хужа Хужиевич — ферма мөдире.
Сания — аның хатыны.
Сания — кош караучы кыз.
Бәдри — колхозчы.

Кошчылык фермасы. Әтәчләр кычкыра. Тавыклар кыткаклый. Сания, кәрзин өстендә утырып, нәрсәдер яза.

Сания. Ике сигезен уналты... алты да җиде була унөч, янә унтугыз. Шулай итеп күпме була? Ике мең дә тугыз йөз унбиш. Әйбәт! Бер атнадан квартал планы үтәлә дигән сүз! Тавыкларга рәхмәт, күз генә тия күрмәсен.... *(Сәхнә артында «Сания, Сания!» дигән аваз.)* Нәрсә бар? Мин монда ич!

Бәдри керә.

Нәрсә шул хәтле бугаз ертасың, әллә төлке күрдеңме?

Бәдри. Ниткән төлке, ди. Мөдир йомышы белән килдем. Менә укып бак, сиңа бирергә кушты. *(Кәгазь суза.)*

Сания *(кәгазьне укый)*. Нишләп төлке дисең, төлкенең үзеннән хат алып килгәнсең бит.

Бәдри. Яле, яле, кычкырып укы.

Сания *(укый)*. «Сания! Немедленно Бәдридән әйбәтрәк ике тавыкны суйдыр»... Кара син аны, тапкан Әндри казнасын! «Янә, шуңа өстәп, ике дистә йомырка да биреп җибәр. Хужа Хужиевич». *(Ачу катыш көлә.)* Тот капчыгынны, иптәш мөдир. *(Кәгазьне ертып ташламакчы була.)*

Бәдри. Тукта, җүләрләнмә! *(Кәгазьне тартып ала.)* Мөдир агаң белән алай шутить итмә!

Сания. Әйттем ич: миндә аның атасының малы да юк, Әндри казнасы да юк. Тавык суйдыр, имеш. Йомырка биреп җибәр, имеш.

Бәдри. Холкын беләсең ич инде, шаяртуны бер дә яратмый. Так што, карышып тору файдасызга гына булыр дим.

Сания. Үзе кайда соң хәзер? Кәнсәдәме? Валлаһи, менә барып тузгытып кайтам үзен!

Бәдри. Күл буенә төшеп китте. Председательләр белән. Кунак итмәкче буладыр, күрәсең. Хәер, анда безнең ни эшебез бар. Безнең эшегә хуҗа кешенең әмерен җиренә җиткереп үтәсәк, шул җиткән.

Сания. Син, пажалыста, җиткер. Ә мин җиткермим әле.

Бәдри. Алай димә, Сания. Таяк ике башлы бит ул. Шап иттереп үзенә кундыруы бар. Бел шуны!

Сания. Белмәгән кая, беләм. И син, пажалыста, Бәдри, йомырка шикелле, тавыкны өйрәтеп маташма.

Бәдри. Гафу ит! Мин синең кебек урта белемле түгел, надан кеше, булганы алты класс. Акыл сатмыйм, сатарга да теләмим. Сак бул, диюем генә. Киңәш йөзеннән. Мөдир бит председательнең уң кулы. Безнең башлык. Ни эшләгәнен беләдер инде. Үзе суйдыра икән, үзе үк соңыннан списать итү ягын да карар.

Сания. Төлке исәбенәме?

Бәдри. Анысы минем эш түгел. Ярар, Сания, житте, күп сүз — юк сүз, ди. *(Пәке чыгара.)* Кая, күрсәт: кайсыларын тотарга?

Сания *(каршысына басып)*. Тотмый тор әле, яме! Телисең икән, әнә мөдирнең үз йортыннан барып тот! Тавыклары бик күп, күркә кебек симезләр... Туктале, туктале! *(Серле елмаеп.)* Каяле, Бәдри, бир әле монда записканы!

Бәдри. Нәрсәгә ул? Бирмим, бирмим! Ертып ташларгамы?

Сания. Курыкма, ертмыйм.

Бәдри *(суза)*. Зинһар, ерта күрмә! Хужа Хужиевич аннары терелләй тотып ашар!..

Сания Бәдринең колагына нидер пышылдый. Кәгазьгә бармагы белән төртеп, нәрсәдер аңлата. Бәдри икеләнеп тора.

Сания. Нәрсә шүрләп калдың? Мин сине егет дип йөрим тагын, ә син арыш ипие...

Бәдри. Арышмы-бодаймы — тикшереп тормас Хужа Хужиевич...

Сания. Аптырагансың икән. Белмәдем, диярсең. Ялгышканмын, диярсең. Бетте-китте! Нәрсә куркып торырга. Ә инде соңыннан гаугa чыга калса, гаепне үз өстемә алырмын. Үзем шулай өйрәттем, диярмен. Бар, бар, кушканны эшлә! Хужа кешене интектермә! Дүрт күзләп көтә булыр!

Бәдри *(көрсенеп)*. Ну, Сания! Ялгыз башымнан колак кактырасың бит! *(Чыгып китә.)*

Пәрдә ябыла. Уң яктан зур гына төенчек күтәргән Бәдри керә.

Бәдри. Сания! Сания, дим!

Сания *(ишектә)*. Әү, җаныем!

Бәдри *(төенчеккә ымлап)*. Килештердем, Сания. Ике тавык, егерме күкәй. Үзе каядыр чыккан иде, үскән кызына бирдем записканы. *(Көлә.)* Дәресен туктатып, тавыкларны тотышып йөрде. Шундый житез кызчык!

Сания. Молодец, Бәдри! Элдерт тизрәк давай Хужа янына! Сыйла үзләрен һәйбәтләп кенә. Тавык шулпасы бик тә шифалы була ул. *(Көлә.)*

Бәдри. Аллага тапшырдым, Сания! *(Икесе ике якка китәләр.)*

Пәрдә ачыла. Сания белән ферма мөдире күренә.

Мөдир *(тешләрен казый-казый)*. Рәхмәт, Сания, хөрмәтең өчен. Зур рәхмәт. Кунаклар алдында хур итмәдең...

Сания. Нинди хөрмәт турында сөйлисез соң? Һич аңламыйм.

Мөдир *(шаяртып)*. Кара, кара, белмәмешкә салынып маташа. Тавыкларың өчен рәхмәт, йомыркалар өчен.

Сания. Аңлашылырлык итеп сөйләшегез, зинһар. Нинди тавык та нинди йомырка?

Мөдир *(авызындагы шырпысын төкереп)*. Обыкновенный тавык, ике тәпиле, кызыл кикрикле...

Сания. Беренче тапкыр ишетүем.

Мөдир *(сагая төшеп)*. Постой, постой! Бәдри синең янында булдымы?

Сания. Кайсы Бәдри? Белмим, күргәнем дә юк.

Поса-поса Бәдри керә. Яшеренә.

Мөдир. Как то-есть? Мин бит аны синең янына записка тоттырып җибәргән идем ләбаса.

Сания. Килеп җитмәгәндер...

Мөдир. Ничек килеп җитмәсен, ди...

Сәхнә артында шау-шу, «Кая ул, килмешәк!» дигән тавыш.

Чү! Минем хатын тавышы ич бу!

Сания. Әйе шул, Сания апа тавышы. Сезне эзли, ахры.

Уклау тоткан Сания керә.

Сания *(зәһәр)*. Ә, менә кайда икәнсең. *(Уклау белән кизәнә. Мөдир сәхнә буйлап кача.)* Үз тавыкларыңны суеп ашатып, председательгә ярарга тырышасыңмы? Үз хатыныңа запискалар язып яткан була! Имеш, фәлән тавыкны суй, имеш, фәлән дистә йомырка өлгерт, имеш...

Мөдир. Кичер, карчык, мин биноват түгел. Бәдри гаепле! Записканы бутаган. *(Саниягә ишарәләп.)* Аңа дип язган идем. Валлаһи, дим!..

Сания *(тыңламыйча)*. Аңгыра бәрән! Аңгыра сарык! Сиңа колхоз тавыгы беткәнмени! У, юньсез, нинди һәйбәт тавыкларымны харап иттең! Менә мин сиңа, хәзер! *(Кизәнә.)*

Мөдир *(башын тотып)*. Ай, уй, ой! Суйдылар! Пычаксыз суйдылар! *(Чыгып кача, артыннан хатыны куа китә.)*

Бәдри *(яшеренгән җиреннән чыгып)*. Ну, эләгә икән Хужа Хужиевичка уклауның калын башы!

Сания. Әйдә, эләксен! Сабак булыр!

# НӘКЪ ҮЗЕ

## *Скетч*

**КАТНАШАЛАР:**

Мөдир.
Әби.
Бабай.
Егет.

Кабинет. Өстәл янында мөдир утыра. Кулында карандаш. Ул телефонда сөйләшә.

Мөдир. Сәхибҗамаловны бир әле, җан кисәгем... Сәхибҗамалов! Я, эшләр кай тирәдә? Ал да гөл түгел дисеңме? Ал да гөл итәргә кирәк, әйе. Нәрсә? Әйе, запчасть. «Беларусь» тракторы өчен. Давай инде, сузма, җәһәтрәк... Минераль ашлама мәсьәләсе дә хәл ителмәгән әле. Хәл кылу белән үк шалтырат. Көтәм! *(Трубканы куюга, телефон шалтырый.)* Тыңлыйм. Миңлегәрәевме бу? Синдә нәрсә иде әле? Әһә, күп еллык үлән. Ничек дисең? Хәзер бер секунд, күз генә төшереп алыйм. *(Алдындагы кәгазьгә иелә.)* Әйе, ялгышмагансың. Башың эшли, маладис. Тагын нәрсәң калды әле синең? Тавыклар азыгымы? Булдымы соң? Булдыр син аны, тизрәк булдыр! *(Трубканы куя.)*

Әби керә.

Әби. Исәнме, балакаем?

Мөдир. Хуш киләсең, әбекәем! Әйдүк! *(Кулъяулыгы белән янәшә урындыкны сөрткәли.)* Ничек дип җырлыйлар әле? Утыр әле яннарыма, ял булсын җаннарыма. *(Көлә.)*

Әби. Рәхмәт, улым, рәхмәт. *(Утыра.)* Балаларыңның игелеген күрергә насыйп булсын.

Мөдир. Карап-карап торам да үзенә, шатланып бетә алмыйм. Бер

дә бирешмисең, ә? Синең яшьтәге карчыклар таякка таянып йөри, ә син прәме маладис.

Әби *(көрсенеп)*. Кая инде ул миңа маладис булу. Бөтен җирем ватык.

Мөдир. Белең чәнчиме әллә? Врачка күренергә кирәк, сәламәтлек бит ул — зур байлык.

Әби. Хак сүз, балам, хак. Мин теге... әлеге дә баягы йомыш белән килгән идем. Юллап җибәрсәң, диюем. Унтугызынчы тапкыр киләем, югыйсә...

Мөдир. Ансыз булмый шул, әбекәем. Кирәк булса, туксан тугыз тапкыр да киләсең аны. Аннары һәр эшнең үз тәртибе бар. Картлар әйтмешли, һәр эш җае белән, ботка пешә мае белән. Сабыр ит, әбекәем. Сабыр төбе сары алтын. Гаризаң, хәтерем ялгышмаса, Галәви Иванычта булырга тиеш.

Әби. Кайсы Галәви? Ничәнче комнатта утыра? Әллә кереп чыгыйммы?

Мөдир. Кереп йөрмә. Командировкада ул. Унбиш көнсез булмас.

Әби. Кайткач керермен инде алайса.

Мөдир. Кереп йөрисе юк, әбекәем. Зур кешенең эше күп була аның. Синең гаризаң барыбер безнең бүлеккә әйләнеп кайтачак. Әйләнеп кайту белән үк лично үзем сине чакыртып алырмын...

Әби. Теге вакытта да шулай дигән идең диюен...

Мөдир. Заманасы шундый бит, әбекәй. Бүген — болай, иртәгә — тегеләй. Ләкин аңа карап кына борчылма, бер җае чыгар әле, чыкмый калмас.

Әби *(торып)*. Шулай итеп, миңа кайчан килергә боерасың?

Мөдир *(көлемсерәп)*. Безнең контора казарма түгел, әбекәй. Боермыйбыз без. Үтенеп сорыйбыз. Рәхим итеп, килеп чык бер ике-өч атнадан соң. Аннары күз күрер.

Әби. Рәхмәт инде, балам, җылы сүзләрең өчен. Хуш!

Мөдир *(ишеккә кадәр озата)*. Хуш, әбекәй, хуш! *(Өстәл янына килеп утыра, трубканы ала.)* Кәримбеков! Язып куй әле шунда берәр төшкә. «Кеше үртәүче маймыл». Әйе, маймыл. Сине һәр якшәмбе зоопаркка йөри диләр, белергә тиешсең син ул хайванизмны. Тәк. Киттек дәлше. «Коньякта үсә торган җимеш агачы». Син нәрсә ихахайланасың? Шаяртма! Коньяк түгел, кон як!

Бабай керә.

Бабай *(ишек янында таптанып)*. Керергә ярыйдыр бит?

Мөдир. Нәрсә аны сорап торырга! Кер, давай, кер! Түргә уз!

Бабай. Рәхмәт.

Мөдир. Утырып җибәр, бабай. Хәл җый, аякларың талгандыр.

Бабай. Тала шул. Коридорыгызның очына чыкканчы...

Мөдир. Түбәтәеңне дә сал, башларың тирләгәндер. Җилли торсын.

Бабай *(түбәтәен салып)*. Менә, теге кәгазьнең яңа күчермәсен алып киләем *(суза)*.

Мөдир *(кәгазьне алып)*. Эһем, эһем. Да. Имзалар җитешми икән, бабай, ягъни визалар. Сиңа беренче чиратта Галәви Иваныч янына кереп чыгарга кирәк, аннары Казбек Нариманович янына, аннары Аюхан Соломонович янына... Шуннан соң гына миңа. Аңладыңмы?

Бабай. Гафу ит, аңлап җиткерәлмәдем. Узган айда үзең әйтеп чыгарган идең бит: «Яңа ай тууга туп-туры лично үземә кил», дип. Бик тә сөенеп килгән идем, булмады болай булгач...

Мөдир. Нишлим соң, бабакаем. Тәртибе шундый. Картлар әйтмешли, һәр эшнең җае бар, ботканың да мае бар. Сабыр ит, бабакаем, сабыр төбе — сары алтын...

Б а б а й *(күңелсезләнеп)*. Һай, ул төпкә житкәнче, сакалым саргаер. *(Ишеккә таба юнәлә.)*

М ө д и р *(бабайны култыклап)*. Син, бабакай, күнеленә авыр алма инде, яме. Тәртибе шундый бит...

Б а б а й. Ярар, ярар, исән бул. *(Чыга.)*

М ө д и р *(артыннан)*. Хуш иттек, бабакаем! *(Телефон шалтырый.)* Да, мин. Кандала агулый торган дару? Тәк. Дүрт хәрефтән дисеңме? Дөрес, бернинди ялгыш юк. Маладис, Сәхибҗамалов! Булдыргансың. Ярый. Покага телефон янында утырып тор.. Кирәксәң, шалтыратырмын. *(Трубканы куя, янә ала.)* Миңлегәрәев? Ник шалтыратмыйсың? Шалтыратырга гына тора идем дисеңме? Я, тыңлыйм. Әһә. Димәк, канның йөрешен тизләтә торган эчемлек булдымы? Булды. Австралия эте булдымы? Булды. Робинзонның ярдәмчесе булдымы? Булды. Чүлдә яшәүче елан булдымы? Булды. Әйбәт, бик әйбәт. Тыңла, тагын бер задание сиңа. Монысы соңгысы, әйе. Игътибар белән, дикъкать белән тыңла. «Үз эшенә формаль карый торган, канцелярия шартлары турында чиктән тыш кайгыртучы кеше». Хәрефләр санымы? Хәзер саныйм. Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез!..

Е г е т керә.

Е г е т. Исәнмесез.

М ө д и р *(баш ия, утырырга ишарә ясый)*. Карале, Кәримбеков синең яныңдамы? Бир әле... Я, нинди уңышлар? Җимеш агачы нишли? Абрикос дисеңме? Дөрес. Кеше үртәүче маймыл? Әһә, эзлисең пока. Ну, эзлә. Ярый, анысын әйтеп торма, соңыннан әйтерсең. Чөнки минем янда иптәш посетитель бар. Кешене зряга тилмертмик, әйе. *(Трубканы куя.)* Сәлам, егеткәем! Ни йомыш? Ник утырмыйсың, утыр. Тартынма алай!

Е г е т. Рәхмәт, утырып сөйләшсәк бик озакка китәр, мин дилбегә буе лыгырдарга яратмыйм. Әйттем-бетте!

М ө д и р. Миңа ничек? Гаҗәп, просто удивительно. Шул яшьтән нервларыңны тота алмагач, тора-бара нишләрсең? Яшьли әрәм булуың бар. Сакланырга кирәк.

Е г е т. Ярар, иптәш мөдир, дипломатияне читкә куеп торыйк. Ин элек миңа шуны әйтеп бирегез: ни өчен минем әбине мыскыл итәсез?

М ө д и р. Как то-есть? Сез мине кем белән булса да бутыйсыз түгелме?

Е г е т. Бутый, ди. Әбием барысын да сөйләп бирде инде. Адәм мәсхәрәсе! Унтугызынчы тапкыр килә бит кабинетыгызга! Җитмеш ике яшь бит аңа, җитмеш ике! Җитмәсә аяклары ревматизм. Ә сез аны, чебен кугандай, куасыз да чыгарасыз.

М ө д и р *(ачулана төшеп)*. Гафу ит, егеткәем, монда сан-эпидстанция юк, әйе. Һәм без монда кеше куу өчен куелмаган. Посетительны куып чыгару — безнең стиль түгел, әйе! Аннары шунысын да әйтим, егеткәем, речевой аппаратыңны иплә́брәк ач, яме! Разный түзга язмаганнарны сөйләү егет кешегә бер дә килешми... *(Телефон шалтырый.)* Кем? Миңлегәрәев? Соң, акыллым, язып ал дидем ич. Шуны да исеңдә тотмагач! Кабат тыңла булмаса. Укыйм: «Үз эшенә формаль карый торган, канцелярия шартлары турында чиктән тыш кайгыртучы кеше». Булдымы? Действуй! *(Трубканы куя.)* Вәт шул, егеткәем. Кулымнан килгәнен эшләдем, киңәшемне җәлләмәдем. Әбиеңә сәлам әйт, килеп чыксын минем яныма... Киләсе атнада ук. Аннары күз күрер...

Е г е т *(бүлдереп)*. Бюрократ сез! *(Чыгып китә.)*

М ө д и р *(җанланып)*. Нәрсә? Нәрсә, диде? Бюрократ, дидеме? (Кроссвордка иелә). Яле, яле, санап карыйк. Бю-ро-крат! Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез! Кара син аны, туры килә бит, ә? Нәкъ үзе!

П ә р д ә.

## БЕЗНЕҢ САФКА



### Төкле аягың белән!

Марс Шабаевның биш китабын да, әле туктап, сөенә-сөенә, әле кулга каләм алып, ачулана-ачулана укып чыктым...

Үзенчәлекле, үз тавышын тапкан шагыйрь Марс Шабаев!

Әйбәт шигырьләре бар.

Уйландыра торган яхшы поэмалары бар.

Шулай ук күп кенә уңышсыз шигырьләре дә, буталчык фикерләре дә юк түгел.

Китаплары арасында чын шагыйрь кулы белән, чын кеше күңеле белән язылганнарыннан «Ашкыну» һәм «Сине эзлим» җыентыклары.

Сазлыкларга такыр сукмак ята:
— Юл бирегез,
Бу мин...
Мин, — дисәм, —
Кочак җәеп көткән болыннарда
Серен сөйли миңа һәр сусән.

*(«Монда миңа бар да таныш...»)*

Күзләр капшый Бикүтбәне,
Моңсу карый җил тегермәне.
Канатлары аска салынган,
Ялгыз атлы үтә янынннан.

*(«Аерылышу»)*

Тугызынчы май.
Упалнамуч абый:
«Җиңү» диеп
Авызын ачуга,
Әллә кайдан җан өшеткеч сорау
Пуля булып атылып чыкты да:
— Әтиең кайда!
Кайда,
Кайда! — диеп,
Буразнага сугып екты да...
Җиңү таңы туган бер иртәдә
Бала чагым шулай җан бирде.

*(«Сине эзлим» поэмасыннан)*

«Җирән Конрад» поэмасы һәм соңгы елларда язылган шигырьләре Марсның кеше буларак нәрсә белән януын, теләкләрен, уйларын, мәхәббәтен һәм нәфрәтен күрсәтәләр. Гади кешеләр һәм үз җире турында уйлана башласа, шагыйрь дулкынлана, укучыны да дулкынландыра. Югарыда мисал итеп китергән юллар күңелемне бәйләп алып киттеләр. Монда җан сызланулары, тере уйлар, җанлы хисләр аралашып баралар, шагыйрь үз фикерен образлы, үтемле итеп үрә алган. Яза ала Марс, чын хисләрне, чын сүзләрне эшкә җигә белә!

Ләкин аның үзе язганча «наив» рәвештә космос белән мавыгуы, үз йөрәгенә барын да сыйдырырга, кочакларга омтылуы, «галәмнәргә йолдыз чөйгән чорда ник начарлык яши арада» дип беркатлы декларацияләр тәкъдим итүе мине сагайтты. Марс әдәбиятны, поэзияне аңлауда, аның җәмгыятьтәге урынын билгеләүдә әле буталчыклык та күрсәтә. Көндәлек вак-төякләргә ияреп китүе аның чын гражданлык хисләре белән сугарылган шигырьләренә дә кимчелек китерә.

Марс тырыш, кече күңелле, кешелекле иптәш. Ул «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре. Йөзләрчә башлап язучылар аның белән бәйләныш тоталар. Шагыйрь тормышның, әдәбиятның үзәгендә кайнап яши. Югарыда саналган кимчелекләрне ул җиңеп үтәр, аның моңа ихтыяр көче дә, таланты да җитәрлек. Әле генә СССР Язучылар союзына член итеп алынган иптәшкә чын күңелдән:

— Төкле аягың белән, Марс! — дип әйтәсе килә.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.

——□——

*Гариф Ахунов*

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ЗАМАН

Маңгайга тирән генә бер сыр өстәп, тагын бер ел узды. Бер кеше гомеренә телгә алып сөйләрдәй үзгәреш бирмәгән үткән гасырлар өчен бу, бәлки, күп вакыт та түгелдер, әмма көн саен зур ачышлар, тетрәүләр, дөнья күләм вакыйгалар булып торган безнең заманда бер ел нык сизелә.

Узган ел — Партиянең XXIII съезды елы. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә, халык белән партия мөнәсәбәтендә ленинчыл нормаларның гамәлгә кайтарылып, совет демократиясенең тагын да ныграк эзгә салынуы елы. Съезд барган көннәрдә миңа Мәскәүдә булырга туры килгән иде. Башкаланың үзәк проспектларында беренче номерлы партбилеттан Ильич рәсеме карап тора, гүя, Ленин бабай үзе съездның эшен тикшереп, барлап, күзәтеп бара кебек иде. Күңелләргә Ленин күбрәк килә икән — бу инде яхшылыкка!

1966 ел—яңа бишьеллыкның беренче елы. Үзәк Комитет безгә Совет власте елларында моңарчы әле беркайчан да ирешелмәгәнчә күп иген уңышы җыеп алынганны хәбәр итте. Монда мин тагын бер тойгымны белдерми уза алмыйм. Партия зур уңыш турындагы мәгълүматны бернинди сокланумазарсыз, гап-гади хакыйкать итеп әйтеп бирде. Димәк, партия безне ирешкән уңышларыбызга сабыр-тыйнаграк карарга өйрәтә.

Узган елда ил хәзинәсенә безнең республика керткән өлеш тә байтак. Татарстан 1966 елда дәүләт амбарына 58 млн. пот ашлык салды, нефть диңгезенә 84 млн. тонна нефть китереп кушты. Түбән Кама химия гигантына яңа бер магистраль юл килеп ялганды, Казан оргсинтез заводының яңа чираты эшли башлады... Республикабыз хезмәт ияләренең ирешкән уңышы — саный башласаң күп ул.

Ә без, язучылар, узган елда нинди уңышларга ирештек?

Проза дигән йөк атыбыз күмәк көшелгә нәрсә төяп китерде: бодаймы, арпамы, әллә солы кибәгеме?

1966 ел, образлы итеп әйткәндә, прозаиклар өчен күзне күккә терәп, яңгыр көтеп утырган явымсыз ел булмады. 30 лап хикәя, 7 повесть һәм ике роман — бу инде аз түгел. Ә сыйфат ягы ничек? Менә шул хакта без бүген күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшергә тиешбез.

## СЮЖЕТ КОРУ — ОСТАЛЫК

«Онытылмас еллар» романының икенче китабында без акка кара белән язылган «Бетте» дигән сүзне укыган идек. Ләкин бу авторның хәйләсе булган икән. «Казан утлары»ның узган елгы 3 — 4 саннарында И. Газиның «Канатланыр чак» исемле 8 табаклар күләмендәге яңа повесте басылды. Һәм менә без элекке танышыбыз белән тагын очраштык. Чанага кырын ята төшеп, Галиулла абзагызның улы, сызылып кына кара мыек чыккан Хәлим бара. Детдомнар үткән, югары уку йортын тәмамлаган, үскән, ныгыган яшь егет. Рәхәт тә соң малай чактан ук белгән дустыңны кабат очрату! Әсәрнең беренче битләреннән үк автор укучы җилкәсенә дәү генә бер таш бастырып куя. Хәлим Галиуллин обком вәкиле булып, «бөккәннәрне» турайтырга бара. Димәк, без чамалап алдык, бу утызынчы еллар, күмәкләшү еллары булырга тиеш.

«Канатланыр чак» өч төп сыйфаты белән аеруча хәтердә кала. Беренчесе — материалның гаять күп һәм кызыклы булуы. Икенчесе — теленең юморга, төргмә сүзгә, усаллыкка бай булуы. Өченчесе — сюжетның шактый ук таркау, оешмаган булуы белән.

Авторның нияте бик әйбәт. Ул Татарстан тарихындагы зур бер дәверне хроникаль тәртиптә, безгә таныш Хәлим биографиясе аша хикәяләп бирергә тели. Повестьта нэпманнар Казаны да, галстук урынына кашык тагып йөрүче футуристлар да, Татарстан татарларга гына булсын дип лаф оручы Дәүләтъяров та, Бишбалтаның текстиль комбинаты да, Польшада безнең илчене үтерү вакыйгалары да, авыл ярлыларының күп тавышлы, ярсулы дәгъваләре дә, «мировой рвәлүтсә» дә — барысы да бар. Тик болар бер повестька ничек сыеп беткәннәр?

Хәлим чанага кырын ятып авылга бара диган идек. Юл озын. Вакыт күп. Чана бара да бара, Хәлим уйлый да уйлый. Ул үзенең институтка килеп кергәнен искә төшерә. Футуристлар аның уена кайчандыр бергә укыган яшьлек дусты Кафия белән бәйле рәвештә килеп керәләр. Текстиль комбинатына Хәлим җәмәгать эше белән барып чыга һәм Галимә исемле бик чибәр бер кыз белән таныша. Менә шунда инде әсәрнең сюжет җебе берничәгә бүленеп, тармаклана, чәбәләнә башлый. Әсәрнең беренче бит-

ләрендә үк куелган төп вакыйга — Хәлимнең «бөгелгәнне» турайтырга баруы — торабара онытыла. Ник дигәндә, Хәлим утырган атлы чана повестьның буеннан-буена диярлек бара, шуның өстәвенә юлда баручы әлеге чана композициясе эченә тагын берничә «чана» килеп керә. Хәлим моннан дүрт-биш еллар элек, чанага утырып, авылларга чыкканын искә төшерә. Укучы аптырый башлый: кайсы чана соң әле бу? Әсәрнең башында ук, кагылмалы юлдан чыгып китеп, «бөгелгәнне» турайтырга баручы чанамы, әллә бөтенләй бүтән чанамы?

Бераздан без кыенлык белән булса да аңлыйбыз, юк, бу әле башка «чана» икән. Менә, ниһаять, беренче чана тиешле урынына барып җитә. Бөгелгәнне турайткан чакта авыл халкы Хәлимне һәм тагын бер бәкре уполномоченныйны чанага җигеп йөри. Сүз дә юк, бик зур осталык белән, чын сәнгатьчә тасвирланган бүлек бу. Ләкин шушы бер күренеш өчен укучыны бөтен повесть буена зарыктырып, көттереп тоту үзен-үзе аклый ала микән?

Әгәр сюжет әнә шул хикмәтле «чанага гына» корылган булса, әсәр бик ялыктыргыч булыр иде. Повестьның композициясендә Кафия бар, Хәлимнең аңа мөнәсәбәте бар. Укучыны үз тирәсендә Кафия тотып тора. Дөресен әйтим, миңа калса, «Канатланыр чак»ның төп герое Хәлим түгел, Кафия. Әсәрнең иң колоритлы, иң җанлы образы әнә шул кыз. Ул — тынгысыз, ул — эзләнүче кеше. Ул футуристлар артыннан да китеп карый, ул Хәлимдә дә мәхәббәтенә җавап эзли, гражданнар сугышы герое колаксыз Хәйри белән дә дуслаша. Ул яңа дөньяны аңларга тели, яңача семья корырга тели. Югнштурм формасындагы рабфакның күн картузларын киеп йөрүче бу кызның йөрәгендә искелеккә каршы көрәш романтикасы дөрли. Ә бит нэпманнар Казаны, футуристлар Казаны, «долой стыд!» Казаны, еллар үткәннән соң безгә бик аңлаешлы булып тоелса да, Кафияләргә аңлашылмаган ул. Батыр йөрәкле, эчкерсез бу бала, халык эше белән авылларга чыгып йөргәндә, утка ыргытылып һәлак була. Кыскасы, автор тудырган Кафия, аның ихтыярына гына буйсынмыйча, үз ирке белән беренче планга килеп чыга. Кафиянең төп герой икәнен, сюжет җебенең, вакыйгаларның гел шул тирәдә тупланырга тиеш булганын азактанрак автор үзе дә сизеп ала. Хәлимнең күз камаштырырлык дәрәҗәдә чибәр кыз Галимәгә өйләнүен, аларның инде балалары булуын ашыгыч кына бер эпизодта сөйләп-сурәтләп китә дә (пьесаларда моны сәхнә артында булган эш диләр), соңгы бүлектә безне Кафия каберенә алып килә. Дөресрәге, Кафия кабере дип өзеп кенә әйтүе дә кыен әле моны. Туганнар кабере бу, күмәкләшү елларында һәлак булган каһарманнар кабере. Аларның инде исемнәре дә җуелып бара, тик халык күңеле генә аларны һаман җуймый, булганын-булмаганын өстәп, үзеннән кушып, әкият-хыял итеп яшәтә.

«Канатланыр чак» повестен укып чыккаңнан соң Америкаының мәшһүр язучысы, мәрхүм Эрнест Хемингуэй сүзләре искә төшә: «Тормышта чын-чынлап булып узганнардан чыгып, һәм чынбарлыкның үзендә ни булса, шуңа таянып, янә дә шуларга үзең белгәннәрне һәм берничек тә белә алмаганнарны кушып, хыял ярдәмендә... чынлыкның үзеннән дә чынрак булган яңаны иҗат итәсең. Син ул яңага җан өрәсең. Әгәр дә үз эшеңне яхшы башкарсаң, җан өреп кенә калмыйсың, бәлки аңа мәңгелеккә юл ачасың. Менә ни белән рухланып язасың».

«Канатланыр чак» повестенда, минемчә, «чын-чынлап булып узганнар» күп, чынбарлыкның үзенә таяну да зур, ләкин «чынлыкның үзеннән дә чынрак булган яңаны иҗат итү» җитәрлекме икән?.. Минемчә, ул — Кафия образында яхшы ук төсмерләнә башлый, тик сюжет җепләре чәбәләнеп бетү, йокымсыраулы истәлекләр белән, чибәр кыз Галимә күләгәсе белән күмелү сәбәпле, автор иҗат иткән, автор җан өрергә теләгән яңаны без күңелдә зур тәэсир калдырырдай дәрәҗәдә тәеп җиткерә алмыйбыз.

«Канатланыр чак»ның теле әйбәт булуы турында әйткән идем. И. Газиның тел-сурәтләү чараларына оста булуы мин ачкан хакыйкать түгел. «Катя Сорокина» повестеннан башлап ук инде ул тел остасы — юморист булып саналып килә. «Канатланыр чак» та буеннан-буена юмор белән коендырылган; геройлар язмышындагы иң авыр вакытлар да авыр тойгы калдырмый, тормышчан үткен, бераз чеметтереп, әчеттереп тә ала торган юмор аларга карата теләктәшлекне көчәйтә. Бу әсәрдә авторның теле тагын да халыкчанрак, гадирәк була баруын аеруча шатлыклы хәл дип санарга кирәк.

Былтыр язылып, дөнья күргән әсәрләрдән Г. Минскийның «Яшенле янгыр» повесте тагын да элеккерәк заманны — беренче империалистик сугыш һәм революция алды елларын тасвирлый. Татарстаннан шактый еракта — Астраханьда яшәүче татар балыкчыларының һәм эшчеләренең, рус туганнары белән бергә, революцион көрәшкә күтәрелүләре бу повестьта шактый ук үзенчәлекле итеп, шул якларның табигате, халыкның сөйләү телендәге бизәкләре белән тыгыз бәйләп күрсәтелә. Кырыс реализм белән маҗара элементлары да бергә кушылып, әсәрнең мавыктыру көче тагын да арта төшә. Тик шуны әйтергә кирәк, «Яшенле яңгыр» повестенда көчле сурәтләү чаралары белән бергә, бөтенләй көчсез, зәгыйфь алымнарның да янәшә яши алуына хәйран каласың.

«Завод моржалары сөременә баткан бистә таңы күп көннәрдә шулай кояшсыз башлана иде».

Игътибар итегез! Автор нибары бер җөмлә белән никди зур, колачлы картина тудыра алган. Инде менә икенче җөмлә:

«Петяга Хәйдәрне очратып эчке дөньясына үтеп карауны (?) Норен заводы слесаре Андрей кушты.»

Бу җөмләнең исә әдәбилеге бик шикле. «Эчке дөньясына үтеп карау» — таушалып беткән шаблон булса, Петя, Хәйдәр, Норен, Андрей кебек исемнәрнең

бер-бер артлы килүе исә җөмләнең аһәңлелеген, музыкаль агышын юкка чыгара.

«Баржалар астына эшчеләр яшүсмер чагыннан керәләр дә, картаеп эшкә ярамас хәлгә җиткәч... чыгалар».

Бу җөмлә шулай ук авторның зур гомумиләштерүләр ясый алу осталыгын әйтеп тора, ягъни ул нибары бер җөмлә белән баржа төпләрен мүкләүче эшчеләрнең биографиясен бирә ала. Шуннан ерак та түгел, муеныңны сындырырдай җөмлә: «...Госпитальләрдә оештырылган инициатив группаларыннан берсенең җитәкчесе слесарь Андрейга Хәйдәр белән шөгыльләнүне (?) тапшырды».

«Яшенле янгыр» да осталык белән примитивлык бергә яши. Әгәр шуның примитивлыгы алып ташланып, осталыгы гына калса, әсәр бик нык отар иде.

## ТУГАН ИЛ ТОЙГЫСЫ

Узган елда «Казан утлары»нда басылган һәм авторның аерым җыентыгына да кергән икенче бер әсәр — Әмирхан Еникиның «Әйтелмәгән васыять» повесте.

«Әйтелмәгән васыять»нең сюжеты гади, мин әйтер идем, хәтта гап-гади. Акъәби, башкорт карчыгы, үлем түшәгенә ята. Уфадан зур урыннарда эшләүче балалары кайтып, аны үз яннарына алып тәрбияләр. Һәм ул, безнең Акъәбиебез, үлеп китә. Бары шул гына. Без басып йөри торган җир кебек, без сулаган һава, без эчкән су кебек үк гади һәм чын сюжет бу. Без хәтта монда сюжет бармы-юкмы дип тә уйлап тормыйбыз. Автор артыннан барабыз да барабыз. Ә менә Еники-художник «чынбарлыкның үзеннән чынрак» дөнья төзеп, ана җан өрә, һәм аның рухланып, илһамланып эшлаве, нәрсә хакына язуы укучыларга бик яхшы аңлашыла.

Туган ил тойгысы, туган җир тойгысы, туган тел тойгысы... Һәрбер халыкның борын-борыннан килә торган үз гореф-гадәтләре, үз йолалары бар. Аларның бер ишесе инде, бәлки, искерә дә төшкәндер, инде онытылып та бара торганнардыр. Әмма бәйсез-горур яшәү, күңелдә тирән моң һәм шигърият саклау, чаялык, батырлык, Тукай әйткән «без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез» кебек гадәт-сыйфатларның үлүе дә, искерүе дә мөмкин түгел. Әнә шуларны яклап күтәрелә Әмирхан-художник һәм ул үз эшен, моңарчы язган барлык әсәрләрендәге кебек, гаять зур җаваплылык тоеп, барлык осталыгын, күңел җылысын салып башкарган.

Алыгыз иксез-чиксез башкорт даласын. «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып, һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу... Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!»

Хисе, эпик зурлыгы ягыннан соңгы елларда безнең әдәбиятта сирәк очраган пейзаж бу. Ләкин бу соклангыч пейзаж автор өчен үзмаксат түгел, аның табигатькә мөкиббән китеп утыруы да түгел; ныклабрак уйласаң — бу Акъәбинең дала белән саубуллашуы. Зур музыкаль әсәрнең эчке пружинасын кереш музыка ачып биргән шикелле, Еники даласы да «Әйтелмәгән васыять» нең эчке моңын, аһәңен әзерли.

Дала белән янәшә бирелгән йөз яшәр Миңлебай картның уйлары әүвәлге белән бүгенгенең контрастлыгын тоярга ярдәм итә. Былтыр микән, өченче елмы, кемнәрнеңдер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа исе китә. «Кара син аны. Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән, сөләктәй яшь айгырга атланып, далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм 10—15 чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу, ичмасам, бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан агып йөриләр, имеш! Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!»

Моңысы дөньядан китеп барган өлкән кешенең драмасы, сагышы. Шушы ук сагышны Акъбикә әби дә кичерә. Авырып, үлем түшәгенә яткач, ул үткән гомерен, балаларын, балаларының балаларын күңеленнән барлап чыга. Өфедәге олы улы Суфиян инде хәзер отставкага чыккан полковник; кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә; кияве исә аның җаваплы зур урында утыра. Барысы зур кеше булып беткәннәр: кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач. «Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр.» Сүз дә юк, бәхетле аның балалары. Тик менә шул бик бәхетле балалар Акъәбидән ераклаша шикелле. Вакыт юк дип зарланалар, ә бактың исә, хатыннарын, балаларын төяп, үз машиналарында Кырымга барып ял итәләр.

Акъәби ач та, ялангач ат түгел, шөкер, аңа акчасын җибәреп торалар. Тик... атаанага, туган-үскән җиргә хөрмәт юк. Юк хөрмәт, ни хәл итәсең...

Өзгәләнеп васыятен әйтергә тели карчык. «— Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! — дип әйтәсе килә аның. — ...Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акъбикә дигән гади баш-

корт кешеләре, дөньяга китердек. Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде,— сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Ләкин Акъәбине берәү дә тыңламый. «Һай, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма»,— диләр. Һәм безнең чиста күңелле, эчкерсез Акъәбиебез изге васыятен әйтә алмаган килеш үлеп тә китә.

Юк, үлеп китә дип әйтергә ашыкмыйк. Әгәр ул кызлары Гөлбикәдә яткан килеш, җылы түшәге өстендә, үз җаена гына үлеп китсә, бер хәер иде. Югары белемнәр алган, «илгә файдалы кешеләр» булган балакайлар, карчыкның соңгы көннәрен, әҗәлен үзләрендә күрергә теләмичә, больницага илтеп салалар. Хәтта мөселманча күмегез, дигән сүзен дә тыңламыйча, табутка салып күмәләр.

Менә шул бер генә деталь белән дә Әмирхан Еники укымышлы Гөлбикәләрнең, полковник Суфияннарның туган-үскән авылга, сине тудырган ата-анага ихтирамы ни дәрәҗәдә икәнен оста гына әйтеп бирә.

Күңелдә тагын дала образы җанлана. Ул бик киң дә, ул бик буш та һәм моңсу да, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә.

Әсәрдә шагыйрь образы бар. Автор аның исем-фамилиясен дә атап әйтми, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге кеше дип кенә атый. Димәк, әдәби канұннар буенча, гомумиләштерүгә тулы ирек куя.

Акъәбине, аның тойгыларын, аның өметләрен аңлаучы каладагы бердәнбер кеше — әнә шул шагыйрь. Шагыйрь образы халыкның тел байлыгына, йолаларына, гореф-гадәтләренә фәлсәфилек кертә, аларны җыйный.

«— Акъәби! Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә. — Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем Акъбикә,— ди карчык, көтелмәгән сорауга бераз пошынып. — Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

— Димәк, син гомерең буе ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең син, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, ә менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!»

Монда киная белән әйтелгән ике зур мәгънә ята: автор, бердән, Акъәбинең асыл мәгънәсен ачып бирүе белән халыкның ак һәм пакь күңелле икәнен расласа, икенчедән, шагыйрьнең «әсәй кирәк» дигәне, мәгънәви әнигә, ягъни нәсел-нәсәпне онытмауга кайтып кала.

«Әйтелмәгән васыять» һәм мәгънә тирәнлеге, һәм тәэсир көче, сәнгатьчә бөтенлеге ягыннан булуы ягыннан узган елда иҗат ителгән хикәя-повестьларыбызның иң көчлесе, яңа, катлаулы заманның драматик күренешләренә бәя бирә торганы.

Ләкин «Әйтелмәгән васыять»кә карата, басылып чыгуына бер ел вакыт узса да, матбугатта әле бәя бирелгәне юк. Әле сөйләгәннәр минем үз фикерем генә... Аннары әдәби әсәрнең никадәр халыкчан, яшәүчән булуын вакыт узгач кына беләсең. Кайсы әсәр совет кешеләренә коммунизм төзүдә күбрәк булыша — аны билгеләү аерым язучылар кулында түгел, чикләнмәгән ул хокук — халык кулында, җәмгыять кулында, партия кулында.

## ӘТИЛӘРЕБЕЗ ЮЛЫННАН

Узган елгы дүртенче повесть — Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре».

Прозада Хәсән Сарьян инде биш-алты ел күренеп килә. Дәфтәр калынлыгы ике китап та чыгарып карады, тик әле ул укучылар теләнә дә, язучылар теләнә дә керә алмаган иде. Тормышта без аның балта остасы икәнен белә, холкында крәстиян агайга хас кайбер сәеррәк гадәтләре барлыгын да шәйләп йөри идек, ләкин күңелдәгене яшермичә әйтсәк, аның әйбәт повесть язачагына бик үк ышанып җитми идек.

«Әткәм һөнәре» безнең прогнозны челпәрәмә китерде. Алынган тормыш материалы белән дә, тел-сурәтләү чараларының сәнгатьчә тәэсирле, чын һәм төгәл булуы белән дә бу әсәр татар совет әдәбиятының бүгенге уңышлы әсәрләре рәтенә килеп баса.

Повестьның кыскача эчтәлеге болай: Әбел-Гаяз армиядән кайтып төшә. Аңа эш кирәк. Әтисе балта остасы булган. Кораллары сандыкта ята. Абыйсы Кави — менә дигән балта остасы. Олы туганы Локман — авылда бер оста. Тагын ни кирәк? Солдат гимнастеркасын салып ташлап, яшьтиләр, дус-ишләр белән, кайту шатлыгын ду килеп бер бәйрәм итеп алырга да — балтага тотынырга. Ләкин заманасы бүтән шул — солдатта малайның борынына машина исе кереп кайткан. Председательдән ул машина даулый, колхозда шуннан бүтән эшкә һич риза түгел. Ә бүгенгә генә машина юк. Әнә шул машина көткән арада Әбел-Гаяз, абыйсы Локман белән бергә яллапып, шабашкага чыгып керә —Нух исемле бер комсыз бәндәгә йорт салып бирә.

Менә шушы бер йорт салуга бәйле рәвештә әсәрнең барлык геройлары ачылып, ачыкланып бетәләр.

Иң элек Локман карт. Эшне сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән кеше бу. Сез аның беренче көнне Нух белән сөйләшүенә генә игътибар итегез.

Локман карыйсын карап, сорыйсы хакын, күпме төшәсенә хәтле исәпләп бетергәч, сүз башлый:

«— Кичә күңелең төшмәсен дип әйтмәгән идем, Нух, хәзер әйтим инде. Менәвыннан икегез дә түшәмне карагыз әле. Күрәсеңме, ничек кысканнар: такта араларыннан пычкы гына йөрткәннәр — такта читләрен пычкы ничек талаган, ә? Иске чабата кебек чачакланып тора! Бүтәнгә бик башлы бит соң син, Нух апай. Моңа нишләп башың

житмәде? Закрой тарттырырга кирәк иде бит!

Нух, алдануын исенә төшергән Локман картка әдәпсез бер сүз әйтте һәм:

— Осталары да шуның кебек иде анын, — дип өстәп куйды.

— Хәзер аларның барысы да шуның кебек, апай, элгәреге урыс осталары юк шул инде хәзер. Менә алар эшли торган иде, байтка! Әл-ләл-ләл-лә! Коеп кына куялар иде! Ул корал-инструментларын күрсәгез, ушың китәр иде, дурак! Ә хәзергеләрнең ние бар? Балтасы да пычкысы. Алары да түн тимер. Шуларны тота да хәзерге «оста», агач-ташны аннан талап, моннан талап, өй салып йөри...»

Бәләкәй генә бер өзек укыдык. Локманның теле дә, дөньяга карашы да, үз һөнәренең остасы икәне дә аермачык ярылып ята. Мондый кешеләр ышандыра, алар турында күбрәк беләсе килү тойгысы уяна.

Русларда «крепкая писательская рука» дигән тәгъбир бар. Әнә шул нык кул, ышанычлы язучы каләме сизелә монда.

Локманның бер кимчелеге бар: ул индивидуалист һәм акча колы. Кәефе бик киткән чакта, Гаяз әйтә аңа: карт башың белән, акча дип кешегә ялланып йөрмәсәң булмыймыни, ичмасам, әзрәк ял итәр идең, ди. Локманның җавап кыска: эшсез торсам, үләм мин, ди.

«Бик эшлисең килсә, әйдә колхозга. Бир һөнәреңне яшьләргә, ичмасам, даны икенче булыр. Ичмасам, картлык көнендә: «Акча сугып йөри», — дип әйтмәсләр.

Локман көрсенеп куйды.

— Әгәр инәй мәрхүм терелеп, мине яңадан тапса, мин гел син кушканча эшләрмен».

Әдәби образның тәгәллеген, бөтенлеген шуннан яхшырак күз алдына китереп булмый. Югыйсә, кайбер тәҗрибәсез прозаиклар Локманны бик тиз генә төзәлү юлына бастыра алган булырлар иде.

«Әткәм һөнәре»ндә истә калырдай образлар бер Локман гына түгел. Тракторда эшләгәндә салкын тидереп, үпкәсе авырып киткән Таһирҗан — изге күңелле егет; чамадан тыш аек акыллы, кырыс табигатьле председатель Сәйдәшев; турысын-турыга ярып сала торган балта остасы Кави; тилгән тырнагына эләгеп тыпырчынучы Халидә, баянчы кыз Земфирә, тормышны колачлап, көрәп, үзенеке генә итеп яшәргә омтылучы комсыз Нух... Әлбәттә, иң уңышлысы Әбел-Гаяз. Гаделсезлекләр аның күңелен җәрәхәтли ала, төчелек, кемгәдер ярашу аның табигатенә бөтенләй чит; юк-барга ул җебеп тә төшми, авыл агаенча практик акылы да үзе белән булган, сөйкемле егет ул. Кыскасы, Гаяз — гаделлеге, эш яратуы, уйлый һәм уйлана белүе белән безнең заманның типик бер яшь кешесе булып күз алдына баса.

Автор бер генә урында бу образның үсү логикасына хыянәт итә: Халидә ашханә мөдире Закиевтән котылу өчен акча сорый. Мәкерле Закиев юкны бар итеп, кыз өстенә акча өйгән, хәзер шуны түли алмас дибрәк. Халидәне үзенеке итмәкче. Гаделсезлекне җен урынына күрүче Гаяз мөдирнең тузанын очырмыйча, аның явызлыгын ачмыйча туктамас иде, ә Сарьян Әбел-Гаязның хәләл күкрәк көче белән тапкан 250 сум акчасын биреп, йолып алмакчы була Халидәне. Әсәрнең тагын бер кимчелеге бар: автор ахырга таба ашыга төшкән, повестьны, карандаш очлагандай, кинәтрәк очлап куйган. Геройлар язмышын ахыргача алып чыгып бетермәгән. Шул сәбәпле бик зур мөмкинлеге булган Гаяз дулкынландыргыч зур герой дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгән.

Шулай да Хәсән Сарьян бу повестьта үзен тапкан, ул үз тавышы, үз моңы белән сайрый. Сүзне кат-кат үлчәп, төгәлен генә, нәкъ кирәклесен генә язарга омтыла. Әсәрнең бик күп өлешендә ул моңа ирешкән.

## «БЕРӘҮ» ИНДИВИДУАЛИЗМ ЧИРЕ ЙОККАН ӘСӘРМЕ?

Узган ел басылып чыккан әсәрләрнең, минемчә, иң сөендерә торган төп сыйфатлары — гамьсез-битараф булмаулары. Заманның катлаулы күренешләрен аңларга һәм заман агымына бәя бирергә омтылу без әле тикшергән әсәрләрдә ярылып ята.

Аяз Гыйлаҗевнең «Берәү» исемле повестендә исә ул сыйфат бигрәк тә нык күзгә ташлана. Аяз, гомумән, соңгы елларда язган пьесалары белән дә, повестьлары белән дә тормышка актив катнашучы, чуар һәм тынгысыз җанлы язучы булып танылып килә. Ун ел буена драматургиядә кыйналу, ниһаять уңышка ирешә бару аның прозаик әсәрләрендә дә сюжет-композицияне мавыктыргыч-кызыклы итеп кора белүгә китерде. Әбит беркемгә дә сер түгел: үткен сюжетлы әсәр бер сулышта укыла, димәк, автор күтәргән мәсьәлә укучыга да кайнар килеш барып җитә.

1958 ел. Уттай урак өстендә пожар чыгып, авылның сигез өе чатырдап янып бетә. Тугызынчысын басудан кайткан трактор ишеп төшерә. Кичен идарәгә җыелалар. Урманга кытлык булган бу якларда тугыз кешене ничек өйле итәргә?

«Нигә тугыз? — дип каршы чыга Гыйльми Салихы, — Маһибәдәр карчыкка йорт кирәкми, калада яшәүче малае Исхак алып китсен анасын».

Гыйльми Салихының ни өчен болай сөйләнүе колхозчыларга ачык: аңа Маһибәдәр карчыкның кара туфраклы әйбәт бакча урыны кирәк. Шушы конфликтка бәйле рәвештә автор зур вакыйгаларны актарып ташлый. Сугыш чорын, сугыштан соңгы авылны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне эзлекле рәвештә, психологик мотивировкалары белән тулы бер дөнья итеп гәүдәләндерә.

Заманында «тайный милиция» булып торган Гыйльми Салихы кешеләрнең каннарына тоз салган. Колхоз председателе чагында басу өстендә тырмачы малайларны камчы белән яру дисеңме, авыру хатыннарны урын өстеннән типкәләп төшереп эшкә куу дисеңме — берсе дә калмаган. Маһибәдәрнең улы Исхак та Гыйльми Салихыннан аз җәфа чикми. Әнә шулай ике кешенең бәрелешендә туган зур бер вакыйга авылның бик күп кешеләрен үз тирәсенә җыйнап ала.

Минем ишетүемчә, бер тикшерү вакытында «Берәү»не индивидуализм чире кагылган әсәр итеп бәяләгәннәр, имеш. Бу — минем өчен бик сәер. Индивидуализм, гадәттә, чит ил язучыларына әйтелә торган бәя. Коточкыч пессимизмга бирелгән, үзен чолгап алган мөхит белән, җәмгыять белән алыш-биреше булмыйча, үз эчендә генә казынучы геройларга карата әйтелә ич бу сүз. «Берәү» аңа ни өчен лаек булды? Исеме берәү булганы өченме? Кайсы герой индивидуалист монда? Нурулламы? Бер кулсыз, бер аяксыз, сыңар күзле бу кеше ни гомерләр каравылда тора, сугыш чорында Белоруссиядә партизанлык итеп, Кызыл Йолдыз ордены алып кайта. Әллә Исхак индивидуалистмы? Үсмер килеш сугыш елында күпме эш башкара, институт тәмамлап чыга, җәмгыять турында тирәнтен уйлый белә.

«Берәү» — кайнар темперамент белән язылган әсәр. Матурны матур дип, ямьсезне ямьсез дип, үз исеме белән атап, бөтен тавышка кычкырып әйтеп биргән әсәр. «Калын-калын болытлар агылып, йолдызларны сүндереп-каплап йөриләр... Сугыш быел гына тынган. Сугыш куптарып төрле якларга сибеп ташлаган кешеләр үз урыннарына урнашып бетмәгәннәр... Нервлар соң дәрәҗәдә киерелгәннәр, йөзләр борчулы, тегендә дә, монда да урын өчен, кайнар су өчен ызгышып-талашып китәләр. Алама җиннәрен селкеп, хәерчеләр йөри. Бер почмакта лач-лоч төкеренеп, карта сугалар; талаш, кычкырыш, ызгыш...»

Күзләрне иркәли, күңелләрне рәхәтләндерә торган күренеш түгел бу. Сугыштан соңгы әнә шул күренешләр булмасын өчен Нуруллалар, Хәерлебанатлар, Исхак һәм Маһибәдәр карчыклар күпме тир түгәләр, күпме күңел хисен сарыф итәләр. Совет кешесенең бөеклеге дә әнә шунда бит, авырлыкны җиңә белүдә. Фашизм афәте китергән ачлыкны, хәрабәләрне генә түгел, кешеләр арасына шәхес культы китереп керткән иң әшәке, иң вәхши чирне — бер-береңә ышанмау чирен дә җиңәргә кирәк булды ич әле безгә.

Ярым гарип Нурулланың, сыңар күзле, сыңар куллы, сыңар аяклы Нурулланың фәлсәфәсе җаннарны тетрәтердәй көчле. Сугыштан соңгы беренче көннәрдә, басуларны баскан шайтан таякларына карап, ул менә нәрсәләр сөйли:

« — Төнлә уянам да тынлап ятам... Әгәренки тәмуг дигән нәрсә булса, аның җиле дә шулай шаулыйдыр дип уйлыйм. Коточкыч бит!.. Җиргә ятып җылыйсыларым килә... Күз бит, күз... Кыр тулы чүмәлә, кибән, ындыр тулы эскерт, ишек аллары тулы көшел, келәтләр тулы икмәк була торган иде. Күз җитә башласа, тәрәзәмне япмый идем мин... Һай, бу басулар!.. Кыр янында яшисем килеп, шушы Иманлe очыннан күчмәдем дә мин... Һай, бу кырлар! Аларны адәм төсенә керткәнче чиең чыгар әле. Һай, бу кырларның туфраклары... Шундый бер чакта йөрәксенеп агроном булырга йөрисен икән, молодецтан башка сүз юк синә. Вәйт. Их, егәрлегем булса, мин... Кыр тутырып бодай чәчәр идем. Офыктан офыкка бодай кыры булсын иде... Җир иркәләгәнне шулкадәр ярата бит ул... Назлы бит ул! Аны ятим итәргә ярамый, Исхак».

Җиргә теш-тырнагы белән ябышкан, җирнең ямен, бодай көшелләренең муллыгын җаны-тәне белән тоя белгән, шушы оптимист кешене ничек индивидуалист дисең? Бердәнбер кызы, багалмасыдай Саниясе бомба төшеп юлда һәлак булганнан соң да тешләрен шыгырдатып чыдый, яши ул. «Сизәсеңдер, Хәерлебанат апаң җылый. Күрәсеңме икән, көн дә җылый. Җылагач җиңелрәктер аңа, мөгаен. Ир кеше җылый алмый шул, — Нурулла ябык, сөякчел кара йодрыгы белән күкрәген төя. — Бөтен хәсрәте менә монда аның, җыя да җыя ир кеше. Җыелган хәсрәт, озак түгелмәгән су кебек ачый да ачый, зәһәрләнә, йөрәк маен кимерүче агуга әйләнә. Тик аннан котылырга кирәк... Ир кеше бер тапкыр җылый һәм шуны гомер буе хәтерендә тота. Җылаганын оныткан ир — ир түгел ул... Ир кешенең күз яше алтын бәясе тора.»

Татар әдәбиятында бик акыллы булып, остарып йөрүче картлар күбәйгән иде, ләкин аларның сүзләре инде, җил-яңгырлардан каралып беткән салам кебек, тәссез иде, күңелгә ятышсыз иде, менә безнең ул картларга яңа сулыш өстәп, зирәк һәм шигъри күңелле Нурулла килде.

«Берәү» повестеның ахырында төп геройның — Исхакның моңсу уйлары бар. Бәлки, шуңа карап кайбер иптәшләр бу повестьны индивидуализм чире йоккан әсәр дип әйтергә телиләрдер? Ләкин бу бит Исхакның үз эченә бикләнеп, дөньядан туеп калуы түгел, җәмгыятьтәге үз урынын эзләве. Иң зур сердәше Хәерлебанат карчык та, әнисе Маһибәдәр дә аңар авылга бу кайтуында караңгырак чырай күрсәтәләр. Һәм бу табигый. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, агроном белеме алган яшь, таза егетнең шәһәрдә каңгырап йөрүенә гомерләре иген эшендә үткән бу кешеләрнең кәефе китмимени? Әсәрнең иң азагында килеп кергән тагын «берәү» бар. Яшен ялтыраганда ялан аякларын салындырып яр өстендә утыручы Сания ул. Туктале, Исхакның сөйгән кызы да Сания иде түгелме? Әйе шул. Ләкин бу икенче Сания — 1943 елда туган ялгыз Сания. Берәүләр аңардан өлкәнрәк, икенчеләре бик бәләкәй, үзе генә йөри бу Сания: яшен яктыларына, су чылтырауларына гашыйк булган бу бала беренче Санияне бик хәтерләтә. Әсәр бу ике яшь кешенең алга таба тормыш сукмагыннан икәүләп китәчәкләренә зур өмет, зур киная белән тәмамлана.

1966 елда татар прозасына житди сүз алып килгән әсәрләр — менә шушы повестьлар. Болардан кала тагын ике повесть бар. Берсе — Г. Гобәйнең «Коръән серләре», икенчесе С. Тажетдиновның «Үлемнән яшәүгә» повесте. Икесе дә кирәкле, халык тарафыннан укыла торган әсәрләр. Әмма икесе дә специфик әсәрләр булганлыктан, мин аларга озак тукталмыйм. «Коръән серләре» — публицистика, темпераментлы, үткен тел белән язылган, дин йортының нигез ташларын берәм-берәм сүтеп ташлый. «Үлемнән яшәүгә» — документаль повесть,

сугыш чорының дәһшәтле бер документы. Нәби Дәүли повесте кебек үк, үз укучысын табар дип ышанам. Ин авыр шартларда да совет кешесенең зур булып, олы булып калуын раслый бу повесть.

## ЮЛЛАРНЫҢ ТӨРЛЕСЕ БУЛА...

Мәхмүт Хәсәновның узган ел басылып чыккан яңа романы «Юллар, юллар...» дип атала. Хәсәновны без «Яңа горизонт», «Урман шаулый», «Кыюлар юлы» повестьлары һәм «Саф җилләр» романы буенча беләбез. Холкы дуамал булган кебек, әсәрләрендәге дуамаллык, тигез түгеллек тә Хәсәновка бер генә мәртәбә әйтелмәде. «Ашыгасың, кабаланасың, җиренә җиткереп язмыйсың», — дип өлкән язучылар аңа кат-кат әйттеләр. Шуңа күрә М. Хәсәновның яңа романын мин әчке бер каушау, каләмдәш иптәшебез өчен зур бер борчылу белән кулга алдым. Дөресен әйтим, производство бүлекләре, җыелышлар минем борчылуымны расладылар. Мәхмүт Хәсәнов, Азнакайда ун ел чамасы яшәсә дә, нефтьчеләр тормышын әдәби әсәрнең җаны итеп алыр дәрәҗәдә белми, романда юл төзүчеләр әше күз алдына килердәй чын һәм аңлаешлы итеп тә, образлы итеп тә бирелмәгән. Мәхмүтне моның өчен тиргәргә кирәк.

Әмма М. Хәсәнов романының күрер күзгә үк уңышлы булган, өмет уята торган икенче бер ягы бар. Хәйрүш Исмаевның һәм Варис Исламовның язмышлары бар бу әсәрдә. Хәйрүшнең төрмәдән котылып, намуслы тормыш юлына аяк басуы әзлекле рәвештә, сәнгать чаралары белән ачып бирелгән булса, Варис, партия һәм профсоюз житәкчесе буларак, кешечә гади һәм тирәнтен уйлый белүче итеп тасвирлана. Менә шушы ике язмыш безне үз тирәләренда тотып торалар, алар турында язганда авторның теле дә җанга ятышлырак, образлы һәм төгәлрәк булып китә.

Сарьян Хәсән повестенда без авторның үзе белгән, күңеле аша кичергән балта остасы һөнәренең әсәрдә дә гаять җанлы, чын булып чыгуын әйткән идек. М. Хәсәнов романында да урман шавы, су буйлары, кумер яндыручы Минзаһир карт, аның ихлас күңелле кызы Миләүшә, балык тоту һәм киек кошлар аулау күренешләре сәнгатьчә матур һәм кызыклы язылганнар. Ул бүлекләрне укыганны сизми дә каласың. Ә менә юллар салу трестының эше шактый ук күңелсез, хәтта максатсыз диярлек. Автор бу тирәләрдә ни әйтергә теләгәнен үзе дә белми. Бу бүлекләрне төрле чәнечкеле сүзләр, юк-бар авыз ерулар белән тутыра. Бирелә тел дә төссезрәк, кешеләр дә схематиграк.

Әмма бу романны роман иткән юллар образы бар. Коры сүз белән генә әйтелгән образ түгел ул. Хәйрүш аркылы, партия җитәкчесе Варис Исламов аркылы, комсыз ана Сәрия түти аркылы ышандыргыч итеп бирелгән юллар образы. Юлларның төрлесе була, дип әйтергә тели автор: бар туры юл, бар кыек юл. Никадәр генә сикәлтәләр, казылмалар аша булмасын, Варис белән Хәйрүшнең юллары — мавыктыргыч, кояшлы юл. Спекулянт Сәриянең һәм явыз түрә Яруллинның юллары әйләнгеч, өметсез, караңгы юллар. Җыйнап кына әйткәндә, Мәхмүт Хәсәновның романында кимчелекләр бар, романның суын сыгарга, бәлки, кайбер бүлекләрен бөтенләй сызып ташларга да кирәк булгандыр. Әмма юллар образындагы кешеләр аны чын итәләр, шулар хакына романның басылып чыгуын хупларга, моны М. Хәсәновның алга таба үсеше дип карарга кирәк.

## ХИКӘЯЛӘР ТУРЫНДА

«Казан утлары»нда, «Азат хатын» журналында һәм газеталарда 30 лап хикәя басылып чыкканын әйткән идек. Сан ягы ярыйсы гына булса да, күңелдә җуелмас эз калдырырдай, әдәбият дөньясында вакыйга булырдай «гениальный» хикәяләр күренми.

Булганнар арасыннан әйбәтләре кайсы дигәндә, И. Газиның «Тургай картаямы икән?», Р. Төхфәтуллинның «Алсу болытлар», Г. Әпсәләмовның «Поши баласы», И. Салаховның «Колагир», Г. Мөхәммәтшинның «Хөсәен абзый», С. Сабировның «Капитаннар» хикәяләрен күрсәтергә була.

Рафаил Төхфәтуллинның балалар күңеле аша зурлар дөньясын бирә белә торган матур бер сыйфаты бар. Былтыр басылган «Алсу болытлар» хикәясе дә шундый. Аягы сынып больницага эләккән Илдус исемле малай аркылы Әлмәт кешеләренең тормышын, бер-берсенә мөнәсәбәтен, хезмәтен бик самими итеп бирә алган автор.

И. Салахов «Колагир» хикәясендә казакъ даласын, казакъ халкының матур йолаларын, шигъри күңелен, шул дөньяны бик белеп, бик яратып сурәтләгән.

Диңгезеннән байтак вакыт аерылып торган Сафа Сабировның бер табак күләмендәге «Капитаннар» хикәясен бастыруы — шулай ук игътибарга лаек. Гәрчә әхлак мәсьәләләренә багышланган булса да, авторның диңгезче җаны Иделнең кичке сулышын, төнге серлелеген әйләнеп уза алмаган. Җылы итеп, лирик буяулар белән тасвирлаган. Тик капитан Әсәдуллин белән җилбәзәк хатын Зәйтүнәнең тәртипләренә карата авторның ачык позициясе җитеп бетми.

Газиз Мөхәммәтшинның «Иван муллалары», «Изге Галиәкбәрләре» уенчык кебегрәк тоела иде. «Хөсәен абзый» хикәясе кызыклы характер бирүе белән әйбәт тәэсир калдыра. Тик вакыйгасына күрә күләме зуррак, азакка таба бераз ялыктыра башлый.

Узган елгы хикәяләрнең күбесе бик кыска, өч-дүрт кенә битле. И. Газиның «Тургай картаямы икән?» дигән хикәясе кечкенә генә күләмдә, табигый юмор хисен саклап, өч характер бирә алуы белән уңышлы, кыска һәм оста язу ягыннан яшьләргә үрнәк. Капка баганасын сөяп торучы Шәйхәттәр карт, Идел камышыдай зифа Гөлҗиһан карчык, район түрәләрен җайлап-майлап йөрүче председатель Мөхип — болар җыйнак, төгәл язылган характерлар.

Фатих Хөсни «Сабан туе» исемле юмористик хикәясендә бәйрәм ыгы-зыгысын, елларның иминлеген, халык күңеленен көрлеген һәм Арча ягы кешеләренең кунакчыллыгын, көлке-мазарны күп катыштырып, җанлы итеп сурәтли. Хикәя: «Бу мин, Фатих Хөсни сабан туе!» — дип, бер чакрымнан кычкырып тора.

Радик Фәизовның «Әниемнең куллары» исемле өч-дүрт кенә битле хикәя-нәсере дә әйбәт тәэсир калдыра. Әни кешеләрне олылау, ярату сизелә бу парчада.

«Казан утлары» яшь шагыйрьләрне көлтәсе-көлтәсе белән бастырып чыгара. Әмма яшь прозаикларга журналда урын бик чамалап, үлчәп кенә бирелә. Узган елны башлап язучы авторлардан Альберт Хәсәновның ике хикәясе («Гомер иткән нигез», «Яшь наратлар») һәм Мәдинә Маликованың «Кыр ягы» исемле бер табаклар чамасындагы хикәясе басылды. Альбертның теле-теше бар, хикәяне чамалый, тоя белә, кызыклы сюжетлар таба, тик хәзергә әле үз сүзе, менә бу бары тик минеке генә дигән үз тавышы, доньяны үзенчә генә тоя белүе юк. Яшь хикәяче Мәдинә Маликованың беренче хикәяләре ясалмарак иде, «Казан утлары»нда басылган «Кыр ягы» хикәясе ышандыра, колхозга җәйге эшкә килгән студентка кыз Дилбәр һәм аның күңел доньясы аша авыл кешеләре сөйкемле булып истә калалар. Моннан бер генә нәтиҗә ясап була, беренче башлаганда берәү дә таң калдырырдай хикәя язмый, прозаик бик авыр туа, авыр үсә, яшьләргә ышанырга, яшьләр белән иренмичә эшләргә кирәк.

Икенче бер журналда — «Азат хатын»да басылып чыккан хикәяләрне күздән кичергәч, редакциянең әле хикәяләр сайлап алу буенча ныгып җиткән үз тенденциясе юк дигән тәэсир кала. Моның өчен журналны гаепләп тә булмый: сайлар өчен хикәяләрнең күп булуы кирәк бит. Хәзергә әле андый мөмкинчелек юк, редакция үз агымына килеп кергән әсәрләрне, ә күп очракта язучылардан ялынып сорап алган әсәрләрне баса. Узган елны «Азат хатын» журналында чыккан хикәяләрнең иң уңышлысы, минемчә, Социалистик Хезмәт Герое, колхоз председателе Зәйнәп Садыйкова хикәяләре. Диләрә Зөбәерова язмаларында бирелгән бу хикәяләрдә тормыш бар, бүгенге колхоз авылы кешеләренең матур күңеле, җор табигате бар, халыкчан тел бар. Гомумән, авыл кешеләре бик самими булып ачыла. Бәлки шул юнәлештә эшләү, тормышның үз эченнән килгән чын хикәяләрен табу «Азат хатын»ның хикәяләр сайлаудагы үз принцибы, үз традициясе була алыр.

«Азат хатын»ның уңышлы хикәяләре итеп тагын Л. Ихсанованың «Кара урманда бер төн», И. Салахованың «Төн кызы», И. Нуруллинның «Башкала белән саубуллашканда» хикәяләрен күрсәтергә булыр иде. Редакциянең зур әсәрләрдән өзекләр бирә баруын да хупларга кирәк. 200 мең тиражы булган журнал татар әдәбиятының яңа әсәрләрен пропагандалауда зур эш эшли ала, билгеле.

Шулай да безнең әдәби-иҗтимагый журналларыбыз хикәя кебек иң кирәкле, иң нәфис, иң кыен жанрда эшләүче авторларны тиешенчә тарта белмиләр әле. Мәскәү журналларының күбесе ел саен иң яхшы хикәяләргә бүләк биреп баруны күптән оештырды инде. «Казан утлары», «Чаян», «Азат хатын», «Ялкын» журналларына да кызыксындыру чараларына керешергә вакыт җитте шикелле.

## КӨРӘШЧЕГӘ МӘЙДАН КИРӘК

Менә без 1966 елда басылып чыккан проза әсәрләрен күздән үткәрдек. Алар бездә нинди фикерләр уяталар? Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк, татар прозасы елдан-ел үсә, сгәрләнә, психологик тирәнәя. Моннан сигез-ун еллар элек съезд трибуналарыннан безнең геройларыбыз уйлый һәм уйлана белми дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә иде. Бүгенге әсәрләрдә геройлар тормыш фәлсәфәсенә төшенергә теләп, шундый күп эзләнәләр һәм шундый күп уйлыйлар, аларның ул уйлары таррак карашлы кайбер иптәшләргә хәтта ошап та җитмәве мөмкин. Үсү, тирәнәю, заманның иң мөһим мәсьәләләрен күтәрү кырыктагылар исәбенә бара. Әле күптән түгел генә яшь язучылар саналып йөргән унлап исем бүгенге көндә татар прозасының байрагын күтәреп барырдай дәрәҗәгә килеп җиттеләр. Без Галимҗан Ибраһимовтан, Фатих Әмирханнан, Шәриф Камалдан өйрәндек. Без бүгенге күренекле язучыларыбыз А. Шамов, К. Нәҗми, Г. Бәширов, И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Ф. Хөснидән өйрәнәбез. Һәм өлкән язучыларыбыз горурлана алалар, сугыштан соң алар тәрбияләгән буын татар әдәбиятына яхшы сортлы, татлы җимешләрен мул итеп бирә башлады. Соңгы ун елда язылган һәм заманыбызның иң актуаль мәсьәләләрен күтәргән әсәрләрне алып карагыз: «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Тамчылар ни сөйли?» — Рафаил Төхфәтуллин; «Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада», «Артта калган юллар» — Нурихан Фәттах; «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Берәү» — Аяз Гыйләҗев; «Кояш көн дә чыга», «Гомер ике килми» — Эдуард Касыймов; «Мәхәббәт сагышы» — Шәриф Хөсәенов. Узган елны шулар сафына «Әткәм һөнәре» белән Хәсән Сарьян килеп кушылды. Шушы ук исемлеккә Мәхмүт Хәсәнов, Газиз Мөхәмматшин, Барлас Камаловның да керергә хаклары бик бар. Тик аларга берничә теләк телисе килә: Газиз Мөхәмматшин, ваемсызлыгын бетереп, заманның җитдирәк проблемаларын күтәрсен, Барлас Камал активрак иҗат итсен, Мәхмүт Хәсәнов, киресенчә, сангатьчә эшләү бәрабәренә, темпын киметә төшсен иде.

Мин ничектер шулай кызыксынып, татар прозасының беренче әсәрләреннән башлап бүгенге көнгә чаклы басылган роман һәм повестьларны санап карадым. Заһир Бигиев романнарыннан башлап 1953 елга тикле барлыгы 100 повесть һәм роман басылып чыккан. Бу — 80 ел чамасы вакыт эчендә. Ә 1953 елдан узган елга чаклы арада, ни-

бары унөч ел эчендә, шулай ук 100 гә якын повесть һәм роман басылган. Димәк, татар язучысының активлыгы, язу культурасы үсә диган сүз. Ләкин тынычланырга бик иртә әле. 1965 елда миңа Нальчик шәһәрендә бүгенге проза турында сөйләшү өчен чакырылган зур гына киңәшмәдә булырга туры килде. Әле революциягә кадәр прозалары бөтенләй диярлек булмаган Төньяк Кавказ халыклары үзләреннән шундый күп язучылар үстереп чыгарганнар, бөтен Союзга чыгардай әллә никадәр повесть-романнар иҗат иткәннәр. Мин ул әсәрләрнең байтагы белән танышып та чыга алдым. Якача язылган бик үзенчәлекле әсәрләр алар.

Шул уңай белән һәм, бүгенге җыелыштан файдаланып, тагын берничә фикеремне әйтми кала алмыйм. Сугыштан соңгы яшь прозаиклар буыны үсеп җитте, җитди һәм актив яза. Анысы, әлбәттә, бик сөенечле. Әмма кырыктагылардан соң килә торган яшь прозаиклар бармы? Юк бит. Яна гына борын төртеп чыккан, бик каушап һәм бик капшанып кына атлый торган берничә бөртек егетебез бар. Минемчә, моның һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре бар.

Объектив сәбәбе икәү: беренчедән, бүгенге башлап язучы прозаикларны чын туганлык, каләмдәшлек тойгысы белән барлау җитми. Икенчесе, башлап язучыларга басылырга урын юк. Мәрхүм Гали Хуҗи «Идел» альманахын кузгатып, 3—4 номер чыгарып калган иде. Нинди гаҗәеп җанлылык башланган иде яшьләр арасында! Яки «Үсү юлын» алыгыз. Безнең кайсыбыз «Үсү юлында» чыкмады? Рафаил да, Аяз да, Нурихан да, бүтәннәр дә әдәбиятның зур юлына шуннан чыгып киттеләр ләбаса!

Әдәби әсәргә карата таләп язучының башлап яки очлап язуына карап куелмый дип, никадәр генә матур сүзләр сөйләмик, беренче әсәр ул беренче әсәр инде һәм аңарда тәҗрибәсезлек тулып ята. Безнең заманның атаклы язучысы Михаил Шолохов та: язучы никадәр талантлы булса да, аның беренче әсәре, күп очракта урта кул булудан узмый диган иде. Ә «Казан утлары» андый әсәрләргә урынны бик аз бирә. Без солидный журнал, без җитлекмәгән әсәрне баса алмыйбыз, ди. Ә кайда җитлегергә тиеш соң яшь язучы?

Бөтен тавышка кычкырып әйтәм — көрәшчегә мәйдан кирәк булган кебек, яшь язучыларга әсәрләрен бастырырга мәйдан кирәк! Яшьләрнең үз журналы кирәк!

Бездә сугыштан соң бик матур бер гадәт бар иде: ел саен диярлек яшь һәм башлап язучыларның конференцияләре уздырыла иде. Хәзер без конференцияләрне семинарлар белән алыштырдык. Янәсе, семинар күбрәк файда бирә, яшь автор өлкән язучылардан турыдан-туры киңәш ала, иркенләбрәк сөйләшә. Ләкин без мәсьәләнең икенче бер ягын онытабыз: конференциягә килгән яшьләр, бәйрәм хисе тоеп, күмәк ташкыннан канатланып кайтып киталәр, үзләре турында сүзне барлык иптәшләре алдында ишетәләр иде. Семинарга килгән ялгыз автор «Дом печать»нең соры стеналары арасында каңгырап кына йөри бит ул! Хикмәт менә нәрсәдә. Ел саен дип әйтмим, язучылар съезды арасында, ягъни дүрт елга бер мәртәбә булса да, яшь язучыларның конференциясен җыйнарга кирәктер, ахрысы... Канат куярга кирәктер яшьләргә.

## ЗАМАН ТӨШЕНЧӘСЕ

Кече яшьтән үк безнең күңелебезгә бер сүз кереп урнаша. Ул — революция. Кызыл галстуклы малай чагында ул безгә октябрь бәйрәме булып, ал байраклар күтәреп, урамнардан узган демонстрация булып тоела. Тора-бара без аның канлы көрәшләрен, азатлык хакына башларын салган батырларын китаплардан укып беләбез. Ләкин революция ул статистик бер нәрсә түгел. Гражданнар сугышы, илне күмәкләштерү, бишьеллык гигантлары төзү, Бөек Ватан сугышында Совет халкының данлы җиңүе, һәм, ниһаять, дөньяны таң калдырган космос эрасы — болар барысы революциянең үсүе, камилләшүе.

Логик яктан, уй-фикер йөртү ягыннан караганда, без заман төшенчәсен әнә шулай революциянең үсүе белән бәйләп аңлыйбыз. Ләкин бит язучы логик категорияләр белән генә эш итми. Ул хисләр дөньясына, кешенең психологиясенә үтеп керә, ул үз чорының тавышын, ритмын тотып алырга, замандашларының ниндирәк дулкында яшәүләрен әдәби-эстетик төшенчәләр белән әйтеп бирергә, «хисләргә исем табарга» омтыла.

Себер тайгасыннан кулына Колчакка каршы көсәк тоткан партизан күтәрелде. Ул моны батырлык эшлим дип эшләмәде. Утызынчы елларда авыл агае күмәк хуҗалыкка кушылам дип кулын күтәрде. Ул шулай ук батырлык эшлим дип уйламады. Бөек Ватан сугышында бөтен Россия соры шинель киде. Ул чакта да безнең ил халыклары батырлык эшлибез дип уйламадылар. Ә тәптәнрәк карасаң — боларның барысы батырлык иде. Партизан илне ак генераллар афәтеннән коткарды. Крестьян агай колхозга керәм дип күтәргән кулы белән бер кишәрлек җирен, атын зур көчкә әйләндерде. Соры шинельле Россия бөтен дөньяны фашизм чирүеннән йолып калды.

Әнә шул бөек борылыш елларының борчулы дулкыны иң әүвәл кайсы язучының җаныннан уза, кайсы язучы аның әйдәүче көчләрен беренче булып тотып ала — шул новатор. Утызынчы еллар хакында язылган әсәрләр хәзер татар әдәбиятында аз түгел. Ләкин шулар арасыннан без иң элек Такташны һәм аның «Киләчәккә хатлар»ын искә төшерәбез. Үз эчендә яшәгән «шайтанны», каршылыклы ике «мин»не җиңә алмыйча азапланган Мохтар карт образын Такташ ачып бирде. Димәк, ул чорның борчулы дулкыны иң элек Такташ җаны аша узган.

«Матур туганда», «Агыйдел», «Язгы җилләр», «Онытылмас еллар», «Тукай», «Тапшырылмаган хатлар», «Алтын йолдыз», «Намус», «Җәяүле кеше сукмагы», «Язгы авазлар» кебек әсәрләрне әйткәндә,

аларның авторларын тагын йөртү дә мәҗбүри түгел. Укучылар шундук үзләре әйтеп бирәчәкләр. Совет властенын 50 елы эчендә илебез халыклары тормышында булган үсеш-үзгәрешләрне, бая әйткәнемчә, борчулы дулкынны зур һәм колачлы итеп чагылдырган бу әсәрләр татар совет прозасында, олы юл баганалары кебек, ерактан ук күренеп торалар.

Әгәр 1966 елда иҗат ителгән проза әсәрләрен күңелебездән шушы әсәрләр янына куеп карасак, ихтимал, аларның берсе дә бу сафны тулыландыра алмаслар. Димәк, безгә әдәбиятның зур юлы, магистраль юлы турында һичкайчан онытырга ярамый.

«Правда» газетасы күптән түгел редакция исеменнән язылган мәкаләсендә ике зур журналның заманнан артта калуларын әйтеп узды. Партиянең әдәбият-сәнгать хакындагы әлеккерәк документларында күбесенчә әдәби әсәрләрнең идея ягы күздә тотыла иде. Соңгы документ «Новый мир» журналы безнең тормышыбызның төп пафосын дөрес яктыртмый, караңгы якларны гына эзли, ә «Октябрь» журналы редакциясе әдәби-эстетик кыйммәте түбән булган төссез әсәрләрне күккә күтәрә дип кисәтте.

Без моны дөрес аңлый һәм дөрес нәтиҗә ясый белергә тиешбез. Чөнки милли әдәбиятлар практикасында кирәкмәгән ябырылулар, үзәктән әйтелгән фикергә көчәнә-көчәнә иллюстрация эзләү, тартып китерү фактлары да булмады түгел.

Татар совет әдәбияты, минемчә, җиргә, халыкка бик якын торган әдәбият. Халык интереслары, эш кешеләренең уй-тойгылары белән, хезмәт багырлары белән рухланып яши торган әдәбият. Тик безгә, язучыларга, тормышның эченә тирәнрәк чумарга, заманга лаеклы әсәрләр тудыру турында кайгыртырга кирәк.

...Мәңгайга тирән генә бер сыр өстәп, иске әдәби ел узып китте. Яңа әдәби ел башлана гына әле. Алда — нефть мәйданнары, төзелеш эстакадалары, кызыклы очрашулар һәм кеше күңеле. Кайгы-хәсрәтне, моң-сагышны, шатлык-сөенечләрне дә сыйдыра ала торган кеше күңеле!

Безне язу өсталләре көтә. Каләмнәр күгәрмәсен, кәгазьләр саргаймасын, илһам чишмәләре кипмәсен!

*Зәет Мәҗитов*

# ФӘННИ ТИРӘН ҺӘМ ТУРЫ СҮЗЛЕ ТӘНКЫЙТЬ ӨЧЕН[1]

## I

Узган елда әдәби тәнкыйтебез тагын да җанлана төште, сизгеррәк, үткенрәк һәм уйчанрак төс алды, әдәби-эстетик фикернең тирәнәя, хәрәкәтчәнрәк һәм сугышчанрак була баруы, һичшиксез, әдәбият һәм сәнгать алдына куелган бүгенге таләпләр белән дә, фикерләү колачын кысып торган һәртөрле киртәләрнең аударылуы белән дә бәйле. Әдәбиятыбызның офыклары киңәя килә, кеше тормышын тирән итеп, бөтен матурлыклары һәм катлаулылыгы белән сурәтләү, кешенең рухи дөньясына үтеп керү тенденциясе көчәя, жанрлар яңара һәм байый бара икән, тәнкыйть тә үсә, үзенә әдәбиятның җанлы практикасыннан торган саен баерак азык ала. Соңгы елларда әдәби тәнкыйтьнең торгынлыктан чыгып, җанланып-тармакланып үсә башлавы шул шартларга бәйле. Узган ел басылып чыккан әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменә караган әсәрләрне барлаганда, күзгә ташланган беренче нәрсә нәкъ менә тәнкыйть әсәрләренең төрләре һәм тематикасы арту булды.

1966 елда без татар совет әдәбият белемендә өлеш булып керерлек монументаль монографияләрне дә, күренекле язучыларыбызның индивидуаль иҗат йөзләрен ачуга багышланган әдәби портретларны да, полемик кайнарлык белән сугарылган мәкаләләрне дә, язучыларның яңа чыккан әсәрләренә карата язылган рецензия һәм китап күзәтүләрне дә, теге яки бу жанрның торышын күзәткән докладларны да, әдәби мирасыбыз турында зур кайгырту белән сугарылган төпле хезмәтләрне дә байтак таба алабыз.

Узган ел укучы кулына кергән хезмәтләр арасыннан иң элек өч әсәрне билгеләп үтәсе килә. Болар: филология фәннәре докторы М. Гайнуллинның «Татарская литература и публицистика начала XX века», Г. Халитның «Тукай и его современники» һәм И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» исемле монографик хезмәтләре. Өч хезмәт тә иң бай һәм кызыклы чорны — әдәбиятыбызның XX йөз башындагы барышын анализлауга багышланган. Куанып әйтергә мөмкин: бу хезмәтләр татар совет әдәбият белеменең Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәтиләрдән килә торган сызыгын — соңгы елларда Х. Госман, Г. Кашшаф монографияләрендә гәүдәләнгән колачлы һәм җентекле өйрәнүне — дәвам иттерәләр һәм тулыландыралар.

М. Гайнуллин хезмәте А. Сайганов, Б. Гыйззәт, Ш. Хамматов иптәшләр мәкаләсендә: «татар әдәбиятын һәм журна-

[1] Доклад кыскартып басыла.

листикасын өйрәнүдә житди хезмәт»[1], дип бәяләнде. Мәкалә авторлары, хаклы рәвештә, хезмәтнең бай фактик материалга, күп төрле чыганакларга таянып язылган булуын, әсәрдә татар әдәбиятының һәм журналистикасының үсеше илдә барган иҗтимагый вакыйгалар белән бәйләп өйрәнелүен күрсәтеп үттеләр. М. Гайнуллин хезмәтендә моңа кадәр күләгәдә калып килгән бик күп язучыларның, журналистларның һәм сәнгать кешеләренең эшчәнлеге яктыртыла, әдәби һәм иҗтимагый вакыйгаларга бәя бирелә. Фактик материалның байлыгы өстенә, китапта байтак мәсьәләләргә карата кызыклы күзәтүләр ясала, күп кенә бәхәсле мәсьәләләр кузгатыла. Мәсәлән, Тукайның музыка белән кызыксынуын, аның «Евгений Онегин» романы характерында зур әсәр язарга ниятләнеп йөрүен күрсәткән дәлилләр бик кызыклы. Тукайның С. Рәмиев, Г. Ибраһимов кебек әдипләр белән мөнәсәбәтен ачуда да әһәмиятле фикерләр әйтелә. Нәҗип Думави эшчәнлеге һәм поэзиясе турында язылган бүлекчәне мин әдәби осталык серләренә үтеп керүнең әйбәт үрнәге дип санар идем. Н. Думави иҗаты еллар буе тискәре яктан гына бәяләнеп килде, моңарчы язылган кайбер хезмәтләрдә хәтта Думави беренче империалистик сугышны яклау позициясендә торды, кебегрәк фикер әйтелә һәм дәлил итеп шагыйрьнең «Сугыш тәэссораты» исемле шигыре китерелә иде. М. Гайнуллин башка фикер әйтә. «Шигырьнең икенче кисәгенә нигезләнеп, — ди ул, — тәнкыйтьчеләр Думавины сугышка өндәүдә гаепләп килделәр. Ләкин, игътибар белән укыганда, ул юлларның ирония белән сугарылуын искәртү кыен түгел» (265 бит).

Ирония Н. Думави шигырьләрендә, чыннан да, зур урын алып тора, һәм шагыйрьнең иҗатын өйрәнгәндә бу моментка игътибар итәргә кирәк.

Хезмәттәге аерым кимчелекләр дә гыйбрәтле. Аларның күбесе югарыда без телгә алган рецензияләрдә дә күрсәтелә. Өстәп шуны гына әйтәсе килә: әдәби процесс хезмәттә, башлыча, иҗтимагый-тематик, социаль-политик яктан анализлана, ә әдәбиэстетик, осталык-поэтика ягы, әдәбиятның эчке сыйфат үсеше җентекләп каралмый.

Г. Халит — күп һәм нәтиҗәле эшли торган тәнкыйтьчеләребезнең берсе. Моннан ике-өч ел элек ул Тукай турында татарча китап биргән иде. Узган ел исә «Тукай һәм аның замандашлары» исемле китабы рус телендә басылып чыкты.

Монографиядә, Тукай поэзиясенә бәйләп, күп әдәби-теоретик мәсьәләләр куела. Болар: реализм һәм романтизм арасындагы мөнәсәбәт, Тукай һәм көнчыгыш әдәбияты, Тукай һәм рус әдәбияты, Тукайның көнбатыш һәм көнчыгыш әдәби традицияләренә бәйләнеше һәм мөнәсәбәте, Тукайның новаторлыгы нәрсәдән гыйбарәт, Тукай һәм охранка һ. б. һ. б.

Г. Халитның Тукай чорын өйрәнүгә багышланган бу яңа хезмәте татар совет әдәбият белемендә соңгы елларда күзәтелә башлаган матур үзенчәлекне — әдәбият тарихын проблематик планда өйрәнү тенденциясен тагын да көчәйтә. Бу инде шагыйрьнең тормыш һәм иҗат хроникасы да, шагыйрь иҗатына тематик күзәтү дә түгел. Тукай иҗаты бөтен татар поэзиясенең фонына куеп, поэзиянең гомуми барышына бәйләп анализлана һәм халык шагыйренең татар поэзиясе үсешендәге урынын билгеләү поэзиянең үткәне, бүгене һәм киләчәге белән бәйләп карала. Шуңлыктан Тукай иҗаты турында моңарчы әйтелгән фикерләр дә Г. Халит хезмәтендә яңа яңгыраш ала, шагыйрь иҗатының моңарчы ачылмаган сыйфатлары эзлекле һәм тирән яктыртыла.

Шунысы аеруча куанычлы: тәнкыйтьченең анализы салкын канлы «академизм» белән өртелгән «саф фәнни трактат» түгел, бәлки полемик кайнарлык белән сугарылган уйлану һәм эзләнүләрдән гыйбарәт. Һәм ул публицистик мәкалә яки очерк шикелле үк җиңел укыла. Шул ук вакытта хезмәттә фәнни дәлилләү ягы да җитәрлек. Бөтен күзәтүләр, бөтен дәлилләр бер төп мәсьәләне чишүгә хезмәт итә. Тукай ничек Тукай булды, ни өчен Тукай булды, поэзиясенең кайсы сыйфатлары белән халык тавышына әверелде һәм татар поэзиясенең байрагы булып күтәрелде? Хезмәт тулысы белән әнә шул сорауларга җавап бирү рәвешендә язылган.

Г. Халит хезмәтендә кузгатылган мәсьәләләр турында күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Кызганычка каршы, хезмәткә детальләп тукталырга безнең вакытыбыз юк. Шулай да тагын бер генә мәсьәләгә күз ташлап үтәсе килә. Татар шигырен үстерүдә Тукай керткән яңалыклар турында сөйләп, тәнкыйтьче кызыклы күзәтүләр ясый. Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, Х. Госман, М. Хәмраев кебек белгечләр белән бәхәскә кереп, ул «Тукай шигыренең нигезендә гарәп-фарсы гарузы ята» дигән фикер белән дә, «Тукай шигыре төрки җирлектә генә үсте» дигән фикер белән дә килешми. Халит фикеренчә, «гаруз элементлары һәм төрки шигырь, үзенчәлекле кушылу кичереп, вакытлар үтү белән, төрки якның өстенлек алуы җирлегендә үсеп» киткән һәм «Тукай моңа рус поэзиясе һәм татар халык җырлары үлчәүләренең дә элементарын» берләштергән. Без биредә Г. Халит фикеренең бөтен дәлилләрен дә китерә алмыйбыз, әлбәттә. Ләкин, схематик планда караудан ук, Г. Халит концепциясендә Тукай шигырь төзелешен аның барлык чыганакларыннан эзләү һәм татар шигырь төзелешенә Тукай керткән яңалыкны төрле яклап билгеләргә омтылу ачык күренсә кирәк.

И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» исемле хезмәте, Г. Халит китабы төсле үк, эзлекле бер концепциягә нигезләнеп язылган. «XX йөз башы татар әдәбияты, — ди үзенең бу хезмәтендә И. Нуруллин, — мәгърифәтчелек реализмы кысаларына сыеша алмыйча, алга, критик реализмга омтыла, реакция һәм яңа революцион күтәрелеш дәверендә критик реализм төп методка әверелә, чәчәк ата». Минем кара-

[1] «Советская Татария» газетасы, 1967 ел, 11 январь.

шымча, И. Нуруллин чорларга биргән характеристикасында да, аерым язучыларның иҗатына караган монографик бүлекләрдә дә шушыңа якын бер төп концепцияне үстерә һәм анализлый бара. Нуруллин хезмәте вуз студентлары һәм укытучылар өчен бик файдалы кулланма булыр, дип ышанырга мөмкин. Китапның кыска вакыт эчендә сатылып бетүе дә шуны раслый.

XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә багышланган бу житди хезмәтләр һәркайсы аерым тукталып, киң күзәтүләр ясауга лаек. Г. Халит һәм И. Нуруллин китапларында, мәсәлән, XX йөз башы әдәбиятының нинди шартларда, ни рәвешле яңа методны — критик реализмны үзләштерүе Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек аерым язучыларның иҗатын конкрет өйрәнү җирлегендә раслана, критик реализмның прогрессив романтизм казанышлары белән үрелеп китүе һәм баюы күрсәтелә. Бик кызыклы һәм кирәкле бу мәсьәләләр И. Нуруллин китабында аеруча тулы яктыртылган.

Соңгы еллар әдәбият белемендә бер мөһим үзенчәлек бар: бу — вульгар социологизм догмаларын кире кагу. Хәзер телгә алынган хезмәтләр дә әдәби фактларны бәяләүдә шушы юлдан баралар һәм Тукай, Ф. Әмирхан, Дәрдмәнд, С. Рәмиев кебек атаклы язучыларыбыз иҗатын чын фәнни объективлык белән анализлыйлар. Моңарчы язылган хезмәтләрдә XX йөз башында иҗат эше алып барган күп кенә язучылар һәм тәнкыйтьчеләр күләгәдә калып килде. Бу хәл әдәби атмосфераны тулы күзаллауга комачаулый иде. Хәзерге хезмәтләр исә икенче һәм өченче дәрәҗәдәге язучыларны да игътибарга ала, аларның әдәби хәрәкәттәге урынын истән чыгармый. Бу да, минемчә, уңай казаныш.

Әйе, XX йөз башы әдәбиятын өйрәнүгә караган төпле хезмәтләребез хәзер байтак. Әмма совет чоры татар әдәбиятын яктыртуга багышланган хезмәтләр һич кенә дә житәрлек түгел. Дөрес, узган елда Н. Юзеевның «Традицияләр яңарганда», З. Усманованың «Гадел Кутуй», Р. Нуруллинаның «Һәрвакыт сафта» дигән китаплары чыкты.

З. Усманова һәм Р. Нуруллинаның Гадел Кутуй иҗатын һәм тормышын яктыртуга багышланган хезмәтләрен, тулаем алганда, хуплап каршыларга кирәктер. Башка күренекле язучыларыбыз турында да шундый характердагы китаплар тизрәк язылсын иде. Аерым алганда, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Афзал Шамов, Гариф Гобәй, Габдрахман Әпсәләмов кебек язучыларыбыз иҗатын, аларның индивидуаль иҗат үзенчәлекләрен укучыга төшендерерлек кечерәк күләмле булса да монографияләргә бик мохтаж без. Башка халыкларда мондый язучылар иҗаты әллә кайчан зур-зур монографияләрдә өйрәнелгән инде.

Дөрес, Р. Мостафинның «Литературные портреты» дигән китабы һәм шундагы очеркларның ук «Казан утлары» журналында татарча басылган вариантлары бу бушлыкны тутыруга беркадәр өлеш булды.

Р. Мостафинның иҗат портретлары — икеләнмичә әйтергә мөмкин — матур тел белән, чын мәгънәсендә очерк итеп язылганнар. Аеруча С. Хәким һәм Х. Туфан турындагылары җылы тәэсир калдыра. Г. Әпсәләмов турындагы очеркта ул вакыт-вакыт кыенлык кичерә төсле. Очеркның татарча варианты белән русчасы арасында кайбер әсәрләрне бәяләүдә аерма булу да шуны күрсәтә.

Шуны да әйтик, әдәби портретлар жанрын безгә тагын да үстерергә һәм активлаштырырга кирәк. «Казан утлары» журналы бу жанрга аерым рубрика ачып дөрес эшли. Әле күләмле монографияләр язылмаган чакта, бу жанрның әһәмияте, кирәклеге аерата зур. Ләкин теләк рәвешендә бер нәрсәне әйтәсе килә: иҗат портреты дигәч тә, ул язучының иҗат йөзен бизәп-буяп күрсәтү, яисә бары уңай якларын гына ачудан гыйбарәт булмасын, беркадәр иҗат үзенчәлекләренә, үсү юлындагы кытыршылыкларга да күз салсын иде.

Н. Юзеевның «Традицияләр яңарганда» дигән китабы үзенә аерымрак бер урын алып тора. Автор анда сугыштан соңгы татар поэзиясенең кайбер үзенчәлекләрен, үсеш тенденцияләрен билгеләү максатын куйган. Бүгенге әдәбиятыбызның барышын анализлауга багышланган мондый типтагы хезмәтләр безгә бик кирәк.

Н. Юзеев китабында берничә момент аерым игътибарга лаек. Беренчедән, автор сугыштан соңгы татар совет поэзиясен үсештә карый һәм, шушы юлдагы уңай моментларны гына күрсәтеп калмыйча, кимчелекләргә дә күз сала. Икенчедән, шагыйрьләрнең иҗатын бәяләгәндә, ул аларның индивидуаль сыйфатларын да билгеләргә омтыла. Өченчедән, «Тормыш каршылыклары, әдәби конфликт һәм характер» дигән бүлектә поэмаларга ясалган анализ үзенең конкретлыгы белән әйбәт тәэсир калдыра. Бездә нәкъ менә бүгенге язучыларыбызның әсәрләрен дәлилле итеп, эченә кереп анализлау житми дә.

Тәнкыйтьчеләребез, әдәби хәрәкәтнең бүгенге торышын тикшергәндә, эстетик-теоретик фикерләүнең соңгы казанышларын истә тотарга, шуларга таянып эшләргә, бүгенге әдәби вакыйгаларны системалаштырып, проблематик планда анализларга омтылалар. Н. Юзеевның яңа китабы — шуның матур мисалы. Безгә бу тенденцияне якларга һәм аңа хәрәкәт мәйданын киңрәк ачарга кирәк. Хәзер, яңа романнар һәм повестьлар, шигырь җыентыклары, шигъри романнар мәйданга килеп торган чорда, әдәбиятыбызның яңа казанышларын укучыга төшендерү тәнкыйтьтән башка мөмкин түгел. Тәнкыйтькә күбрәк мәйдан таләп итү белән бергә, аның алдына куелган бурычларның да артуын әйтергә кирәк. Әдәби тәнкыйть әсәрләре бездә әле һаман башлыча язучы һәм белгечләр өчен генә язылa. Укучыны күздә тотып язылган тәнкыйть әсәрләре юк дәрәҗәсендә. Ә бит тәнкыйть әсәре киң катлау әдәбият сөючеләргә аңлаешлы да, кызыклы да булырга

тиеш. Тәнкыйть теленең әдәби әсәр теле кебек үк җанлы һәм шигъри булуы сорала хәзер. И. Нуруллинның «Образлар дөньясында», Р. Мостафинның «Әдәби портретлар»ында шушыңа омтылыш ясалган иде. Безгә моны дәвам итәргә һәм үстерергә кирәк.

Инде Н. Юзеев китабы турындагы сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. Күп кенә уңай, мактауга лаек яклары булу белән бергә, бу китапта, минем карашымча, аерым кимчелекләр дә юк түгел. Барыннан да элек китаптагы төп мәсьәлә — традицияләрнең ни рәвешле яңаруы мәсьәләсе ачылып җитми төсле. Н. Юзеев «Традиция белән бәйләнешнең бердәнбер чарасы — аны дәвам итү, үстерү. Ә традицияне баету, дәвам итү үзеннән-үзе новаторлыкка илтә», (8 бит) дигән тезис куя. Беренчедән, монда, «традицияне баету» дигән тәшенчәнең чикләре билгеләнмәү, аның нидән гыйбарәт икәнен дәлилләмәү аркасында, ачыклык җитми. Чыннан да, традиция, конкрет алганда, нәрсә соң ул? Традицияне баету, дигәне нәрсәдән гыйбарәт? Традицияләр күп бит. Икенчедән, «традицияне баету үзеннән-үзе новаторлыкка илтә» дигән тезис та ачык ук түгел, минемчә. Традицияне төрлечә баетырга мөмкин. Бездә бу төшенчәләр әлегә хәтле ниндидер абстракт бернәрсәгә охшабрак кала бирә. Н. Юзеев та аны ачыклап бетерә алмаган. Дөрес, хикмәтле шигырьләр, робагыйлар традициясен сөйләгәндә, ул максатына шактый якыная да. Ләкин менә, мәсәлән, поэзиягә Хәсән Туфан яисә Сибгат Хәким китергән яңалык нәрсәдән гыйбарәт? — кебек зуррак сорауларга ул җавап биреп бетерми.

Хезмәттә «романтизм», «романтик форма», «романтик шартлылык» кебек терминнар күп кулланыла, ләкин бу төшенчәләрне куллануда эзлеклелек җитми төсле. Шунлыктан, күрәсең, хезмәтенең 71 битендә Н. Юзеев «тормыш вакыйгаларын реалистик гадилегендә тасвирлаудан романтизмга, шартлылыкка күчеп китү дә очрый» дип, поэзиядә кимчелек күрсә, 78—79 битләрдә шагыйрьләрне «шигъри шартлылык» куллануда кыю булмаган өчен гаепли. Бу каршылыклы фикер Х. Туфан иҗатын бәяләүдә дә күренә. «Элек, — ди тәнкыйтьче, — Х. Туфан реалистик планда яза иде, хәзер үзе романтик шагыйрьләр рәтенә басты». Ә миңа калса, киресенчә, егерменче елларда Х. Туфанда романтик киеренкелек нык сизелсә, хәзер чын мәгънәсендә социалистик реализмга хас сурәтләү көчле. Китапта анализлана торган әсәрләр белән мавыгып китүләр, конкрет мисалларны үз концепциясенә яраштырырга тырышулар да сизелә. Х. Туфанның «Каракөм ягында» шигырен романтик итеп күрсәтү өчен, Н. Юзеев аны шагыйрьнең иң яхшы әсәрләреннән берсе сыйфатында анализлый. Хәлбуки, Х. Туфан мондый «шартлы» шигырьләреннән бигрәк, ягымлы, тирән хисле, драматизмлы шигырьләре белән көчле бит.

С. Хәкимнең «Язгыз, җир уллары» поэмасына хезмәттә тирән анализ ясалган, ләкин лирик-фәлсәфи поэма бүгенге поэма үсешендә төп урынны алып торырга тиеш» дигән караш нәтиҗәсендә, С. Хәкимнең нигездә әйбәт бу поэмасында очраган кимчелек — с ю ж е т н ы  х а р а к т е р  а ч у  б е л ә н  б ә й л ә ү н е ң  җ и т м ә в е — киресенчә, уңай момент итеп күрсәтелә. Болар — Н. Юзеев китабының бәхәсле яклары. Әмма, тулаем алганда, хезмәт, һичшиксез, уңай бәягә лаек. Ул — безнең тәнкыйтьнең бүгенге әдәби процесс турында җитди уйлана башлавын күрсәтүче бер үрнәк.

2

Узган ел ике зур әдәби бәхәс барды. Аларның берсенә — «Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән конкрет темага караганына — бик әйбәт йомгак та ясалды. Н. Юзеевның йомгаклау җыелышындагы докладьі һәм Н. Исәнбәт, С. Хәким, Х. Госман кебек олы язучыларның һәм әдәбият белгечләренең анда ясаган чыгышлары, ниһаять, «Социалистик Татарстан» газетасында соңыннан басып чыгарылган бер битлек йомгак әдәби бәхәсне нәтиҗәсез калдырмастыр.

Н. Юзеев бу дискуссияне йомгаклау җыелышында тулы һәм эчтәлекле доклад ясады. Соңыннан ул «Социалистик Татарстан» газетасында (8 январь, 1967 ел саны) «Традицияләр дәвам итә, баый һәм яңара» дигән исем астында гомуми йомгак итеп басылып та чыкты. Тәнкыйтьче биредә «Традицияләр яңарганда» китабында әйтелеп бетмәгән кайбер фикерләрен ачыклаган, тулыландырган, диясе килә.

Традиция, дибез. Нәрсә соң ул? Тукай традициясе дигәннән нәрсә аңларга? Бик гадиләштереп кенә җавап биргәндә, без «Тукай традициясе» төшенчәсен, мөгаен, искиткеч шигъри көч, сугышчанлык һәм үткенлек, халык язмышын үз язмышың итеп карау, тематиканың чикләнмәгән колачы, жанр, форма һәм сурәтләрнең тематик колачка бәрабәр киңлеге, хис байлыгы, дип формалаштыра алыр идек. Җәлил традициясе безгә батырлык һәм ихтыяр көче белән сугарылган лирик герой хисләренең чын табигыйлек белән гәүдәләндерелүе, яңа хисләрнең яңа шигъри алымнарда җырлануы булып аңлашылыр иде. Тукай һәм Җәлил безгә идея югарылыгы, шигъри ялкынлылык, заман белән бәйләнеш үрнәген, чын ватанчылык, искиткеч фидакарьлек, олы гуманизм һәм интернационализм, язмыш һәм шәхес, зур тормыш һәм лирик герой мөнәсәбәтенең аерылгысыз булуы үрнәген, халыкчанлык тантанасын мирас итеп калдырдылар. Һәм без Тукай һәм Җәлил традицияләре турында сөйләгәндә нәкъ шул моментларны калку итеп куярга тиешбез дә. Әмма дискуссия барышында бу моментларга җитәрлек басым ясалмады, бүгенге поэзиябез әсәрләрен шушы яктылыкта бәяләү азрак булды.

Дискуссия барышында традиция төшенчәсен аңлауда берничә төрле караш барлыгы беленде. Берәүләр аны «гражданлык мотивларында», «тормышка актив катнашуда» күрсә, икенчеләре «классик шигырьгә туры булуда», өченчеләре, киресенчә,

шигырьне әледән-әле яңартып торуда һ. б. күрделәр. Ләкин «гражданлык мотивлары» мәсьәләсе дискуссия вакытында йомшаграк яңгырады. Бәхәстә төп урынны шигырь төзелешенә бәйләнешле мәсьәләләр алды. Бу — дискуссиянең кимчелеге һәм ул йомгаклау җыелышында дөрес күрсәтелде.

Шагыйрь М. Шабаев әлеге бәхәс уңае белән язылган «Ак шигырь белән ирекле шигырь «үгиләрме» исемле мәкаләсендә ак шигырь белән ирекле шигырьне «үги итәләр», ә бит ул безнең поэзиябездә Такташлардан, Туфаннардан ук килә, дип белдерә һәм акка кара белән: «рифмасыз ирекле шигырь ритмиканы яңарта һәм баета, интонацион мөмкинлекләрен арттыра», дип яза.

М. Шабаев, дәлил итеп, Такташның: «укучы ненормальный шаблоннан ялыкты. Бүгенгене ялангач җырлаудан туйды», дигән сүзләрен китерә. Хәлбуки, Такташның: «халык шаблоннан ялыкты» дигән сүзләре һич тә «ритмика яңарту һәм баету» максаты белән әйтелмәгән. Бәлки, «социаль заказны турыдан-туры үзләре ала алмый, башкаларга сукыр рәвештә ияреп баручы», «чәйнәп биргән буенча эшләүче» шагыйрьләргә каршы юнәлдерелгән. (Такташ. «Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр». 1953 ел. 233 бит.)

Сүз уңаенда шуны әйтеп үтик: дискуссия барышында татар совет поэзиясенең титаннары булган һ. Такташ һәм Ф. Кәрим исемнәре аз искә алынды. Ә бит бу ике шагыйрь иҗатындагы казанышлардан башка поэзиябездәге уңай традицияләрне тулы итеп күз алдына китерү һич мөмкин түгел. Шулай ук без аларның әдәби-теоретик фикер үсешенә керткән өлешләрен дә онытып барабыз. Такташ мәкаләләрендә, мәсәлән, дискуссиядә күтәрелгән бик күп мәсьәләләргә ачык һәм үткен җаваплар бар. Такташны тыңлап карыйк:

«Шагыйрьнең кыйммәте нәни бер идеяне кеше аңламаслык итеп язуда түгел, бәлки бөек идеяләрне җиңел, гади рәвештә өчдүрт җөмләдә әйтеп бирә алуда» («Ничек үсәбез» дигән мәкалә).

«Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында» исемле мәкаләсендә ул «безнең әдәбиятыбызда булган авыру якларның» берсен шигырьдәге оригинальлекне шигырьнең юлларын «кызыклы» итеп бүлгәләп, төрле фигуралар ясап төзүдә дип белү, яңа рифмалар белән генә бизәүне яңа форма, оригиналь шигырь дип аңлауда күрә.

«Зур бер фикерне, аның зурлыгын югалтмый, җиңел рәвештә әйтә алу — бу шагыйрьнең таланты булуын, әйтергә теләгән фикерен этрафлы рәвештә белүен һәм ялангач формага түгел, бүгенге теләкләргә хезмәт итәргә теләвен күрсәтә («Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр». 261 бит).

Безнең күп шагыйрьләребезгә, һәм бигрәк тә форма белән мавыгучы яшьләргә Такташның бу фикерләрен кабат кайтып өйрәнү кирәк түгелме икән? Такташ һәр мәкаләсендә шагыйрьләрдән чын халыкчанлык таләп итә. Ләкин дискуссия барышында бу категория, кызганычка каршы, аз телгә алынды. Халыкчанлык — абстракт категория түгел. Халыкчанлык таләп итү — безнең бүгенге әсәрләребез яратып укыламы, үз итеп, көндәлек юлдаш итеп кабул ителәме? дигән сорауга уңай җавап бирерлек әсәр язуны таләп итү дигән сүз. Безд бүгенге әсәрләребезне бәяләүгә шушы яктан якын килү җитешкерәми төсле.

Икенче бәхәс турында берничә сүз. Бәхәс И. Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» («Казан утлары» журналы. 1966 ел. 3 сан) дигән мәкаләсе белән башланып китте. Бәхәстә Тукай иҗатын өйрәнүгә кагылган мәкаләләр белән Ш. Байчура («Инәсеннән җебенә кадәр», 7 сан), Х. Госман («Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны», 10 сан), М. Гайнуллин («Дөреслекне төгәл ятыртыйк»), Р. Нәфигов («Г. Тукай биографиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре») һәм Г. Халит («Бер бәхәс уңае белән») иптәшләр катнашты. «Социалистик Татарстан» газетасында К. Фасеев һәм М. Абдрахмановның И. Нуруллинга каршы мәкаләсе басылды. Соңыннан «Казан утлары» журналының редакцион мәкаләсе бирелде. Бу бәхәс кирәк идеме, юкмы? Вакытлы идеме, түгелме?..

И. Нуруллинның әлеге мәкаләдә уздырган төп фикерләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

«Тукайны шагыйрь итеп өйрәнү, поэзиясенең «серенә төшенү»не әйтеп тә тормастан, иҗатының идея юнәлеше, шагыйрьнең фикер иясе буларак үзенчәлеге дә безгә бик үк ачык түгел икән әле» (124 бит). Моның сәбәбе, ди автор, шагыйрь иҗатындагы каршылыкларны шомартып күрсәтүдән, алдан корылган концепцияләргә яраштырырга тырышудан килә. Кыскасы, объективлык җитми. Мәкаләсен ул: «нәтиҗәгә карап факт җыюны ташларга вакыт. Фактлар үзләре нәтиҗәгә китерсен. Фән яхшы мәгънәсендәге объективлыкка, дөреслеккә корылырга тиеш», дигән сүзләр белән тәмамлый (137 бит). М. Гайнуллин Нуруллин кузгаткан бәхәскә катнашып, түбәндәгеләрне яза:

«Бөек шагыйребезнең 80 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнгән көннәрдә аның күпкырлы бай иҗат мирасын бәяләү һәм өйрәнүдәге ялгышларны һәм кимчелекләрне төзәтергә омтылу — табигый һәм кирәкле эш» (124 бит).

Соң алай булгач, И. Нуруллин мәкаләсен штыкка алу кирәк идеме?!. Мин И. Нуруллин әдәби мирасыбызны бәяләүдә фәнни объективлык булырга тиеш, дигән әһәмиятле мәсьәлә күтәрде, һәм, бәхәс вакыт-вакыт сабырлык рамкаларыннан чыгып, урынсыз каты сүзләр яргыту белән аралашып китсә дә, мәгълүм файда китерде, дип саныйм. Әлеге мәкаләгә кискен каршы чыккан Р. Нәфигов һәм М. Гайнуллиннар да, күп кенә моментларда Нуруллин белән килешүгә якын торган Г. Халит та һәм башка иптәшләр дә Тукай иҗатын һәм тормышын өйрәнүнең яңа аспектларын ачыкладылар, кызыклы яңа фактлар китерделәр, ачыклаулар ясадылар. «Казан утлары» журналының 1967 елгы беренче санын бер укучы: «И. Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләсен журналда тәкъдим итү белән, редакция бик үк зур ялгыш ясамаган» дип яза һәм

«Тукай шәхесен өйрәнү буенча кыйммәтле фикерләр әйтелгән» мәкаләләр чыгуы, яңа фактлар китерелү шуны раслый, дип белдерә.

Соң ни өчен бәхәс артык кискен төс алды? Минемчә, монда ике сәбәп бар: беренчедән, И. Нуруллин үзе кайбер кечкенәрәк мәсьәләләрне күпертебрәк куйды һәм вакытсызрак чыгыш ясады. Икенчедән, кайбер иптәшләр, тәнкыйтьнең аз гына чеметеп алуын да артык авыртулы кабул итеп, орылып-бәрелү юлынарак бастылар. Тәнкыйть иптәшләрчә булырга, сабыр һәм теләктәш булырга тиеш. Безгә тәнкыйть итүнең этик нормаларын үзләштерергә вакыт инде. Юк, мин тәнкыйть тешсез булырга тиеш дигән караштан ерак торам. Тәнкыйть үткен һәм принципиаль булырга тиеш. Ләкин тәнкыйть сабырсызланып кычкырынудан ерак торырга тиеш.

Бу бәхәс тә, «Казан утлары» журналында узган ел басылып чыккан башка мәкаләләр һәм хезмәтләр дә әдәби мирасыбызны тирән фәннилек белән өйрәнергә чакыралар. Әдәби мирасыбызны өйрәнүгә багышланган хезмәтләр арасында кызыклы һәм бик әһәмиятле әйберләр бар. Мин алар рәтенә барыннан да элек Х. Госманның «Идел буе Гөлстан»ына 575 ел тулу уңае белән язган «Ерак гасырларның шигъри авазы» дигән мәкаләсен, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Г. Кариев юбилейлары уңае белән басылган байтак мәкаләләрне һәм шул исәптән истәлекләрне дә кертер идем. Г. Халитның «Бәхәсле һәм бәхәссез хакыйкатьләр», Н. Исәнбәтнең «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре», М. Госманның «Олы мирас», «Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр», М. Мәһдиевнең «Солтан Рахманколыйның иҗат эшчәнлеге» исемле мәкаләләре дә шулар рәтенә керә. Шакир Абиловның «Борынгы әдәбиятыбызны өйрәнүнең өлгергән проблемалары» дигән мәкаләсе, борынгы татар әдәбиятының этапларын билгеләүдә шактый бәхәсле фикерләр күзгатуына карамастан, шулай ук игътибарга лаек. Күренеп тора: үткәндәге бай әдәби мираска әһәмият бирү көчәеп бара һәм без моны хупларга тиеш.

3

Үткәндәге әдәби мирасны өйрәнү кирәк. Сүз дә юк. Ләкин бүгенге әдәбиятыбыз казанышларын бәяләүгә дә игътибар кимемәсен иде. Бу бигрәк тә хәзер — Октябрьнең илле еллык бәйрәменә якынлашкан көннәрдә мөһим. Тәнкыйтьнең тәнкыйть булуы нәкъ менә бүгенге әдәбият күренешләрен дөрес һәм вакытында бәяләүдә, уңай күренешнең уңай ягын, тискәре күренешнең тискәрелеген укучыга һәм язучыга төшендерүдә күренә дә. «Казан утлары» журналының 12 нче санын ачып, аннан 1966 елда чыккан тәнкыйть мәкаләләренең исемлеген карасак, шактый пошынып калырбыз. Анда Ш. Маннаповның «Әнвәр Давыдов поэтикасы», Ф. Хатиповның «Ихтыярсыз геройлар һәм кырыс дөреслек» исемле мәкаләләреннән башка әйбер юк, диярлек. Дөрес, «1965 ел әдәби ел йомгаклары», «Язучының иҗат портреты», «Язучы трибунасы» һәм «Шагыйрь турында шагыйрь» дигән рубрикалар астында бирелеп барган тагын берничә әйбер бар. Кайбер мәкаләләр әйбәт кенә язылган.

А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте турында Ф. Хатипов язган мәкаләдә, мәсәлән, әсәргә шактый тирән анализ ясалган. Әсәрдә сурәтләнгән төп герой белән әсәрнең проблемасы һәм аны чишү үзенчәлекләре мөнәсәбәтен теоретик планда карап, Ф. Хатипов кызыклы күзәтүләр ясый. Әмма мәкаләдә үткәрелгән бер тенденция белән — тормышта таралу җирлеге чикләнгән геройларны сурәтләүче әсәрләрне тулаем яклау тенденциясе белән — килешеп бетәсе килми. Ф. Хатипов турыдан-туры мондый тезис куя: «Язучы биредә, без күрергә күнеккән, кискен бәрелеш-конфликтларга катнашучы, шуның белән әсәр сюжетына киеренкелек бирүче һәм, димәк, шактый отышлы сайлаган типны алмаган. «Икенче төрле әйткәндә, — дип дәвам итә тәнкыйтьче, — язучы аңлы рәвештә эффектлы, мавыктыргыч вакыйгаларны киракссенмичә, геройның эчке дөньясын яктыртуны мәгъкуль тапкан» («Казан утлары» журналы. 1965 ел. 9 сан. 117 бит).

Аннары, «нигездә уңайны яктыртырга чакырып, тискәрене гәүдәләндерүгә каршы чыгучыларны» тәнкыйтьләп, Ф. Хатипов: «Әгәр язучы тискәре образ тудыра икән, ул бөтен җәмгыятьнең типик хәлен күрсәтергә дәгъва итә, дип уйлыйлар», «әсәрдә сурәтләнгән бөтен образ-типларның да гомумилек дәрәҗәсе, типның таралу мәйданы бердәй тигез түгел», дип белдерә (123 бит).

Минем карашымча, бу тезисларда берничә төгәлсезлек бар. Беренчедән, әсәрдә сурәтләнгән нинди генә герой да бәрелешконфликтта катнашмыйча кала алмый һәм, гомумән, конфликттан башка әсәр була алмый. Биредә конфликтның характеры, үзенчәлеге турында гына сүз барырга мөмкин. Аннары, бу тезис белән барсак, «Өч аршын җир» повестенда конфликт юк, дип танырга тиеш булыр идек.

Икенчедән, «язучы менә шундый геройны сурәтләүне мәгъкуль тапкан» дигән төсле фикер дә берьяклы, минемчә. Язучы мәгъкуль тапса, шул җиткән, язучы мәгъкуль тапкан образ дөрес сурәтләнгән була, дигән кебегрәк фикер кала. Образ типик булсын өчен, язучы мәгъкуль табу гына җитми бит. Язучы «тормышта булуы ихтимал булганны сурәтләү» өлгесе белән эш итә. Тегеяки бу типның характеры язучы ихтыяры белән генә билгеләнми.

Өченчедән, язучы тискәре образ тудыра икән, ул әле җәмгыятьнең типик хәлен күрсәтү түгел, дигән фикер дә сәер тәэсир калдыра. Тискәре образ да, уңай образ да җәмгыять белән бәйле, һәм, димәк, җәмгыять хәленнән килеп чыга. Әгәр образ тип дәрәҗәсенә килеп җитсә, аның гомумилек дәрәҗәсе дә югары була. Тип иҗат итү — гомумиләштерү дигән сүз.

Шушындый каршылыклы тезислар ярдәмендә тәнкыйтьче «Өч аршын җир» әсәренең һәр ягы җиткән, уңай, дип күрсәтергә

омтыла, аны «Агыйдел», «Уч төбендә йө-рәк», «Җәмилә» кебек әсәрләр белән рәттән куярга тели. Хәлбуки, ул әсәрләрнең үзә-генә, ничек кенә карама, тормышның кис-кен конфликтлары, җәмгыятебезнең алдын-гы кешеләре куелган бит. «Өч аршын җир» повестеның да максаты, минем карашымча, Мирвәлинең үз эчендәге хәлне ачуга кай-тып калмый, бәлки шушы герой язмышы аша җәмгыятебезнең киң фонын, үсә ба-руын күрсәтүдән гыйбарәт. Әмма нәкъ шушы моментта язучы саранлык күрсәтә, иҗтимагый фонны тоныграк сурәтли. Шу-ның аркасында А. Гыйләҗев Мирвәлинең әчке көрәшен генә сурәтләргә алынган, ди-гән кебегрәк тәэсир кала. Әгәр автор аңлы рәвештә Мирвәлинең рухи кичерешләрен генә сурәтләүгә алынса һәм аны кызганды-рырга тырышса, без А. Гыйләҗевне, һич-шиксез, тәнкыйтьләр идек. Бәхеткә каршы, А. Гыйләҗев андый тар максат куймаган.

Тәнкыйть әдәбиятыбызның идея һәм ху-дожество сафлыгы сагында торырга, үткен күзле, актив һәм таләпчән булырга бурыч-лы. Хәлбуки, әдәби тәнкыйтебез күреп бе-термәгән әйберләр күп кала әле. Әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйтьнең кайбер тар-маклары бик сүлпән үсә. 1965 елгы тән-кыйть турында сөйләгәндә Ф. Миңнуллин «Бездә әдәбият теориясе буенча хезмәтләр юк», дип бик урынлы зарланган иде. Чын-нан да, мәктәпләр өчен дә, вузлар өчен дә, яшь язучылар өчен дә үтә кирәкле «Әдә-бият теориясе» бүгенгә кадәр күтәрелмәгән чирәм булып ята. Чаралар күрергә вакыт-тыр инде.

Әдәби тәнкыйть аерым жанрларга аз игътибар итә. Мәсәлән, драматургиябез ту-рында мәкаләләр бик аз. (Бу өлкәдә Бәян Гыйззәттән башка тәнкыйтьче эшләми.) «Социалистик Татарстан» битләрендәге бә-хәстә катнашып язылган мәкаләсендә Н. Фәттах:

«Кайберәүләр әдәбиятка килеп кергәндә дә үзләре турында бер сүз ишетмиләр, «чыгып киткәндә» дә ишетмиләр», дигән иде. Әйе, күп китаплар чыга, әсәрләр ба-сыла, ләкин аларның бик аз өлеше генә тәнкыйть сүзе ишетә.

Кайбер әсәрләргә һәм җыентыкларга үз вакытында ук тәнкыйтьче күзе төшү сора-ла, әмма бу эшләнми. Мәсәлән, Н. Фәттах-ның «Артта калган юллар» дигән озын хи-кәясе чыкканга инде елдан артты. Ул әсәр-дә язучы «сугыш елларында, шәхес культы нәтиҗәсендә, кеше язмыш иркенә ташлан-ган иде» дигән позициядән торып, геройла-рын гадәттән тыш пассив һәм бәхетсез итеп сурәтли. Сурәтләү принцибы хәтта критик реализм принципларыннан да артка — на-турализмга таба чигенгән төсле. Мин бөтен җитдилек белән әйтәм: сугыш чоры ника-дәр генә авыр булмасын, мохтаҗлык ничек кенә көчле булмасын, кешеләребез олы кү-ңелле кешеләр булып калды, «үз сыныгын да башкаларга бүлеп каптыручылар» аз булмады. «Артта калган юллар» хикәясендә һәм кайбер башка әсәрләрдә сурәтлән-гән председатель образлары кулаклардан да яман буяулар белән сыйфатлана. «Гай-ре табигый» булып чыга түгелме соң? Тән-кыйть бу хакта ләм-мим сүз әйтмәде.

Соңгы араларда яшь шагыйрьләр турын-да күп языла, ләкин берсенә дә «син сай-ларга тиешле юл — менә бусы» дигән харак-терда аның төп уңышын күрсәтү җитми. «Казан утлары» журналында «яңачарак» язган яшьләргә ташлама ясау, аларны «сөеп-сыйпап» йөртү тенденциясе сизелә. Мәсәлән, анда Р. Фәйзуллинның бик йом-шак шигырьләре дә дөнья күрә. «Иңемә кулларың орынгач» дигән шигырьне күрсә-тергә мөмкин. (1966 ел, 7 сан.)

Анда мондый юллар бар:

«Өстәлдәге агач ручка яфрак ярды,
урындык аяклары сөенешеп үзара
пышылдаштылар
(такмак язучы шагыйрьдән акыллырак
булып
күренделәр алар бу минутта). h. б.

Гипербола алымы шигырьдә карикатура-га әверелгән.

Шушылай иркәләбрәк йөрткәнгә күрә, күп кенә яшь язучылар тәнкыйтькә колак салмый торган булып үсәләр. Бездә, гому-мән, тәнкыйтькә колак салу җитми. «Әт өрер, бүре йөрер» диебрәк карау гадәте яши.

Икенче караш та тәнкыйть үсешенә кире тәэсир итә: «чебен тисә чер итәр» дигән-дәй, тәнкыйть аз гына тел тигезсә, ул мә-кәлә яки рецензия авторына кырын күз белән карау, хәтта сәлам бирмәүгә кадәр барып җитәбез. Тәнкыйтькә мондый мөнә-сәбәт бетсен иде.

Тәнкыйтебезнең уңай казанышларын кү-реп, аңа ярдәм итеп торырга, тәнкыйть хезмәтләрен вакытында бастыру чарала-рын күрергә кирәк. Бигрәк тә оператив тәнкыйть ярдәмгә мохтаҗ. Югыйсә бик әй-бәт, үткен мәкаләләр, китап итеп җыеп чыгарылмыйча, газета-журнал битләрендә югалып кала. Бездә оператив рәвештә тән-кыйть җыентыклары чыгаруга ирешәсе иде.

Тәнкыйть үзе дә олы күңелле, дусларча таләпчән һәм сизгер булырга тиеш, әлбәттә. Аннан шулай ук зур активлык таләп ителә. Ләкин безнең тәнкыйтьчеләр сүлпәнрәк эш-лиләр. Дөрес, Х. Госман, Х. Хәйри, Г. Ха-лит кебек өлкән тәнкыйтьчеләр, Р. Моста-фин, Ф. Мусин кебек яшь буын тәнкыйтьче-ләребез матбугатта еш күренә. Ләкин бу гына аз. Әдәби тәнкыйтьтә язучылар үзлә-ре дә активрак катнашсын иде.

Үсеп килүче яшь тәнкыйтьчеләр исемлеге-нең бик ярлы булуы да безне борчырга тиеш.

——□——

# Әдәбият тарихына материаллар

## АЗАТЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШЛӘРНЕҢ ЯҢА БЕР ӘДӘБИ ДОКУМЕНТЫ

### Салават бәете

Агачай — казак, мин — казак,
Агачай менгән акбүз ат.
Инде лә китеп барабыз,
Барасы юл бик озак.

Салават сугыш итәдер,
Алладин өмет итәдер.
Салават сугыш иткәндә
Алты йөз солдат бетәдер.

Җаек дигән жап-йар су —
Сай жирендә сөңге буйлайдыр.
Урынбуркайның ягасында
Алтынлы тулар уйнайдыр.

Ике генә ротник
Йөгерде урам буена.
Салават дигән пулкинник
Боерылды Мәскәү юлына.

Бөрмә-бөрмә кара илтер
Болгадир Салават башында.
Салаваткайны сорасаңыз —
Падишаһ хәзрәт кашында.

Йелүзән буе чыршылык,
Чыршылык эче — яктылык.
Салават белән Юлайга
Юктыр гына һич яхшылык.

Йелүзән буе андызлык,
Ай-һай ла гына безнең аңсызлык.
Болай гына аңсыз дәгел ирдек,
Ай-һай гына безнең ялгызлык.

Йелүзән буе бүтәкә,
Йибәрсәнә, атың симерсен.
Ыспай сөяк, нәзек бил,
Кайчан гына кайтып килерсең.

Йеләдер белән боладыр,
Яссы гына тауның саурында.
Җефәк кенә кара чәчкенән
Йәлмелтәйдер яссы яурында.

Кесәмдә лә сабыным —
Әнекәйгә илтеп биреңез.
Юсын да ла бетмәсен,
Әнекәй лә безне көтмәсен.

Салаваткайның билендә
Алтын гына кылыч ялтырай.
Салават торып сүз әйткәндә
Гәвер урыс калтырай.

Әдернә тарттым, ук аттым.
Беләккәемә ышанып.
Яшь башларымдин яу яуладым —
Бүгәчәү картка ышанып.

Сүзлек:
1) агачай — агакай, агай, ага, абый. Оригиналда «агачи» рәвешендә язылган.
2) казак — ирек даулап яуга чыккан кеше (борынгы төрки сүз).
3) жап-йар — бу сүз ачык танылып җитми.
4) яга — тирә-юнендә, янында, ягында.
5) ту — байрак.
6) ротник — гаскәри чин. Пулкинник — полковник, болгадир — бригадир (гаскәри чин).
7) илтер — бәрән тиресеннән тегелгән бүрек.
8) кашында — алдында, каршында.
9) Йелүзән — Уралдагы бер елга исеме, «Йөрүзән» формасында әйтелә.
10) андыз — үсемлек.
11) бүтәкә — үсемлек.
12) йеләдер белән боладыр — борынгы җырларда еш очрый торган поэтик сурәт. үсемлек исемнәреннән булырга кирәк.
13) саурый — сырты.
14) йәлмелтәй — җемелди, ялтырап китә.
15) яурыны — инсәсе.
16) әдернә — җәя.

●

1773—1775 елларда Идел һәм Урал буйларын Пугачев җитәкчелегендәге, феодаль изелүгә каршы юнәлтелгән крестьяннар кузгалышы тетрәтеп узган. Үз заманында ук бу зур вакыйга төрле-төрле формаларда фольклорда да, язма әдәбиятта да чагылган. Бу әсәрләрнең беренчеләре хәтердән, тел-сөйләм традициясе буенча, икенчеләре — язма традиция буенча буыннан-буынга бирелеп, сакланып, халыкка үз тарихының данлы сәхифәләрен таныта килгәннәр.

Әмма, аянычка каршы, гыйлем ияләре боларга бик соң, күп гомер үтү сәбәпле инде хәтердән җуела, онытыла, югала башлагач кына игътибар иткәннәр. 1920—30 елларда халык теленнән шундый берничә әсәр язып алынган, атап әйткәндә, проф. Газиз Гобәйдуллин тарафыннан Салават турында берничә җыр, язучы, галим Мөхәммәт Гали тарафыннан Пугачев турында берничә җыр («Пугачев патша бар диләр...») фән өчен теркәп калдырылган [1].

Бу эпик җыр яки бәетләрдә халык үзе кичереп үткән тарихи вакыйгаларны сәнгатьчә гомумиләштереп күрсәтә. Патша ялчылары белән көрәшләрдә каһарманлыклар күрсәткән күп санлы татар егетләренә, оста җитәкчелек иткән гаскәр башлыкларына хас күркәм сыйфатлар бөтенесе бер генә эпик образга җыеп гәүдәләндерелгән. Менә шундый җыелма эпик образ, эпик характер иясе итеп Пугачевның тугрылыклы юлдашы, кылычы белән дә, ялкынлы сүзе белән дә халык арасында шөһрәт казанган Салават Юлаев — башкорт халкының данлы улы алынуы бер дә гаҗәп түгел.

Мәгълүм булганча, башкорт халкының аңында, авыз иҗатында Салават гаять тирән эз калдырган. Халык хәтере Салаватка һәм аның юлдашларының батырлыгына багышланган уннарча тарихи-героик җырларны саклап килгән. Салават турында башкортлар башкортча җырлаган булса, татарлар татарча җырлаган. Әмма татар иҗатында мондый әсәрләр башкорттан аермалы, үзгәрәк язмышка очраган: татар кебек борынгы язма традициягә ия булган, язма әдәбияты даими рәвештә фольклор белән дә тыгыз бәйләнештә торган бер халыкта, Салават турындагы әсәрләр кульязма китап дөньясына да тартылганнар. Күңелдән генә әйтелеп йөргән җыр (йыру, җыру) яки бәет язмага теркәлгән, һәм китаби әдәбият әсәрләре белән бергә, кулдан-кулга күчерелеп таралган.

Салават турындагы татарча йыру яки бәетләрнең моңарчы бары бер генә кульязма күчермәсе мәгълүм иде. Аны XIX гасыр урталарында Урал татарларының язма әдәбият һәм фольклорын җыйнау, тикшерү эше белән шөгыльләнгән Уфа галиме Руф Игнатьев безгә килеп җитмәгән иске бер татар кульязма китабыннан оригинал язуынча күчереп алган, текстны русчага тәрҗемә иткән, әмма матбугатта бастыра алмый калган. Соңыннан бу күчермә Мәскәү профессоры А. Н. Максимов кулына кереп, ул төрки телләр белгече проф. Н. К. Дмитриевка тапшырган. Бу галим аны 1935 елда башкорт фольклор эпик традициясендәге җырлар белән бергә бастырып чыгарган [2]. Гарәп хәрефендәге оригинал тексты, русчага тәрҗемәсе белән бергә, бу басмада тәфсилле фәнни комментарийлар да бирелгән. Н. К. Дмитриев кульязма бәетнең яки йыруның поэтикасы, стиле белән халык хәтерендә йөргән җырларга якын булган хәлдә, тарихи колоритны тулырак һәм төгәлрәк саклавын һәм шуның белән әһәмиятлерәк булуын беренче булып фәнни анализлап бирде.


Күптән түгел Салават турындагы татарча бәетнең яңа бер күчермәсе, тагын да кызыграк, тулырак һәм әһәмиятлерәк бер варианты (версиясе) табылды. 12 строфалы бу әсәр гарәп теле синтаксисына караган «Шоруху Мисбах» исемле гарәпчә әсәр күчерелгән кульязма китапның соңгы битенә (81 б кәгазь яки 162 бит) язылган [3]. Бу китапны

---

[1] Боларның текстлары: 1) Бәетләр. Төзүчесе Х. Ярми. Казан. 1960 ел. 59 һәм 62 битләр; 2) Борынгы татар әдәбияты. Казан. 1963 ел. 425 бит.

[2] М. М. Билалов, Н. К. Дмитриев. Башкирские песни о Салавате. Советский фольклор. Сборник статей и материалов. № 2—3. АН СССР. М. — Л., Рус телендә. 1935 ел. 294—295 һәм 305—306 битләр. Безнең татар әдәбиятының төрле антология, хрестоматия һәм җыентыкларына бу бәетнең тексты менә шушы басмадан алынган. Кара: Татар халык иҗаты. Казан. 1954 ел. 336—337, 590 бит; Бәетләр. 60—61, 342 бит; Борынгы татар әдәбияты. 438—439 битләр.

[3] Кульязма Казан университеты фәнни китапханәсенең Көнчыгыш кульязмалары бүлегендә саклана (гарәп фонды, № 1622 (2189).



Кулъязма китапның «Салават бәете» язылган бите.

татар кешесе күчергән. Буш калган башка битләргә татарча көнкүреш хроник истәлекләре, борынгы китаплар исемлеге, догалар кебек төрле текстлар язып куелган. Безне, әлбәттә, әлеге соңгы бит кызыксындыра. Һәр строфа бер юлга сыйдырылган. Башында әсәрнең исеме ике төрле — «Салават бәете» һәм «Салават йыруы» рәвешендә бирелгән. Мондый терминологик параллелизм, күрәсең, телдә генә түгел, язма хәлдә дә яши торган сюжетлы эпик әсәр белән бары телдә генә яши торган әсәрнең терминнары катгый билгеләнеп житмәүдән киләдер. Дөресрәге, инде монда билгеләнү, ачыклануга таба борылуны күрәбез. Күптәннән бирле кулланылып килгән һәм һәр ике очрак өчен дә яраган «йыру» термины гына инде бу заманда канәгатьләндерми башлый. Бу «жыр» (яки «жыру») рәвешендә бары телдә генә яши торган әсәргә атама булып кала, язмага да беркетелә торган әсәргә исә «бәет» термины куела (бу термин китаби әдәбияттан алынган). Моңарчы билгеле кулъязмада (алда без аны Игнатьев-Максимов версиясе дип йөртәбез) жанр атамасы «йыру» рәвешендә генә бирелгән, әмма аны галимнәр танып житкермичә, «Салават йыруы» дигәнне «Салават Иәрмей» дип укып килгәннәр һәм, нәтиҗәдә, ул аңлаешсыз булып килгән («Татар халык иҗаты»ндагы текстның исемен кара).

Хәер, хикмәт терминнарда — атамаларда түгел. Яңа табылган кулъязма даталы булуы, күчерелгән вакыты һәм якынча төбәге дә билгеле булуы белән әһәмиятле. 80 б кәгазьдә һиҗри исәбенчә 1199 елның шагъбан аена, безнеңчә 1785 елның июленә караган хроник истәлек бар. Бу — бер дата. Икенче датаны «Салават бәете»н күчергән кеше кулы белән арткы тышлыкның эченә язып куелган хроник истәлек ачып бирә: «Карга-

лыга килендә җомадил-әүвәлнең йегерме икенче көнендә, тарих меңдә йите йөз туксан икенче елның эчендә», диелгән анда. Күрәсең, бәетнең күчерелгән (яки теркәлгән) елы да нәкъ менә шушы 1792 елдыр, төбәге исә Оренбург янындагы Сәгыйт (Каргалы) бистәседер. Нәкъ менә шушы төбәктәге татарларның Пугачев хәрәкәтенең иң кызган чорларына шаһит булганлыклары безгә тарихтан мәгълүм иң — бәетнең үзенең өченче строфасындагы мәгълүмат та безгә шуны раслый.

Кулъязманың тышкы кыяфәте — кәгазе, карасы, язу стиле дә бу күчермәнең шул заманныкы булуын аермачык күрсәтеп тора. Менә шушы хәл, ягъни булып үткән тарихи вакыйгага якынлык бу версиянең сыйфатында ачык сизелә: йыруны китапка теркәүче кешенең вакыйгаларны үз башыннан кичерүче, шаһиты, замандашы булуы бәет яки йырда конкрет чор рухының тәгәл һәм тулырак чагылуына китергән. Шуңа күрә яңа табылган бәет Игнатьев-Максимов кулъязма версиясеннән эпик сюжетның эзлеклерәк бирелүе, эпик герой характерының тирәнтенрәк ачылуы белән аерылып тора. Алда без менә шушы ике версияне чагыштырып, икенче, ягъни яңа табылган бәетнең тарихи әдәби кыйммәтен билгеләмәкче булабыз.

Беренче бәеттә сюжет эпик геройның патша властьлары кулына төшкәннән соңгы хәлен, кичерешләрен гәүдәләндерү рәвешендә генә ачыла. Бәеттә булган ун строфаның барысы да шуны сурәтләүдән гыйбарәт. Яңа табылган бәетнең баштагы дүрт строфасында исә без эпик геройның данлы һөҗүмнәре, изүчеләргә ут чәчеп йөргән чагы гәүдәләнүен күрәбез. Монда яуның театры — барган урыны (Җаек буе, Оренбург тирәсе) да, аның обстановкасы, динамикасы һәм герое да конкрет детальләр белән күрсәтелгән. Озын юл, акбүз ат, сөңге, кылыч, алтынлы ту (байрак) менә шуны күз алдына бастыралар. Менә шушында геройның эпик характеры, каһарманлыгы борынгы татар эпик традициясенә хас гипербола алымы белән сурәтләнә («... Салават сугыш иткәндә алты йөз солдат бетәдер», 3 нче строфада). Эпик герой үзенең ныклыгын, каһарманлыгын ахыргача саклый. Бу да беренче бәеттә күрелмәгән хәл. Аңарда кулы-аягы богауланган, зинданга салынган Салават үткәндә кылган эшләре өчен үкенүче һәм яшь коючы бер кеше итеп, геройны эпиклыктан мәхрүм итә торган сентименталь ноталар куертып бирелгән (чагыштырып кара: «Борынгы татар әдәбияты», 438 — 439 бит). «Салават белән Юлай байның күз яшьләре агар су кебек» рәвешендәге сурәтләр бу бәетнең берничә строфасында бар.

Яңа табылган бәеттә исә Салават хәтта кулы-аягы богаулы хәлдә дә үзенең эпик-героик характерын саклый, допрос алучы, каты җәза белән янаучы патша түрәләре алдында калтырап төшми, киресенчә — аларны калтырата (унберенче строфада: «Салаваткайның билендә алтын гына кылыч ялтырай, Салават торып сүз әйткәндә гәвер урыс калтырай»). Бу бәеттә геройның салкын канлылыгы, зинданда да аек фикер йөртү, үткәндәге эшләрдән дөрес хөкем чыгару, сабак алу сәләтен югалтмавы гәүдәләндерелгән. Бу ике бәеттә геройның үзенең үткән юлына, кылган эшенә мөнәсәбәте бер-берсеннән бөтенләй аерыла. Беренчесендә бу менә болай бирелгән:

**Әдернә лә тартып ук атмаенча,**
**Талды гына бәнем беләккәем.**
**Яшь йөрәккәемә чыдый алмый**
**Хур иттем лә сәне, әнекәем.**

Монда геройның кичерешләре дә аерым бер шәхеснең үзенең фаҗигале язмышы өчен генә рухи газаплануы, субъектив бер акт булып кабул ителә. Икенче бәетнең соңгы строфасында исә, сентиментальлекнең әсәре дә булмау белән бергә, бу язманың конкрет тарихи, социаль мәгънәсенә басым ясалган. Монда кузгалышларның юлбашчысы, үзен «Мин Петр Өченче падишаһ, Пит Фидрич» дип игълан иткән Пугачев шәхесенең телгә алынуы һәм эпик геройның үз авызыннан аңа мөнәсәбәтен белдерүе әнә шул конкрет тарихилекне көчәйтә. Күп санлы документлар буенча безгә мәгълүм булганча, Пугачев татарларга үзен патша итеп таныта торган («белмәк вә иманмак өчен!») татарча манифестлар — өндәмәләр җибәреп, халыкны үзенә «тугъры ихлас вә ихласынча йөреп хезмәт вә чиру кыйлмак» ка чакырган иде һәм чынлап та күптәннән инде «мәрхәмәтле патша» өмете белән яшәгән халык арасында үзенә күп теләктәшләр тапкан иде. Бәеттә халыкның Пугачевка ихлас күңелдән самими ышануы эпик герой авызыннан бик тәгәл, ышандырырлык итеп әйтеп бирелгән:

**Яшь башларымдин яу яуладым,**
**Бүгәчәү картка ышанып.**

(Пугачевка инде «патша» дип түгел, бәлки гадәти бер кеше итеп карау, аны «карт» дип әйтү үзе үк азмы-күпме вакыйга булып үткәннән соң алынган сабакка ишарә ясый. Монда инде без хәтердән, сөйләү традициясеннән язып алынган «Пугачев патшаны күрсә идең, алларыннан буй бөгеп узса идең. Аргамак менеп, дан тотып, Җаек яуларында йөрсә идең», бәетендәге романтик рухтан аермалы булган аеграк, реалистик хөкем йөртүне күрәбез.)

Менә шундый аек хөкем, үткәндәге иҗтимагый вакыйгадан сабак алу, гыйбрәтен чыгару бәетнең җиденче строфасында да чагылып китә.

**Йелүзән буе андызлык,**
**Ай-һай гына безнең аңсызлык.**
**Болай гына аңсыз дәгел ирдек**
**Ай-һай гына безнен ялгызлык.**

Моны зинданда утырганда эпик герой әйтә булса кирәк. Шунысы кызык, безнең халык иҗатындагы кыска, дүрт юллык җырлар арасында да менә шушы җыр очрый. Әллә ни үзгәреш тә кичермәгән: ерак араларга җәелә алмаган «Йөрүзән» исеме шөһрәтле «Агыйдел» белән алыштырылган. Әмма ул хәзерге көндә ниндидер бер конкрет заман, җирлек, вакыйгага нисбәтле булмаган, аерым бер шәхеснең язмышына карап теләсә кайсы очракка да ярый торган гомуми мәгънәле бер әсәр буларак кабул ителә. Күрәсең, бу һәрвакыт шулай булмаган, элегрәк хәл башкачарак булган. 1792 нче елгы «Салават бәете» күчермәсендә бу җырда конкрет бер тарихи вакыйга белән бәйләнеп, шәхси язмыштан бигрәк социаль төсмер көчлерәк сизелә. Безнең халык иҗатының тарихи үсешен, жанрлар эволюциясен күз алдына китерү өчен гыйбрәтле хәл бу, дип уйлыйм мин. Ничек кенә булса да бер нәрсә ачык: халык авыз иҗатының язма рәвештә иртәрәк теркәлеп калган әсәрләрендә тарихилык көчлерәк саклана һәм андый күчермәләр фән өчен хәтер-сөйләү традициясе саклый алмаган күп кенә сыйфат һәм мәгълүматларны алып килә. Яңа табылган «Салават бәете», безнең карашыбызча, шуның ачык мисалы. Вакыйгага якынрак заманда теркәлүе сәбәпле, аңарда чор рухы икенче бер кулъязма күчермә — Игнатьев-Максимов версиясенә караганда да төгәлрәк чагылган. Шушы сыйфат бу күчермәнең тарихи-әдәби кыйммәтен билгели.

Әлбәттә, Пугачев һәм Салават турындагы әдәби әсәрләр безнең халык кичереп үткән күп гасырлык катлаулы һәм озын тарихның бер эпизоды гына. Халык тарихында андый зур иҗтимагый вакыйгалар, феодаль изелүгә, социаль явызлыкка каршы корал белән көрәшкә күтәрелүләр аз булмаган. Степан Разин күтәрелешеннән алып XIX гасырның 70—80 нче елларындагы татар крестьян кузгалышларына хәтле генә дә күпме күтәрелеш булган. Бу вакыйгаларның һәркайсысы халык авыз иҗатында да, китап әдәбиятында да тегеләйме-болаймы чагылмый калмаган. Мондый вакыйгаларга актив катнашкан каләм ияләренең тырышлыгы белән тарих мәңгеләштереп калдырылган. Боларның бер ишеләре ике-өч юллык хроник истәлек итеп язып куелса, икенчеләре «Миръат-ел-вакыйгат» (вакыйгалар көзгесе — калейдоскоп) рәвешендә зур, тәфсилле документаль-хроникаль очерклар итеп теркәлгән. Булган хәлне сәнгатьчә гомумиләштерә торган әдәби әсәрләр (йыру, бәет һ. б.) дә иҗат ителгән һәм кулъязма китап эченә язып куела торган булган. Аянычка каршы, боларның күбесенең булганлыгы, исеме мәгълүм булып та, җисемнәре — нөсхәләре сакланмаган. Моның да иҗтимагый сәбәпләре бар: патша хөкүмәтенең азатлык фикерен һәм рухын даими рәвештә әзерлекләп торуы булган әсәрләрнең кулъязма күчермәләре күбәюгә, таралуга ирек куймаган, булган нөсхәләр дә туза, югала яки рәсми властьлар тарафыннан юк ителә торган. Шуңа күрә, минемчә, бу төр әсәрләрнең бүгенге көндә гыйльми китапханә һәм архивларда саклана торганнарын барлау, өйрәнү, бастырып чыгару эшенә житдирәк игътибар кирәк. Шулай булганда фән тагын да байый төшәр иде.

АЛЬБЕРТ ФӘТХИ.

*Әбрар Кәримуллин*

# БЕРЕНЧЕ ТАТАР КИТАПЛАРЫ

Язма, басма сүз — кешелек җәмгыяте уйлап чыгарган бөек могҗизаларның берсе. Аннан башка хәзерге фән һәм техниканың, әдәбият һәм телнең үсешен, халыкларның үзара аралашуын күз алдына китерүе дә кыен. Басма сүз үткән белән бүгенгене, хәзерге белән киләчәкне бәйләүче күпер дә. Китапларда кешеләрнең күп гасырлар дәвамында тупланган бай тәҗрибәсе, күзәтүләре, уй һәм тойгылары, теләк һәм омтылышлары теркәлгән һәм теркәлә бара.

Авазларны хәрефләр белән билгеләргә өйрәнгәнче, китап барлыкка килгәнче, күп гасырлар үткән. Бары тик алфавит уйлап чыгарылганнан соң гына китап басу өчен шартлар туа.

Күчмә литер — шрифтлар кулланып китап басу XI йөздә Кытайда башлана. XIV гасырда инде бу ысул уйгурларда да билгеле була. Европа территориясендә литерлардан сүзләр җыеп басылган беренче китап 1445 елда чыга. Ул — Иоганн Гутенберг тарафыннан эшләнгән «Библия». Шуннан соң китап басу эше тиз арада бөтен Европага тарала.

Славян телләрендә китап басу эше XV гасырның ахырында барлыкка килә. 1564 елда Иван Федоров чыгарган «Апостол» беренче рус китабы санала.

Беренче гарәп литерлары XV гасырның уртасында Италиянең Генуя шәһәрендә эшләнә. Ләкин баштарак бу литерлар фәнни басмаларда гарәп язмаларыннан мисаллар китергәндә генә кулланыла. Гарәп хәрефләре белән басылган беренче китап та 1510 елда шушы Генуя шәһәрендә үк чыга. Алга таба гарәп шрифтлары белән китап басу эшенә Истамбул яһүдләре алына. Төрекләрдә гарәп хәрефләре белән китап басу эше XVIII гасырның беренче чирегендә генә башлана.

XVI—XVIII йөздә Италия һәм Төркиядә, XVIII—XIX йөзләрдә Һиндстан һәм Мисырда басылган китаплар татарлар арасында да киң таралган. Татар сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләре, хаҗга баручылар бу басмаларны Идел буена шактый күп алып кайта торган булганнар. Хәтта Казан, Оренбург һәм Уфа кебек шәһәрләрдә татар китаплары күпләп басыла башлагач та, Көнчыгыш илләреннән китаплар алып кайту тукталмаган. Татарлар арасында Көнчыгышта чыккан китапларның чагыштырмача киң таралуын күрсәтү өчен, бер-ике мисал китерик. Казан университеты китапханәсендә Әбү Гали Синаның 1593 елда Италиядә гарәп телендә басылган «Канун фи тыйбб» исемле китабы саклана. Бу — бик сирәк очрый торган шәрыкчә басмаларның берсе. Шул ук китапханәдә Ван Кулиның 1727 елда Истамбулда чыккан ике томлык «Төрки-гарәпчә сүзлеге», күренекле географ һәм библиограф Чәләбинең 1730 елда басылган «Җиһаннамәсе» һәм башка меңнәрчә Көнчыгыш басмалары бар. Университет китапханәсенә аларның күпчелеге Казан татарларының шәхси китап фондларыннан алынган.

Ә Россиянең үзендә гарәп хәрефләре белән китап басу эше кайчан башлана? Ул кайсы телдә булган? Беренче татар китабы кайчан, кайда, кем тарафыннан чыгарылган?

Башка халыкларның матбагачылык тарихын шактый яхшы белсәк тә, беренче татар басмасының кайчан чыгуы турында, кызганычка каршы, хәзерге көнгә хәтле тулы һәм төгәл мәгълүматыбыз юк. Дөрес, матбугат битләрендә, сирәк булса да, татар китабы тарихына карата әйтелгән фикерләр очрый. Шушы мәсьәләгә багышланган махсус хезмәтләр дә юк түгел. Татарда матбагачылык тарихына караган беренче сүзне

Риза Фәхретдин, Шиһап Ахмеров һәм Исмәгыйл Рәмиевләр әйтеп үттеләр[1]. Бу хезмәтләрнең авторлары, беренче татар китаплары турында сөйләгәндә, академик Б. Дорн хезмәтенә таянып эш итәләр[2]. Кызганычка каршы, Б. Дорн хезмәте дә, безнең татар галимнәренең хезмәтләрендәге мәгълүматлар да бүген инде шактый искергән.

Ул хезмәтләрдәге төгәлсезлекләргә тукталганчы, тагын бер мәсьәләне ачыкларга кирәк. Соңгы елларда Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә 1618 елда Львов шәһәре типографиясендә татар телендә басылган «Альгыш бөтеки» исемле бер китап табылды. Бу — татар телендәге безгә билгеле китапларның иң өлкәне. Ләкин аны татар китабы дип атау, безнеңчә, дөрес булмас иде. Беренчедән, ул әрмән хәрефләре белән басылган. Шуның өстенә аны әрмән осталары эшләгән. Әрмәннәр өчен чыгарылган бу догалык татар халкына бөтенләй билгеле булмаган. Шулай да әлеге китап ни өчен татар телендә язылган соң? Төрле тарихи сәбәпләр аркасында, XI гасырдан башлап әрмәннәрнең бер өлеше төрки халыклар арасында яши башлый, ана теле, хәтта язма, эш теле итеп тә төрки телне кабул итә, шул телдә китаплар чыгара[3].

Әрмән филологы һәм тарихчысы М. Чямчян борынгы татар төркисе телендә әрмән хәрефләре белән китап басу Италиядә әле XVII—XVIII йөзләрдә дә дәвам итүен күрсәтеп үтә[4].

Билгеле, безнең культурабыз өчен бу китапларның зур әһәмияте бар. Бу басмалар — борынгы татар телен, бигрәк тә хәзерге татар теле формалашуда зур роль уйнаган кыпчак телен өйрәнү өчен кыйммәтле чыганаклар. Ләкин, югарыда инде бер кат күрсәтеп үтелгәнчә, боларны татар китабы дип санау дөрес булмас иде.

Төрки телләрдә гарәп хәрефләре белән басылган беренче китаплар XVII гасырда чыга башлый. Безгә 1649 елда Италиядә чыккан бер басма билгеле. Ул — «Гарәпчәтөркичә лөгать». 1670 елда Италиядә аның тагын бер яңа басмасы чыга. Нигездә, борынгы төрки сүзләрен эченә алган бу «лөгать» китапларын барлык төрки халыклар өчен уртак басма дип карарга мөмкин. XVII йөздә төрки телдә болардан башка китаплар да чыккан булырга тиеш. Аларны ачыклау өчен Европа китапханәләрендә ныклап эзләнергә кирәк.

Югарыда исеме күрсәтелгән хезмәтендә Дорн беренче татар басмасының 1711 елда, икенчесенең 1722 елда дөньяга чыгуын яза. Ләкин аларның кайда, кайсы типографиядә басылулары турында бер сүз дә әйтми. Р. Фәхретдинов һәм Ш. Ахмеров исә, академик Б. Дорн күрсәткән бу беренче басмаларны телгә алсалар да, беренче татар китабы итеп 1787 елда Петербургта чыккан «Коръән»не саныйлар. Инде И. Рәмиев фикеренчә, беренче татар китабы — Сәгыйт Хәлфиннең 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә басылган «Татар әлифбасы»[5].

Академик Дорн хезмәтендә күрсәтелгән 1711 һәм 1722 елгы басмалар соңгы елларда гына табылдылар. Татар галимнәре, әлбәттә, аларның үзләрен күрә алмаганнар. Шуңа да татар басмасы дип санамаганнар булса кирәк.

1711 елда чыккан беренче басманы без Мәскәүдәге СССР Дәүләт тарих музее архивыннан таптык[6]. Иңе 175 см, буе 285 см зурлыгындагы бу басмада Петр I «Мани-

---

[1] Р. Фәхретдинов. Милли матбугатыбыз. «Шура» журналы. 1908 ел. 8 сан. 231—233 битләр. 10 сан. 324—326 битләр. 17 сан. 525—527 битләр. 21 сан. 673—675 битләр; Ш. Ахмер. Матбагачылык тарихы. Казан. 1909 ел. VIII. 70 бит; И. Рәми. Татарда басмачылык һәм китапчылык эше. «Яналиф» журналы. 1931 ел. 8—9 саннар. 74—81 битләр; И. Рәмиев. Истәлекләр. Татарча басма сүз. Казан. 1965 ел. 31 бит.

[2] Б. Дорнның бу хезмәте 1869 елда Санктпетербургта чыккан «Mélanges Asiatiques tirés du Bulletin de l' Academie Jmperiale des sciences de St. Peterbourg» исемле журналның 5 нче томында басылган.

[3] Ф. Е. Корш. Каменец-Подольские армяно-татарские документы Киевского центрального архива. Журнал «Древности восточные. Труды Восточной комиссии Московского археологического общества». т. 2, вып. 2, М., Рус телендә. 1901 ел. 136 бит.

[4] М. Чямчян. История Армении. т. 3. Венеция. 1786 год. Әрмән телендә. 664 бит.

[5] И. Рәмиев. Истәлекләр. Татарча басма сүз. Казан. 1965 ел. 81 бит (И. Рәмиев китапның басылу елын ни өчендер 1774 дип күрсәткән).

[6] СССР Дәүләт тарих музее. Дашков архивы. Шифр Д/К я. 6 папка. 41, 42, 43 саннар.

фест»ының[1] рус телендә чыккан текстына кушымта рәвешендә, әлеге «Манифест»ның татарча кыскартылган тексты китерелгән. Петр I үзенең бу «Манифест»ын, немец, француз, грек, латин телләрендә бастырып, илчеләр арасында тараткан. Патша Төркия белән сугышның сәбәпләре белән татарларны да таныштыруны кирәк тапкан икән. Без моны текстның беренче юлларындагы: «...без падишаһ Петер Алексеевич, урысның бойрыкчысы... белдерермез урысның мирзаларына вә татарларына...», — дигән сүзләрдән аңлыйбыз. «Манифест»ның татарча варианты: «Безнең мөһеребез илән вирелде Мәскәүдә тарих бең йиеде йөз (ун) беренче йылында, февралендә», — дип тәмамлана.

Ләкин һәр б а с м а китап булып санала алмый бит әле. Б а с м а н ы ң китап булып саналуы өчен аның литерлардан җыелып басылган булуы шарт. Югыйсә «ксилографик» китапларны да фәндә кабул ителгән к и т а п төшенчәсенә кертсәң, рус китабы тарихын 1564 елда чыккан «Апостол»дан түгел, ә Киев Русе вакытында ук басылган «ксилографик» китаплардан башларга туры килер иде.

1711 елда татарча чыккан әлеге басма исә бакыр пластинкага уеп язу юлы белән эшләнгән. Шуңа күрә аны китап дип атап булмый, ул гравюра ысулы белән эшләнгән басма гына булып кала. 1722 елга хәтле Россиядә гарәп литерлары бөтенләй булмый.

XVIII гасырның 20 елларында Иранда төрле чуалышлар башлана. Иран кул астында булган төньяк-көнчыгыш Кавказда рус сәүдәгәрләрен талау, кимсетү фактлары ешая. Астрахань губернаторыннан шул турыда хәбәр килгәч, Петр I, рус дәүләте интересларын яклау өчен, Персия походына әзерләнә башлый. Бу поход уңае белән ул тагын «Манифест» яза. Дөресрәге, аның кушуы буенча манифестны Дмитрий Кантемир яза[2]. Петр I бу походка үзе белән типография дә алып чыга һәм типографияне оештыру, анда гарәп шрифтлары булдыру, «Манифест»ны татарчага тәрҗемә итү һәм бастыру эшен Дм. Кантемирга йөкли. Патша хәзрәтләренең 1722 ел 30 апрель указы белән, Мәскәүнең синодаль типографиясеннән бер станок, бер хәреф калыбы ясаучы мастер, бер хәреф җыючы, биш ярдәмче, шулай ук шрифт ясау өчен илле пот металл җибәрелә. Россиядә гарәп шрифтлары булмау сәбәпле, хәрефләрнең рәсемен Кантемир үзе ясый, ул хәрефләрне кою өчен калып — пунсон эшләнә. 1722 елның 15 июлендә Астраханьда суднога урнаштырылган поход типографиясендә Персия походы уңае белән язылган манифест татар телендә аерым китап булып басылып чыга.

«Манифест» — 250 см×150 см зурлыгындагы дүрт битле брошюрадан гыйбарәт. Китапчыкның 1,2 һәм 3 битләрендә татарча текст басылган. Басманың титул бите, тышлыгы юк. Исеме дә куелмаган. Текстның беренче сүзләреннән чәчәк сыман вензель — турга ясалган. Турга — шәрык кулъязмаларында киң кулланыла торган традицион алым. Бу факт Кантемирның көнчыгыш язма әдәбияты белән якын таныш булуын күрсәтә. Аның рәсемнәре буенча ясалган шрифтларның нәфислеге дә игътибарга лаек. Соңыннан XVIII—XIX йөзләрдә, Россиядә кулланылган гарәп шрифтларының рәсеме Кантемирныкыннан шактый түбән булуын күрәбез.

1722 елның 15 июлендә басылган менә шушы «Манифест»ны без Россиядә чыккан беренче татар китабы дип санау ягында торабыз[3]. Бу фикерне түбәндәге дәлилләр куәтли. Беренчедән, ул — литерлардан җыеп эшләнгән басма. Икенчедән, теле — татарча, татар теленең югары стиле. Билгеле булганча, бу стиль гади халык теленнән шактый нык аерыла. 1816 елда Карл Фукс: «Ю г а р ы с т и л ь (Карл Фукс ассызмасы) белән язу татар сүзләренә бернинди чама белмичә гарәп, фарсы, төрек сүзләре катнаштырудан гыйбарәт»[4],— дип язган иде.

«Манифест»ның теле белән танышу өчен бер-ике өзек карап үтик. Петр I нең титуллары саналып үтелгәннән соң, басмадагы төп текст түбәндәге сүзләр белән баш-


---

[1] Манифест [или] Объявление о вероломном розрыве мира солтана турского Ахмета против его царского величества. По указу его величества выдан в 1711 года, февраля в 22 день. М., Синодальная типография. Рус телендә. 1711 ел.

[2] Дм. Кантемир — 1711 елда үзе теләп Петр I гә хезмәткә күчкән Кырым татары. Кантемир заманының зур укымышлы кешеләреннән саналган. Кантемирлар нәселенең шәҗәрәсен язган Беер аның төрки, рус, фарсы, гарәп, грек, славян, итальян, молдаван, француз телләрен яхшы белүен күрсәтә.

[3] «Манифест» рус телендә аерым басма булып чыкмаган.

[4] К. Фукс. Татарские училища. Газета «Казанские известия». Рус телендә. 1816 ел. 16 сан. 19 январь. 34 бит.




«Манифест»ның беренче бите.

лана: «Шәүкәтле вә газаматлы [бөек] сәгадәтле вә мәһабәтле олы мөхәббимез [сөеклебез] вә кадими [күптәнге] дустымыз шаһ галиҗаһ [титуллы] хәзрәтләренең хөкемәтендә вә хезмәтендә улан [булган] гыйззәтле вә хөрмәтле сипаһсаларнан [генераллары]»...

Алга таба бу походның сәбәбе һәм максатлары санала. Басылу урыны һәм елы болай күрсәтелгән:

> «Фи шәһре Аҗтархан
> сәнаи хазрәте Гайса
> бең йиде йөз йегерме ике илән
> тәмүзың [июльнең] унбишендә».



«Манифест»ның соңгы бите.

Күрәсез, текстта фарсы, гарәп сүзләре гаять күп. Аларның күбесе — борынгы татар теленең югары стилендә актив кулланылышта йөргән сүзләр.

Бу китапчык кем өчен чыгарылган? Кайсы халык арасында таратылган? «Манифест»ның эчтәлегеннән күренгәнчә, Петр I рус армиясе үтәчәк җирләрдә яшәүче халыкларны солдатлардан курыкмаска, үзләренең өйләрендә торырга, дошманга ярдәм итмәскә чакыра. «Манифест» җирле халыкларга бу походның сәбәпләрен алдан белдерүне, аңлатуны максат итеп куя. Документаль материаллардан күренгәнчә, «Манифест» Петр I нең приказы буенча, төньяк Кавказ һәм Иделнең түбән агымында яшәүче халыклар арасында таратыла. Бу эш белән поручик Андрей Лопухин шөгыльләнә, аңа ярдәмгә 15 татар солдаты да бирелә [1]. Тиражы 1000 данә (заманы өчен бу зур тираж) бу басма татарлар, ногайлар, балкарлар һәм кумыклар арасында таратыла. «Манифест»ны татарчага кем тәрҗемә итүе, шрифтын, текстын кем җыюы әлегә ачыкланмаган.

Петр I нең свитасында татарлар да була һәм Персия походында 30 меңгә якын

---

[1] Походный журнал (Петра I) 1722 года. Спб., Рус телендә. 1885 ел. 51 бит.

татар солдаты катнаша[1]. Бу поход вакытында, юл унаеннан, патша Болгарга туктала. Болгар хәрабәләрендәге 50 язманы (47 се гарәп, 3 се әрмән хәрефләре белән) күчертеп алдыра. Аларны күчереп алучылар Персия походына катнашкан Ахун Кадермәмәт Сүнчәләев, Бистә тәрҗемәчесе Иосыф Ишбулатов һәм әрмән Иван Васильев булалар[2]. Шул ук походта, яшерен советның өлкән тәрҗемәчесе булып, Тәфкилев тә катнаша[3]. «Манифест»ның Персия походына катнашучы шушы татарлар тарафыннан тәрҗемә ителүе һәм текстының да алар тарафыннан җыелуы мөмкин. Билгеле, Кантемир архивында бу турыда материаллар да булгандыр. Кызганычка каршы, поход типографиясе директоры Дм. Кантемирның кульъязмалары бу поход вакытында һәлак була.

Б. Дорн 1722 елны тагын бер татар китабы басылуын күрсәтә. Ләкин аның әлегә табылганы юк, эзләү дәвам итә. Бәхеткә каршы дип әйтикме, Б. Дорн бу басманың исемен дә язып калдырган: «Низамәт сәйәсийә хәрбийәдән улып гаскәр забатында улан аразиның әһәлисенә дәхи гаид улан бәгъзе мүәдәк хөләсәседер».

Бу «Низам» да Петр I нең Персия походы уңае белән басыла һәм Кантемир типографиясендә чыга. Аның кайда басылуы мәсьәләсендә шикләнмәскә мөмкин. Чөнки Петр I заманында Россиянең башка бер генә типографиясендә дә гарәп хәрефләре булмый. Петр I нең поход типографиясеннән соң, XVIII гасырның соңгы чирегенә хәтле Россиядә гарәп хәрефләре белән басылган башка китаплар чыгуы билгеле түгел. Бу чор арасында чыккан фәнни басмалардагы гарәп текстлары ксилография ысулы белән эшләнгән. 1723—1775 еллар арасында Россиягә килгән көнчыгыш илчеләренә һәм кунакларга гарәп тексты белән басылган «подносный лист»лар басып бирү фактлары мәгълүм[4]. Россия Фәннәр академиясе типографиясе ачылгач (1729), анда гарәп шрифтлары да булдырыла. Ләкин китап басуда алар кулланылмаган булса кирәк. Моның шулай булуын исбатлау өчен бер мисал китерик. 1767 елда, Екатерина II Казанга килү уңае белән, Архирей дачасында зур тантана үткәрелә. Тантана вакытында сөйләнгән мәдхияләр 1769 елда Санктпетербургта аерым китап булып чыга[5]. Рус, грек, немец, француз телләрендә укылган мәдхияләр шул телләрнең графикасында һәм рус теленә тәрҗемә итеп басылганнар. Ә керәшен мәктәбендә укучы балаларның татар, чуваш, мари, мордва телләрендә сөйләгән сүзләре шул телләрдә, ләкин рус транскрипциясендә бирелгәннәр.

Түбәндә татарча текстны үзгәртмичә, ничек язылса шул килеш китереп үтәбез:

«Рахимне падьша хазретляри! Барча земягатляръ ичюнъ синь каярасень безъ курябезь узегне узегъ кызганъманнче кюпъ кюпъ јерлярга юрисинъ карапъ юрисинъ, кшениндъ ни реушле турганнаганъ. Аней сенъ безнеке рахимне: сен куштынъ безне мякъ туптя укатмага. Без акаллы булсагиде, без белсадіе деннынъ нирeушле иканнеданъ, без укапъ белдекъ деннынъ нирeушенъ сининъ рахимъ инда. Ананъ ичюнъ санда тянъире джарлакасинъ».

Игътибар итегез: теле нихәтле аңлаешлы! Ә бу бит моннан 200 ел элекке татар халык теле, гади тел. (Бу текстның телен «Манифест» теле белән чагыштырып карагыз!)

Әгәр Россиядә гарәп шрифтлары куллану гамәлдә булса, үзен «бөтен телләр» мактавын яраткан Екатерина II татарча мәдхиянең текстын, әлбәттә, гарәп шрифтлары белән бирдерер иде. Алда күрербез: гарәп шрифтлары Россия типографияләрендә булдырылгач, патшадан түбәнрәк дәрәҗәле кешеләргә карата чыгарылган басмаларда да татарча текст гарәп шрифтлары белән бирелә башлый.

---

[1] Голиков. Деяния Петра Великого. 2 е изд., т. 9. Спб., Рус телендә. 1838 ел. 147 бит.

[2] Ю. Крачковский. Избранные сочинения. т. 5. М. — Л., Рус телендә. 1958 ел. 32 бит.

[3] Соңыннан Тәфкилев Россия илчесе итеп Персиягә җибәрелә, тора-бара генерал-майор дәрәҗәсе ала.

[4] А. С. Тверитинова. Несколько слов к вопросу о первопечатании арабским шрифтом в типографии Академии наук. «Очерки по истории русского востоковедения». Сборник 2. М., Рус телендә. 1956 ел. 416 бит.

[5] Духовная церемония, производившаяся во время всевожделеннейшего присутствия Ея Имп. величества Великия Государыни премудрейшия Монархини и попечительнейшия матери Екатерины Вторыя в Казане... Спб., тип. Акад.-наук. Рус телендә. 1769 ел.

XVIII йөз ахырларында Россия территориясе, төрки халыклар яшәгән җирләр хисабына, бик нык киңәя, Көнчыгыш илләре белән аралашу, сату-алу эшләре көчәя. Бу территорияләрдә яшәүче халыклар белән эш итү өчен, аларның телләрен белү ихтыяҗы туа. Шушы практик ихтыяҗдан чыгып, Россиянең уку йортларында төрки-татар, бигрәк тә татар телен өйрәнү зур урын ала башлый. XVIII йөзнең ахырында, XIX йөзнең башында Санктпетербург, Мәскәү, Одесса, Харьков, Дерпт, Самара, Астрахань, Казан, Тобольск һәм башка шәһәрләрнең гимназияләре, кадет корпуслары, духовное училищеләрендә татар теле өйрәтелә [1]. Көн тәртибенә дәреслекләр булдыру мәсьәләсе килеп баса. Һәм 1776 елда Санктпетербургның Фәннәр академиясе типографиясендә, француз теленнән тәрҗемә ителеп, төрек теле грамматикасы басылып чыга [2]. Шушы ук басма, яңа тәрҗемәдә, 1777 елда Мәскәү университеты типографиясендә дә басыла. Петр I заманыннан соң, гарәп алфавиты белән язылган текстлар гарәп шрифтлары белән беренче мәртәбә шушы басмаларда чыгарыла. Димәк, шул чордан башлап Россия типографияләрендә китап басуда яңадан гарәп шрифтлары кулланыла башлый.

1776 елда Мәскәү университеты типографиясендә тагын бер китап басыла [3]. Биредә, патша тәхетенең варисы Павел Петрович өйләнү уңае белән, Мәскәү университетында үткәрелгән тантаналы кичәдә укылган мәдхияләр тупланган. Котлаулар латин, грек, рус, немец, итальян, француз, инглиз һәм татар телендә укылганнар һәм, шул телләрдә басылып, тәрҗемәләре рус телендә китерелгән. Татар телендәге мәдхияне Мәскәү университетының Академик гимназиясе укытучысы Арасланов укыган [4]. Гарәп хәрефләре белән басылган татарча текст 3 бит һәм аның рус теленә тәрҗемәсе 2 битне тәшкил итә. Соңыннан Арслановның бу нотыгы, аерым бер китапчык итеп чыгарылып, татар мирзаларына да таратыла.

1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә Сәгыйт Хәлфиннең мәгълүм әлифбасы чыга. Бу басманың татарча исеме: «Әлифбаи татар дилинең әлифбиянең тәкъыйкъ язылган хөрүфләре вә иҗекләре үтелмеш. Казан гимназияләренең остазы вә Адмирал кантурасының тәрҗеманы Сәгыйд Хәлфә угълы илә вә Казан калгасындагы муллалар илә шул ук гимназиеләрдә каралмыш вә макталмыш».

XVIII гасыр ахырында, Мәскәү университеты белән чагыштырганда, Фәннәр академиясе типографиясендә гарәп хәрефләре белән басылган китаплар күбрәк чыккан. Болар арасыннан титул битләре, шулай ук текстлары бер үк вакытта госманлы төрек (гарәп шрифты белән) һәм рус телләрендә басылган «Трактат о торговле между Российскою империею и Портою Оттоманскою, заключенный в Константинополе июня 10 го дня 1783 года» (1783 ел. 69 бит), «Тариф о сборе пошлин с привозимых и вывозимых из Константинополя Российскими купцами товаров, поставленный между Российскою империею и Портою Оттоманскою сентября 5 го дня 1782 года» (1784 ел. 61 бит) исемле китапларны һәм төрле ярлыкларны күрсәтергә мөмкин.

1783 елда Екатерина шәхси типографияләр ачарга рөхсәт бирү турында указ чыгара. Шәхси типографияләрдә шәрык телләрендә дә китаплар басарга ирек бирелә. 1785 елда типография хуҗасы Шнор, чит ил эшләре коллегиясе белән төзелгән килешү буенча, үз типографиясендә гарәп, татар, фарсы, төрек, грузин телләрендә китаплар басарга рөхсәт ала. Россия Фәннәр академиясенең барлык шәрык шрифтлары һәм дүрт станогы, договор белән, Шнорга тапшырыла [5]. 1785 елдан алып XIX йөзнең 20 елларына кадәр Фәннәр академиясенең гарәп хәрефләре кулланып эшләнгән барлык

---

[1] Н. И. Веселовский. Сведения об официальном преподавании восточных языков в России. Спб., Рус телендә. 1879—1880 ел. 98—256 битләр.

[2] Ж. Б. Гольдерманн. Турецкая грамматика или краткий и легчайший способ к изучению турецкого языка с собранием имян, глаголов, нужнейших к познанию речи, и многих дружественных разговоров. Переведена с французского в Санктпетербурге 1776 года при Артеллирейском и имперском шляхетном кадетском корпусе. (Спб.) при тип. имп. Академии наук, 1776. 228, 7 с. 2 л. табл. 8°.

[3] Исеме бик зур булу сәбәпле, кыскартып бирәбез: «Торжество по совершению бракосочетания великого князя Павла Петровича...»

[4] С. Шевырев. История императорского Московского университета. М., Рус телендә. 1855 ел. 190 бит.

[5] Полное собрание законов Российской империи. 1830 год. № 16048.

басмалары Шнор типографиясендә чыга. Бу типография бик тиз үсә һәм яңа ачылган типографияләрне шрифтлар белән тәэмин итә башлый. Мәсәлән, А. Н. Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» исемле атаклы әсәре Шнор типографиясеннән алынган шрифтлар һәм типография станында басыла [1]. 1800 елда Казанда ачылган Азия типографиясе дә Шнор типографиясе базасында оештырыла.

Шнор типографиясендә гарәп шрифтлары белән басылган беренче татарча китап: «...Русия империясендә валиәтләрнең низам вә тәртибе...» дип атала (күләме 247 бит). Китап рус телендә 1775 елда чыккан «...Учреждение для управления губерний Российская империи» исемле басманың тәрҗемәсе. Китап татар теленә Казан гимназиясенең татар теле укытучысы Сәгыйть Хәлфин улы Исхак Хәлфин тарафыннан тәрҗемә ителгән [2]. Шушы законнар җыентыгын тәрҗемә иткән өчен, Екатерина II Исхак Хәлфинне 1000 сум акча белән бүләкләгән һәм аңа губерна секретаре дигән чин биргән. 1785 елда ук бу законнар Крым татарлары телендә дә басыла. Һәр басманың тиражы 2000 әр була. Китап бик тиз таралып беткән булса кирәк, Казан татарлары телендәге басмасы, 500 данә тираж белән, 1786 елда яңадан чыгарыла.

Бу китаплар да, Петр I заманында чыккан татарча басмалар кебек үк, югары стиль белән тәрҗемә ителгәннәр. Текстта гарәп, фарсы, борынгы төрки теле элементлары шактый зур урын алып тора. Шушы үзенчәлегеннән чыгып булса кирәк, бу басмаларны әзербәйҗан китабы дип санаучылар да очрый [3]. Икенче бер әзербәйҗан галиме В. Әфәндиев 1785 елгы басманы Россиянең «Закавказ өлкәләре турындагы административ, хокукый һәм хәрби положениеләрне эченә алган законнар җыентыгы» дип күрсәтеп үтте [4].

Билгеле, бу китапта «Закавказ өлкәләре» турында бер сүз дә юк. Хәзерге Әзербәйҗан ССР территориясе Россия белән Иран арасындагы 1813 һәм 1828 елгы солых договорлары нигезендә Россиягә кушылды [5]. Екатерина II Әзербәйҗан Россиягә кушылганчы ярты гасыр алдан бу территория белән идарә итү турында законнар чыгара алмаган, әлбәттә. А. Алиев һәм В. Әфәндиевләрнең бу басманы әзербәйҗан китабы дип санаулары хата икәнлеген, аның татар китабы булуын белгечләр дә күрсәтеп үттеләр [6].

Культурабыз тарихының тиешенчә өйрәнелмәве, төрки тел проблемасының хәл ителмәве менә шундый күңелсез күренешләргә китергәли. Мондый очраклар татар китабы тарихында гына түгел, татар әдәбияты, сәнгате, тарих өлкәләрендә дә соңгы елларда шактый еш күренә башлады.

1785 елда Шнор типографиясендә Исхак Хәлфин тәрҗемәсендә татарча тагын бер зур күләмле китап чыга. Ул губерналарның эчке эше белән җитәкчелек итүне эченә алган «Благочиниййә яхуд поличә» исемле законнар җыентыгы. Татар телендәге зур күләмле бу басмалар Казан, Мәскәү, Ленинград китапханәләрендә шактый күп саклангән. Шнор типографиясендә хәреф җыючы, корректор, гарәп хәрефләренең рәсемнәрен ясаучы булып татарлар эшли. Сенатның указы белән, Шнор типографиясеннән Казан типографиясенә ике кеше дә җибәрелә. Алар корректор Хәмзә Мамышев һәм наборщик Гали Рәхмәтуллин [7].

1783 елда ук шәхси типографияләр ачарга рөхсәт бирелгәч, ни өчен безнең бабаларыбыз да китап бастыруны оештырмаганнар соң? Әллә патша цензоры В. Смир-

---

[1] Русское книгопечатание до 1917 года (ч. 1.) 1564—1917. М., Рус телендә. 1964 ел. 195 бит.

[2] Н. Н. Булич. Из первых лет Казанского университета. Спб. Рус телендә. 1904 ел, 47 бит.

[3] А. Алиев. Азербайджанская книга. т. 1. 1780—1920. Баку. 1963 ел. 3 бит.

[4] В. Эфендиев. История азербайджанской книги. «Дружба народов» журналы. 1964 ел. 3 сан. 264 бит.

[5] БСЭ, 2 ое изд., т. 1. с. 445; Советская историческая энциклопедия. т. 1, с. 237.

[6] А. И. Веревкина и З. А. Керимова. Библиография дореволюционной азербайджанской книги. «Сов. библиография». 1966 год. Рус телендә. 2 (96) сан. 94 бит.

[7] ТАССР Үзәк дәүләт архивы. 977 фонд. 376 архив. 1820 ел. 1-кәгазь; шул ук фонд. 1023 архив. 1819 ел. 26-кәгазь.

иовның татар халкы культура белән кызыксынмый, үзләрен агарту өчен патша үзе ачып биргән типографиядән дә файдалана белми, дигән сүзләре дөресме? [1]

Фактлар бу фикернең киресен күрсәтәләр. Татарларга басма китап XVI гасырдан бирле таныш иде. Югарыда без XVII—XIX гасырларда татарлар арасында Италиядә, шәрык илләрендә чыккан китапларның шактый киң таралуын күреп үткән идек. Татарларның Екатерина II гә язган хатларында, дини китаплар белән беррәттән, мәктәп-мәдрәсә өчен уку китаплары җитмәве, Төркиядән алып кайтыла торган китапларның кыйммәтлеге күрсәтелә, «мөселманча» китап басарга рөхсәт сорала. Ләкин Екатерина II шәхси типографияләр тотарга рөхсәт бирүнең нәрсәгә китерүен бик тиз төшенә. Мәскәү университеты типографиясен арендага алган мәгърифәтче Н. И. Новиковны Екатерина II, самодержавиегә тәнкыйть сүзләре әйтелгән китаплар бастырган өчен, Шлиссельбург крепостена яба. Шәхси типографиясендә «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» исемле китап баскан өчен А. Н. Радищев сөргенгә җибәрелә. Шуның өстенә Көнбатыш Европада буржуаз революцион хәрәкәт башлана. Болардан коты очкан Әби патша, икенче указ чыгарып, барлык шәхси типографияләрне тыя.

Әлбәттә, ул татарларга да шәхси типография ачарга рөхсәт бирми. Шул ук вакытта хәйләкәр Әби патша татарларны беразга тынычландыру юлын да таба. 1787 елда Шнор типографиясендә үз хисабына гарәп хәрефләре белән «Коръән»не бастырып чыгара. 477 битлек бу калын китап, бернинди үзгәрешсез диярлек, 1790, 1793, 1796 һәм 1798 елларда шул ук типографиядә яңадан чыгарыла. Екатерина II моны ислам диненә яки мөселманнарга мәхәббәтеннән эшләми, әлбәттә. Бу эше белән, берьяктан, ул, вакытлыча булса да, татар руханилары һәм байларының авызларын каплап тора. Икенчедән, «Коръән» сатудан зур файда күрә. Шуның өстенә академик Ю. Крачковский күрсәтүенчә, Әби патша «Коръән» бастыруны Төркиягә каршы сугышта үзен мөселман халыкларын яклаучы итеп күрсәтү өчен дә файдалана [2].

Ләкин татарлар «Коръән» белән генә канәгатьләнмәделәр. Мәктәп-мәдрәсәләр өчен уку китаплары кирәк иде. Типография ачуны сорап, үтенечләр пайтәхеткә агыла торды. Екатерина II үлгәч, тәхеткә Павел I утыра. Типографияләрне кысрыклау тагын да көчәя. Ул хәтта, Академия, Сенат, I нче кадет корпусы типографияләреннән кала, Петербургтагы барлык казенный типографияләрне яптыра [3].

Ләкин 1799 елда Павел «Дини китаплар һәм догалыклар» бастыру өчен, Казанда «Азиат» типографиясе ачарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Һәм бер елдан соң бу турыда Сенатның 20823 номерлы Указы да чыга [4].

Указдан күренгәнчә, типография ачуны сорап, Казан, Уфа, Оренбург һәм татарлар яши торган башка төбәкләрдән күп үтенечләр килгән. Петербургта кунак булганда Бохара әмире дә бу үтенечне куәтләгәч, башкалада патша хезмәтендәге татар мирзалары да поручательство биргәч кенә татарлар өчен махсус типография ачарга рөхсәт ителгән. Һәм Шнор типографиясе базасында оештырылган беренче татар типографиясен отставкадагы татар поручигы Г. Бурашев [5] 1800 елда Казанга алып кайта. Казан гимназиясе каршында татар типографиясе эшли башлый. 1801 елда инде беренче китаплар чыгара. Бу шәхси типография түгел, ә казенный басмаханә иде. Ул 1829 елны университет типографиясенә кушыла. Казанда «Азиат» типографиясе ачылу белән, татар китап тарихының яңа сәхифәсе башлана.

[1] В. Смирнов. Мусульманские печатные издания. Журнал «Записки восточ. отделения имп. Российского археологического общества». т. 3. Рус теләндә. 1885 ел. 106—108 битләр.

[2] Ю. Крачковский. Избраные сочинения. т. 5. М.-Л., Рус теләндә. 1958 ел. 40 бит.

[3] Н. Г. Малыхин. Очерки истории книгоиздательского дело в СССР. М., Рус телендә. 1965 ел. 139 бит.

[4] Татарстан үзәк дәүләт архивы. 977 фонд. 644 архив. 5—6 кәгазьләр.

[5] Кайбер тарихчылар Г. Бурнашев дип язалар.

# Мәңге яшь талант

Менә ул мәйдан уртасына чыга һәм, тынлык урнашкач, акрын гына сөйли башлый:

**Ия төшеп башын,**
**Керт-керт итеп басып,**
**Нәни генә матур**
**Чиләкләрен асып,**

**Кара, кара, кара!**
**Сара кайтып бара,**
**Судан кайтып бара,**
**Безнең җитез Сара!**

**Көянтәсе чуар,**
**Чиләге дә чуар,**
**Чуар чиләгендә**
**Көмеш кебек су бар...**

Чирәм-паласта утыручы әти-әниләренең, әби-бабаларының кочакларына сыенган тиктормас октябрятлар бу абыйның сүзләрен йотлыгып тыңлыйлар. Тик аратирә алар, үзләре дә сизмәстән, кычкырып җибәрәләр, яисә гөж килеп кул чаба башлыйлар.

Шагыйрьнең көр авазы үсә бара:



**Котлап әнием бәйрәмен**
**Мин челтәрләр бәйләдем,**
**Үскәч әле, матур итеп,**
**Мамык шәлләр бәйләрмен.**

. . . . . . .

**Бүген дә тик йөрмәдем:**
**Үтүкләдем керләрен,**
**Үтүкләп куйдым бәйрәмгә**
**Кия торган күлмәген...**

**Коймакларымны майладым,**
**Самоварым кайнады.**
**Әни кайткач нишләр инде,**
**Аңа эш тә калмады, —**

дип, һич тә көтелмәгәнчә күңелле нәтиҗә ясап куя.

— Тагын... тагын сөйләгез... — диләр аңа. Менә шагыйрь үзенең тыңлаучыларын табигать кочагына, нарат урманы уртасындагы Зәңгәр күлгә алып килә:

**Суы чиста: топ-тонык,**
**Гөлгә кунган чык кебек,**
**Шундый тонык: күренә төбе,**
**Анда су да юк кебек.**

**Җем-җем итеп җемелди**
**Якты кояшлы көндә,**
**Ак таңкәләр, таш тәтиләр**
**Күренеп ята төбендә...**

Лагерь үзе дә тып-тын хәзер. Бал кортларының безелдәп очулары ишетелеп китә. Шагыйрь, пионерлар арасындагы яшүсмер вожатыйларның уйчан йөзләрен күреп-терме, кинәт икенче дулкынга күчә:

**Зәп-зәңгәр төн. Зәңгәр күл өстендә**
**Аккош кебек йөзә бер көймә.**
**Әллә кылга, әллә күлгә чиртеп**
**Кемдер уйный моңлы бер көйгә...**

Шагыйрь, тыңлаучыларның хисләрен шулай иркәләп ала да, тагын үзенекенә кайта:

**Ике карчык гәпләшәләр тышта,**
**Берсе әби, берсе бабушка...**
**Берсе оек, берсе чулок тоткан,**
**Икәүсе дә оста бик эшкә.**

**Дуслар да бик. Пирог пешкән көнне**
**Әбине дә дәшә бабушка.**
**Бәлеш пешкән көнне бабушканы**
**Әби дәшми калмый бәлешкә...**

Ул сөйли дә сөйли, ә без, пионерлар лагерена очрашуга килгән балалар язучылары, әле үзебезгә дә сөйләргә кирәклеген онытып, барча тыңлаучылар кебек үк:

— Тагын... тагын сөйләгез... — дип кабатлыйбыз.

Шагыйрь Бари Рәхмәт турында язарга утыргач, моннан ун ел чамасы элек булган менә шул вакыйга искә төште. Татар совет балалар әдәбиятында ул үзенә аерым бер урын алып тора. Аның гаять үзенчәлекле, шуңар күрә мин әйтер идем — тылсымлы шигырьләре дөньяга һәм тормышка сабыйларча гаҗәпләнеп карауга, көр күңеллелеккә, тапкырлыкка, шатлыклы юморга һәм телебезнең мөмкинлекләреннән гаҗәп оста файдалана белүгә корылганнар.

«Балалар язучысы булып туарга кирәк», дигән иде Виссарион Белинский. Бари Рәхмәт моны бөтен иҗаты белән исбат иткән зур талант. Аның әле революциягә кадәр язылган беренче шигырьләрендә үк менә мондый сабыйларча ачышлар бар иде:

**Эш күп икәнлеген белгән күк,**
**Җәй көне таң ата төннән үк.**

**(«Кадерле вакыт», 1916 ел.)**

Ләкин Октябрь революциясенә кадәр чыккан журнал «Ак юл»ның егерме ай чамасы гына яшәп, 1916 елда бөтенләйгә ябылуы, күрәсең, Бари Рәхмәтнең күңелен шактый төшергәндер. Бары тик егерменче елларда гына «Кызыл Армия» газетасында аның зурлар өчен шигырьләре күренә башлый. Ул күп төрле темаларга байтак кына әсәрләр иҗат итә. Әмма аларның берсендә дә шагыйрьнең үз авазы ишетелми әле. Шуңа күрә булса кирәк, ул шактый озак вакыт язудан туктап тора. Ниһаять, күп эзләнүләр, тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе аны яңадан балалар әдәбиятына китерә: 1949 елда «Укыйсым килә» һәм «Кем көчле» исемле беренче китаплары басылып чыга. Шуннан соң ул нәниләр өчен язуны ешайта. «Зәңгәр күл», «Туган илдә», «Нәниләр китабы», «Бакчада күңелле», «Сабан туенда», «Безнең җәй», «Кыш бабай», «Ялкау, иренчәк һәм кире», «Иң күңелле чак», «Шигырьләр», «Курчак батыр» исемле күңелле китаплар иҗат итә һәм ул балаларыбызның иң сөекле язучысы булып китә.

Менә шулай гаять зур энергия белән, нәкъ балаларча дәртләнеп язганда, шигъри осталыгы тәмам чәчәк атып җиткәндә, алтмыш яшь туларга өч кенә көн калгач, Бари Рәхмәтнең кинәт үлеп китүе бөтен әдәбиятыбыз өчен зур кайгы булды.

Бари Рәхмәт Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы барган көннәрдә, сәхнәгә чыгып халык алдында гаять зур уңыш белән үзенең шигырьләрен сөйләгән чакта, вафат булды. Аның күңелле поэзиясе, бәхет йолдызыдай, укучыларга шатлык чыганагы булып, әдәбият күгебездә мәңге балкып торыр.

**Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ.**

# Төрлесеннән

*Срур Сүнчәләй*

# КАРГАЛЫДА ТАТАР ТУЕ

Туй дигән нәрсә ул егет өйләндерү һәм кыз бирүгә бәйләнгән бик борыннан килгән халык йоласы. Элек туй ясамыйча егет белән кызны кушмаганнар. Туй ата-ана өчен дә, өйләнешкән яшьләр өчен дә зарури бер бәйрәм-тантана булган. Шушы туйдан егет белән кызның бергәләп тора башлаулары, семья корулары, гомер итүләре башланып киткән. Һәм бу туй тантанасы һәркемнең йөрәгендә, картайган көненә кадәр, онытылмас матур бер хатирә булып сакланган.

Ләкин туйлар, иле-ягына карап, электән килгән гореф-гадәтләргә бәйләнеп, төрле җирдә төрлечәрәк узган. Биредә исә сүз элекке Уфа губернасы (хәзерге Башкортстандагы) Яңа Каргалы [1] авылында үткәрелә торган туй тәртипләре турында барачак. Каргалы туйларының, билгеле, үзләренә генә хас яклары бар. Иң элек шуны әйтергә кирәк, бу авылда яшәүче кешеләр 18 гасырның ахырларында Тамбов губернасыннан Башкортстан җиренә килеп утыралар. Аларның тамырлары бик ерактан башлана, алар кайчандыр Алтын урда заманнарында гаскәри хезмәт кешеләре булалар һәм билгеле бер өстенлек (привилегия) белән файдаланалар. Ләкин соңыннан, Казан ханлыгы бетерелгәч, гади крестьяннарга әйләнеп калалар. Шулай да алар үзләренең борыннан килгән ыру традицияләрен нык саклыйлар һәм бу нәрсә аларның туйларында да ачык чагыла. Мәсәлән, Каргалы кешеләре баштарак читтән кыз алмыйлар, читкә кыз бирмиләр иде. Тик күп еллар узгач кына алар, бу традицияне бозып, тирә-як авылның исемлерәк кешеләре белән туганлаша башлыйлар. Гадәттә алар кыз биргәндә яки кыз алганда, туганлаша торган кешенең байлыгыннан бигрәк, аның нәсел затын тикшерәләр. Кеше халык арасында яхшы исәптә йөриме, акылы-әхлагы ничек, көнкүреше бөтенме, — башлыча менә шулар белән кызыксыналар. Аннары алар егетне бик иртә өйләндерергә яки кызны бик яшьли бирергә дә ашыкмаганнар. Шулай ук кыз баланы яратмаган кешесенә бервакытта да көчләп бирмәгәннәр.

Инде туйның үзенә күчик.

## Киңәш салмасы

Ир баласы үсеп җиткән ата-ана башта үзара киңәш коралар. Гадәттә сүзне бу турыда ана кеше башлый: «Картым, улыбызны башлы-күзле итәр вакыт җитте, әллә быел кузгалабызмы?» — ди. Әгәр картының хуҗалык хәлләре шушы елда туй күтәрерлек булмаса, ул быелга сабыр итеп торырга кирәк, дип әйтә. Инде хәле җитәрлек

[1] Оренбург Каргалысы белән бутамас өчен бу авылны «Бәләкәй Каргалысы» дип тә йөрткәннәр.

булса, ризалыгын белдереп, кем кызын сорау турында сүз ача. Шушы хакта алар бер генә түгел, берничә тапкыр үзара сөйләшеп алалар. Ана кеше кемнәрдә җиткән кызлар барын белеп тора һәм аның күз тотыбрак торганы да булырга мөмкин.

Ләкин кыз сайлау һәм туй ясау мәсьәләсе ике арада гына хәл ителеп бетми. Моның өчен якын туганнарны чакырып, бер киңәш мәҗлесе уздыралар. Бу, бердән, туганнар фикере белән хисаплашу йөзеннән эшләнсә, икенчедән, аларның туйга катнаша алуларын белү өчен дә кирәк була. Чөнки зур туйны якын туганнар да күтәрешергә тиеш. Менә шул мәҗлес «Киңәш салмасы» дип атала. Шушы мәҗлестә инде кемнең кызын сорап карау мәсьәләсе тәмам хәл ителә һәм туган тиешле берәр олырак, дәрәҗәлерәк кеше башкода итеп билгеләнә.

Башкода гадәттә, җибәрүче кешенең атын җигеп, кыз өенә бара. Башкода килү инде кызның ата-анасы өчен зур вакыйга: кызларын рәсми рәвештә кемгәдер сорау дигән сүз. Шуңа күрә башкода килүе кыз ягы өчен бөтенләй көтелмәгән вакыйга булырга тиеш түгел.

## Сүз салу

Менә шуның өчен дә башкода җибәрер алдыннан кыз ягына сүз салу, икенче төрле итеп әйтсәк, аларның кылларын тартып карау була. Бу эш егет ягыннан берәр хатын-кыз өстенә йөкләнә. Ул кызның анасын җае белән туры китереп бик сакланып кына: «Сезгә фәлән кешеләр ниятләп торалар», дигән мәгънәдәрәк сүз сала. Бу үзенә күрә нечкә эш. Шул сәбәпле кызның әнисе дә серен ачып бетермичә бик әдәп белән генә: «Рәхим итсеннәр, ризык эшен белеп булмый», дигән рәвештәрәк җавап кайтара.

Шулай итеп кыз ягы башкода киләсен алдан белеп тора, аны әзерләнебрәк көтәләр.

## Башкода

Беренче килүендә ул яучы итеп җибәрүчеләрнең сәламнәрен тапшыра, хәл-әхвәл сораша, изге теләкләрен белдерә һәм килүнең максатын сак, ихлас сүзләр белән әйбәтләп кенә аңлата. Ул, мәсәлән, «кызыгызны сорарга килдем», дип әйтми, ә «аманәтегезне фәләннәргә тапшырмассызмы», дигән төслерәк итеп әйтә. Чынлап та Каргалыда буй җиткән кызларны кемгәдер тапшырылачак аманәт итеп карыйлар иде. «Җиткән кыз ул — аманәт» яки «җиткән кыз ата йортында кунак кына», дип әйтә торганнар иде.

Хуҗалар, ягъни кызның әти-әнисе, сәлам өчен рәхмәтләрен белдереп, башкодание яхшы гына чәйләп, озак кына сөйләшкәннән соң, «уйлашырбыз», дигән сүзне әйтеп һәм сәлам әйтергә кушып, озаталар. Башкода яңадан кайчан киләсен билгеләп китә. Гадәттә күбрәк атна кич көнен (пәнҗешәмбе көнне) сайлыйлар.

Башкоданың икенче килүенә инде кызның әти-әнисе әйтер сүзләрен әзерләп торалар. Әгәр бирмәскә булсалар: «Кызыбыз яшь әле, быелга сабыр итәбез», дигән кебек сәбәп табып, җайлап кына башкоданы кире боралар. Инде бирергә булсалар, моны аңлатыр өчен, «ил йоласы» дип, әдәп белән генә мәһәр турында сүз ачалар. Үзләре тарафыннан күпме нәрсә салачакларын әйтәләр.

Башкода кайтып шуларны егет ягына җиткерә. Анда киңәшәләр, уйлашалар. Егет ягы мәһәргә күнсә, башкода өченче баруында «вәгъдә» алып кайта.

Кайчак егет ягы мәһәрне киметүне сорый. Яучы берничә мәртәбә бара. (Мондый чакта авылда: «Мәһәргә күнмәгәннәр», дигән сүз дә тарала.) Ләкин шулай да мәһәр өчен генә эшне бозмыйлар, ничек тә килешәләр. Гомумән мәһәр турында сөйләшкәндә ат сатулашкан кебек сатулашмыйлар. Барысы да тыныч, тату эшләнә. Монда башкоданың да роле бик зур: димче буларак ул үзенең акыллы киңәше, тәмле сүзе белән һәр ике якны көйләргә, килештерергә тырыша.

Тагын шуны өстәп әйтергә кирәк: башкода йөрү дәверендә кызның ата-аналары егет ягын һәрьяклап тикшерәләр. Хәлле кешеләрме, бала-чагалары бик ишле түгелмә

(чөнки кыз ишле семьяга беренче килен булып барса, аның өстенә эш-мәшәкать күп төшәчәк), кайната-кайнана буласы кешеләрнең холыклары ничек, башка якыннары ниндирәк кешеләр, — менә болар барысы да исәпкә алына. Иң мөһиме: ипле һәм төпле кешеләр булсын. Менә шуннан чыгып, кайчагында ярлы гына егеткә яхшы тормышлы кешенең кызын биргән кебек, ярлы гына семьяның кызын хәлле йортка да алалар иде. Ягъни, «ару суны читкә түкмиләр».

Аңлатма: Мәһәр — кыз аталары ягыннан егет ягына йөкләнә торган салым. Аны «мәһәр салу» дип йөртәләр. Мәһәргә, туйны күтәрү өчен кирәк булган нәрсәләр белән бергә, кызның киләчәк тормышы өчен кирәкле әйберләр дә керә. Әйтик, кызга 4—5 күлмәклек,ука белән әйләндергән бәрхет камзол, тун яки бишмәт, шәл (кышкы яки җәйге), бөркәнчек, шәлъяулык, укалы калфак, читек-ката, түшәк, ястык, юрган, сандык; туй расходлары өчен 30—50 сум акча, ярты пот бал, бер кадак чәй, куш каз, күпмедер ит-май... Билгеле, бу бик чама белән генә әйтелгән урта хәлле кешеләрнең мәһәре, моңа егетнең кыз куенына кергән чакта илтә торган бүләкләре керми.

## Егет, кыз арасы

Ата-аналар киңәшеп, башкода җибәреп шундый зур эш башлаганда, егет белән кыз берни белми торалармы? Юк, алар үз тирәләрендәге хәрәкәтне сизәләр. Сизү генә түгел, егетнең, башкода җибәргәнче, теләге дә билгеле була. Аның ризалыгын алмыйча торып эшне башламыйлар. Кыз белән ата-ана арасында исә мондый ачык сөйләшү булмый. Кызга сиздерәләр, ләкин ризалыгын турыдан-туры сорамыйлар. Әгәр кыз дәшмәсә, шул риза санала. Инде риза түгел икән, ул якын җиңгәсе яки апасы аша әнисенә «бирмәсеннәр» дигән сүзне ишеттерә. Һәм шушы бер сүз җитә: кызны көчләп бирмиләр.

Әмма егет белән кыз бер-берсен күреп беләләрме соң? Дөрес, ул ерак заманда егетләр белән кызларның ачыктан-ачык танышып, күрешеп йөрүләре булмаган. Ләкин бер авылда яшәгәч, алар бер-берсен күрмичә дә тормаганнар. Егетләр, кызлар кич утырганда, тәрәзәгә йөриләр, каз өмәләрендә яки тау уеннарында якыннанрак күзәтәләр, кыскасы, өйләнәчәк егет белән чыгачак кыз күпме-азмы бер-берсен күргән-белгән булалар.

Хәтта мондый хәл дә була: бер егетне читтән өйләндерергә уйлагач, башкода җибәрер алдыннан егет ат менеп, кырык чакрымдагы авылга төн эчендә барып, кызны тәрәзәдән генә күзләп тә кайта.

Башкода килеп, ике арада вәгъдәләшү булганын әйттек инде. Моны кызны ярәшеп куюу диләр. Ярәшелгәннән соң кыз әти-әнисе күзенә, бигрәк тә атасына, күренергә ояла. Мондый чакта аны берәр якыны үзенә кунакка алып китә. Кияү буласы егет, кызның кемдә кунакта утырганын белеп, төннәрен шул өйнең тәрәзәсенә барып йөри. Зур тыйнаклык белән ул буласы каләшен күзәтә һәм үзе дә аңа күренә. Шуның белән ул үзенең кызны бик яратып, бик теләп өйләнергә йөрүен белдерә. Җае килсә, акрен генә җырлап та бирә:

Карлыганнан кара күз генән,
Бөрлегәннән нурлы йөз генәң,
Бөрлегәннән нурлы йөзләреңне
Күреп туймый ике күз генәм.

Кыз, үз нәүбәтендә, пәрдә төшереп качмаса да, тыйнаксыз булып күренмәс өчен, егеткә игътибарын ачыктан-ачык белдермәскә тырыша. Ул нинди генә хәлдә дә үзенең кыз горурлыгын, кыз оялчанлыгын саклый. Дөресен әйтергә кирәк, заманында Каргалы кызлары арасында бу горур тыйнаклык, бу гыйффәтле оялчанлык бик көчле иде.

Әлбәттә, егетнең өйгә, кыз янына, керүе турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Әнә шулай күләгә төсле тәрәзәдән генә күренеп һәм ярәшелгән кызын ут яктысында гына күреп китә ул. Әгәр тәрәзәгә килмәсә — бу бик зур игътибарсызлыктан, монсытлыктан санала.

## Билге

Билге дип сүз куешканнан соң кыз ягыннан егетнең ата-анасына бирелә торган бүләккә әйтәләр. (Авылда: «Сүз куешканнар, билгегә баралар икән», дип сөйлиләр.) Бу вагъдә билгесен бирү ике якның туганлашып китүен күрсәтү һәм ныгыту өчен эшләнә. Билгене алырга башкода һәм төп кода (егетнең атасы) хатыннары белән парлап баралар. Билге бирнәсе итеп кодага күлмәк яки чиккән намазлык, кодагыйга яулык яки шәлъяулык, башкодага тастымал, аның хатынына яулык куялар. Кияү өчен перчатка биреп җибәрәләр.

Билге алышканнан соң ике семья туйга чаклы гомумән йөрешмиләр, ашка-фәләнгә чакырышмыйлар. Эчтән генә кардәшлек җылысын саклап, очрашканда үзләрен ярым рәсми рәвештә тоталар.

## Яраш туе

Билге алганнан соң, егет ягы яраш туй үткәрүне сорый. Гадәттә яраш туй хәлле кешеләр арасында гына була. Бер сыйланып, бал эчеп, яңадан бер туганлыкныраслау өчен эшләнә.

Кыз ягы кайчак яраш туен үткәрергә теләр-теләмәс кенә ризалыгын бирә, чөнки «яраш туй — ярты туй» диган сүз. Тагын бирнәләр бирергә кирәк, якын туганнар катнашы белән аш-су кузгатырга кирәк, — расходы, мәшәкате күп була. Ләкин бу сатулашып эшләнә торган эш түгел, егет ягы сорагач, туйны барыбер ясамыйча калмыйлар.

Яраш туена башкода хатыны белән, төп кода белән кодагый һәм аларның якын бер туганы ялгызы гына килә.

Аларга яраш туй бирнәләре итеп кода белән кодагыйга бирәр күлмәклек, башкодага күлмәк, хатынына яулык, ялгыз кодага тастымал бирәләр. Кияүгә тапшырыр өчен куш күлмәк-ыштан, ике тастымал куялар һәм бу бирнәләрнең барысын да зур ашъяулыкка төреп биреп җибәрәләр.

Яраш туйны да кыз ягы, зур туй кебек итеп, якын агай-энеләре белән бергәләп күтәрә. Төп йортта, баллар әчетеп, зур мәҗлес үткәрелә, аннары агай-энесе кодаларны чиратлап ашка йөртәләр.

Инде ике гаилә арасында кодалашу дәвере үтте — билге дә бирелде, яраш туй да үткәрелде. Хәзер зур туйга әзерләнергә кирәк. Каргалыда зур туй бернichә айдан, хәтта бер елдан соң була. Шул вакыт эчендә егет ягы мәһәргә кирәген нәрсәләрне хәстәрли, ә кыз ягы кызның приданын тәгалләүне ашыктыра.

## Кыз тирәсе

Кыз баланың приданын бик иртә әзерли башлыйлар. Ул заманда бөтен нәрсә диярлек һәр өйдә кулдан эшләнгән. Кызлар үз куллары белән йонын язганнар, җебен эрләгәннәр, киндерен сукканнар, агартканнар, манганнар, чиккәннәр, тегкәннәр... Кызның бөтенлеге барысыннан элек әнисенең һәм үзенең уңганлыгына, хәстәрлегенә бик нык бәйләнгән. Шуңа күрә кыз бала 14—15 яшеннән стан артына киндер сугарга утыра торган була.

Кыз тирәсе дигәнебез — әнә шул үзенең приданы өчен әзерләнгән әйберләре инде. Моңа түбәндәге нәрсәләр керә (сүз урта хәлле кешенең кызы турында бара): кунак өен бизәр өчен киң кылычта гарыслап суккан озын кашага, чүпләм сөлгеләр, кендәлек бит сөрткеч тастымаллар, аяк тастымаллары, түр өйне икегә бүләрлек зур чүпләм чаршау, тагын бер шакмаклап суккан кечерәк чаршау, зур сәкенең бер башыннан икенче башына җитәрлек көреле чүпләм һәм шакмаклап суккан ашъяулыклар, өй бизәр өчен тотыла торган чиккән ашъяулыклар, тагын көн дә җаяр өчен вак ашъяулыклар (40 тастымал, 30 ашъяулык белән киткән кызлар була иде), аннары кыз

урыны өчен чиккән япма, чиккән мендәр тышлары, киндердән түшәк-ястык суруләре (ястык тышы ситсадан яки сатиннан тегелә), шакмаклап суккан түшәк җәймәләре, кунаклар алдына сузып сала торган озын салфеткалар, читен каймалап суккан вак салфеткалар, аслап тегелгән, сатинга чиккән намазлыклар һәм бер ак киез белән үзләре суккан бизәкле йон палас. Болар өстенә сатып алынган ак яки җиз самовар белән поднос, җиз таз белән җиз комган һәм аш, чәй савыт-сабалары, шуларның барысы янына тагын яшел сандык. Ул замандагы тормышта сандык иң кирәкле йорт җиһазыннан санала иде. Кызның бөтен әзерләгән әйберләре шул сандыкка җыела бара, шул сандыкта саклана, һәм шул сандык кыз артыннан ияреп тә китә.

Ләкин кызның әзерләгән нәрсәләре болар белән генә бетми әле. Югарыда без «билге» һәм «яраш туй» вакытында кодаларга бирелгән, кияүгә җибәрелгән бүләкләрне күрдек инде. Ә зур туй вакытында күпме килен бирнәсе өләшеначәк! Кияү егетләренә йон перчаткалар, оеклар, бияләйләр, әбиләргә күкрәкчәләр, су юлын күрсәтүче кызларга яулыклар, кульяулыклар, хәтта җәймә ертучы малайга бирелә торган бияләйгә чаклы барысы да алдан исәпләнеп, әзерләнеп куела... «Киткән кыздан кисәү агачы да курка», ди халык. Ягъни ул, бу кыз мине дә алып китмәгәе, дип куркып тора имеш!

Әлбәттә, бу чаклы әйберне җитештерү-әзерләү гаять күп көч һәм вакыт сорый. Шуңа күрә җиткән кызны өй эшләреннән ничек тә бушатырга тырышалар. Ул, бичара, кыш буе җеп эрли, яз башыннан печәнгә чаклы станда киндер суга, кунакка барган җиреңдә чигү чигә, озын кичләр утырып һаман ни дә булса бәйли, тегә... Әнә шулай әзерләнә китәсе кызның приданы.

Ярәшелгән кызның хәле тагы да катлаулырак. Эше-мәшәкате никадәр күп булса да, ул һаман «килер әле» дигән өмет белән төн йокламыйча егетен көтә. Ике яшьнең йөрәкләре кузгалган, уйлары-күңелләре белән бер-берсенә омтылып кына торалар. Егет тә кыз тәрәзәсе төбенә барып бер әйләнмичә тыныч йоклый алмый. Кышкы төн булса, егет әтәчләр кычкырганчы, туңып беткәнче тәрәзә төбендә «әйләнә». Бер-берсенең шәүләләрен генә күреп калсалар да, алар шат, алар бәхетле.

Күрешү, сөйләшү мөмкин булмаса да, алар арасында элемтә җепләре сузыла. Егет вакыт-вакыт кызга кучтәнәч, бүләк китерә. Кыз да әзерләп куйган перчаткасын, чиккән кульяулыгын, берәр төрле тәмле ашын (мәсәлән, чәкчәген) егеткә чыгара. Бу алыш-биреште гадәттә кыз ягыннан берәр якын җиңгәсе яки сеңелесе башкара. Тәрәзә аша ымлашканнан соң, уңган җиңгәсе тиз генә чыгып, кызның бүләген тапшыра һәм егетнең кайнар сәламе белән бергә хуш исле сабынын, конфет-перәннекләрен ала керә.

Әгәр никах туена вакыт ерак булса, кыз ягы егет йортына кучтәнәч җибәрә. Аны да якын туганнардан берәр хатын-кыз илтеп тапшыра. Егет ягы кучтәнәч китерүчене бик әйбәтләп сыйлап, алып килгән ашъяулыгына бүләкләр төреп озата.

## Срок (вакыт билгеләү) туе

«Башланган эш — беткән эш», ди мәкаль. Инде ярәшелгән кыз белән егетне никахлап, зур туй ясап кушарга кирәк. Моның өчен егет ягыннан шул ук башкода, кыз ягына барып, срок туе үткәрүне сорый. Срок дигән сүз — зур туйның көнен билгеләү дигән сүз. Менә шушы көнне билгеләү өчен махсус очрашу үткәрелә.

Срок туена егет ягы вәгъдә иткән мәһәрен китерә һәм килешенгән акчасын тапшыра. Мәһәр тамам әзер булмыйча торып, срок туе үткәрелми. Бу туйга егет ягыннан ике-өч пар кунак катнаша. Төп кода зур аш-сый белән килә.

Шушы очрашу вакытында, әйткәнебезчә, зур туйның көне билгеләнә. Аннары ике яктан да зур туйга ничәшәр пар кода катнашуы турында сөйләшү була. Бу үзенә күрә шактый мөһим мәсьәлә, чөнки ике яктан да туйга катнашучылар туйны күтәрешергә дә тиешләр.

Егет ягыннан туйга баручылар — «кодалар» дип, ә кыз ягыннан озата килүчеләр — «җиңгәләр» дип атала. Әлбәттә, алар барысы да парлы-парлы була (кызны озатучылар: «Җиңгәли бардык», дип сөйлиләр). Ике яктан да катнашучыларның саны тигез булырга тиеш.

Шулай итеп срок куела, ягъни зур туйның көне тагаен билгеләнә. Хәзер инде кыз йортында кызу эш башлана. Хәер, кыз йортында гына түгел, туйны күтәрүче якын агай-эненең өйләрендә дә шул ук хәл: мичкә-мичкә бал куела, сарык-тәкәләр суела, казылыклар тутырыла. Туй күтәрү уен эш түгел. «Туй — ике атыңның берсен суй», диләр абзыйлар. Шулай булса да туйны бик яхшы әзерләнеп, теләп, көтеп каршы алалар. Һәркемнең туе авыл эчендә зур вакыйга, шатлыклы бер бәйрәм булып санала.

## Ястыкчылар

Срок туе үтү белән кыз өенә «ястыкчылар» җыелалар. Болар — китәсе кызның ахирәтләре һәм якын туганнарының кызлары. Алар кызга булышалар, кызның әйберләрен өлгертешәләр. Чаршавын, түшәк-ястыгын, мендәрләрен, кием-салымнарын әзерләп куялар, кияүгә диган күлмәк-ыштаннарны, кода белән кодагыйга дигән күлмәкләрне тегәләр, өләшенәчәк бирнәләрне дә әзерләшәләр. Кыскасы, килен булачак кызны ястыкка илтеп җиткергәнче гел аның янында булып, аңа ярдәмләшеп торалар. Шуңа күрә аларны «ястыкчы кызлар» дип атыйлар да.

## Чыбылдыкка һәм чәкчәккә чакыру

Туйга берничә генә көн калгач, кызлар белән яшь киленнәрне чыбылдыкка чакыралар. Бу — күмәкләшеп чыбылдык тегү. Олырак хатыннар чыбылдыкны кисәләр, яшь киленнәр һәм ястыкчы кызлар аны тегәләр.

Шул ук көнне кыз чәкчәге дә пешерелә. Ата-анасы тигез ике уңган кызга чәкчәк камырын басарга кушалар. Алар икесе берьюлы, бер үк вакытта йомыркаларны бер савытка сугып сыталар, икесе кашыкларын кара-каршы йөртеп кабарталар, аннары камырны икәүләп дүрт кулдан басалар. (Болай эшләтү булачак семьяга бердәмлек, татулык теләү өчен, имеш.)

Камыр әзер булгач, аны берничә кыз уа, берничә кыз кисә, ә бер-ике хатын казан янында пешереп тора. Пешкән чәкчәкне подноска баллап катыралар, өстен төрле монпаси белән бизиләр.

Бу чәкчәк, башка туй ашлары белән бергә, кыз артыннан бара. Аны корбан көнне килен чәкчәге итеп табынга чыгаралар. Бу зур чәкчәктән башка тагын бер кечерәк чәкчәк тә ясап катыралар. Бусы килен төшкән көннең иртәсендә, ягъни әйбер чыккан көнне, беренче чәйгә, кыз балы белән бергә, кыз чәкчәге итеп куела.

Кайсыбер туйларда зур чәкчәкне җиләк кагына төреп илтәләр. Бу инде кызның уңганлыгын һәм анисенең тырышлыгын күрсәтә торган нәрсә һәм моны туй кунаклары күрмичә, мактап үтмичә калмыйлар.

## Катлама пешерү

Кыз ягында чәкчәккә җыелсалар, егет ягында «катлама» га җыелалар. Шулай ук җиткән кызлар, яшь киленнәрне чакырып, катлама пешерәләр. («Катлама» дигәннәре чәкчәк камыры кебек үк йомыркага баскан камырны җәймә итеп җәйгәннән соң, тасма-тасма сырлап кисеп һәм урап, кызган майда пешерелгән нәрсә була.)

Бу катламаларны махсус тартмага салып, туй ашлары белән бергә кыз йортына илтәләр. Аннары төп кодагыйны (егет анасын) никах тыңларга килеп алалар. Ул кызны озата киләчәк һәрбер җиңгә башына берәр бөккән (ачы камырдан уртасына тәмле әйбер кыстырып пешерелгән ашамлык) өстенә катлама куеп алып бара. Никахтан соң кодагый кайтып китә.

Катламага килгән кызлар, эшләре бетәрәк, яшерен генә камыр ясап, шуның белән егет анасын, егетнең үзен һәм бер-берсен буяшалар. Янәсе, килен ягымлы булсын. Шулай итеп бер шау-гәр килеп, шаярып-уйнап алалар.

Аннары, беренче катламаларны казанга салган чакта, егет анасын биетәләр. Монысының да ырымы бар: катламалар уңышлы пешсен һәм килен дә уңган булып чыксын!

Чыбылдыкка, чакчакка, шулай ук катламага җыюлар барысы да туй тәртипләренә керә. Болар зарури рәвештә үткәрелә торган туй низамнары.

Туйга әзерләнүнең мәшәкатен санап бетереп булмый. Күпме азык-төлек әзерләнә, күпме ашлар пешерелә. Шуның өстенә кыз йортында кызны әзерләсәләр, егет йортында кияүне әзерлиләр. Анда да баштанаяк киендерәләр. Кода белән кодагый да үзләренә яңа күлмәкләр, бишмәтләр, туннар тектерәләр. «Туй сылтавы белән тун беткән» [1], ди мәкаль.

## Кыз төшерү

Кияү керәсе урынны аерым йортта, җәй булса, ак келәттә әзерләп куялар. Туй көнне шул урынга кызны бөтен әйберләре белән күчерәләр. Чыбылдык корылып, яшьләрнең урыны кабартылып куелган була. Менә шушы күчерүне «Кыз төшерү» [2] дип әйтәләр.

Кызның туып-үскән өеннән, әти-әнисеннән аерылуы әнә шул «төшү»дән башлана. Кыз күңеле тулып елый, ястыкчы кызлар да елашалар. Алар кызны киендереп, кияү куенына керергә әзерлиләр. Шул чакта махсус җырлар җырлыйлар — моны борын «кыз чыңлавы» дип әйтә торганнар иде. Бер генә җырын китерик:

Каргалыкай буе киртләч-киртләч,
Киртләчләре бетәр кар киткәч.
Ир балалар кайта хезмәт иткәч,
Кыз балалар кайтмый бер киткәч.

## Кияү егетләре

Кыз янында ястыкчылар булган шикелле, егет янында да кияү егетләре була. Алар кияүнең якын туганнарыннан, күбрәк, өйләнмәгән егетләр булалар. Алар туй киткәнче гел егет янында булып, аңа һәртөрле хезмәт күрсәтәләр, аннары кияүне кыз куенына озата баралар. Гомумән, туйда аларның күп ярдәмнәре тия. Кыз йортында кияү бүләкләрен күренешкә алар чыгаралар. Кияү йортында аш бирешеп, аш чыгарышып торалар. Җиңгә-кодаларны барып алалар һәм илтеп куялар. Мәҗлесләрне җырлап-биеп җанландыручылар да алар булалар.

## Туй көне

Бу көнне ике йорт та умарта күчедәй гүләп тора. Берсендә туйны каршы алырга якын кардәш-ыру, никах мәҗлесенә чакырылган кунаклар җыела. Капка төбендә — бала-чагалар.

Икенче йортның ишек алдына туйга баручыларның кыңгыраулар тагып, парлап җиккән атлары тула. Атларын кыргычлап, ялтыратып, ялларын тарап, таңкәле каеш сбруйлар белән җигәләр. Читән тарантасларның артларына салындырып палас җәяләр, кабартып мендәрләр салалар. Атлар башларын чайкаган саен, кыңгырау тавышлары чыңлап куя. Капка төбенә бала-чагалар, күрше-тирә җыела.

Менә кучерда утыручы егетләр атларын ишек төбенә китерәләр. Беренче атка башкода хатыны белән, икенче атка төп кода ялгызы менеп утыра. Башка кодалар, туганлык якынлыгына һәм яшьләренә карап, калган атларга утырышалар.

Туй кузгала. Атлар, капкадан чыгу белән, бик кызу чаптырып китәләр, авыл өстен кыңгырау тавышлары яңгыратып җибәрә. Иң арттан ялгыз ат җиккән аш арбасы чаба (безнең авылда соңга калып йөргән кешене «аш арбасы» дип көлеп әйтү да бар).

[1] Ләкин бу сүзнең асыл мәгънәсе бу очракта, минемчә, «бетүгә» түгел, ә «булдыруга» кайтып кала. Ягъни «тун бетертү», «йорт бетертү» — үл яңа-яхшы кием тектерү һәм яңа өй өлгертү дигән сүз булырга тиеш.

[2] Кыз төшерү — килен төшерү түгел әле. Килен төшерү дип кызны кияү үз

Капка, койма буйларына туйны карап калыр өчен хатын-кызлар, бала-чагалар йөгерешеп киләләр. Юлда очраган агайлар сәлам биреп, «Хәерле сәгатьтә!» дип калалар. Әнә шулай, бөтен халыкны аякка бастырып, бөтен авылны шаулатып туй китә.

Туй киткәндә, озатучылардан бер карт азан әйтеп кала. Аннары барысы да өйгә кереп чәй эчәләр дә үзләренә таралышалар. Кайбер хатыннар гына кодагый (егетнең әнисе) янында калып, аңа киенергә, әзерләнергә булышалар: тиздән аны никах тыңларга килеп алачаклар.

Шулай ук кияү дә, үзенең кияү егетләре белән, «никах укылды» дигән хәбәрне көтеп, өендә утыра. Кайчагында кияү туй белән бергә үк тә китә, ләкин, кагыйдә буларак, ул никах укылганнан соң гына барырга тиеш. Алар өчен иркен тарантаска бик чибәрләп җигелгән, кыңгыраулы тройка ишек төбендә әзер булып тора. Кияү егетләре кияүне урталарына утыртып алып китәләр.

Кыз йортында иң элек капка төбендәге бала-чагалар: «Туй килә... Туй килә!» дип шаулаша башлыйлар. Шул арада, инде берсе артыннан берсе выжлатып, пар атлар капкадан килеп тә керәләр. Атлар баскыч төбенә килеп туктый торалар, кода-кодагыйлар арбадан төшә баралар, кучерда утыручылар ишек алдын уратып, атларын кире алып китә торалар.

Кызның якыннарыннан: ирләр — кодаларны, хатыннар — кодачаларны: «Хуш килдегез, рәхим итегез!» дип, каршы алалар. Ишекләрне киң ачып, иң алдан төп коданы, аннан башкоданы уткәрәләр, алар артыннан, дәрәҗәләренә карап, калганнарын өйгә алып керәләр. Ирләрне ирләр ягына, хатыннарны — хатыннар ягына кертәләр. Ирләр хатыннар белән бергә утырмыйлар.

Кунаклар урнашып беткәч, никах уку башлана. Никахны укыр алдыннан, хәзрәт, кыздан ризалык сорар өчен, ике шаһит җибәрә. Алар кыз утырган җиргә барып, үзенә күренмичә генә, кычкырып: «Ризамы?» — дип сорыйлар. Кыз үз теле белән «риза» сүзен ишеттерә. Шаһитлар хәзрәт янына кайтып, кызның ризалыгын «әшһәде» дигән гарәп сүзе белән әйтергә тиешләр. (Кайчагында гарәпчә әйтә белмәгән шаһитлар көлке хәлгә дә калгалыйлар. Мәсәлән, бер шаһит «әшһәде» диясе урынга «дәшмәде, хәзрәт!» дип әйтеп ташлаган.)

Шаһитлар аркылы кызның ризалыгын алгач, хәзрәт әүвәл егет атасыннан: «Фәлән агай, улыгыз Фәләнгә, Фәлән агайның Фәлән исемле кызын хәләл җефетлеккә алдыгызмы?» — дип сорый. Егет атасы: «Алдым, хәзрәт», — дип җавап бирә. Аннары шул ук сорауны кыз атасына: «Бирдегезме?» — дип кабатлый. Кызның атасы да: «Бирдем, хәзрәт», — дип җавап кайтара. Шуннан соң гына никах укыла.

Әгәр кызның яки егетнең әтисе булмаса, «алдым-бирдемгә» ата урынына якын ага тиешле бер өлкән кеше утыра. Моны «алдым-бирдем»гә утыру диләр.

Никах укылу белән, махсус куелган кеше ат чаптырып барып, кияүгә хәбәр итә. Хәбәрне алгач та, кияү һәм кияү егетләре әзер җигүле тройкага утырып, кыз йортына китәләр. Алар кыз урнашкан өй яки келәт алдына килеп туктыйлар. Алдан бер кияү егете, аның артыннан кияү һәм башкалар тарантастан яшьләрчә җиңел генә сикерешеп төшәләр. Кияүнең кулында төрле бүләкләр салган кечкенә сандыгы була.

Аларны кызның якыннарыннан егетләр, яшь ирләр каршы ала. Кияү һәм кияү егетләре, шул төшкән тәртиптә кулга-кул тотынышып, ак келәткә керәләр. Анда кияү өчен баллар белән өстәл әзерләнгән була. Җитезрәк кияү шул арада чыбылдык эченә кереп, кәләше белән күрешеп тә чыга. Аннары өстәл тирәсенә утырышалар. Ләкин кияү бер тамчы да эчми. Кияүнең эчүе зур гаептән санала, чөнки изге эшне эчеп башларга ярамый.

Кыз урыны чаршау белән бүленеп куелган. Чаршау эчендәге яшьләр өчен әзерләнгән ятар урынга чыбылдык корылган. Кыз менә шул чыбылдык эчендә утырып тора.

Кияү егетләре бераз ашап-эчкәннән соң, кияүгә изге теләкләр теләп, чыгып китәләр. Кияү ялгыз гына кала. Табын караучы хатын да кияү белән кызга гына чәй әзерләп һәм саубуллашып чыгып китә. Кыз кияве янына чыга.

Бу вакытта ястыкчы кызлар, кияү атларына утырып, авылны әйләнәләр.

Кунак өендә никах мәҗлесе дәвам итә. Бу мәҗлес, билгеле, әнкәсез генә үтә. Төп йортның ашларын ашаганнан соң, туй белән килгән кода ашларын[1] чыгаралар. Бу ашларны зур подносларга өеп, күркәле итеп әүвәл олы табынга куялар. Олы табын кирәк кадәр генә алып кала да, башкасын поднослары белән кире кайтара. Шул ук килеш ашларны хатыннар табынына кертәләр, аннары кечерәк табыннарга бүлеп-бүлеп бирәләр. Кода ашын бераү дә авыз итмичә калмаска тиеш. Бу ашларны авыз иткәндә, һәркем яшьләргә бәхетле тормыш, тигез гомер тели.

Никах мәҗлесеннән соң, кода-кодачаларны кыз ягыннан туй күтәрүчеләрнең бернесе үзләренә кунакка алып китә. Ирләр бер йортка, хатыннар икенче йортка баралар. Бу мәҗлесләр инде әнке белән, җырлашып, күңел ачып утырулар белән уза. Шулай итеп, кодалар ике-өч көн буена кызны озата барачак җиңгәләрдә кунак булып йөриләр. Кодаларга кияү егетләре дә кушылалар. Ләкин алар һәр көнне иртәнге чәйгә кияү янына җыелалар.

Бу туй мәҗлесләрендә хуҗалар, хуҗаның якыннары аягүрә басып, мактау җырлары җырлап, кодаларны сыйлыйлар. Олылар алдында такмаклап җырлауны килештермәгәннәр, күбрәк озын көйләргә җырлаганнар:

Синең генә, кода, атларың,
Алдан җибәр җирән чаптарың.
Бәхетең бар, кода, дәүләтең бар,
Рәхәт кенә яшәр чакларың.

Кызыл гына төлке кырлар күрке,
Камчат та гына бүрек ир күрке.
Камчат та гына бүрек ирләр күрке —
Сез кодакайлар түр күрке.

Каргалыкай буе түтәл-түтәл,
Түтәленнән былбыл кош үтәр.
Бу дөньялар бездән үтәр китәр,
Тату яшәүләргә ни җитәр.

Ахырдан кушымтасын җырлап куялар:

Атлый-йөгерә килә күк юрга,
Хәерле гомер бирсен күп елга.
Атлап барыйк үрне менгәнче,
Ташлашмаек гүргә кергәнче.

Гомумән, бу мәҗлесләрдә бик матур көйләр (мәсәлән, башкорттан кергән «Ялан-яркәй», «Сибай», «Ашказар», шулай ук Каргалының үзендә чыккан «Шайсолтан» көйләре) һәм бик мәгънәле җырлар җырлана. Җырлашудан башка нара-каршы тапкыр, җор сүзләр әйтешүләр була.

Кыскасы, мәҗлесләр гаять җанлы, күңелле уза.

## Коймак чыгару

Беренче кичтән соң, иртән иртүк кияү белән кызны мунча кертәләр. Мунча махсус алар өчен бөтен шартын җиткереп, бик чиста итеп әзерләнгән була. Кияү белән кыз керәсе мунчаны бик саклыйлар. Бу эштә, ягъни яшьләргә һәртөрле хезмәт күрсәтү эшендә, кызның иң якыннарыннан тәҗрибәле бер хатын йөри. Кияү беренче кичнең урынына, беренче мунчага бүләкләр сала — болар барысы да шул хатынга тия.

Мунчадан соң кияү белән кыз үзләре генә ашап-эчеп алалар. Бераздан алар янына кияү егетләре киләләр. Яңадан чәй әзерләнә. Менә шул чәй табынына төп йортның килене булса — килене иссеннән, икенче җиткән кызлары булса — шул кыз

[1] Әлеге арбада килгән ашлар: дүрт күмәч, ике төче күмәч, катламалар, ике каз, казылыклар, сарык билдәмәсе.

исеменнән коймак белән бер чирек бал чыгарып куялар. Кияү һәм кияү егетләре коймакны капкалагач, бүләк итеп кәмеш таңкалар салалар.

Беренче коймактан соң, ястыкчы кызларның коймаклары чыга башлый. Һәр кызның исемен атап, бу Фәләннән дип куялар. Аларга да кәмеш таңкалар салалар. Шуның өстенә әле ястыкчы кызларга кияү, кәләш куенына кергәндә, сабын, исле май, көзге кебек бүләкләр дә өләшә.

Коймак чыгару икенче көнне дә кабатлана, чөнки барлык кызлар да коймакларын беренче көндә генә чыгарып бетерә алмыйлар.

## Күренеш

Туйның шул ук икенче көнендә кияүне кызның әти-әнисе һәм башка якын туганнары белән күрештерәләр. Моңа бик тантаналы төс бирелә.

Түр өйдә кызның әти-әнисе һәм якыннары «күренешкә утыралар». Кияү егетләрен иртәләп кияү керә. Ул бабасы һәм әбисе белән, кулларын үбеп, күрешә. Аларга беренче тапкыр «атакай» һәм «анакай» дип дәшә. Аннары кызның калган туганнары белән күрешеп чыга. Шуннан соң кияү егетләре поднос белән һәркемгә аерым-аерым күренеш бүләкләре чыгаралар. Кызның әти-әнисе, бүләкне алган чакта, үзләреннән, яшьләргә атап, сыер, сарык, тана кебек аяклы мал вәгъдә итәләр. Башкалар шунда ук бүләк өстенә акча салалар. Аннары картлар кияү белән кызга тату, бәхетле тормыш, тигез гомер, иминлек-саулык теләп дога кылалар.

Күренештән соң кияү яңадан кыз янына кайта. Кияү егетләре башка кодаларга ияреп ашка йөриләр. Кияү мәҗлесләргә йөрми, кыз янында гына сыйланып ята.

Кыз ягыннан туйны күтәрешүчеләргә кунак булып йөрү, ниһаять, тәмамлана. Кодалар һәм кодачалар төп йортка кайталар. Монда соңгы мәҗлес үткәрелә. Бу мәҗлес мул сый-хөрмәт һәм эчке белән бик җанлы уза. Кодалар күбрәк аерылышу җырларын җырлыйлар. Мәҗлес барышында башкода, мәсәлән, мондый җыр җырлап, кузгалыр сәгать җиткәнен белдерә:

Кикрикүк әтәч — күк әтәч
Кычкырыр да вакыт җитте инде.
Ашадык-эчтек, сәрхүш булдык,
Китәр вакытлар да җитте инде.

Шуннан башкода кыз атасына мөрәҗәгать итеп: «Фәлән кода, фатиханңы бир, җибәрәсе кешеләреңне әзерлә», ди. Кыз атасы кемнәрне җиңгә итеп җибәрәчәген, аларның әзер булуларын әйтеп бирә. Башкода: «Кабул итәбез, рәхим итсеннәр!» ди.

Шушы сөйләшүдән соң, кызмача кодалар, җырлаша-җырлаша, шау-гөр килеп, китәргә кузгалалар. Бу вакытта аларның кыңгыраулы пар атлары ишек төбенә килеп туктаган була.

Ниһаять, кызны кияү йортына озатуның соңгы әзерлекләре башлана. Кыз янына озата баручы җиңгәләр җыела, алар, берсеннән-берсе белдеклерәк булып, кызга төрле киңәшләрен бирәләр, үгетләрен әйтәләр.

## Кызның әти-әнисе белән саубуллашуы

Бераздан кияү яткан урынга ата-ана кереп, кызлары белән саубуллашалар. Хәердогаларын, изге теләкләрен әйтәләр. Кыз әтисе белән әнисенең кулларын үбеп саубуллаша. Барысы да елашалар.

Ата-ана саубуллашып чыгып киткәч тә, хатыннар кызның урынын җыеп төйниләр, кияү егетләре чыбылдыкны чишеп алалар. (Кияү йортына баргач, бу чыбылдыкны җиңгәләр яңадан корып куялар.)

Башкодадан кузгалырга әмер булгач, кодалар тезелеп торган атларга утырышалар.

Кызны чыгаруда аерым тәртип саклана: алдан кияү кызны җитәкләп чыгара, алар артыннан җиңгәләр тотынышып чыгалар. Келәт ишеге төбенә китергән тройкага кызны күтәреп утырталар, аның янына кияве утыра, кучерга кияү егетләре менәләр.

Ниһаять, кыңгырау тавышлары белән авылны яңгыратып, туй кузгала. Алдан башкода, аның артыннан төпкода, аларга калганнары ияләр. Кияү атлары арттан бара. Иң артта — кыз әйберләрен төягән арба.

Туй китте, азан әйтелде... Озатучылар өйгә кереп ашый-эчәләр дә хуҗаларга җылы, юату сүзләрен әйтеп таралышалар.

## Килен төшерү

Туй шау-гөр килеп кияү йортына барып керә. Кияү егетләренең берәрсе шулчакта мылтыктан атып җибәрә. Кияү атларын ишек төбенә китереп туктаталар. Киез җәйгән җиргә киленне бертуган агасы яки кияве күтәреп төшерә. Кызның бите шәл белән капланган, тик күзләре генә ачык калдырылган була.

Киленне тарантастан төшерүгә, кайнана алдан әзерләп куйган баллы суны аның өстенә бөркә. Моны «ширбәт сибү» диләр, һәм аның үз ырымы бар: килен ширбәт кебек һәркемгә ягымлы, сөйкемле булсын!

Шул ук вакытта кияү арбасыннан мичәүдәге атны тугарып, килен алдыннан үткәрәләр. Килен ат колагына сөлге элә. Бу сөлге өчен кияү егетләре тартышалар, кем җиңсә, сөлге шуңар була.

Шуннан соң кияү киленне җитәкләп алдан, алар артыннан җитәкләшкән җиңгәләр өйгә керәләр. Башта киленне казан янында туктаталар. Анда кияүнең сеңелләреннән ике кыз киленне баллы май белән каршы алалар. Иң элек кияү катлама кисәге белән баллы майны элэктереп, бер үзе каба, бер кәләшенә каптыра. Алардан соң шунда булган кияү егетләре, җиңгәләр майны кабалар.

Бу йоланы да үтәгәч, киленне казан яныннан махсус билгеләнгән урынга озаталар. Анда җиңгәли килгән хатыннар чыбылдыкны корып, киленнең урын-җирен җәеп куялар. Кияү егетләре кызның сандыгын һәм башка әйберләрен кертәләр.

Килен төште. Кодаларның урыннары алмашынды. Инде кызны җиңгәли озата килгән кодалар түргә менделәр. Кияү йортында беренче зур мәҗлес. Хуҗалар, аягүрә торып, җиңгәләрне җырлый-җырлый сыйлыйлар. Шундый ук мактау җырлары, уенкөлке, тапкыр-җор сүзләр.

Бу мәҗлестән соң, кияү ягыннан туй күтәрүчеләр җиңгәләрне үзләренә кунакка йөртәләр.

## Киленнең беренче иртәсе

Яшьләрне, бик иртә, кеше аягы кузгалганчы, мунча кертеп, чәй эчерәләр. Бу эшне кияү ягыннан бик ышанычлы берәр хатын үти.

Бу иртәдә кыз кияү куенына кергәндә кигән киемнәрен яшь килен киеменә алыштыра. Башына чәеп яулык бәйли, аның өстеннән бөркәнчек, бөркәнчек өстеннән шәл ябына, биленә альяпкыч бәйли. Бераздан килен төшкән җиргә егетнең әнисе, ягъни кайнана килә. Яшь килен аның белән чәгенеп, кулын үбеп күрешә. Бу — аларның беренче күрешүләре, кияү дә шунда була. Кайнана изге теләкләрен әйткәннән соң, яшьләрнең урыннарын котлап, урын өстенә борынгы тәңкәләр сала. Аннары киленне ияртеп, аш өенә алып китә.

Киленгә, беренче эш итеп, токмач басарга кушалар. Беренче җәймәне ир баладан ерттыралар. Килен балага бүләк итеп бияләй яки перчатка бирә.

Бу иртәдә яшь килен янында гел кыз-кыркын булып тора. Алар киленгә гаять ягымлылык күрсәтеп, һәр эшендә булышырга, һәр теләген үтәргә әзер торалар. Җыйнаулашып, киленгә «су юлы» күрсәтергә баралар. Килен аларның барысына да бүләк

## Әйбер чыгару

Шул ук көнне кияү йортына ике яктан да туйга катнашучы кодалар һәм җиңгәләр җыелалар. (Җиңгәләрне кияү белән кияү егетләре туй атларында барып алалар.) Җыелудан максат — кыз артыннан килгән әйберләрне (приданны) карау, шуңа күрә бу көнне «әйбер чыккан көн» дип йөртәләр.

Җиңгә хатыннар килү белән, кыз әйберләрен чыгара башлыйлар. Чаршавын коралар, сөлгеләрен озын бауга эләләр, ашъяулыкларын өстәлгә кат-кат җәяләр, чиккән намазлыкларын, озын салфеткаларын һәм бүтән барлык суккан-чиккән әйберләрен бер урынга өеп куялар. Кыскасы, киленнең үзе белән алып килгән бөтен нәрсәсе шунда матур, бай булып күренергә тиеш. Шуңа күрә аның самовар, поднос, савытсаба, таз-комган кебек җиһаз әйберләрен дә чыгарып куялар.

Җыелган туганнар һәм башка кунаклар бу әйберләрне бик дикъкать белән күздән кичерәләр. Чөнки яшь киленнең төзеклеге, хәстәрлеге шул чакта күренә. Шуңа чаклы кыз әйберләре сер булып саклана, алдан бу хакта шауламыйлар.

Әйберләрне караганнан соң, «килен чәе» әзерлиләр. Бу чәйгә җиңгәләр үзләре белән алып килгән күчтәнәчләрен куялар. Кызның кечерәк чәкчәген дә шушы чәйгә чыгаралар. (Зур чәкчәге «Корбан көн ашы» дип аталган соңгы мәҗлестә чыгарыла.)

Көннең калган вакытын җиңгә-кодалар кияү ягына чиратлап кунакка йөриләр. Һәр өйдә бал эчеп, җырлашып, күңел ачып утыралар. Биредә шуны әйтеп китәргә кирәк: Каргалыда туй мәҗлесләренә аракы чыгарылмый иде. Аракы булса да, аны яшьрәк кешеләргә, күрсәтмичә генә, чамалап эчерәләр. Өлкәннәр исә бары бал гына эчәләр, ә колмаклап куйган бал әчкелтем-татлы һәм бик үткер була. Гомумән, Каргалы туйларында бервакытта да аяктан егылганчы эчү юк, шуңа күрә ызгышу, сугышу кебек ямьсез күренешләр һич булмый иде.

## Кияү йортында икенче иртә—корбан көн

Бу көнне кияү йортында үткәрелә торган мәҗлес «Корбан ашы» дип йөртелә. Ни өчен «Корбан ашы»? Әйтүе читен, чөнки корбан-мазар чалуның булганы билгеле түгел.

«Корбан көн» мәҗлесе бик зур була, аңа туйга катнашкан һәм катнашмаган барлык кардәш-ыру, күрше-күлән чакырыла. Муллалар да чакырыла, шул сәбәпле, мәҗлес бернинди эчкесез, рәсми төстә, тантаналы итеп үткәрелә.

Шушы мәҗлестә кыз ягыннан килгән ашларны һәм бирнәләрне чыгаралар. Ашлар шул көнне генә кыз өеннән махсус арбада китерелә.

Башта төп хуҗаның ашларын ашаталар, аннары подносларга өеп кыз ашларын чыгаралар (тураган икмәк, ит, каз, казылыклар). Һәрбер кунак кирәгенчә алып капканнан соң, подносларны кире кайтаралар. Башка табыннарга бирәләр.

Иң ахырдан зур подноска өеп, катырып эшләнгән «Кыз чәкчәге» чыга («Килен чәкчәге» дип тә әйтәләр). Һәркем, чәкчәкне авыз иткәннән соң, акча сала, тик кайбер карчыклар гына: «Бездән фатиха», дип куялар.

Шул рәвешчә ашларны авыз иттергәч, кызның бирнәләрен чыгара башлыйлар. Бирнәләрне дә подноска өеп, кемгә нәрсә икәнен әйтеп чыгаралар. Төп кода белән кодагыйга (кияүнең әтисе белән әнисенә) дигән бирнәләр аерым подноста була.

Бирнәләргә нәрсәләр кирә? Кайнатага, мәсәлән, пар күлмәк-ыштан, намазлык, тастымал... Кайнанага — ука изүле күлмәк, шәльяулык, күкрәкчә. Башкодага — үзенә һәм хатынына — берәр күлмәк. Кияүнең башка туганнарына, якынлык дәрәҗәсенә карап, я күлмәк, я намазлык, я яулык бирәләр. Сеңелләре булса, аларны да бирнәсез калдырмыйлар.

Кияүнең үзенә исә аерым чиккән букча белән дүрт күлмәк, ике ыштан, пар тастымал, намазлык, перчатка һәм алка-йөзек куялар.

Бирнәгә каршы ата-ана мал әйтә, башкалар акча салалар. Күрсәтелгән бирнәләрне кодаларга шунда ук биреп тә җибәрәләр.

«Корбан ашы» әнә шулай уза. Бу мәҗлестән соң, кыз ягыннан җиңгәли килгән кодаларны, кияү ягыннан чакырырга өлгермәгән кешеләр булса, шулар үзләренә

кунакка алып китәләр. Чакырырга тиешле кешеләрнең барысында да булып чыккач, кунаклар барысы да төп йортка кайталар. Анда, күбесенчә төнлә белән, иң соңгы эчке мәҗлесе була. Соңгы сыйлашулар, соңгы җырлашулар... Ә ишек төбендә инде пар атлар җиңгәләрне өйләренә илтеп куярга көтеп торалар.

Шуның белән рәсми туй тәмамлана. Ләкин туйның койрыгы һаман дәвам итә әле.

## Килен мунчасы

Туй кайтып киткәч, икенче көнне, кияү ягыннан туйны күтәрүчеләрнең барысын да парлап-парлап килен мунчасына чакыралар. Шулай ук туйда катнашмаган якын карт-корыларны да килен мунчасыннан калдырмыйлар.

Безнең татарларда мунчага чакыру, гомумән, зур сыйдан санала. Бу очракта исә мунчага чакыру яшь киленнең кияве туганнарына хөрмәтен һәм туй күтәрешкән өчен рәхмәтен белдерү йөзеннән эшләнә.

## Шәл салдыру

Бераз вакыттан соң, кияү үзенең егет дусларын, яшь каләше белән таныштырыр өчен, кунакка чакыра. Менә шушы мәҗлесне «Шәл салдыру туе» дип атыйлар. Ни өчен «Шәл салдыру»?.. Хикмәт шунда: яшь килен кияү йортында күпмедер вакыт беркөнчек өстеннән шәл ябынып йөри. Кунакка килгән егетләр килен әйләнәсендә күмәкләшеп бииләр һәм шул чакта киленнең башыннан шәлен таяк белән эләктереп алалар. Килен үзе егетләр биегән чакта уртада чүгенгән килеш басып тора.

Шушы туйда кияү дә үзенең егет чагы белән саубуллаша.

## Кода төшерү

Укучы күргәндер инде: кызның әти-әнисе кияү йортына зур туй белән бергә килми. Алар, кызлары белән саубуллашып, үз өйләрендә калалар.

Инде туйлар үтеп, кияү ягы бераз хәл алгач, кызның әти-әнисен чакыралар. Менә шушы — «Кода төшерү» була.

Беренче килүендә кода-кодагый, туйдагы шикелле үк, ашлар белән киләләр. Кода янына мөхтәрәм олкән кешеләрне кунакка дәшәләр. Мәҗлес үткәрелә, кода ашы чыгарыла. Аннары коданы ашка йөртәләр. Гадәттә, бу мәҗлесләр ике көн дәвам итә.

Туйның койрыгы да бетте дияргә ярый. Тик кайбер аңлатмалар гына бирәсе калды.

Кыз килен булып төшкәч, сез «чүгенү» диган сүз очрата башладыгыз. Нәрсә соң ул чүгенү? Бу — русча әйтсәк, реверанс, ягъни тез чүгеп күрешү була. (Күрешкән чакта уң аякны алгарак атлап, сул аякны аз гына артка калдырып, чүгенеп алалар.)

Каргалыда киленнәр буын-буыннан кияү ягы белән чүгенеп күрешәләр. Аларның болай күрешүләре үз кызлары үсеп җиткәнчегә кадәр бара.

Чүгенүнең билгеле бер тәртипләре бар: мәсәлән, килен кеше киявенең берәр кардәшенә кунакка барса, бусагадан кергәндә, өч тапкыр чүгенеп ала. Берсе — кергәч тә, өй нигезенә, икенчесе — бер атлап, хуҗалар хөрмәтенә, өченчесе — тагын атлап, түрдәге картлар хөрмәтенә чүгенә.

Кеше белән исәнләшкәндә, бер генә чүгенеп ала. Кул бирү юк.

Килен йөргән җирендә олы ирләр яки карчыклар очратса, аларга да хөрмәт йөзеннән чүгенеп уза. Моның кадерен бик беләләр, ирләр: «Рәхмәт, килен, исән бул!», карчыклар исә: «Рәхмәт, килен, үзең дә олы кеше бул!» дип калалар.

Каргалыда туйлар әнә шулай уза иде. Бер көе тыныч, кызыксыз гына аккан авыл тормышын ул туйлар җанландырып җибәрә, бәйрәм төсен кертә һәм кешеләр хәтерендә озак вакытлар сөйләнә торган бер якты, матур истәлек булып кала иде. Мин үзем дә яшь чагымда андый туйларны шактый күп күрдем. Хәзер инде бу рәвешчә туй итүләр күптән бетте, ләкин, халыкның бик борыннан килгән зур бер йоласы булганга күрә, мин аны, белгәнем кадәренчә, тулы, дөрес итеп язып калдыруны кирәк

# *Балаларга укыгыз*

*Нури Арсланов*

## Тиен

Бакчабызга бер тиен
Алып кайтты әтием.

Мин чикләвек бирергә
Бик яратам тиенгә:
Төшә дә куышыннан
Җимне ала учымнан
Һәм, сөенә-сөенә,
Аны ташый өенә.
Өе аның наратта —
Ул наратны ярата.

Ылыс, бөре аңа аш.
Ике күзе асылташ,
Чуклыдыр колаклары,
Үткендер тырнаклары,
Мамыктай йомшак йоны,
Төймә кебек борыны,
Койрыгы үзе чаклы...
Кинәт җәеп кочакны
Бер ботактан атыла,
Икенчесенә куна.
И оча ул канатсыз,
Шаккатарсыз карап сез.

«Тиен яши урманда.
Алар күбәүләр анда.
Ә бусы — кунакта, — ди, —
Бик кадерләп сакла, — ди, —
Бер ялгызы бу тиен,
Рәнҗетмә», — ди әтием.



## Тукран

Тукран агач тукылдата:
«Тук, тук, тук!
Минем томшыктан нык
томшык
Юк, юк, юк!

Сер сынатмый бер дә
томшык —
Тукмагым,
Чукып алам мин тук агач
Кортларын.

Тукылдатмый мөмкин түгел
Торырга,
Яшәр өчен кирәк хезмәт
Кылырга.

Балаларым азык сорый
Шулай ук.
Тукылдатсам гына минем
Тамак тук».

Шулай итеп без тукран
Серен ачтык.
Саубуллаштык. Шактый ук
Ераклаштык.

Ә ул — урман күзәтчесе:
«Шык та шык...»
Ай-яй ничек чыдый икән
Бу томшык?!



## Икмәк валчыгы

*(Бурят халык әкияте)*

Юлга чыга ике юлдаш —
Бай белән ярлы.
Бай тук була, ә ярлы ач —
Буш була карыны.

Юл киселә бара торгач
Бер текә ярда.
Ашап ял итмичә булмас —
Туктыйлар ялга.

Күмәч белән ашый берсе
Маен, итләрен...
Суга манчый икенчесе
Каткан икмәген.

Туйгач ярлы ашын төрә,
Җыя янчыгын,
Шунда ялгыш җиргә төшерә
Икмәк валчыгын.

Алырга дип иелгәндә,
Киткәндәй качып,
Тоттырмый бит бер дә генә —



Валчыкны тотам дип ярлы
Сикерә-йөгерә,
Шулай итә-итә ярның
Җитә төбенә.

Менә ул валчыкны өреп,
Кадерләп ала...
Ә бай юлчы моны күреп
Шаккатып кала.

«Таудан валчык кына ташлап
Шулай төшәлгач,
Мин төшәрмен бигрәк ансат —
Мин ташлыйм калач!»

Ди дә ата бер түгәрәк
Калачны аска,
И китә шунда тәгәрәп
Ул таштан-ташка.

Бай чаба калач артыннан.
Юл хәтәр, ай-яй!
Тукта, бу ни? Яр башыннан
Мәтәлә бит бай...

Үз башына җитә үзе...
Әкият тә бетә.
Истә тот бабайлар сүзен:
«Икмәкне рәнҗетмә!»

## Өч дус

*(Калмык халык әкияте)*

Бер көн Тоз, Камгак, Кабырга
Туры килгәннәр бергә.
Сүз биргәннәр дус булырга,
Корганнар матур тирмә.

Бер вакыт, күкләр күкрәтеп,
Яңгыр килгән далага,
Яшенле телен күрсәтеп
И тотынган яварга.

Кабырга әйткән: — Төнлекне
Ябасы иде, дуслар.
Тоз әйткән: — Син бездән ипле,
Камгак, яп әле, дус, бар.

Камгак: — Була ул! — дигән дә
Тәгәрәп чыккан икән, —
Кинәт шаян җил килгән дә
Өргән дә алып киткән...

Тоз: — Үзем ябам, Кабырга,
Борчылма, — дип әйткән ди.
Чыгуы булган — яңгырда
Эрегән дә беткән ди...

— Тоз да югалды лабаса,
Миңа калды ябарга,
Болай булмый бит, су баса! —
Дип чыккан ди Кабырга.

Ул чыгып төнлек бавына
Тотынган гына икән,
Карамыйча ай-ваена,
Бер эт алган да киткән.

Сөякне капкан да ди эт
И тотынган чабарга,
Сөяктә ни сеңер, ни ит —
Тапкан ризык кабарга.

Эт этлеген итә инде.
Кабырга тыпырчынган...
Менә җил авышкан кире,
Һәм Камгак килеп чыккан.

Кабырга кычкырган күреп:
— Ярдәм ит, дустым, беттем!
Ә Камгак тәгәрәп килеп,
Котын алган бит этнең.

Китүе булган бәрелеп,
Эт шыңшып авызын ачкан:
Камгакның куенына кереп
Кабырга эттән качкан.

Тәгәрәп килеп җиткәннәр;
Тирмәдә юк тоз гына...
Эзлиләр алар бергәләп
Бик кызгана-кызгана.

Чокырга җыелган судан
Бер тавыш килә менә:
«Әй, эзләмәгез, мин монда,
Таптый күрмәгез генә!..»

Яңгыр туктаган, бераздан
Су да кибеп өлгергән.
Менә бер вакытны Тоз да
Ишектән килеп кергән.

Шатланганнар өчесе дә
Исән калуларына,
Шул матур тирмә эчендә
Яши алуларына.

Күңелле дә соң бу җирдә
Гөрләшеп гомер итмәк!
Тату яшәүгә ни җитә?
Дуслыкта бөтен хикмәт!



# Яңа китаплар

**ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИН ӘСӘРЛӘРЕ**

**Библиография**

*Бәясе 24 тиен*

Бу библиографик белешмәдә В. И. Ленинның 1917 — 1965 елларда татар телендә басылып чыккан әсәрләре һәм В. И. Ленин турындагы художестволы әсәрләр исемлеге тупланган.




Белешмә түбәндәге тәртиптә төзелгән: башта, алфавит тәртибендә, В. И. Ленинның томнары, Сайланма әсәрләре һәм аерым хезмәтләре, аннары В. И. Ленин турындагы художестволы әсәрләр теркәлгән.

В. И. Ленин әсәрләрен һәм аның турындагы әдәбиятны өйрәнүдә җиңеллек тудыру максаты белән, хронологик күрсәткеч төзелгән. Шулай ук В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итүчеләр һәм редакцияләүчеләр, В. И. Ленин турындагы әсәрләрнең авторлары, тәрҗемәчеләре һәм редакторларының алфавит тәртибендә исем-фамилияләре дә бирелгән.

Белешмәне Татарстан китап палатасы директоры Әхмәт Булатов төзегән.

**ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ БАТЫРЛАРЫ**

**Биографик очерклар җыентыгы**

*Бәясе 62 тиен*

Бу җыентыкта гражданнар сугышы чорында Кызыл Армия берләшмәләренә һәм партизан отрядларына җитәкчелек иткән күренекле полководецларыбыз М. Фрунзе, С. Каменев, А. Егоров, В. Блюхер, Я. Фабрициус, С. Вострецов, Г. Котовский, М. Тухачевский, Н. Щорс һәм В. Азин турында язучылар, журналистлар һәм хәрби белгечләр тарафыннан язылган биографик очерклар тупланган. Очеркларны татарчага Г. Миннуллин тәрҗемә иткән.






Зыя Мансур

**ЭТАПЛАР КИТАБЫ**

*Бәясе 61 тиен*

Шагыйрьнең сайланма әсәрләре тупланган бу китабына татар укучыларының күбесенә таныш булган «Яшьлек җыры», дулкынланып укырлык лирик шигырьләре, совет халкының Бөек Ватан сугышы чоры һәм аннан соңгы еллардагы

батырлыгын тасвирлаган поэма белән балладалары урнаштырылган.

Әле күптән түгел генә вафат булган Зыя Мансур, йөрәкләрне тетрәндерерлек житди әсәрләр язу белән бергә, бик матур итеп елмая һәм көлә дә белде. Моның шулай икәнлеге жыентыктагы «Сәнди Мәндиев һәм башкалар» бүлегенә кергән шигырьләрне укыганнан соң бик ачык күренә.

Х. Сәлимжанов

## АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ

*Бәясе 27 тиен*

Бу китапның авторы — татар театры дөньясында, аеруча Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрында, радио һәм эстрадада озак еллар эшләгән һәм хаклы рәвештә Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемне яулап алуга ирешкән өлкән артист Хәким ага Сәлимжанов. Хәким аганың бу истәлекләре үзе белән бергә эшләгән сәхнә осталарын һәм татар театрының үткән юлын сурәтләүгә багышланган.




Р. Саттар

## ЖЫР ДӘВАМ ИТӘ

Шигырьләр жыентыгы

*Бәясе 13 тиен*

Бөек Ватан сугышы елларында совет сугышчылары дөньяда тиңе булмаган батырлыклар күрсәттеләр. Ул каһарманнарның исемнәре һәм эшләгән батырлыклары һаман-һаман ачыклана бара. Әле соңгы елларда гына шагыйрь Рәхим Саттарның да язмышы ачыкланып, аның шигырьләре туган илебезгә кайтты. Фашист тоткынлыгында газап чигүенә карамастан, Р. Саттар совет иленә турылыклы булып калган. Алай гына да түгел, ул тоткынлыкта да жиңүгә ышаныч һәм илбасарларга нәфрәт белән сугарылган шигырьләр ижат иткән. Р. Саттарның «Жыр дәвам итә» исемле бу жыен-




тыгына сугышка кадәр һәм сугыш чорында тоткынлыкта ижат ителгән иң әйбәт шигырьләре тупланган.

Ә. Баянов

## МӘҢГЕ ЗӘҢГӘР КҮГЕБЕЗ

Шигырьләр һәм поэма

*Бәясе 11 тиен*

Күп кенә шигырь жыентыклары, «Күзләре нинди иде?» пьесасы һәм әле бу ел гына «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Яшьлегемне эзлим» исемле лирик повесть авторы Әхсән Баяновның бу жыентыгында шагыйрьнең соңгы вакытларда ижат иткән яңа шигырьләре һәм «Сез анларсыз мине» исемле зур күләмле поэмасы басылган.



Р. Мингалимов

## ӘЙТ, КОЯШЫМ!

Шигырьләр жыентыгы

*Бәясе 6 тиен*

Рөстәм Мингалимов — соңгы елларда әдәбиятка килеп кергән яшь шагыйрьләрнең берсе. Әсәрләре вакытлы матбугат битләрендә




еш кына басылып килсә дә, Р. Мингалимовның китабы чыкканы юк иде әле. «Әйт, кояшым!» исемле бу китап яшь шагыйрьнең беренче жыентыгы. Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына адресланган бу жыентыкка авторның унбер шигыре урнаштырылган.

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР

Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре әдәбият, музыка, сынлы сәнгать һәм башкару эшчәнлеге өлкәсендә идея эчтәлеге, сәнгатьлелеге ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләргә һәм хезмәтләргә бирелә. Ул әсәрләр хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә булышлык итәргә, социалистик реализм принципларына җавап бирергә һәм киң җәмәгатьчелекнең ихтирамын казанган булырга тиеш. Узган ел шагыйрь Хәсән Туфан һәм композитор Җәүдәт Фәйзи шушы зур бүләккә лаек булганнар иде.

КПСС өлкә комитетының һәм ТАССР Министрлар Советының карары нигезендә Г. Тукай исемендәге республика премияләре комитеты түбәндәге составта расланды: ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары Р. Ю. Ярмөхәммәтова (председатель), ТАССР культура министры Б. М. Гыйззәтуллин (председатель урынбасары), республика Язучылар союзы правлениесе председателе Мирсәй Әмир, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре Н. А. Андрианов, М. Х. Хәсәнов, ТАССР композиторлар союзы правлениесе председателе, СССРның халык артисты Нәҗип Җиһанов, язучы Тихон Журавлев, Казан дәүләт педагогия институты проректоры М. З. Зәкиев, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре В. С. Морозов, «Казан утлары» журналы редакторы, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты директоры М. К. Мөхәррәмов, РСФСРның атказанган һәм ТАССРның халык артистлары В. М. Павлова, Х. И. Уразиков, композитор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Җәүдәт Фәйзи, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Р. Д. Фәрхиев, шагыйрь Хәсән Туфан, ТАССР журналистлар союзы правлениесе председателе Ш. Х. Хамматов, РСФСРның халык һәм ТАССРның атказанган артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина, культура работниклары профсоюзының өлкә комитеты председателе Я. С. Шәмсетдинов, РСФСР художниклар союзының Татарстан бүлеге правлениесе председателе, РСФСРның халык художнигы Харис Якупов.

Габдулла Тукай исемендәге республика премияләренә әсәрләр һәм хезмәтләр ТАССР Культура министрлыгы, Татарстан АССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты, матбугат идарәсе, иҗат союзлары правлениеләре, Бөтенроссия театр һәм хор җәмгыятьләренең Татарстан бүлекләре, газета һәм журнал редколлегияләре, вузлар һәм җәмәгать оешмалары, хезмәт ияләре җыелышлары тарафыннан тәкъдим ителә. Бу — һәр елны 1 февральгә кадәр эшләнә.

Г. Тукай исемендәге республика премияләре комитетының карары 26 апрельдән дә соңга калмыйча матбугатта басыла.

Ел саен меңәр сум күләмендә ике премия билгеләнә.

Тукай премиясе алган кешеләргә «Габдулла Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты» дигән исем бирелә, диплом, почетлы значок һәм бүләкләр тапшырыла.

## Г. ИБРАҺИМОВ ЮБИЛЕЕ

Республикабызның авылларында, районнарында һәм шәһәрләрендә, шулай ук туганлаш республикаларда татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның 80 еллык бәйрәме зур итеп, тантаналы шартларда билгеләп үтелде. Галимҗан Ибраһимов юбилеена багышланган тантана кичәләре тугандаш Башкортстан республикасында — әдипнең туган авылы Солтанморатта башланып китте. Март урталарында республикабыз башкаласы Казан зур бәйрәм төсен алды.

Галимҗан Ибраһимов юбилеена катнашу өчен Казанга илебезнең төрле почмакларыннан күп кенә язучылар һәм фән эшлеклеләре, әдипнең көрәштәшләре һәм туганнары килде.

Алар арасында РСФСР язучылар союзы секретаре Франц Таурин, рус язучысы Виталий Василевский (Мәскәү), казакъ язучысы һәм галиме Сагынгали Сеитов, төркмән язучысы Ораз Акмамедов, үзбәкстаннан язучы һәм галим Гөлсем Мөхәм-

мәдова, язучы Вил Уразаев, башкорт шагыйре, филология фәннәре докторы Гыйлемдар Рамазанов, әзербайҗан язучысы Алевия ханым Бабаева, башкорт язучысы Иосыф Гәрәй (Уфа), удмурт шагыйре Аркадий Клабуков, Мари язучылар союзы председателе, драматург Сергей Николаев, таҗик шагыйре һәм прозаигы Фатех Ниязи, Галимҗан Ибраһимовның туганнарыннан Фәридә Рафикова, Мотаһар һәм Альберт Ибраһимовлар һәм башка бик күп кунаклар бар иде.

---

13—14 мартта В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында татар әдәбияты классигы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу уңае белән фәнни конференция ачылды. Анда университет проректоры Ш. Т. Хәбибуллин кереш сүз әйтте. КПССның Татарстан өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты М. Х. Хәсәнов Г. Ибраһимовның идея-иҗат эволюциясе турында доклад ясады. Казагыстаннан шагыйрь һәм галим Сагынгали Сеитов, башкорт язучысы Гыйлемдар Рамазанов, тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмов, журналист Ү. И. Гыймадиев һәм башкалар әдип эшчәнлегенең төрле якларына кагылышлы белдерүләр белән чыктылар.

---

14 мартта Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасына әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, тугандаш республикалардан килгән кунаклар, шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре җыелды. Алар татар әдәбияты классигы, күренекле революционер, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу датасын билгеләп үтәргә килгәннәр иде.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев ачты. Әдипнең тормышы һәм иҗаты турында филология фәннәре кандидаты М. Х. Хәсәнов доклад ясады.

Мәскәүдән һәм тугандаш республикалардан килгән кунаклар интернационалист әдип турындагы фикерләре белән уртаклаштылар. Ахырдан сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде. Концертта Г. Ибраһимов әсәрләреннән өзекләр башкарылды, татар совет композиторларының җырлары яңгырады.

---

15 мартта республикабызның җәмәгатьчелеге вәкилләре, Казанга килгән кунаклар Казанның Архангел зиратындагы Г. Ибраһимов каберенә бардылар. Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе М. Әмир Г. Ибраһимов иҗатының әһәмияте һәм бу кабернең табылу тарихы турында кыскача сөйләде. Мактәп укучылары, төрле оешма вәкилләре әдип каберенә чәчәк бәйләмнәре куйдылар.

---

16 мартта Мәскәүдә Язучыларның үзәк йортында Г. Ибраһимов иҗатына багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне РСФСР язучылар союзының секретаре Ф. Н. Таурин ачты. Әдипнең иҗаты турында кереш сүзне Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ясады.

Кичәдә М. Әмир, А. Шамов, С. Әдһәмова, Г. Халит, И. Юзеев, Г. Гобәй, М. Фәйзуллина, С. Сеитов (Казагыстан), О. Акмамедов (Төркмәнстан), Г. Мөхәммәдова (Сәмәрканд), Г. Уразай (Үзбәкстан), Ю. Гәрәй (Башкортстан), В. Давыдов (Чувашстан), А. Клабуков (Удмуртия), Ф. Ниязи (Таҗикстан) һәм зур төркем Мәскәү язучылары катнаштылар. Язучылар һәм Г. Ибраһимовның замандашлары чыгышларыннан соң, зур концерт булды.

---

Республикабызның В. И. Ленин исемендәге үзәк китапханәсендә Г. Ибраһимов иҗатына багышланган әдәби кичә булды. Кичәдә язучылардан А. Шамов һәм И. Рәми катнаштылар.

---

Мехчылар культура сараенда булган Г. Ибраһимов кичәсендә язучылар Ф. Хөсни, А. Шамов, С. Хәким һәм Г. Халит чыгыш ясадылар.

---

Мактама нефтьчеләр поселогының «Тәзүче» клубында Г. Ибраһимов иҗатына багышланган әдәби кичәдә Әлмәт язучылары Г Ахунов, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин һәм Г. Афзал катнаштылар.

---

11 нче номерлы интернат мәктәптә үткән Г. Ибраһимов кичәсендә язучы Г. Бакиров һәм Л. Ихсанова чыгыш ясадылар.

## РЕДАКЦИЯГӘ ТЕЛЕГРАММАЛАР

Төрки язучы-реалистлары арасында Галимҗан Ибраһимов гаять күренекле урын тота. Аның йөзендә татар прозасы хәзерге заман совет әдәбиятына сизелерлек өлеш кертте. Ибраһимовтан җитди тормышны җитди өйрәнергә мөмкин. Ибраһимов — татар халкы улы, һәм татар халкы аның белән лаеклы горурлана ала.

Чыңгыз АЙТМАТОВ, Ленин премиясе лауреаты.

* * *

Галимҗан Ибраһимовны татар халкы, татар интеллигенциясе ничек яратса, мин дә аны шулай яратам. Татар халкы, татар әдәбиятчылары белән беррәттән, мин дә Галимҗаннан күп нәрсәләр өйрәндем. Татар әдәбиятының гына түгел, Урта Азия халыклары совет әдәбиятының үсешендә дә Галимҗанның тоткан урыны бик зур.

Үзе исән чакта гына түгел, бүгенге яшьләр дә, вакыйганы ничек өйрәнү, ничек сюжет төзү, геройларга характер бирүдә Галимҗаннан өйрәнәләр. Шуның өчен дә, уртак остазыбыз буларак, Галимҗан гасырларча яшәр.

Дөньяга шундый талантны биргән татар халкына, татар халкы данын югары күтәр-

гән Галимҗан Ибраһимовка сүнмәс шөһрәт!

Берди КЕРБАБАЕВ, төркмән әдибе. Ашхабад.

* * *

Бу көннәрдә күренекле язучы, татар әдәбияты классигы, мәшһүр тарихчы, филолог һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу юбилеен уздыруда катнашучыларга кушыла алуыбызга чиксез шатбыз.

Кайсы гына өлкәдә булмасын, Галимҗан Ибраһимов бөтен энергиясен һәм талант көчен тулысынча үз халкына хезмәт итүгә багышлады.

В. И. Ленин белән очрашып сөйләшүләре һәм ВЦИКта эшләве аны КПСС сафына китерде.

Совет власте өчен көрәш, социаль тигезсезлеккә каршы протест һәм гуманизм идеяләре Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең буеннан буена кызыл җеп булып сузыла.

Иҗаты белән күп милләтле социалистик культураның бер сәхифәсен язган татар халкының данлы улы Галимҗан Ибраһимов турындагы якты истәлек гаделлек һәм гуманизм идеяләре йөрәгенә якын булган һәркемнең күңелендә мәңге сакланыр.

Юбилей тантанасы уңае белән зур художник һәм гражданин Г. Ибраһимов таланты алдында сезнең белән бергәләп баш иябез һәм чиксез горурланабыз.

Сәхи РӘХМӘТИ, НАЗЫЙРОВ,
Мәрьям РӘХМӘТИ, ТЕРЕГУЛОВ,
ГАЛЛӘМОВ, БУЛАТОВ,
МОЗАФФАРОВА, УРАЗАЕВ,
Зәйнәб СӘГИДӘ, СИРАДҖИ,
ЮНУСОВ, ХӨСӘЕНОВ,
СУЛЕЙМАНОВА, БИККУЛОВ,
АБЛАЗИННАР, БАКИРОВ,
ФӘТХУЛЛИН, ЛАТЫЙПОВА,
АЛЬХАМОВА, ЯХИНА.
АХМАРОВ,

Ташкент.

* * *

Тууына 80 ел тулу көнендә күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, большевик-революционер Галимҗан Ибраһимовның якты истәлеген олылыйбыз.

Революцион көрәш буенча
Ибраһимовның сафташы
ШӘРИФ СҮНЧӘЛӘЙ гаиләсе.

Мондый телеграммалар илебезнең башка почмакларыннан да күп килделәр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БЮРОСЫНДА

Татарстан язучылары союзы идарәсе шагыйрь Илдар Юзеевне әдәби консультант итеп билгеләде. Яшь язучылар үз әсәрләрен консультация алыр өчен түбәндәге адрес белән җибәрә алалар:

*г. Казань,*
*ул. Баумана, 19,*
*Союз писателей,*
*Литературному консультанту*
*Илдару Юзееву.*

21 мартта шагыйрь Рәшит Гәрәй һәм «Ялкын» журналының әдәбият бүлеге мөдире Тәүфыйк Камалиев Чаллы район газетасы редакциясе каршындагы әдәбият түгәрәгендә булдылар. Анда түгәрәк членнарының яңа әсәрләре укып тикшерелде, яшь авторларга киңәшләр бирелде. Иң яхшы әсәрләр республика матбугатына тәкъдим ителде.

---

## Я. Җ. ЧАНЫШЕВКА — 75 ЯШЬ

Карт коммунист, актив җәмәгать эшлеклесе, Бөек Октябрь вакыйгаларында гади көрәшче булып катнашучы, соңыннан үзенең зур һәм фидакарь хезмәтләре өчен генерал-лейтенант дәрәҗәсенә ирешкән Якуб ага Чанышевка 75 яшь тулды. Шул уңай белән Татарстан АССРның Верховный Советы Я. Җ. Чанышевны Почет грамотасы белән бүләкләде.

## ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ ИҖАТ ОТЧЕТЫ

Юбилей елында илебезнең алдынгы театрлары Актерларның үзәк йортында мәскәүлеләр алдында отчет бирәләр. 23 мартта бу иҗат клубының сәхнәсе Казаннан килгән кунакларга — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистларына бирелде.

РСФСРның атказанган артисты Э. Краснянский, кичәне ачып, соңгы вакытларда татар театрының күп кенә кызыклы спектакльләр куйганлыгын әйтте. Г. Камал исемендәге театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов коллективның иҗат планнары белән таныштырды.

Бу кичне татар артистлары Н. Исәнбәт, Г. Камал, мәгълүм кыргыз язучысы Ч. Айтматов һәм башкаларның пьесалары буенча эшләнгән спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр.

Якын арада Актерларның үзәк йортында башка союздаш һәм автономияле республикаларның сәнгать осталары чыгыш ясаячак.

## КАЗАН ТЕАТР ХУДОЖНИКЛАРЫ ЭШЛӘРЕ — БӨТЕНСОЮЗ КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Башкаланың Үзәк күргәзмәләр залында Октябрьның 50 еллык юбилеена багышланган зур күргәзмә булды. Бирелә илебезнең театр художникларының иң яхшы эшләре куелды. Күргәзмәдә Татарстан художниклары да катнашты. ТАССРның халык художнигы мәрхүм П. Т. Сперанскийның «Түләк» операсына (Н. Җиһанов), ТАССРның халык художнигы Э. Б. Гельмсның «Катерина Измайлова» операсына

(Шостакович), һәм «Синең хакка» драматик композициясенә (Р. Кутуй һәм А. Бикчәнтәев), Тукай премиясе лауреаты Ә. И. Тумашевның «Кара йөзләр» спектакленә (М. Гафури) эшләнгән декорация эскизлары аеруча уңыш казанды. Мәскәү театр һәм рәсем сәнгате осталары Татарстан художниклары иҗатына югары бәя бирде.

## ҮЗЕШЧӘН СӘНГАТЬ КӨЧЛӘРЕНЕҢ РЕСПУБЛИКА СМОТРЫ

Республикабызда булып узган үзешчән сәнгать коллективларының смотры уңышлы тәгәлләнде.

Сәхнә осталарының көрәш мәйданында 9 хор коллективы, 27 жыр, 16 инструменталь, 26 бию ансамбле һәм башка төрле номерлар белән барлыгы ике мең кеше чыгыш ясады.

18 мартта иң көчле коллективлар Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында республикабыз хезмәт ияләре каршында йомгаклау концерты белән чыгыш ясадылар (концерт телевидение һәм радио аша да тапшырылды).

Түбән Кама, Саба һәм Минзәлә районнарының берләштерелгән хор чыгышы, Казан шәһәренең Урицкий исемендәге культура йорты ансамбле башкарган «Тоткын» жыры, Актаныш район коллективының чыгышы, Буа район культура йортының «Сабан туе» дигән хореографик күренеше, Чистай район вәкилләренең биюе һ. б. бик күп номерлар тамашачыларга илебезнең үткән юллары һәм бүгенге бәхетле тормышы турында сәнгать теле белән сокландыргыч итеп сөйләп бирделәр.

Концертның финалында барлык коллективлар бәйрәм тантанасын чагылдырган бию башкардылар. Сәхнәдә 900 кешедән торган зур ансамбль «Без синең белән, Россия!» дигән жырны башкардылар. Хор белән Лемир Джураев житәкчелек итте. Коллективларны әзерләүдә шулай ук композиторлардан Ж. Фәйзи, З. Хәбибуллин, М. Имашев, И. Хисамов, А. Батыршин, М. Латыйпов һ. б. зур тырышлык куйдылар.

## ӘДӘБИ АТНАЛАР, ОЧРАШУЛАР

Пермь өлкәсенең Барда районында 27 февральдән 4 мартка кадәр татар әдәбияты атналыгы булды. Атналыкта язучылардан И. Гази, А. Гыйләжев, Р. Ишморатова, М. Ногман, Г. Афзал һәм К. Фәсәхов катнаштылар. Татар язучылары әдәби кичәләр, укучылар конференцияләре үткәрделәр, укучылар белән очраштылар.

---

Татарстан язучылары союзы идарәсенең председателе Мирсәй Әмир Мамадыш һәм Бөгелмә районында булды, укучылар белән очрашты.

---

«Казан утлары» журналының жаваплы редакторы Рафаэль Мостафин Германия Демократик Республикасында һәм Көнбатыш Берлинда булды, шагыйрь-көрәшче Муса Җәлилнең соңгы көннәренә бәйләнешле материаллар жыйды.

---

Арча китап кибетенең яшьләр клубы ачылышында язучы Б. Камалов һәм А. Сәләхетдинов катнаштылар.

---

Ульяновск өлкәсе, Чардаклы районының «Октябрьның 40 еллыгы» колхозында ялкынлы көрәшче-шагыйрь Демьян Фәтхинең 60 еллыгына багышланган әдәби кичә булды. Кичәдә М. Хөсәен һәм Ә. Синегулов катнаштылар.

---

Шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, прозаиклар Г. Мөхәммәтшин, Б. Камалов Лаеш районы культура университетының чираттагы занятиесендә булдылар. Сүз бүгенге татар әдәбияты турында барды. Авторлар укучылар сорауларына җавап бирделәр, үз иҗат планнары белән уртаклаштылар, яңа әсәрләрен укыдылар.

---

Дербышки поселогының 106 мәктәп укучылары язучы Усман Бакиров һәм Сарьян Хәсән белән очраштылар.

——□——

## ТӨЗӘТҮ:

Журналыбызның 4 нче санында 14 нче битнең астан 9 нчы юлын: «...безнең чираттагы резолюцияне тикшереп карыйк», — дип укырга.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/III-1967 ел. Басарга кул куелды 24/IV-1967 ел. ПФ 05085. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 58 846 экз. Заказ М-521. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# ВЬЕТНАМ СОЛДАТЫНА




А. КЛЮЧАРЕВ музыкасы
НӘБИ ДӘҮЛИ сүзләре

Ерак илдә сугыш бара,
Дусларның йорты яна.
Анда аткан мылтыклардан
Минем йөрәктә яра.
Барасы юллар арасы,
Диңгезләр, таулар гына.
Без ярдәм кулы сузабыз,
Вьетнам солдатына.

Дошманнар белеп торсыннар,
Истә калыр кан эзе.
Диңгезләр, таулар аркылы
Яңгырый нәфрәт сүзе.
Ил чакырса, без китәрбез,
Булсын тик набат кына.
Без әзер алмаш булырга
Вьетнам солдатына.

Без бит җирдә бик күбәүләр,
Көньякта да төньякта.
Диңгезләр, таулар аркылы
Дуслык юллары ята.
Без дуслыкны йөрәкләрдә
Тотабыз саклап кына.
Җырларым, сәлам әйтегез
Вьетнам солдатына.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210